ISSN 0206—4189

# Казан утлары

11.2002



## Бөтендөнья язучылар конгрессы

# РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

*2002 елның 17-24 сентябрендә Македониянең Охрид шәһәрендә Бөтендөнья язучылар конгрессының (Халыкара ПЕН-клубның) 68 нче Ассамблеясе эшләде. Ассамблея делегатлары татар телен латин имласына кайтару эшенә Россия Дәүләт Думасы ясаган тоткарлыкка карата махсус резолюция кабул иттеләр.*

Ассамблея:

илдәге барлык дәүләт телләренең имлаларын бердәйләштерү (унификацияләү) турында Россия Федерациясе Дәүләт Думасында беренче укылышта кабул ителгән закон проектын мәдәниятләрне һәм тел дөньясындагы күптөрлелекне киметүгә юнәлдерелгән дип саный;

үз көченә кергән очракта, бу закон Татарстан Республикасында татар әлифбасының законлы рәвештә латин имласына күчүенә киртә тудырачак һәм, шулай итеп, телләрнең үз лингвистик системасын саклау һәм үстерү буенча халыкара танылган хокукларын чикләү булачак дип исәпли;

бер территориядә яшәүче һәм төрле телләрдә сөйләшүче халыклар һәм аерым төркемнәр, үзара ихтирамлы булып һәм демократияне тагын да кинәйтүне күздә тотып, бер-берсенең үз телләренә булган хокукларын сакларлар дип ышана;

латин имласы нигезендә татар әлифбасын торгызуны яклап чыгыш ясаучы галимнәргә һәм язучыларга теләктәшлеген, аларны хуплавын белдерә;

Россия хакимиятен Россия Федерациясе халыклары файдаланган телләргә һәм имлаларга бәйле барлык законнарны, һәр халык үз мәдәниятен яклау һәм үстерү өчен тигез хокуклар һәм мөмкинлекләр алырлык итеп, анализ ясарга чакыра;

Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән Татарстанда латин имласы нигезендә татар әлифбасын торгызу барышына киртәләр куймавын гарантияләүне һәм Россия Федерациясе халыкларына аралашуда тел төрлелеге һәм мөстәкыйльлек тәэмин итүне катгый сорый.

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2002*

# 11

**(961)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Шәүкәт ГАЛИЕВ. Сез дә, без дә түгел тамырсыз. *Шигырьләр* ..... 5
Мәдинә МАЛИКОВА. Өермә. *Детектив роман* ..... 9
Наис ГАМБӘР. Исән чакта... *Шигырьләр* ..... 63
Луиза ЯНСУАР. Әле кош мин—күкләреңдә. *Шигырьләр* ..... 79
Хәбир ИБРАҺИМ. Арыш арасыннан йөгерүче бала. *Хикәя* ..... 81
Камил МОСТАФИН. Юлчы турында баллада. *Шигырьләр. (Р. Гаташ кереш сүзе белән)* ..... 87

ЯҢА ИСЕМНӘР

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Хикәяләр. *(М. Закир кереш сүзе белән)* ..... 69

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Рөстәм МИНГАЛИМ. Дүрт кешелек утыргыч ..... 92

III БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ

Минтимер ШӘЙМИЕВ. Татар халкының киләчәгенә өмет белән карыйм ..... 109
Индус ТАҺИРОВ. Без бербөтен, бүленмәс милләт ..... 115
Зөлфәт ХӘКИМ. Һәр замана безне сыный ..... 127
Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае резолюциясе ..... 130

ПУБЛИЦИСТИКА

Мөнир АБДУЛЛИН. Авыл яшәсә, ил яшәр ..... 133
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. «Бәр, мылтыгым, бәр...». *Эссе* ..... 143

Журналыбыз турында. *(Аяз Гыйләҗев, Мостафа Өнәр)* ..... 138, 178

ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ ТИРӘНДЕР

Флера САФИУЛЛИНА. Хәзерге әдәби телебез үсеше ..... 151

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Мәдинә ҖӘЛӘЛИЕВА. Тойгы катламнары ..... 160
Атлас ГАФИЯТОВ. Сөйләр сүзләр әле никадәр ..... 170

СӘНГАТЬ

Юныс САФИУЛЛИН. Мактау гына аз... ..... 173
Кыям МИҢЛЕБАЕВ. Еракта[гы] якын дустым ..... 180

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

33—Әхзаб (Төркемнәр) сүрәсе ..... 182

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман-детектив М. МАЛИКОВОЙ «Буря» *(начало)*, рассказ Х. ИБРАГИМОВА « Девочка, бегущая по полю», рассказы Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ *(с предисловием М. Закирова)*; стихи Ш. ГАЛИЕВА, Н. ГАМБАРА, Л. ЯНСУАР, К. МУСТАФИНА *(с предисловием Р. Гаташа)*.
«Драматургия»: драма Р. МИНГАЛИМОВА.
«III Всемирный конгресс татар»: приветствие Президента М. Ш. ШАЙМИЕВА, доклад председателя исполкома ВКТ И. Р. ТАГИРОВА «Мы единая, неделимая нация», выступления писателя-драматурга З. ХАКИМА «Каждая эпоха испытывает нас»; резолюция III Всемирного конгресса татар.
«Публицистика»: статья М. АБДУЛЛИНА «Да здравствует село!»; эссе Л. ХАМИДУЛЛИНА «Бей, винтовка, бей!»
«О нашем журнале»: заметки А. ГИЛЯЗОВА, М. ОНАР.
«Стихия родного языка»: статья профессора КГУ Ф. САФИУЛЛИНОЙ.
«Литературная критика»: статья М. ЗАЛАЛИЕВОЙ о творчестве А. Еники; статья А. ГАФИЯТОВА посвящена творчеству К. Булатовой.
«Искусство»: статьи Ю. САФИУЛЛИНА об актрисе ТГАТ Ф. Хайруллиной, К. МИННЕБАЕВА. «Дальний близкий друг».
Коран на татарском языке.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Татарский государственный академический театр им. Г. Камала; писатель Ахат Мушинский.

# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": M. MALIKOVA´S detectiv novel «The storm» *(begining)*, KH. IBRAGIMOV´S story «Tne girl running aling the field», R. GABDULKHAKOVA´S stories *(with M. Zakirov´s preface)*; the verses of SH. GALIEV, N. GAMBAR, L. YANSUAR, K. MUSTAFIN *(with R. Gatash´s preface)*.
"Dramatics": R. MINGALIMOV´S drama.
"III Wold congrass of tatars": President M. SHAIMIEV´S greeting, I. TAGIROV´S report «Weare the united and indivisible nation», Z. KHAKIM´S appear «Each epoch test us»; rezolution of the III Wold congrass of tatars.
"Journalism": M.ABDULLIN´S article «Long live village!», L. KHAMIDULLIN´S essay «Beat, rifle, beat!»
"About our magazine": the notes of A. GILIAZOV, M. ONAR.
"Element of native language": professor F. SAFIULLINA´S article.
"Literary criticism": M. ZALALIEVA´S article about creative works of A. Eniki; A. GAFIATOV´S article devoted to K. Bulatova´s cleative works.
"Art": U. SAFIULLIN´S article about artress F. Khairullina; K. MINNEBAEV «The distant intimate friend».
Koran in Tatar language.
The diary of social and cultural life.
On our covers:Tatars state academac theatre of G. Kamal; writer Akhat Mushinsky.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 28.10.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—620
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.



## Шәүкәт Галиев

### СЕЗ ДӘ, БЕЗ ДӘ ТҮГЕЛ ТАМЫРСЫЗ

#### Елама, тал

*«... Таллар тамырсыз микән,*
*Сандугач булып сайрасак,*
*Безне танырсыз микән?»*

Халык җырыннан.

**Ерактан ук күреп аласыз сез,**
**Инеш буендагы талларым,**
**Еллар үткән саен, сизәсездер**
**Танышларның кими барганын.**

**Күпме ир-егетләр бәхилләшеп,**
**Әчтән генә йотты күз яшен,**
**Белә иде алар, белә иде**
**Исән кайтып сезне күрмәсен.**

**Таллар, таллар, сабыр талларым сез,**
**Яфрак ярып, күзен коясыз,**
**Һәр яфракта сары сагыну бар,**
**Шәһитләрнең җанын тоямсыз?**

**Аяз көнне биткә тамчы тамды,**
**Тагын тамды... аңла аңласаң,**
**Безнең әнкәйләрдәй, тып-тын гына,**
**Таныш талым елый лабаса.**

Шәүкәт ГАЛИЕВ *(1928)—Татарстанның халык шагыйре. Күпсанлы китаплар («Сиңа әйтер сүзем бар», «Уйларым-серләрем», «Хисталекләр» һ. б.) авторы. Казанда яши.*

Уйлый идем, әллә үзем генә
Шул сагышлар белән яшимме?
Мин кушылдым синең әрнүеңә,
Син юасың минем яшемне.

Елама, тал җаным, еламсар тал,
Сез дә, без дә түгел тамырсыз.
Сандугачлар булып кайта алсак,
Шәт безне дә әле танырсыз...

## Җәбер

Үткәннәрем күләгәсе
Гел бүгенгемә төшә,
Онытырга һич тә бирми—
Газаплап керә төшкә.

Еллар еракта калса да
Борчулар адашмаган,
Әйтерсең лә ул чактагы
Төннәрем алмашмаган.

Гомер үтә, бәгыреңә
Уелган эзләр бетми,
Җиңелгән куркулар һаман
Җаныңны эзәрлекли.

Дәһшәтләр дә, фаҗигалар
Гасырда узмыйдыр шул—
Һәлак иткәйләр ярасы
Улларда сызлыйдыр ул...

* * *

Безнең якның илчеләре булып
Инешләре чыга Иделгә,
Дәрьяларга барып кушылса да
Чыганагы туган җирендә.

Агымнары кайчак күңелледер,
Тавышлары кайчак моңсудыр,
Сагынулар булып кагылганы
Туган яктан килгән Моң-Судыр.

Илләр-җирләр кичеп ага сулар—
Туктау белми торган чыдам ат,
Туган туфрак сүлен имә-имә
Диңгез булып үсә чыганак.

Балаларын юлга озаткан да,
Аналардай изге теләктә—
Офыкларга карап, гел ымсынып,
Таулар яши туган төбәктә.

## Шифалы җир

Җәйләрендә авылыма кайткач,
Уянам мин һәрчак иртәрәк,
Кырларыма карыйм, үзәннәргә
Күз карашым белән иркәләп.

Һәр тарафы сәнгать әсәредәй,
Әмма җанлы, тере манзара.

Йончыган җан монда тынгы таба,
Бәргәләнгән рухың тазара.

Кырлар киңлегендә тынычланам,
Иркенлеген җыям күзләргә.
Офыклары колач ачып көтә—
Кысанлыклар булса, түз, бәндә.

Игеннәрем дә бит юксынганнар,
Япан кырда ялгыз түгел мин.
Бүтән беркайда да күңелләрем
Мондагыдай ташып-түгелми.

Шушы иркен биеклектә тудым,
Бүтән якка әйтмим ким дип тә—
Сагынулар, чиксез яратулар
Сыяр бары шушы киңлеккә!

## Синең кодрәт

Ходай кошка канат биргән:
Оч күккә таянып, дигән,
Тоеп киңлеген-зурлыгын,
Таты очу хозурлыгын.
Очарсың пар канат барда,
Синең кодрәт—канатларда!

Пар канат бирдең, Иланым,
Мәхәббәтем ул, Илһамым.
Минекеләр җирем-күгем!
Уйга калдым әле бүген:
Канатсыз мин беркем түгел...

## Ак кәгазем

Ак кәгазьдән хикмәт көтә идем,
Киләчәккә баккан шикелле,
Гел ымсына идем, кышкы кырда
Үз юлымны тапкан шикелле.

Омтылуым—ул язмышым икән,
Канат булган миңа хыялым,
Ничек кенә дөнья каралмасын,
Ак кәгазьдә сафлык тоямын.

Илаһидыр илһам, пакь таңнарда
Дәрте йокыларны качыра,
Ак кәгазем, иң әүвәле синдә
Күңелемнең теле ачыла.

Син белмәгән уй-серләр дә кала,
Ачыл, дисең дә бит, сагайма—
Уртак еллар саргайганы җитәр,
Безнең сагышлардан саргайма!

## Тәрәзәдән гөлләр карый...

Тәрәзәдән гөлләр карый,
Гөлләр микән?
Әллә чибәр кызлар микән?
Кемнәр икән?

Тәрәзәмә үрелгәннәр
Гүзәл икән,
Гел дәшмичә ничек алар
Түзә икән?

Күзлегемне киеп баксам—
Гөлләр икән,
Яшьлегемдә чәчәк аткан
Көннәр икән...

Касәләрдә иртәнге чык—
Таммый икән.
Мин таныдым, гөлләр мине
Таный микән?

## Нинди хикмәт

Мәхәббәтле, нурлы күзләр
Шундый якын, шундый тере...
Көне буе мин бәхетле—
Исән булып төшкә кердең.

Нинди хикмәт, могҗиза бу
Заманнарны алыштыра:
Үткәндәге теге дөнья
Яшьлек белән кавыштыра.

Сагынышып, сүзсез генә
Күз карашып алдык төштә.
Сөюеңнән бу дөньяга—
Күңелемә якты төшә...

## Төнге уй

Таң атар алдыннан
Караңгы куера.
Якты көн күз йомган,
Мин дә шул куенда.
Кизүдә шәм-өмет,
Гел сүнми уемда.
Яктыра ышаныч
Офыклар буенда.

*2001–2002*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Мәдинә Маликова

## ӨЕРМӘ

ДЕТЕКТИВ РОМАН

*Көннәр имин. Мин чаң сугам:*
*«Аң булыгыз кешеләр!*
*Өермәләр кинәт куба,*
*Таулар кинәт ишелә!».*

...Июль аенын кояшлы тыныч көнендә, шәһәрнең зур урамыннан килгән аксыл “УАЗик” уң тыкрыкка борылды да, иркен ишегалды уртасына урнашкан өч катлы бинаның капка төбенә килеп туктады. “Ашыгыч ярдәм” машинасына охшаган иде ул—андыйларда носилкалы хасталарны йөртү жинел. Ләкин монын ягына кызыл тасмалар сызып, кызыл тәреләр ясалмаган, номеры да шәхси машина икәнлеген белгертеп тора. Менә анын ачык тәрәзәсеннән берәү аксыл бөдрә башын сузды, түбә өстенә бастырып куелган берәр метрлы хәрефләрне тоташтырып укыды: “Баллы күл” кафесы. Аннары янында утырган шофердан:

—Сәгать ничә?—дип сорады.

—Ун тулып унбиш минут.

—Минеке дә дөрес икән,—диде бөдрә чәчле кул сәгатенә карап.—Сонга калдырдың син мине.

—Сон машинасы нинди бит! Тагын кабынмый интектерде!

Шофер, егерме ике-егерме өч яшьләр тирәсендәге ябык, ак чырайлы егет, кабинаның икенче ягыннан сузылып карады. Түбәдәге хәрефләр искергән, янтайган, “ы” белән “ү” бөтенләй авып төшкәннәр. Бинаның үзеннән дә караусызлык, хуҗасызлык бөркелеп тора, зур тәрәзәләрнең күп өлгеләре ватылган, кайсылары бөтенләй рамсыз калган. Ишегалдын чирәм баскан, анда агач-могач, тимер кисәкләре, ямьшәйгән ләгән,

Мәдинә МАЛИКОВА—*язучы, “Кар сулары”, “Янар таулар яктысында”, “Басып сайрар талы бар”, “Шәфкать”, “Алтын ятьмә” һ.б. китаплар авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

чиләкләр аунап ята. Арада ак ванна гына төзек, чиста булып күренә.

—“Баллы күл” имеш,—диде шофер.—Күле кая соң монын?

—Агачлыкта бер күл бар иде анда,—дип бина артындагы куе өрәнгеләргә таба кулын селтәде анын юлдашы.—Кибеп бетмәсә. Йә чүп-чар белән күмеп куймаган булсалар.

Шулай диде дә, җиргә төште. Җинел, җыйнак гәүдәле, кечерәк буйлы, түгәрәк йөзендә балалык алсулыгы һәм чисталыгы сакланган утыз тирәләрендәге кеше иде бу. Ак күлмәген саргылт чалбарының каешына пөхтәләп кертеп куйды да шоферга карамый гына:

—Көтеп-көтеп торгандыр да, китеп баргандыр инде, бәлки,—диде.

—Кем?

—Бер шагыйрә килергә тиеш иде.

—Шагыйрә?.. Нишли ул монда?

Анын тавышында гаҗәпләнү сизелде. Чыннан да, биредә инде күптәннән бушлык, котсызлык урнашканы күренеп тора. Шагыйрәләр йөри торган урынмы?

—Хәйрия җәмгыяте оештырган. Шушы бинага урнашмакчы икән. Ул әйткән иде, карап кайт әле, дип. Ремонт мәсьәләсендә кинәш сорый. Менә бит, вывескасы да бар.

Чыннан да, кыйшайган тимер ишеккә зур гына ак кәгазь ябыштырылган, ана эре кызыл хәрефләр белән ике телдә “Җәмгыяте хәйрия”—“Благотворительное общество” дип язылган иде.

—Бәлки, эчтә көтәдер,—диде бөдрә чәчле.—Әйдә, син дә кер. Бергәләп карап чыгыйк әле.

Шофер иренеп кенә машинадан чыкты да, күксел костюмын рәтләштереп, начальнигы янына керергә җыенгандай, галстук төенен капшады.

Алар чирәм баскан ишегалдына уздылар. Чүп-чар тирәсендә иснәнеп йөргән өч-дүрт эт ишегалды түренә таба чапты. Шофер ваннага ишарәләде:

—Әллә сон, шагыйрә юк чакта, машинага салып куйыйкмы, Харис Мирзаянович? Мөгаен, алып китәргә дип чыгарып куйганнар моны. Каранғы төшкәнне генә көтәләрдер. Бик кыйбат әйбер бит хәзер. Безнен дә эчне тишмәс, бакчага бик ярый ул.

—Ташла, Даниф, вакланма,—дип, Харис Мирзаянович уалган бетон бусага аша эчкә атлады.

Ишек артында ук җыйнак кына өстәл, анын янында ике урындык тора, аларны, мөгаен, күптән түгел генә китереп куйганнардыр. Өстәлдә зур йозак ята, ачкычы да үзендә.

—Менә бит, ишекне ачып кергәннәр,—диде Харис Мирзаянович.—Килгән булырга тиеш. Берәр кая чыкса да ерак китмәгәндер.

Эчкәрәк узгач, егетләр чын-чынлап вәхшилек дөньясына барып керделәр. Бина эченнән алып китәргә мөмкин булган бөтен нәрсәне: ишекләр, кухнядагы плитәләргә кадәр каерып алып чыгып киткәннәр, хәтта стенага ябыштырылган кафель шакмакларын да куптарганнар. Күбесе ватылган, кыйпылчыклары белән идән тулган.

—Нишләткәннәр бит, ни хәлгә китереп житкергәннәр... Мондый да корткычлык булыр икән...—дип сөйләнде Харис Мирзаянович, зур бүлмәләрдән кечерәкләренә йөргәндә.

—Әйе, иен китергәннәр монын,—дип башын чайкады Даниф та.—Кран алып килеп, стена блокларын каерасылары гына калган.

—Мин үзем төзешкән идем моны. Институт бетереп, трестка эшкә килгән генә вакыт иде. Һәрнәрсә ин яхшыдан булсын дип күпме тырыштык, бөтен СССР буенча чабарга туры килде,—диде Харис Мирзаянович офтанып.—Районның бөтен көче шушына салынды. “Туклану комбинаты” дип атала иде ул. Мәктәп ашханәләре өчен кәтлит-гуляшларны, пәрәмәч-сумса, салатларны шушыннан ташыйлар иде.

Элекке рестораннан кафе булган залга, аннан ыслау цехына, балык, ит, камыр ашлары цехларына кергәндә, башын сузып юыну бүлмәләрен

караганда, Харис Мирзаяновичның ачуы көчәйгәннән-көчәя барды, ул хәтта ярсый башлады. Тавышы нечкәреп китте.

—Моның өчен... моның өчен...—дип, биек түшәмгә йодрыгы белән кизәнде ул,—шәһәр хуҗаларын судка бирергә кирәк! Бу корткычлык! Халыкны күрәләтә талау!

Һәм аяк астында аунап яткан ватык савыт-саба, яньчелгән чүмеч, кашыкларны, сынган пычакларны типкәләде.

—Кем ул халык? Кайда? Хөкүмәтнеке дисәң генә инде. Хөкүмәтнекенә кем булдыра алса, шул хуҗа бүгенгесе көндә,—диде Даниф тоныкк тавыш белән.

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә йөри торгач, тау мәгарәсе кебек караңгы, салкын коридорга барып чыктылар. Шомлы тынлыкта чуп-чуп итеп эре тамчыларның суга тамганы яңгырап ишетелде.

—Фу, шайтан! Каян килгән монда су?

Чыннан да аяклар тубыктан суга батты. Каршы якта ишек бар, күрәсең, ярыклардан яктылык саркый иде. Аннан машина килеп туктаганы, кемнәрнеңдер сөйләшкәне ишетелде.

—Кемнәрдер йөри,—дип сагайды Харис.

—Чатта "Җинел машиналарны төзәтәбез" дигән игълан бар иде бит. Сез утырган яктан күренмәгәндер,—диде Даниф, тыштагылар ишетмәсен, дигәндәй, тавышын әкренәйтеп.— Автосервис булырга тиеш.

Харис ишекне этеп карады, әмма ул ачылмады. Алар, кире борылып, буш шешәле тартмалар өелгән ишексез куышлар турыннан уздылар.

—Болары ничек исән торадыр, бомжлар ияләнеп өлгермәгән, күрәсең,—диде Харис.

Хәер, килеп, кунып-төнеп ятучылар бар икән үзе. Өске катның кысан, тәбәнәк бер бүлмәсендә, өч-дүрт җирдә өелгән иске-москы, сумкалар, калай савытлар, пыяла һәм пластик шешәләр аунап ята иде.

Тагын аскы катка төшеп, рамсыз тәрәзә уемнарыннан кояш нуры тулган зур бүлмәгә килеп керделәр. Яктылыктан күзләр камашты. Харис ирексездән аска карады. Идәнгә тездән диярлек кәгазь-мәгазь түшәлгән. Исәп-хисап—бухгалтерия документлары иде болар.

—Күпме кешенең мие черегән инде бу саннар белән!...— диде Харис. Һәм, иелеп, почмактагы аерата зур өем өстендә яткан калын кенәгәне алды. Өем ишелеп китте һәм кәгазь арасында... кул күренде.

Бүлмә кинәт караңгыланып киткәндәй булды. Уйлар чуалды.

—Нинди бомж йоклап ята монда?

"Әйе, әлбәттә, бомж... Йоклаган... Исеректер... Янына килгәнне тоймый... уянмый..." Бу уй җанны тынычландыра, күнелне баскан шомның авыр ташын җиңеләйтеп җибәргәндәй итә иде. Ләкин озын, нечкә бармаклы кул бик нәфис, шома, чиста. Тырнаклары миндаль чикләвеге рәвешенә китерелеп, кызылга манылган... Бомж мондый булмый... Харис кул иясенең тавышка уянып, торып басуын тели иде. Ләкин кәгазь өеме хәрәкәтсез калды. Күнелгә килеп төшкән таш зурайды, авырайды, тынны кыса башлады.

—Нишлисез сез анда?—дип сорады ишек төбендә калган Даниф.

—Монда берәү ята... Һушсыз...

Шулай диде Харис, аның тавышы карлыгу катыш пышылдап чыкты. Ул әле бу хәлнең хәерле тәмамлануын, кыска вакытлы саташу, бастырылу кебек юкка чыгуын тели иде. Ләкин саташу дәвам итте. Ул тезләре хәлсезләнгәнен тойды, урыныннан кузгала алмас кебек булды. Әмма болай озак тору мөмкин түгел, нидер эшләргә кирәк иде. Ул, иелеп, саннар белән чуарланган кәгазь битләрен, дәфтәрләрне беләге белән читкәрәк шудырды. Алар астында челтәр якалы ак кофта, аклы-кызыллы җепләрдән бизәкләп бәйләнгән итәк кигән яшь хатын ята иде. Башы җайсыз каерылган, эре бөдрәләре тирәсендәге кәгазьләр куе кызылга манылган. Авыз тирәсе, бите ала-кола кызылга буялган. Җәүһәрия...

Харис, аны җайлабрак яткырырга теләп, иңнәреннән тотты. Хатын-

ның тәне сыгылмалы, җылы кебек тоелды. Конгырт бөдрәләре артка авышты. Һәр колак яфрагына икешәр тишек тишелеп, кызыл кашлы нәни алкалар кигертелгән иде. Нәкъ менә шушы алкалар бәгырьне телеп узды: Бу—Җәүһәрия... башка берәү түгел... Менә-менә карашын Хариска төбәр дә:

"О-ой, нишләдем соң әле ми-ин?!"—дияр кебек тоелды.

Әйе, Харисны күрер, елмаер, эндәшер. Тик менә хәзер тиз генә нидер эшләргә кирәк... Бәлки, ярасын бәйләргәдер, бәлки, ясалма сулыш алдырыргадыр? Башта шундый уйлар бәргәләнә, ләкин томанланган зиһеннең бер почмагында, кара шомга уралып, аяусыз хакыйкать басып тора: соң шул инде, соң, соң... Бернишләп булмый...

—Харис Мирзаянович!.. Сез нишлисез... Мәеткә тап булдык бит... Ычкыныйк без моннан яхшы чакта...

Харис, кәгазьләр өстенә тезләнде дә, нишләгәнен аңлап та житкермичә, хатынның киң итәген тартып, йомры тез башларын каплады. Итәге суга чыланган, авыр, салкынча. Сул аягыннан туфлие төшкән иде, аны аягына кигезде. Юка, дымлы оекбаш эченнән кызыл тырнаклы аякның җылысы сизелде. Харис Җәүһәриянең кулларын җайлап куйды, кесәсеннән шакмаклы кульяулык алып, битен сөртте. Иннек... Иреннәрендәге иннегә бөтен битенә сыланган...

—Сез нәрсә, Харис Мирзаянович? Орынмагыз! Китәргә кирәк тизрәк!

—Син бар. Милициягә хәбәр ит.

—Милиция белән бәйләнергәме? Мондый эштәме?!

—Бәйләнми нишлисең?

—Мокрое дело... Якын баралар, димени?!. Башың чыкмас...

—Бар, чакыр.

—Ә сез?

—Мин монда...

Даниф, үзалдына сукрана-сукрана, ишеккә юнәлде. Харис аның сүзен ишетмәде, ул Җәүһәриянең күзләренә текәлгән иде. Кара сөрмә тартылган куе керфекләр арасыннан коңгырт күзләр бик нык гаҗәпләнеп карап тора. "Ярый әле, гаҗәпләнгән генә... Хәйран калган... Газапланмаган, җәзаланып өлгермәгәндер, бәлки..." Үзе өчен шундый кечкенә генә юаныч табарга тырышты ул. Бармаклары белән бик сак кына мәрхүмәнең күз кабакларын япты. Ә уйлары бу фаҗигадән, бу шомлы бинадан ераклашырга омтылды. Хәтер түрендә электр утлары кабынган зур заллы манзара пәйда булды...

* * *

Педагогия институтының тулай торагында сигезенче март уңаеннан оештырылган бию кичәсенә бер танышына ияреп барган иде Харис. Хәзер исенә төшергәндә шулай күз алдына килә: залга барып керүгә, йөзләгән кыз арасыннан Җәүһәрияне генә аерып, күреп алды бугай ул. Кайсы ягы белән дикъкатьне үзенә тартты соң кызый? Хәзер уйлаганда, күз карашы белән иде кебек тоела. Харис янындагы танышыннан:

—Кем ул, теге зифа сынлы кыз?—дип сорады.

—Кайсы?

—Әнә, аклы-кызыллы бәйләгән кулмәктән... Бер урынына ике тапкыр бөтерелә...

—Ә-ә, Жанна Баянова. Рус теле факультетыннан... Әйбәт бии ул. Бар, чакыр.

—Миннән башка да чакырганнар бит инде.

—Отбивать итәбез аны. Бу егет хәзер арып туктаячак. Жаннага чыдый алмас! Ул тәмәке тартырга чыккан арада, барасын да чакырасын.

—Ә ул ... минем белән биер, дисенме?

—Өлгерсән, кире бормас.

—Ничек алай?

—Шулай. Күнеле яхшы. Кызгана бела ул. Егет кешегә кыздан отказ алып кире китү читен бит. Шуны анлый. Она добрая,—дип русчалатып, өстәде егет. Һәм аның бу сүзләрендә җинелчә көлемсерәү сизелде.

Ул чакта ук Харисның күнелендә зифа сынлы, җинел, җитез хәрәкәтле кызны кимсетүле сүзләрдән яклау теләге кабынган иде. Ләкин, бер белмәгән кешене яклап, дустына ничек каршы әйтәсең?

Ул икеләнебрәк торды. Кыз буйга шактый калку күренә, җитмәсә биек үкчәле туфли кигән, ә Харис озынлык белән мактана алмый. Көлкегә калмас микән?

Хәер, озын кызлар белән беренче генә биюе түгел лә. Егет тәвәккәл булырга тиеш. Һәм Харис, яна көй уйный башлауга, зал аша каршы якка атлады.

Үзеннән биегрәк кызлар белән биегәндә, аларның күз карашында тәкәбберлек, кимсетү бар сыман тоя торган иде ул. Жаннаның кин ачылган күзләре исә җылы, дустанә карый. Аларда кызның чиста җаны, сизгер күнеле чагыла иде кебек. "Күзләре иләксез моның,—дигән уй йөгереп узды Харисның башыннан.—Һәр очраган кешегә шулай җанынны ачарга ярыймыни? Күзнең иләге булырга тиеш! Күнел түренә һәркемне уздырырга ярамый! Бәгыренә кылчык кына түгел, үткер тимер ярчыклары кереп кадалуы бар!"

—Мин сезнең исемегезне беләм,—диде ул кыю елмаеп.—Сез—Жанна.

Сүзләр русча әйтелде, тик авылда үскән егетнең татар икәнлеге маңгаена язылган гына түгел, теленә мәнге бетмәслек итеп уелган иде.

Башкалар бер әйләнгәндә, кыз ике тапкыр бөтерелеп алды.

—Ә менә белмисез икән, минем исемем Җәүһәрия. Паспорт буенча. Ә дуслар Жанна дип дәшә.

Җәүһәрия татарча сүзләрне сайлап, русча акцент белән әйтә иде.

—Әти-әниегезгә рәхмәт инде, башыгызга тишек ясаган өчен,—диде Харис.

—Нинди тишек? Аларның мина сукканы юк!

—Татарча анлаган урысны, башы тишек моның, диләр. Татар сүзләре миенә үтә, дигән сүз. Белми идегезме?

—Беренче ишетәм.

—Мин бу өлкәдә сезнең белемегезне арттырырга әзер. Акча сорамам, түләүсез мөгаллим булырмын. Сез мина Харис абый диеп дәшәрсез. Татарда мөгаллимнәргә шулай диләр. Мөгаллимнең кем икәнен беләсезме? Укытучы дигән сүз.

Ә Җәүһәрия көлә, күз төпләрендә очкыннар уйный...

... Соңгы елларда кеше холкы нык үзгәрде. Машина тәрәзәләрен каралтуны модага керткән кебек, күзләрне дә сөремләде замана. Кеше гүяки тыштагыны күрә, ә эчендәгесен күз бәбәгенә сыланган корым астында яшереп тота кебек. Ни уйлый ул, ниләр кичерә—белмәссен.

Ә менә Жаннаның күзләрен вакыт каралта алмады. Алар тылсымлы көзге кебек якты булып калды—анда син үзенне матур, көчле итеп күрә иден. Һәркемгә яхшылык эшләргә әзер тора, башкалардан да гел яхшылык кына көтә иде алар.

Шул сихри көзгедән көч алып, батыраеп, Харис кичәдән сон кызны озата китте. Рөхсәт сорамады, болай гына, юл унае туры килгәнгә генә янәшә барган булып кыланды. Аның беләсе килгәне шул иде—озатучысы бармы кызның, юкмы?

Җәүһәрия трамвайга хәтле дус кызы белән култыклашып барды, яннарында егет-җилән күренмәде. Хәер, нәрсәсе гаҗәп аның. Егетләр серлерәк, тәкәбберрәк кызларга тартыла төшә, беркатлы ачык авызлар ул кадәр мавыктырмый.

Үзенә кире якка булса да Харис кызлар артыннан бишенче трамвайга

утырды. Җәүһәрия Казан кызы икән, барасы җире ерак түгел, ике генә тукталыш булып чыкты. Трамвайдан төшкәндә, кызның сумкасы болганып, ачылып китте, эчендәге бар әйберсе тукталышта таптанган халыкның аяк астына сибелде.

—О-ой! Нишләдем соң әле ми-ин?!

Юеш асфальтта кармаланып иннек-кершән, көзгене, тиеннәрне җыйганда, Харисның колагына аның сүзләре җыр булып керде дә күңел түрендә уелып калды.

...Менә хәзер, шушы минутта, башын калкытсын иде дә, гадәтенчә үз-үзенә хәйран калгандай:

—О-ой! Нишләдем соң әле ми-ин?!—дисен иде ул.

Ләкин юк шул, юк, кузгалмый, башын күтәрми. "А-ай! Нишләдең соң әле син, Җәүһәрия? Ничек болай булды бу? Ни өчен?!"

Ә аның күз кабаклары тагын күтәрелгән, карашы гаҗәпләнеп, хәйран калып, биек түшәмгә текәлгән. Гүяки ул да бу сорауларга җавап табудан гаҗиз иде. Харис бик сак, иркә кагылып, аның күз кабакларын тагын сыйпады. Беренче тапкыр аның йөзенә орынуын уйлап, бәгыре сызланды. Ул кульяулыгы белән мәрхүмәнең битен каплады.

* * *

Машина гүләве ишетелде. Харис торып басты, тәрәзә янына килде, үрелеп тышка карады. Ишегалдына ике милиция машинасы килеп туктады, алдагысыннан эт атылып чыкты, җитез егетләр сикереп төште. Ул арада бүлмәгә алты-җиде ир-ат йөгереп килеп керделәр дә тирә-юньне ыгы-зыгы белән тутырдылар. Көрәнсу овчарка мәет янында аз гына тынгысызланып иснәнде дә, ырылдап Харисның күкрәгенә сикерде. Җитәкләгән егет көч белән этне артка тартты:

—Стоять, Ансар! Стоять!

Калын гәүдәле, салмак хәрәкәтле, иллеләр тирәсендәге абзый эт иясенә бина эчен һәм ишегалдын йөреп чыгарга кушты. Аннары, Харисны рамсыз калган тәрәзә төбенә чакырды да, сумкасыннан кәгазь белән ручка чыгарды. Берәү мәет өстенә иелгән, икенчесе аның тирәсендә рулетка сузып, үлчи, берәүсе кызыл фломастер белән кәгазьләргә мәрхүмә тирәли сызык сыза, шыксыз кара-сорыдан киенгән сакаллы адәм, тирәли әйләнгәләп, иелеп фотога төшерә иде.

—Мин тикшерүче Вәлитов,—диде юан абзый.—Мансур Хужиевич диярсез. Милициягә сез шылтыраттыгызмы?

—Милициягә?—Харисның зиһене чуалды.—Әйе... Мин кергәндә, ул шушылай ята иде... Милиция чакырмый нишлисең...

Мансур Хужиевич Хариска сораулар биреп, җавапларын терки башлады: исем-фамилиясе, туган елы, адресы, монда ник килгән, мәрхүмәне ничә сәгатьтә, ничә минутта күргән, кем икәнен беләме...

—Шагыйрә Жанна Баянова—мәгълүм шәхес,—диде Харис авызында сагыз әвәләгәндәй хәлсез тавыш белән.— Шәһәр гәзитен укып барсагыз, исемен беләсездер. Без аның белән бинаны карап чыгып, ремонт ясау мәсьәләләрендә киңәшергә тиеш идек. Сәгать унда.

Ул арада ике оперативник эт белән бинаны айкап чыкканнар иде инде. Алар өске каттагы тар почмакларга барып ирешкәннәр, андагы чүпрәк-чапрак арасыннан ак төстәге хатын-кыз сумкасы табып алганнар. Сумканы китереп тәрәзә төбенә селкеделәр: эченнән хатын-кыз һәрвакытта үзе белән йөртә торган иннек-көзге, кульяулык, тарак ише әйберләр, телефоннар яза торган кечкенә кенәгә, хәер җәмгыятенең һәм язучылар берлегенең таныкнамәләре коелды, паспорт килеп төште. Арада таушалып беткән кечкенә китапчык бар, аның тышына кызыл Ай сурәте ясалган, латин хәрефләре белән "Төрек Кызыл Ае" дип язылган иде.

—Ә бу нәрсә?—дип сорады Мансур Хужиевич китапны актаргалап.

—Төркиянең шәфкать оешмасы турындагы китап.

—Ник сумкасында йөртте икән ул аны?

—Татарларның оешмасын да шушындый итәргә кирәк, дип, очраган бер кешегә күрсәтә иде.

—Ә сез каян беләсез?

—Мина да күрсәткәне бар... Оешма эшендә катнашырга үгетләгән иде...

—Сез аның кеме сон?

—Мин? Мин...—Харис югалып калды.—Танышы...

—Гади танышы гынамы?

—Шулай булып чыга...

—Ә өендә кемнәре бар?

—Белмим. Ире булырга тиеш...

—Ничек "булырга тиеш"? Булмаска да мөмкинмени?

—Без аз аралаштык. Минем аларның өендә булганым юк.

Ул арада кулына резин перчатка кигән егет кәгазьләр арасыннан ит чаба торган, очы сынык пычак табып, полиэтилен капчыкка тыгып куйды. Аннары Җәүһәриянең битеннән кульяулыкны алып, Мансур Хужиевичка күрсәтте.

—Кульяулык менеке,—диде Харис.

—Ничек сезнеке? Ник сез аны мәет өстенә салдыгыз?

—Мәет ачык ятарга тиеш түгел... Башка әйбер тапмадым...

—Тагын ниләр эшләдегез инде сез мәет тирәсендә?

—Ул кәгазьгә күмелеп ята иде.

—Сез актарып алдыгызмы?

—Әйе. Кулын күрдем дә.

—Ул нәкъ шушы рәвешле ята идеме?

—Юк, башы нык каерылган иде. Мин аны исәндер дип уйладым. Җайлабрак яткырдым...

—Беләсезме, бу ни дигән сүз? Тикшерү эшен саташтыру, эзне адаштыру, дигән сүз. Сез җинаятьченең эзләрен таптап бетергәнсез! Махсус шулай эшләнгән булуы да ихтимал. Башта үтерә, аннары үз кульяулыгын мәет өстенә ташлый да, милиция чакыра. Эт, билгеле, ана килеп ябыша, ә ул, мин үле гәүдәгә очраклы рәвештә генә юлыктым, аны кызганып, битен капладым, дип акланырга маташа...

—Сез... мине гаепләмәкчеме әллә?

—Сездән башларга туры килә. Күптән бәлигъ булгансыз, аны гына белерлек.

—Югалып калдым. Зиһенем чуалды,—дип мыгырданды башын иеп Харис.

—Нәрсәгә зиһенегез шулхәтле чуала? Хатыныгыз да, сенлегез дә түгел, гади таныш дисез үзегез.

—Минем шаһитем бар... Без икәү килдек.

—Шаһитегез булу ярый анысы,—диде Мансур Хужиевич.—Кая сон ул?

—Милиция чакырырга киткән иде.

—Кем ул?

Ул Данифның исем-фамилиясен, өй телефонын язып алды.

—Шулай буласы көн кебек ачык,—дип өстәде, үзалдына сөйләнгәндәй.—Мондагы тәртипсезлек, мондагы хужасызлык җинаятькә китерми кая илтсен! Кайбер хужаларны акылга утыртыр өчен берәр мәет җитми шул! Менә булды инде мәете дә!

Аның биленә беркетелгән телефон шылтырады.

—Урожай мул бүген, тагын мәет,—диде тикшерүче яна хәбәр алгач. Һәм егетләргә таба атлады.—Урман арты бистәсенә барырга кирәк. Юл читендә мәет табылган. Анда ГАИ эшли инде, бездән кеше күп кирәк булмас. Берегез Байбулатованың эш урынына, берегез фатирына чабыгыз. Берегез монда тирә-юньне ныклап карап чыгар. Теге яктагы машина төзәтүчеләрдән башларга кирәк булыр.

—Ә ул?—диде Харис мәрхүмәгә ымлап.

—Без мәет ташымыйбыз. Тиешле кешеләре бар. Хәбәр итәрбез, килеп алырлар. Син, Саша, калып тор,—дип өстәде Мансур Хужиевич егетләрнең берсенә.

Мөселманнарда мәетне көнендә җирлиләр. Мондый эссе чакта озакка сузу бигрәк тә ярамый. Харис шуны уйлап алды.

—Мин аны калдырып китмим,—диде ул.

—Мәйлегез. Ләкин исегездә тотыгыз: сез шәһәрдән беркая да чыгып китәргә тиеш түгел. Без сезнең белән иркенләп очрашып сөйләшербез әле.

...Барысы да чыгып киткәч, Саша, сары чәчле, кырыс чырайлы егет, Харис янына килеп басты. Тәмәке кабызды да мәрхүмәгә ымлап:

—Кемегез?—дип сорады. Ул, күрәсең, тикшерүче белән сөйләшкәнне ишетми калган иде.

—Танышым.

—Монда ничек килеп чыккан соң ул? Фахишәме әллә?

Харисның карашыннан шундый ут бөркелде, күрәсең, егет тәмәке төтененә тончыга язып, башын иде.

—Гафу итегез... Алай да сәер... Үз кадерен белгән туташ-ханымнар мондый җирләрдә йөрми...

Бусында инде Харисның башы иелде: нишлисең, бу сүзләрдә хаклык бар. Ник ялгызы кергән икән Җәүһәрия бу бинаның эченә? Әллә ялгызы булмаганмы? Кем булган аның янында? Кем?!

Урам яктан тагын машина гүләгәне ишетелде. Данифның "УАЗиг"ы икән.

—Әллә килеп тә җиттеләр инде?—диде Саша тәрәзәдән сузылып.

—Юк. Бу минем таныш егет.

—Карагыз әле, машинасы бик җайлы бит. Әйдәгез, мәрхүмәне шуның белән генә илтеп куйыйк?

Харис, авыр кузгалып, урамга, Даниф янына чыгып китте.

—Җен калтырчасы, зажиганиесе сүнеп азаплады, урам чатыннан кузгала алмый әллә ни гомер нужардым,—дип сукранды Даниф.—Милициягә дә барып житеп булмады. Телефоннан шылтыратырга туры килде. Тарттырып кабыздык. Ниләр булды анда?

—Моргка илтергә кирәк,—диде Харис.

—Минме? Аның махсус кешеләре бар бит!

Әмма тәрәзәдән чакырып кулын болгаган Сашаны күргәч, шундук телен аркылы тешләде. Пышылдап:

—Кем ул?—дип сорады.

—Оперативник. Сиңа керергә куша әнә.

...Харис Җәүһәрияне үзе генә күтәреп чыгармакчы иде. Ләкин ул бик авыр тоелды. Тезе астыннан Саша тотып алды.

—Җайлап... Ипләп...—диде Харис.

—Кәгазьләрне кузгатмаска. Сызыкны күрәсезме? Бозылмасын!—диде Саша.

Машина эчендә, алгы якта агач эскәмия генә бар, тимер идәнгә җәяр әйбер дә юк иде. Саша бүлмәдән кәгазь алырга рөхсәт итмәде, андагы бер нәрсәгә дә кагылырга ярамый, диде. Тикшерүчеләр килеп, тагын бер тапкыр һәммәсен бик жентекләп карап чыгачаклар икән.

Харис, күлмәген салып, Җәүһәрияне шуна яткызды. Саша Даниф янына кабинага керде, ак майкадан гына калган Харис исә мәрхүмәнең баш очына, эскәмиягә утырды. Җәүһәриянең битен тагын кулъяулыгы белән каплады. Авыр көрсенеп: "Менә тагын мин аны күтәрә алмадым",—дип уйлады. Ә бит күпме хыялланган иде ул, Җәүһәрияне кочагына алып, көчле беләкләренә салып, зыр-зыр әйләндерү, очыртып кына йөртү хакында!

Ләкин... ләкин... Беренче талпынуында егылды, икенчесендә кеше алдында көлкегә калды, өченче тапкырында, бүген башка берәүнең ярдәменә мохтаҗ булды.

* * *

...Беренче тапкырында иртә яз иде. Кояштан качып, күләгәдә посып яткан керле боз кантарларын юып алып китәргә килгән янгыр, шәһәр урамнарын шаулап-дулап, кинәнеп коендырды. Харис бию кичәсеннән соң Җәүһәрияне озата бара иде. Төптән уйлап тормыйча, бер талпыну белән яши торган Җәүһәрия бу юлы да ашыккан—кичәгә үкчәле җәйге туфлиен киеп килгән иде.

Баштарак алар бер ишек төбенә ышыкланып, янгыр узганны көтеп тордылар. Әгәр кыз кечерәк гәүдәле булса, яисә туфлие биек үкчәле булмаса, Харис аны кочагына алып жылыткан булыр иде. Киноларда егет белән кызның янгырдан качып торганын шулай күрсәтәләр. Ләкин ул кыенсынды, чөнки Җәүһәриягә елышса, үзе ана ышыклангандай тоелыр, дип уйлады. Алар бер-берсенә терәлешмичә, бераз ара калдырып сөйләшеп басып тордылар.

Ул тынгысыз, шаулы язгы кичтә, карангыда мәрҗәндәй жемелдәп коелган тамчыларга карап, мәхәббәт турында сөйләштеләр алар. Чибәр һәм горур патшабикәнен курку белмәс баһадир егеткә мәхәббәте турында. Бер атна элек Җәүһәрия Хариска Стефан Цвейгнын “Мария Стюарт” дигән китабын укырга биреп торган иде. Шотландия королевасынын фажигале язмышы аларнын икесен дә тетрәндерде. Яшьлектә тәхеткә менү, аннары тоткынлыкка эләгеп, озак еллар буе зинданда яту һәм, ниһаять, жәллад балтасы астында жәзаланып үтерелү. Әмма Мариянен фажигасе тоткынлыгында, һәлакәтендә генә түгел, яшьлек мәхәббәтеннән алдануында да иде. Королеваны, тәхеттә чагында ук, үзенен тән сакчысы, урманда сахра кылганда ялгызын туры китереп, тотып көчли! Үгезне мөгезеннән тотып борып салырлык бу адәмгә нечкә сынлы нәфис кыз каршылык күрсәтә алмый... Иң гажәбе шунда—тора торып королева үзен тотып көчләгән шул тупас, каты күнелле, тәрбиясез адәмгә гашыйк була!

—Ләкин алай булуы һич мөмкин түгел!—диде кайнарланып Җәүһәрия.—Ничек инде кеше үзен шул хәтле җәберләгән бәндәне ярата алсын! Бигрәк тә королева!

Урам фонаре яктысыннан жемелдәп биешкән, асфальтта тыпырдашкан янгыр тамчыларына кушылып, анын тавышы көйле, хисле янгырады.

Күрәсен, әсәрдә тасвирланган бу вакыйга анын йөрәгенә бәргән, ризасызлык тудырган иде. Ул, бәлки, нәкъ шуна күрә Харисның да китапны укып чыгуын теләгәндер, анда үзенә фикердәш табарга өметләнгәндер. Язучы бу очракта кеше күнелен—хатын-кыз йөрәген анлап житкермәгән, дип, икәүләшеп Цвейгны гаепләргә теләгәндер.

Ләкин Харис әсәрдә әлеге хәлләрне тасвирлауда бернинди хилафлык тапмаган иде. Бу урынны ул кызыксынып укыды, дөрес, ике королева арасындагы көндәшлек, дуслык-дошманлык аны күбрәк мавыктырды. Шуна күрә ул Җәүһәриянен сүзләрен күтәреп алмады.

—Алай да, әгәр син Мария урынында булсан... Күз алдына китереп кенә кара... Нишләр иден?

—Королева бит ул! Башын чаптырсын иде!

—Ә нәрсә өчен?

—Ничек нәрсә өчен?! Җинаяте өчен!

—Нинди жинаяте? Королеваны кочаклаганы өченме?.. Ярый, шунын өчен башын чаптылар, ди, ул адәмнең. Ә королева кем булып кала инде шуннан соң? Көчләнгән кыз булыпмы? Чиста булырмы ул шуннан соң яраннары алдында, халык каршында? Югары, көчле булырмы? Алай гына да түгел, үз-үзен ихтирам итә алыр идеме ул шуннан соң?

Җәүһәрия дәшмәде. Тик анын ягыннан бөркелгән жылы дулкын көчәеп китте шикелле. Егет аны уйга салды кебек.

—Язучы мине ышандырды. Бик саф күнелле, намуслы кыз булган

шул ул королева. Инде берәүгә бирелгәнсең икән, мәңге аныкы гына булу, аны гына ярату тиеш, дип ышанган. Чын падишаһларча горурлыгы аңа, әйе минем җанымны кыйнадылар, тәнемне пычраттылар, дип икърар итәргә ирек бирмәгән, ул үзенең мескен хәлгә төшүен танырга теләмәгән! Мин ул кешене яраттым, ана үзем биреллдем, дип ышанырга һәм башкаларны ышандырырга тырышкан. Һәм ышандырган да. Беләсеңме, аның ныклыгы, сынмавы, шул ук вакытта күңел бөтенлеген дә саклый алуы миңа бик ошады. Сирәк кеше аның кебек була ала. Безнең татар кызлары андый хәлләрне артык авыр кичерә. Һәрхәлдә элекке заманда шулай булган. Тукай шигырьләрен беләсеңме? Аның “Эштән чыгарылган татар кызына” дигән шигырен ишеткәнең бармы? “Сөялгәнсең чатта баганага, яфрак төсле сары йөзләрең...”

Җәүһәрия Тукайны белә икән. Әлбәттә инде, “Туган тел”не, “Шүрәле”не, “Су анасы”н әнкәсе өйрәткән. Шулай ук “Милли моңнар”ны, “Өзелгән өмид”не дә...

—Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы... Болай итеп Тукайдан башка һичкем әйтә алмас иде,—диде Җәүһәрия.

Шул рәвешле, сүз Шотландиядән Казанга, Цвейгтан Тукайга күчте, күңелләр очынып бар җиһанны иңләде. Җәүһәрия, башын иеп, әкрен тавыш белән үзенең дә шигырен укыды. Аның дүрт юлы Харисның күңеленә уелып калды, ул аны кат-кат кабатлый торган булды һәм атна буе шулай кабатлап йөри торгач, соңыннан үзенчә татарчага тәрҗемә дә итеп куйды:

Ник ашыктың, назлы умырзая,
Күтәрергә алтын керфекләрең?
Кояш баер, кырау төшәр, төзәп
Бәгыреңә бозлы сөңгеләрен...

Җәүһәриянең русча язылган шигырьләрендә татарга хас үзәк өзелү бар иде. Ә башка халыкларда бармы соң ул “үзәкнең өзелүе”?

Алар, бәлки, таңгача шулай, хыял канатларында ерак илләрне гизеп, күптән узган заманнарда, күз күрмәгән җирләрдә яшәгән кешеләрнең газаплары өчен әрнеп, бер-берсенә орынмыйча янәшә басып торган булырлар иде. Янгыр туктады. Кузгалып, трамвай тукталышына таба киттеләр. Асфальт өстеннән ташу булып су ага, Җәүһәрияләр йортының ишек төбенә кереп булырлык түгел. Харис аны күтәреп алып, болдырга илтеп бастырмакчы булды. Кызның тыгыз тәне зур, авыр тоелды. Яктылык та әйле-шәйле, аяк асты күренми иде. Харис абынды, авып китте, бармаклары кызның тез астына шуды... Шунда ул Җәүһәриянең бөтен тәне тетрәнгәнне тойды. Аннан бөркелгән кайнарлык зиһенне өтте, бармаклар аша кан тамырларына йөгерде. Ләкин бу бер мизгел генә дәвам итте. Ул аягында басып кала алмады... Икәүләшеп егылдылар, манма суга баттылар. Харис гарьләнүен яшерергә тырышып, көчәнеп көләргә тотынды. Җәүһәрия исә куркынган тавыш белән:

—Бәрелмәдеңме, аягың каймыкмадымы?—дип аны кайгыртырга кереште.

...Шуннан соң алар берме-икеме генә күрештеләр. Аннары инде бию кичәләренә йөрү бетте, имтиханнар тапшыру вакыты килеп житкән иде.

Моңарчы спорт белән әллә ни кызыксынмаган, иртәләрен киерелеп-сузылып гәүдәсен язудан узмаган Харис, ул җәйне, махсус дәреслекләр алып, мускулларын ныгыту белән шөгыльләнде. Каникулда спорт лагерена китте. Авылга да бер генә атнага кайтып килде.

Август ахырында Харис Казанга самолетта очып килеп төште. Аэропорт бинасына керүгә, Җәүһәрияне күреп алды. Соңыннан, бу очрашуны күп мәртәбәләр күз алдыннан кичергәндә, үзе дә аптырый иде: чынлап та Җәүһәрия аны каршы алырга килгәнме? Һәрхәлдә йөрәге шулай сизде, чөнки шулай тели иде. Кешеләрне этә-төртә, бәргәләнеп

ана ашкынды. Килеп тә житте, кочаклап күтәреп тә алды, зыр-зыр әйләндерергә дә кереште. Әйе, ул көч жыйган иде, Җәүһәрия ана бик жинел тоелды. Ул шунда гына кызның никадәр якын икәнен, аны өзелеп-өзелеп сагынганын аңлады. Гомереннән иң бәхетле мизгелләре шул булгандыр да, мөгаен. Ул көчле, кыю, үз дигәнен итә торган егет иде!

Җәүһәриянең исә күзендә курку чагылды.

—Син нәрсә? Җибәр, җибәр!—диде ул урысчалап.

Харисның йөрәгенә бозлы жил бәргәндәй булды, шунда гына ул кызның бик нык үзгәргәнен сизде. Җәүһәрия ничектер кечерәеп киткән кебек, янәшә баскач, алар буйга бертигез диярлек булып чыктылар. Әллә кыз жилкәләрен жыерып, башын иеп торгангамы?

Менә ул куркынып артына борылды, тоташ тәрәзәдән торган стена буендагы төркемгә карады.

—Кемнәр ул анда?—дип сорады Харис.

—Туганнар. Озатабыз менә. Туйга килгәннәр иде.

Харисның сулышы буылды.

—Нинди туй?!.

—Кияүгә чыктым мин, Харис...

—Кемгә?

—Әнә, күзлекле кешене күрәсеңме?..

—Һай, Җәүһәрия, нишләдең син? Кем ул шундый кап-кара?

Бозлы жил шул тарафтан ыжгыра икән лә. Кара чәч, кара күзлек, кара сакал-мыек, кара костюм... Аннан да бигрәк, котып салкыны... Нәрсәсе белән, кайсы ягы белән үзенә караткан ул Җәүһәрияне?! Ничек итеп аның йөрәк түренә кереп урнаша алган? Ай, иләксез иде шул шагыйрәнең күзләре, саксыз, яклаучысыз иде шул үзе!

* * *

...Җәүһәриянең жан биргәч тә саф калган, гажәпләнү сеңгән карашы Харисның күңеленнән китмәде.

—Күзләре шар ачык иде,—диде ул рульдәге Данифка таба борылып.—Бик гажәпләнгән сыман. Җан бирер алдыннан гына кемнедер күреп хәйран калгандыр, күрәсең, бичаракай. Әйтәләр бит, үлгән кешенең күз бәбәгендә үтерүченең сурәте сеңеп кала, диләр.

—Әкият ул!—диде Саша.—Аның турында газиттә дә яздылар инде. Криминалистлар бик тырышып тикшереп карадылар, әмма бер мәетнең дә күз бәбәгендә сурәт тапмадылар. Алай булса-а-а... Безнең эш ни жиңеләер иде дә бит... Аны ачыклый торган аппаратлар безнең криминалистикада юк шул әле.

Ләкин Харисның мондый өметсезлек белән ризалашасы килмәде.

—Бүген булмаса, иртәгә дигәндәй. Бәлки, кайдадыр уйлап та чыгарганнардыр инде. Без белмәгән әллә ниләр ачыкланды бит соңгы вакытта.

—Бер уйласаң, шаккатарлык хәлләр. Әнә, телевизордан да ниләр генә күрсәтмиләр. Безнең тикшерүче Мансур Хужиевич та әйтә, без эшли башлаган заманда, хәзерге кебек күп төрле анализларны ясау мөмкинлеге юк иде, ди. Ул бөтен журналларны укып бара. Кашпировскийның тапшыруларын да калдырмый. Әгәр, ди, чыннан да, аның телевизор аша миллионнарча кешеләргә тәэсир итү кодрәте бар икән, димәк, ул телевизор каршында утырган кешеләрнең күзләрен күрергә, шулар аша эчләрендә ни барын тоярга тиеш, ди.

Егет беренче карашка гына коры булып күренгән икән. Бер машинада утырып, шәһәр урамнары буйлап барган арада, битлек урынына киеп куелган корылыгы, таләпчәнлеге коелып төшкәндәй булды, фәлсәфә корырга, фикер үткерләгән чарларга омтыла торган тәпле егет икәнлеге беленде. Кайсы гына милиция әһеле жинаятьне ачарлык дәлилләр табарга теләмәс икән? Моның өчен кешеләр белән сөйләшә белергә, аларга тел

ачкычы табарга кирәк. Шаһитләрнең эчке дөньясына кереп, актарып чыга белсәң яхшы. Авызыңны йозаклап, сирәк, сары кашыңны җыерып йөрсәң, ни белерсең?

—Ә бәлки, ул Кашпировскийны чыннан да милициягә эшкә чакырыргадыр?—диде Харис.

—Килер бар! Милициядәге эш хакы белән нишләп ваклансын, ди? Халыктан миллиардларны болай да җыя ул!

—Күз карашы һәркемдә үзенчә бит ул...—диде Харис уйга калып.—Әйтик, шул ук Кашпировскийның күзе безнекеише генә түгел. Чумак дигән адәм тагын, өстәлгә су куегыз, мин хәзер аны телевизор аша тылсымлап бирәм, шуны эчсәгез, бөтен сырхауларыгыз бетәр, ди. Чумак әфсенләгән суны эчеп кенә хәл алдым, дигәннәрен үземнең ишеткәнем бар. Дөрес, мин үзем ышанмыйм, андыйларны шарлатанга саныйм.

—Алай дип кенә булмый... Иллюзионистлар бар бит. Гипнозны инде фән дә таный.

—Алайса, шагыйрьләрдә дә булырга тиеш андый көч,—диде Харис нык ышанган тавыш белән.—Сезнең теге карт тикшерүчегез тотынса, кем әле?

—Мансур Хужиевич.

—Шул ныклап тотынса, бәлки, аның күзендәге сурәтне күрә дә алыр...

Ул Җәүһәриянең күзләре шундый кодрәткә ия булуын, аны харап иткән ерткычның тиз арада табылып, тиешле җәзасын алуын шул хәтле нык тели, үзе уйлап чыгарганга чын-чынлап ышана да башлаган иде кебек.

—Димәк, мәетнең күзләрен алып тикшерәчәкләр?—дип сорады монарчы сүзгә кушылмый килгән Даниф.

—Ник алсыннар?! Ничек?

—“Вещдок” була бит инде ул алайга китсә. Дәлил.

—Әйе, криминалистикада чын ачыш булыр иде ул,—диде Саша хыялга бирелгәндәй.—Җинаятьчене карточкага төшереп алу кебегрәк... Син әнә теге капкадан кер!—диде ул Данифка борылып.

Сүзгә мавыгып, сизми дә калганнар, завод цехын хәтерләткән эре тәрәзәле ике катлы күксел бетон бина янына килеп тә җиткәннәр икән.

—Аргы ишек янына уз,—диде Саша.

Җиргә төшкәндә, Харисның башы әйләнеп китте. Төш кебек иде бу. Сашага ияреп моргка кергәндә, ул нишләгәнен, кая барганын бик үк аңлап та өлгермәде. Җәүһәриянең һәлакәте бөтен ачысы белән хәзер генә аның аңына барып җиткән иде. Кем җинаяте бу? Ни өчен? Нинди максат белән? Һәм ни сәбәпле аны нәкъ менә Харис белән очрашу билгеләгән урында, шул сәгатьтә үтергәннәр? Әгәр Харис бу очрашуга барырга риза булмаса, Җәүһәрия дә анда килмәс идеме?

* * *

—Син нишләп кафеда түгел?—диде Нуржиһан ишектән килеп кергән Насибәгә.—Сәгать унбер тулды бит инде! Җәүһәрия сине шунда көтәдер!

—Исәнмесез,—диде Насибә. Аннары артына борылып кычкырды:—Марс! Марс, дим, кая киттең?! Кил әле монда!

Һәм, кире борылып, кабаланып чыгып китте.

—Тотарсың инде син ул Марсыңны бер кулыңнан ычкындыргач!—дип үзалдына сөйләнде Нуржиһан. Һәм урындыгына жайлабрак утырды. Озын куныччлы ак йон оекбашлар, киез башмаклар кигән аякларын өстәл астына сузып, ак якалы зәңгәр халат астындагы җылы кофтасын төзәткәләде дә, алдында яткан зур дәфтәргә иелде. Аның яна битен ачып, линейка белән сызарга кереште, үзалдына: “Исем-фамилиясе, документ номеры, адресы, телефоны, нәрсә алган, күпме, имзасы...”

дип, сызык сызган саен сөйләнде. Бу дәфтәргә ул хәер җәмгыятеннән кемнәргә күпме азык-төлек бирелгәнен теркәп барачак иде.

Җәмгыятьнең бүлмәсе ярыйсы гына иркен булса да тәбәнәк, дымлы, салкынча иде. Авыл өенеке кебек кечкенә ике тәрәзәсенә юан, сырлы тимерчыбыктан рәшәткә ясап куелган. Тәрәзәләр җирдән чак кына югары булып, аларга кояш төшми, ишегалдындагы зур гаражларның тимер капкалары гына күренә. Нурҗиһан утырган көрәнсу-саргылт өстәл түр тәрәзә төбенә терәп куелган. Өстәл шактый кыршылган, бер почмагы нык сыдырылып, эченнән җилемгә катырылган пычкы чүбе күренеп тора. Ләкин Нурҗиһан аңа игътибар итми, чөнки өстәл бик унайлы, уртада тартмасы, ике ягында киштәләре бар, вак-төякне күп сыйдыра. Өстендә язу машинкасы, кызыл телефон, зәңгәр өстәл лампасы. Шунда ук кадими заманнан калган, агач төймәле зур чут куелган; кирәк чакта Нурҗиһан, элеккедән калган гадәте буенча, тимерчыбыкка тезелгән төймәләрне шудырып саный. Тәрәзәгә каршы як стена буйлап киштәләр ясалган, аларга төрле төстәге әйбер-кара өелгән. Идәндә он, ярма тулы капчыклар. Ишек янында зәңгәргә манылган сейф, шунда ук, стена буйлап, төрлесе төрле дүрт-биш урындык, тагын бер өстәл бар. Анда амбар кенәгәләре ята, тышларына Нурҗиһан кулы белән: "Кеше китергән кием-салымны кабул итү", "Мохтаҗларга кием-салым бирү", "Яңа киемнәр өләшү" дип язылган иде.

Беренче тапкыр килеп кергән кешедә бүлмә бик сәер тәэсир калдыра иде. Нурҗиһанның өстәле берәр кечкенә оешмадагы секретарьнең эш урынын хәтерләтә, ә чүпрәк-чапрак тулы киштәләр, идәндәге капчыклар бүлмәгә чоланмы, сараймы рәвешен бирә. Барча җиһазның аннан-моннан гына җыелганлыгы күзгә бәрелеп тора. Ишектән эчкә атлауга күңелдә үзенә күрә бер хис туа, борынга сәер бер ис бәрелә—ул мескенлек хисе, фәкыйрьлек исе иде. Рәсәй илендә беркайчан да бетмәгән, сугыш, ачлык елларында көчәйгән, тыныч вакытларда менә шушындый урыннарда—биналарның иң түбән катларында, чоланнарда, караңгы ишегалларында посып сакланып килгән ис һәм хис иде бу. Яше алтмыштан узган, чаларган юка чәчен баш артына төенләп куйган, мөлаем, ак битенә беркайчан да иннек-кершән тидермәгән Нурҗиһан үзе дә шушы бүлмәгә бик килешеп тора иде. Ул исне сизми, мескенлекне тоймый да кебек, үзен монда бик рәхәт, иркен хис итә иде.

Сугыштан соңгы авырлыкларны күреп үскән авыл кызы, педагогия институтын тәмамлагач, шәһәр егетенә кияүгә чыгып, ире белән бергә зәгыйфь балалар мәктәбендә укытучы булып эшләде. Инде икесе дә пенсионерлар, азга шөкерана кылып, очын-очка ялгап яшәп яталар иде. Ләкин менә туксан беренче елдан соң очлар очка ялганмый, пенсия акчасы ашарга да җитми торган булып китте. Үз гаиләләре белән аерым яшәүче ике улларына да заводта эш хакы түләнми башлады. Нишләргә? Ничек көн итәргә?

Авыр хәлдән Нурҗиһанны әдәбиятка булган мәхәббәте коткарды. Ул үзләренә якын мәдәният йортындагы китапханәгә йөрүдән олыгайгач та туктамады, китапханәче Халидә белән дуслашып беткән иде. Халидә аны шагыйрә Жанна Баянова, ягъни Җәүһәрия белән таныштырды.

Алар китапханәдә очрашып сөйләштеләр. Чөнки Җәүһәрия хәер җәмгыятен оештырып кына йөри, үзенең куышы юк иде әле.

Тыштан караганда йомыкый, күндәм, сабыр күренсә дә, Нурҗиһан кешенең кемлеген бер күз салуда таный белә. Шагыйрәнең эчкерсез күзләренә туры карап, аның йомшак, кайнар кулларын учына алып күрешкәч, күңелендә рәхәт бер җылылык тойды ул. "Бу гына үскән, үзе балалыктан чыгып җитмәгән бит әле бу!"—дип уйлады үзалдына. Һәм шагыйрәнең бәйләгән көрәнсу күлмәгенә сокланып карап торды. Күлмәкнең түше, иңнәре алтын-сары күн кисәкләр ябыштырып чигелгән иде. Кул эшенә үзе дә оста булганга, Нурҗиһан аларга бигрәк текәлеп карады—мондыйны аның күргәне юк иде әле. "Бигрәк килешле. Үзе бәйләгәнме әллә?"—дип уйлады ул.

Бер-ике авыз сүз алышуга, алар бер-берсен күптәннән белгән, күптәннән якын иткән кешеләр кебек булдылар. Җәүһәрия бу заманда бер-беренә карата мәрхәмәтле булуның мөһимлеге, хәер җәмгыятьләренең кирәклеге турында сөйләп алды. Тавышы ягымлы, йөрәккә ятышлы иде Җәүһәриянең, татарча сүзләрне эзләбрәк сөйләшүе, кала кызларына хас булганча, "һ"не катырак әйтүе дә апаның күңелен кырмады.

—Башта эш күрсәтергә кирәк, эшебез барса, бина да бирерләр, акчасы да табылыр,—дип сүзен йомгаклады Җәүһәрия.

—Ипилек-сөтлек акчасы булса, мин теләсә нинди эшкә дә риза,—диде Нурҗиһан.—Бүгеннән башлыйм алам.

—Менә сиңа журнал,—дип аның кулына көрән тышлы калын дәфтәр тоттырды Җәүһәрия.—Казансу арты районына барырга, анда гарипләрнең, ятимнәрнең хәлен белешеп, шушы кенәгәгә теркәргә кирәк булыр. Кем нинди хәлдә, нәрсәгә мохтаҗ.

—Кемнең ятим, кемнең гарип икәнен каян белим соң мин?

—Адресларын районның социаль тәэминат бүлегеннән сорарсың. Инвалидлар җәмгыятенең исемлеген ал.

—Нинди ярдәм күрсәтә алырмын икән мин аларга?

—Анысын бергәләп уйлашырбыз. Ой, онытa язганмын. Документ кирәк бит. Таныкнамәгә кем дип языйм үзеңне?—Җәүһәрия елмаеп Халидәгә таба борылды.—Аның эш урыны нинди булачак?

—Әле анысы да уйланмаганмыни? —дип сорауга сорау белән җавап бирде Халидә аптырап.

—Яңа эш бит бу! Башлыйбыз гына. Менә хәзер уйлыйбыз да хәл итеп куябыз. Мин җәмгыятьнең президенты бит инде. Нурҗиһан апа икенче кеше була. Ә икенче кешеләрне кем диләр?

—Урынбасар...—диде Халидә.—Йә бухгалтер...

—Минем урынбасар бар бит инде, тик эшләми генә,—диде Җәүһәрия көлеп.—Алай да торсын әле ул үз урынында. Исем өчен генә булса да. Беләсеңме, Нурҗиһан апа, мин сине... директор итәм! Хәзер үк таныкнамәгә "башкаручы директор" дип акка кара белән язабыз да куябыз! Безнең таныкнамә шундый матур! Менә кара әле!

Һәм ул сумкасыннан катыргы чыгарды. Ул чыннан да матур иде—тышына Кызыл Ай белән ак лалә чәчәге ясалган.

—Кая, үзең белән берәр карточкаң юкмы?—дип сорады Җәүһәрия

—Үзем белән карточка йөртмим инде. Китапханә билеты гына бар менә.

—Карточка ябыштырылгандыр бит аңа?

—Әйе.

—Кая, күрсәт әле! Ой, син монда бигрәк чибәр! Хәзер куптарып алабыз да без аны, үзебезнең документка ябыштырып куябыз! Халидә китапханәгә сине болай да кертә.

Шулай диде дә, карточканы куптарып алып, яңа катыргыга җилем белән ябыштырды, сумкасыннан мөһер чыгарып, ике төшкә шап-шап чәпеп тә куйды. Гаҗәпләнүеннән телсез калган Нурҗиһан каршы әйтергә сүз дә таба алмый калды. Телең дә бәйләнер, пенсионер башың белән ун минут эчендә "башкаручы директор" булып куй әле! Ә Җәүһәрия сикереп торып, аның уң кулын кушучына алды:

—Котлыйм! Эшләрең гөрләп барсын, исемең илгә яңгырасын!—Ә үзе көлә, Нурҗиһанның аптыраган кыяфәтеннән рәхәтләнеп хихылдый.

"Шаяра. Әйдә соң, шаярсын, аннан миңа ни зыян. Күңеле булсын",—дип уйлап куйды Нурҗиһан.

Әмма иртәгесен үк эшнең бик җитди һәм авыр икәнлеге ачыкланды. Декабрь аеның салкын, җилле көне иде. Нурҗиһан, сумкасына айлылаләле катыргыны, көрән тышлы калын дәфтәрне салып, кар баскан кырый урамнар, тар тыкрыклар буйлап йөри башлады.

Зәгыйфьләр мәктәбендә эшләү дәверендә язмыш тарафыннан кыерсытылган кешеләрне шактый күргән иде ул. Ләкин биредәге Сталин

заманыннан калган агач баракларда, яртылаш жиргә сенгән тынчу куышларда күргәннәре аны шаккатырды. Нишлисен, шәһәрнен ин төпкә утырган куныгы иде шул бу. Элегрәк сәвит власте түбәннәрне, кимнәрне күпмедер дәрәҗәдә исәпкә алып, аз булса да кайгыртуны тиеш санаса, хәзер исә, һәркем үз жаен үзе карарга тиеш, дигән кагыйдә алга сөрелгәч, көчсезләр, зәгыйфьләр бөтенләй игътибарсыз калган иде. Аягы-кулы корышып, күзле бүкән рәвешендә биләүдә яткан алты яшьлек бала, анын хәсрәтеннән күзләре унып, иртә картайган ялгыз ана дисенме; ата-аналары эчүгә сабышып, ач утырган корчангы сабыйлар, бүлмәсе буйлап сузылган бауларга тотынып кына йөри ала торган, бөтен тәне туктаусыз калтыранган, бердәнбер улы әллә кая китеп юкка чыккан ялгыз карчыклар дисенме...

Нуржиһан һәммәсен тынлый, күргән-ишеткәнен көрән тышлы кенәгәгә теркәп куя.

Чын күнелдән теләсән, көченне, вакытынны кызганмый артларыннан йөрсән, була икән. Мескен анага профсоюз аша түләүсез юллама алып, баласы белән бергә санаторийга жибәрделәр. Калтырча карчыкка бушлай дарулар, азык-төлек табып бирделәр. Корчанды сабыйларны хастаханәгә дәваланырга салдылар.

Анысында тагын врачлар зарланырга кереште: хастаханә бик хәерче, балаларга ни уенчык, ни китап, ни телевизор юк икән. Җәүһәрия "Культторг" директорына хат язып, барып сөйләште, китабын бүләк итте. Анын житәкчесе бик мәрхәмәтле кеше булып чыкты: больницага телевизор, дәфтәрләр, буяулар, уенчыклар илтеп бирделәр.

Ә бер баракнын бүлмәсендә тагын тетрәндергеч хәл: ишек ачылуга, идәндә яткан хатын-кыз заты, терсәкләренә калкынып, Нуржиһанны карашы белән көйдергәндәй итте. Сызлану, гажизлек, өмет чаткысы, шул ук вакытта өметенен акланмавыннан курку да чагыла иде анын күзләрендә. Күрәсен, көтмәгәндә килеп кергән яңа кешедән ул үзенен хәлен яхшыртуны өмет итә иде.

—Нишләп идәндә ята ул?—дип чиксез гажәпләнеп сорады Нуржиһан ишекне ачкан өлкән яшьтәге ападан.

Балачактан зәгыйфь бу кызнын караваты бик жайсыз булган икән, шуннан егылып, бот сөяген сындырган. Тәүлекләр буе кузгала алмый астан карап ят әле! Ата-анасы шактыйдан вафат, киез итек фабрикасында эшләп, пенсиягә чыккан апасы белән икәү генә яшиләр, унайлы караваm алырга берничди мөмкинлекләре юк икән.

Җәүһәрия жәмгыять исеменнән үтенеч хаты язды да үзенен китабын да кыстырып, бер кунакханәнен директоры янына китте.

Берничә көннән Нуржиһан әйләнеп килгәндә, теге гарипнен өендә бәйрәм иде: кунакханәдән машина белән ике егет килгән, унайлы караваm, әйбәт юрган-жәймәләр китергәннәр, бөтенесен жайлап урнаштырып, гарипне күтәреп алып, жылы, чиста урынга яткырганнар. Мескенкәйнен йөзенә нур ингән, күзләреннән елмаю яктысы сирпелә иде.

—Синен белән без башкарганны хөкүмәт кешеләре эшли алмый, Нуржиһан апа,—диде Җәүһәрия сонрак бу хакта сөйләшкәндә.—Аларга монын ишене кушсанмы? Ин элек хөкүмәттән бина сорыйлар, ул бина эченә өстәл-урындык, шкаф, компьютер, факс, ксерокс... Аннары күпме кешегә эш хакы—начальнигына, секретарена, бухгалтерына, жыештыручысына, каравылчысына... Мондый эшләр хөкүмәткә беләсенме күпмегә төшәчәк? Ә безнен аннан бер тиен дә алган юк.

Нуржиһаннын ниләр эшләп йөрүе хакында сүз халыкка тиз арада таралды, урамда туктатып, әнә теге фатирда фәлән кеше тилмереп ята, бусында бүген ашарларына юк, дип әйтә торган булдылар. Ул әйткән бер жиргә керә, күргәннәрен көрән тышлы дәфтәренә язып куя иде. Нәкъ шул рәвешле ул Насибәгә юлыкты да инде...

—Милициянен тулай торагында өч баласы белән бер бүлмәдә яшәп ята, ни ашарларына, ни киярләренә юк,—дигәннәр иде Нуржиһанга анын турында.

Тормышның авырлыгы Насибәнең буй-сынын алга авыштырып, аска тартып куйган иде. Корсагы бүлтәеп чыккан, базык гәүдәле, төссез киемле бу хатынның яшен дә беренче карашка белеп булмас иде. Ә ана исә нибары утыз биш кенә икән әле. Ундүрт яшьлек кызы белән ун яшьлек улы мәктәпкә йөри, ә менә җиде яшьлек Марс Нурҗиһанны бер күрүдә сагайтты: йомры кара башлы, каймак битле бу малай туктаусыз тегендә-монда чаба, әнисен тарткалый, әйткәнне ишетми. Күренеп тора: тыңлаусыз гына түгел, мингерәү иде балакай.

Бүлмәдә рәтләп сөйләшеп тә утырырлык түгел—караңгы коридорга чыгып, аягөсте торырга туры килде. Насибәнең җилсенгән күз кабаклары эченнән төсе унган күзләре монаеп карый, ул, ике учын корсагы өстенә куыштырган—эче зурлыгы күзгә ташланмасын дип шулай гадәтләнгән иде булса кирәк. Балаларга хөкүмәттән пособие-фәлән бирелми, Насибә үзе шушы тулай торакта җыештыручы булып эшли, шунын акчасына көн итәләр икән.

—Бер җыештыручының эш хакына ничек жан асрыйсыз соң сез?—дип сорады Нурҗиһан шаккатып.

—Җан биргәнгә җүн бирә, Ходай тәгалә ярдәменнән ташламый,—диде Насибә.—Тулай торактагы бөтен буш шешәләрне мина калдыралар. Кибет тирәләреннән дә җыеп кайтам.

Буйдак милиционерлар торагында шешә бушамый тормас торуын. Ләкин аның белән генә мантып буламыни?

Ә Насибә зарланмый, сыкранмый, берәүне дә гаепләми. Чөнки закон буенча үзенә бернинди ярдәм тиеш түгеллеген аңлый.

—Атасы булмаса, балаларга пособие бирелер иде,—дип дәвам итте Насибә.—Ә болай, аталары карарга тиеш, дип кенә җибәрәләр. Квартир чиратында тора идек, аннан да сыздылар. Милициядә эшләүчебез юк бит инде хәзер.

Нурҗиһан Насибәнең ире турында сорарга кыенсынып тора иде, үзеннән-үзе җай чыкты.

—Ирең кая соң? Балаларын бер дә кайгыртмыймыни?

Насибәнең хәләле милиционер булган икән, үзбәк кешесе. Коммунистларның сәясәте шундый иде бит: үзбәкләрдә совит власте урнаштырырга татарларны җибәрәләр, ә Татарстанда тәртип сакларга Үзбәкстан белән Казакъстаннан килгән егетләрне хуп күрәләр иде. Халыкны бастырып тотарга шулай кулайрак булгандыр, чөнки килмешәкләрнең монда туган-тумачасы да, кода-кодагые да юк, беркем өчен дә үзәкләре өзелми. Командирларның авызына карап кына эш итәләр.

Эшләр элеккечә барса, бу гаилә яна фатирга күчәр, капитан Турсункаев тиз арада майор булыр иде, мөгаен. Әмма дөнья кинәт үзгәрде, СССР таркалды, Үзбәкстан мөстәкыйльлек алды, Татарстан да суверенитет игълан итте. Болар барысы да Насибәнең бәхетсезлегенә булган икән. Капитан Турсункаев, үзенең үзбәк икәнлеген исенә төшереп, туган якларына тайган, саубуллашканда, дөрес, хатынын, балаларын кайтып алырга вәгъдә иткән. Ләкин менә ике ел инде хәбәре юк, әллә исән, әллә үлгән, Насибә белми дә.

—Нишләп алай икән?—дип гаҗәпләнде Нурҗиһан.—Үзбәкләрне бик бала җанлы дип сөйлиләр бит. Яшь чакта татар кызларына өйләнүне олы дәрәҗәгә санныйлар, олыгаеп, акылга утыргач кына, үзбәк белән яшиселәре килә башлый, диләр. Әмма балаларын ташламыйлар, татар хатыннарын аерып, куып чыгарсалар да, ул-кызларын үзләрендә калдыралар, диләр иде.

—Төрлесе бардыр инде алар арасында да,—диде Насибә сабырлык белән. Аның алгы теше сынган, авазлар сакауланып чыга иде.

—Алиментны да килмиме?

—Үзбәкстандагы кешедән алиментны ничек юллыйсың? Әлегә андый закон чыкмаган, диләр.

... Насибә сабыр гына түгел, гаҗәеп кешелекле, тырыш та булып

чыкты һәм чын мәгънәсендә Нуржиһанның ярдәмчесенә әверелде. Иртән тулай торагын юып чыгара да җәмгыятькә килә. Нуржиһан аны гадәттә урын өстендә ятучы ялгыз хасталар янына җибәрә. Насибә аларга азык-төлек илтә, йомышларын йомышлый. Берзаман шулай кыш буе өennән чыга алмый чирләп яткан карчыкның бүлмәсен юып чыгарырга кирәк булды. Бик иске йортта, су-фәлән кертелмәгән, йомышка ишегалдына йөри торган фатир иде бу. Күршеләре ашарына кертә икән, ә бүлмәсен тазартырга алынмаганнар. Социаль-тәэминат эшчеләре ишекне ачалар икән дә, борыннарын уч белән каплап, тиз генә кире шапылдатып ябып куялар икән. Якындагы мәктәпнең өлкән классында укучылардан үтенеп караганнар, һичкем ул бүлмә эченә керергә риза булмаган. Насибә барды, әбинең өен тазартты, үзен юындырды, урын-җирен юды. Хәер җәмгыяте өчен алыштыргысыз кеше булып чыкты Насибә.

Ул арада җәмгыятькә бүлмә дә бирделәр. Дөрес, шәһәр хуҗалары кушуы буенча түгел, әлеге дә баягы шул китапханәче Халидәнең тырышлыгы белән, мәдәният йортының аскы катыннан. Нуржиһан өчен җәннәт капкалары ачылгандай булды. Монда аның үз көе, үз тәртибе, үз дөньясы. Кешедән җыйган кием-салымны, авылдан килгән азык-төлекне сакларга да урын бар. Рәхим итегез, тормышы ким, күңеле китек мескен-бичаралар! Бу бусагадан атлап керсәгез, тәнегезне капларлык кына булса да кием табылыр, бүген ботка пешереп ашарга ярма бирелер! Өзелгән, сынган минутыгызда Нуржиһан сезнең тормышыгызны ялгап җибәрер. Юанырсыз, хәл алырсыз, аннары алдагысын карарга үзегездә көч табарсыз, иншалла.

Әгәр дә берәр тылсымчы Нуржиһанга: “Ни телисең, әйт кенә! Һәммәсен бирәм!”—дисә, ул, мөгаен: “Бөтенесе шул килеш торсын! Үзгәрмәсен генә!”—дип җавап бирер иде.

Морадына ирешкән иде ул. Шөгыле күңеленә юаныч бирә, берәрсенең хәлен җиңеләйтсә, җанына сары май булып ята. Шуңа өстәп үзенең дә хәле яхшырды, тиен санаудан котылды.

—Мин сиңа эш хакын үземнекеннән артык куям,—диде Җәүһәрия.

—Ничек алай? Ярамас бит!—дип каршы төшеп карады Нуржиһан.—Гади эшче президенттан күп ала димени!

—Беренчедән, син гади эшче түгел, башкаручы директор! Директор! Онытма!

—Һи! Сүз өчен генә бит инде ул!

—Бер дә сүз өчен түгел! Эш өчен. Икенчедән, кагыйдә буенча, башкаручы директор президенттан күбрәк ала, чөнки төп эш ана өелә.

—Төп эше дә синдә бит аның!

—Карышма! Бу сиңа пенсияңне арттыру өчен шулай кирәк! Ә пенсия ул гомерлек!

Эшләвенә бер ел тулгач, Нуржиһан өенә кайтып, сумкасыннан кухня өстәленә бер өем кәгазь акчалар чыгарып салды. Моны күргәч, ире Зыятдин үз күзләренә үзе ышанмый торды:

—Болар барысы да синең үзеңә генәме соң?

—Ноябрь өчен эш хакы белән премия бу миңа. Иртәгә пенсияне яңадан чутлатырга барам.

Хәзерге көндә иң зур пенсия һәм әйбәт кенә эш хакы ала, эшендә исә, күпләрне куандырып, рәхмәтләр ишетә Нуржиһан. Бәхет өчен аңа ни кирәк тагын? Гел шулай гына булып торсын иде!

Сызуын тәмамлагач:

—Туктале, кичә теге бизнесменнар китергән матур кофталарны журналга язып куймадым бит мин,—диде ул үз-үзенә.—Кая соң әле накладнойлары? И, ходаем, югалтмаган булсам гына ярар иде! Бер генә дә хәтерем юк. Нишләргә инде бу баш белән...

Нуржиһан, гадәтенчә хәтере юклыкка сукранып, иелеп, өстәлләге кәгазьләрне актарды. Кирәген таба алмагач, уфылдап торып басты, тулырак, әмма ыспай гәүдәсенә ифрат килешеп торган ак якалы зәңгәр халатын төзәткәләде. Киштә янына барып, нәрсәдер алырга үрелгән иде, өстән

бер-берсенә кигезелгән кайсы кара, кайсы күк дүрт-биш эшләпә килеп төште.

—Уф, урын житмәде инде шушыларга!

Нуржиһан эшләпәләрне идәннән алып, тузанын сөрткәләде.

—Нинди әкәмәт нәрсәләр кия бу банкирлар, ә? Бигрәк хикмәтле инде. Ник китергәннәр инде безгә боларны? Кемгә бирермен микән инде?

Хикмәт шунда, ике көн генә элек саклык банкысыннан алты тартма кием-салым китергәннәр иде. Җәүһәрия төрле банкларның житәкчеләренә хатлар яза, үзегездән калган кием-салымны бирегез әле, без аны мохтажларга бушлай өләшәбез, ди. Анынча, банкта эшләүчеләр үзләрен бик пөхтә йөртә, заманча киенә, алардан калган әйбер янага биргесез булырга тиеш. Һәм, чыннан да тартмалардан затлы костюм-күлмәкләр, мул итеп тегелгән плашлар, бөтенләй диярлек кыршылмаган туфли-ботинкалар килеп чыкты. Алар янында менә бу хикмәтле эшләпәләр дә бар иде.

—Безнең бомж-сукбайларга төс түгел шул болар,—дип сөйләнде Нуржиһан һәм, үрелеп, эшләпәләрне янә өске киштәгә куйды. Аннары аскысыннан зур гына бер төенне өстәлдәге язулар өстенә куеп, чишеп җибәрде. Аннан кыз балаларга яраклы аллы-гөлле бәйләгән кофталарны берәмләп алып, чут төймәләрен шудыра-шудыра санарга кереште:

—Берәү, икәү, өчәү... кырык алты... Кырык алтыны китергәннәр иде шул... Ә кем китергәнен белмим бит инде накладной булмагач... Нишләп шундук журналга теркәп куймадым инде барсын да... И-и, бу башны!..

Ишектән, Марсны кулыннан өстерәп, Насибә килеп керде.

—Баскычлар буйлап чаба да чаба, һич тоттырмый!—диде ул сулышына кабып.—Ярый, Халидә төшеп килә иде, ул эләктереп алды.

—Син миңа әйтмәдең бит әле: кафега бардыңмы-юкмы бүген?—дип сорады Нуржиһан.—Җәүһәрияне күрдеңме? Ул сине шунда көтәм дигән иде бит!

Насибә ак калай белән тышлаган ишекне япты да, аркасы белән шуңа терәлеп, кычкырып елап җибәрде:

—Анда... Анда... Кара бәхетсезлек ул кафеда!..

* * *

Ул сулкылдый, мышкылдый, нидер мыгырдый, ни сөйләгәнен һич аңлап булмый иде.

—Аркан белән тимергә сыланып торма ичмасам,—дип, дер-дер калтыранган хатынны мәжбүр итеп диярлек эчкә алып кереп, урындыкка утыртты Нуржиһан. Аннары кире борылып, чыгып чабарга талпынган малайны джинсы чалбарыннан эләктереп алды да, ишекне эчтән бикләп куйды.

—Ай-һай, банкирлар китергән костюм ничек килешкән сиңа, Марс, ә? Бай малае булгансын бит! Мәле, чын банкир бул! Акча сана!—дип Марсның кулына чут тоттырды ул.—Уйна шуның белән! Карале, төймәләре ничек йөгерешә!

Малай чутны әвеш-тәвеш китерергә кереште, бүлмә тавыш белән тулды. Нуржиһан янә Насибәгә борылды:

—Ни булды? Нинди фаҗига?

—Кызым... Лиана...

—Нишләгән Лианаң?

Насибәнең кызы Лиана быел унбишне тутырып, үзен бик зур үскәнгә саный башлаган иде. Ул инде акылны әнисеннән түгел, үз ишләреннән ала. Ишләре исә—иске йортларда, мохтажлыктан башы чыкмаган эшче гаиләләрдә үскән башка кыз-малайлар. Күзен ачуга авыр тормышның ачысын тоеп, бай яшьтәшләреннән көнләшеп һәм аларга үчләнеп үсеп килгән яшь буын иде бу. Сәвит заманында, яшьләргә, "тырышкан табар",

“намуслы хезмәт бәхет китерә”, “ватан өчен, якты киләчәк өчен яшәргә кирәк”, дигән ышаныч дөнгечләп сендерелә иде. Ләкин менә соңгы елларда бу ышаныч язгы кояшта эреп аккан боз кебек юкка чыкты. Баксаң, эшләп кенә баеп булмый икән бит! Завод-фабрикаларда айлар, еллар буе эш хакы түләнмәү дә бу хакыйкатьне раслый иде. Ә акчасыз кеше кешемени ул? Һәм зур йортларның ишек төпләрендә җыелган үсмерләр арасында сүз гел бер тирәдә әйләнә иде: ничек акча табарга?

Яшьләр күзәтә, күрә: берәүләр алып-сатып баеый, икенчеләр урлап йә талап. Намуслы ананың баласы Лиана урлау-талау юлына баса алмый, сәүдә итәргә кулыннан килми иде. Алай да, журналлар укыштырып, телевизор карый торгач, ул үзенә бер юл тапкан, алдына ачык максат куйган иде: төнге клубта биюче булырга. Стриптизерша ягъни. Шундый бер урынга барып, үзен күрсәтеп, сөйләшеп тә кайткан иде инде ул. Анда мактаганнар, буең зифа, тәнең сыгылмалы, тик яшең генә җитми, унисигезең тулгач килерсең, дигәннәр.

Хәзерге вакытта Лиана, якты сәхнәгә менәчәген уйлап, шома колгага елан кебек уралачак сәгатьләрен көтеп яши, бай егетләрнең аның укалы трусигына долларларны йөзәрлекләп кыстырачакларын күз алдына китереп, хыял диңгезендә йөзә иде. Ә нигә хыялланмаска? Экраннардан, журналлардан, чынаяктай ак тешләрен елтыратып, ымсындыргыч тәннәрен җемелдәтеп, тасыраеп карап торган “стриптизерша”лардан, “топ-модель”ләрдән кай төше ким аның?

Чыннан да, Лиана үз яшеннән өлкәнрәк күренә, көньякның баллы чиясе кебек иртә пешеп килә. Чәчләре чем-кара, йөзе ап-ак, күзләреннән көньяк кояшының эссесе сирпелә, ә буй-сынында гамьсез иркәлек. Әгәр берәр назлы мәченең күзләре кара булса, Лиана нәкъ шуңа охшар иде.

Кызының хыялларын Насибә белә. Бу хакта Нурҗиһан белән дә сөйләшкәннәре булды. Шунысы гаҗәп, авылда туып-үскән, гомере буе әдәп кысасыннан чыгуны күз алдына да китермәгән апа, кыз баланың мондый планнары турында ишеткәч, артык аптырап калмады. Чөнки замана бураннары аның да күңеленә шактый кар көртләре өйгән иде инде. Исерек ир-ат каршында чишенеп бию—кыз бала язмышы өчен һәлакәт, билгеле. Ата-бабадан килгән гадәт-кагыйдәләрдән чыгып уйласаң... Ә заманча карасаң? Бию гаепмени? Күпме алар—кеше алдында шәрә бот-чатларын башыннан югары чөеп биючеләр? Шуның белән макталучылар, бөтен илдә дан алучылар? Алар турында начар уйларга ни хакы бар Нурҗиһанның? Ә бәлки, алар сәхнәдә генә шулай кыланалардыр, аннан төшкәч, озын җиңле күлмәк киеп куялардыр да, яннарына бер ир-атны да якын китермиләрдер?

Шулай уйлады Нурҗиһан һәм Насибәне, кызына каты бәрелмә, дип үгетләде.

—Нихәл итәсең... Заманы шундый... Үзенә җитәрлек кенә акча эшләсә дә сиңа җиңелрәк булачак бит... Тик бозылып кына китмәсен...—дигән сүзләр мыгырдаган иде ул.

Морадына ирешү өчен Лианага нидер майтару, тырышу-тырмашу таләп ителми, фәкать көтәргә генә, ягъни, урыс әйткәнчә, ничек тә булса “вакытны үтерергә” кирәк иде. Шуны белгәнгә күрә Лиана укуында, “стриптиз колгасы”на уралган биюче кебек, “өчле” тирәсендә болгана, җәен исә бөтенләй шөгыльсез кала иде. Бу арада, эч пошканнан, кайчакта әнисе янына кафега баргалыйлар.

Инде менә Насибәнең үзгәләнгәнен күргәч, Нурҗиһанның күңелен шом басты: әллә шул төнге клубка барып берәр афәткә юлыкканмы? Алай булса, Нурҗиһан да гаепле булып чыга түгелме? Ул бит Насибәгә акыллы киңәш бирә алмады...

—Әйт инде, ни булды Лианага? Кунарга кайтмадымы әллә? Кайтмаса, беренче генә тапкыр иптәш кызларында куңуы түгел! Кайтыр!—дип Насибәнең бер җиңе кызыл, икенчесе кара бик модный кофта кигән иңнәреннән тотып селкеде ул.

—Эт тешләде!..

—Кайчан?

—Кичә көндез...

—Нык таладымыни?

—Тубыгын канатты,—дип, Насибә кара атлас итәген кайтарып борынын сөртте.

—Кайсы төштә? Нинди эт соң ул?

—Кафенең ишегалдында...

Әйе, анда иясез этләр йөргәнен күргән иде Нурҗиһан. Ташландык җирдә аларсыз буламыни.

—Тубыгыннан дисең... Матур чалбарлы костюмын кимәгән идемени Лиана?

Гадәт буенча, банктан килгән тартмалардан иң элек Насибә үзенә, балаларына яраклыны сайлап алган иде. Чәчкәле креп-жоржеттан тегелгән җәйге чалбар-кофтаны, кызыл туфлиләрне шундук Лианасына кигезеп тә куйды ул.

—Шуны кигән иде,—диде Насибә. Ул инде бераз тынычлана башлаган кебек иде.

—Шулай булгач, чүпрәк аркылы гына әләктергәндер бит?

—Чак кына сыдырылган шикелле иде. Бака яфрагын төкереклэп ябыштырып куйдым да, шунын белән бетәр, дидем. Шуннан участковый килеп чыкты...—дип тагын еларга керешге Насибә.

—Ай алла, килсә ни? Участковыйның беренче генә килүе түгел бит!

—Теге чакта ул миңа кафе стенасыннан кафель каерып алырга кушкан иде бит...

—Соң?

—Кая, күпме куптардын, мин машина белән килдем, ди.

—Соң сиңа Җәүһәрия әйтте бит инде, сөйләшеп тә торма син аның белән, дип!

Насибә башын күтәрде дә яшьле күзләре белән Нурҗиһанның йөзенә текәлде:

—Мин сөйләшмәсәм... Ул әйтә!.. Аның авызына бөке тыккан кеше юк бит!..

Нурҗиһан ни диярга белми аптырап калды. Кафенең бинасын көпә-көндез кем иренмәсә шул талап ятуга бик җаны көйгән Җәүһәрия милиция начальнигына хат язган иде. Мондый җинаятьне туктатуны, тәртип урнаштыруны таләп иткән иде ул. Шуннан соң участковый килгән, кафены карап чыккан, аннары Насибә янына килеп:

—Синең монда бер эшең дә юк икән, тик торганда менә бу стенадан кафельны ватмый гына куптарып, әйбәтләп өеп куй әле,—ди икән.

—Миңа кафель кирәкми,—дигән Насибә.

—Үзенә кирәкмәсә, миңа булыр,—ди икән теге.

Насибә кайтып бу хакта сөйләгәч, Җәүһәрия шулхәтле гаҗәпләнде ки, милиционерның оятсызлыгына ачулана да, нәфрәтләнә дә алмады.

—Тәртип саклаучы ачыктан-ачык караклыкка өндәмәс, шаяртуы гынадыр, бүтән сөйләшеп тә торма син аның белән,—диде дә шуның белән бетерде.

Баксаң, бер дә шаяртмаган, чынлап әйткән икән теге йөзе кара!

Алай да Насибәнең бу хәтле өзгәләнүе берниндн мантыйкка да сыймый иде. Нииндидер ахмак әйткән сүз өчен ике көн елыйлар димени?

—Нәрсә син шүрәле кебек былтыр кыстырганга быел кычкырып утырасың?!—диде Нурҗиһан.—Тьфу диген дә, өстенә басып сыт! Шуның белән оныт!

Ул, ничек төкереп, сытарга кирәклеген күрсәтеп, йомшак башмагы белән кыршылган линолеумны ышкыштырды.

Әмма Насибәне юата алмады.

—Мин карак түгел сиңа, дип авызымны гына ачкан идем... Әйтмәгән

сүзе калмады жирәнгечнең,—дип тагын сыгылып төште ул.—Гомерем буе милиция арасында яшәп, андыйны ишеткәнем юк иде.

—Күргән-белгән кешең түгелме?

—Яна кеше бугай ул. Мөгаен, әфганда сугышкан адәмдер... Теле пычрак, үзе псих... Син, ди, себерке, ди. Кызың фахишә, ди. Мин аның, ди, шушы бинада егетләр белән себерелгәнен белмим, дип уйлыйсыңмы әллә, ди...

Нуржиһанның өстенә кайнар су коелгандай булды.

—Кит аннан!—диде ул.—Җәүһәрия килсен генә, хәзер начальникларына барачак, кыз баланың намусын пычраткан өчен утка бастырачаклар ул кабәхәтне! Ә син җебеп утырма, үче алыныр!

Насибә башын күтәрмәде, сыкранып сүзен дәвам итте.

—Лиана елый башлады. Мин әйтәм тегенә, мыскалламаган ефәк кебек балага пычрак атарга ничек телең корымый, дим... Әнә, дим, иясез этләрне карар идең ичмасам, баламны тешләде берсе, дим. Җитмәсә син бәгырьгә ук кадыйсың... Ана, ди, кадаласы кадалган инде... Котырасы гына калган, ди...

Нуржиһан хәле китеп, өстәл янындагы урындыкка утырды.

—Чыннан да, иясез эт тешләгәч, кызыңны шундук врачка күрсәтергә кирәк булган шул,—диде.

Насибә ияген какты.

—Алып бардым, больницага салдылар Лиананы.

—Шулай укмыни? Эт тешләгәннән уколларны барып кына калаталар бугай бит.

—Андый очракта корсаклы хатын врач күзәтүе астында булырга тиеш, диделәр.

—Нинди хатын?!

Насибә почмакка караган хәлдә карлыккан тавыш белән:

—Дүрт айлык корсагы бар икән Лиананың,—диде. Моны гүяки ул түгел, күзгә күренмәс радио сөйли иде. Шул хәтле күңелгә кермәслек, башка сыймаслык иде бу сүзләр.—Аборт ясатырга соң инде, диделәр.

—Үзең бер дә сизмәгән идеңмени соң?—дип өзгәләнде Нуржиһан гаҗиз тавыш белән.

—Соңгы вакытта ашау яхшырып киткән иде бит... Шуңа көрәядер, дип уйладым...

—Син туктале, елама. Яшь түгүдән ни файда. Егете бар, димәк. Аның ата-анасы белән киңәш итеп карарсың. Әчләрендә җаннары булса, үз каннарын кайгыртмый калмаслар.

—Исерекләр!.. Юньсезләр!.. Бетләре дә юк!—дип янадан үксергә тотынды Насибә.

Аның ярсып үксүеннән, Марсның чут төймәләрен шакылдатуыннан Нуржиһанның тәмам хәле киткән, колагы чыңлый иде. Ишекне тышкы яктан байтактан шакыйлар иде, ахрысы, инде аяк тибеп дөбердәтә башладылар. Нуржиһан көчкә сынын җыеп, аягына басты да, башы әйләнүдән чайкалып, ишеккә юнәлде.

* * *

Карангы коридорда керле саргылт плащ, ямьшәйгән күксел эшләпә кигән, юынмаган, кырынмаган, бөрешкән бер адәм басып тора иде.

—Синмени әле бу, Семен,—диде Нуржиһан, йолкыштан аңкыган истән котылу өчен ихтыярсыздан йөзен читкә борып.

—Исәнме, Нурзиган апа. Бүген килергә кушкан идең. Чалбар булыр, дигән идең...

—Ие шул, ие. Банктан килгән әйберләр арасында бик матур кәчтүнчалбарлар бар. Сиңа зуррак инде алар зуррагын. Балагын бөкләп киярсең, билен тартыбрак буып куярсың. Бил каешы да әзерләп куйдым. Бик

матур плащлар бар. Бу каткан кожанканны ташласаң да була. Ялт иткән эшләпәләр бар әнә, теләсәң алырсың. Шәһәр урамнарын балкытып узарсың бер. Нинди бай килә икән, дип, артыннан шаккатып карап калырлар.

—Размеры туры килсә, әйбәт булыр иде дә бит...

—И-и, сиңа мәктәп баласының киеме дә ярый. Озынрак булса, чалбар балагының очын бераз бөкләп кенә куярсын,—диде Нурҗиһан йолкышның алга сыгылган арык гәүдәсен күздән кичереп.—Ашау җитми сиңа, Семен, ашау!

—Пешерә алмыйм бит,—кулларын алга таба сузды Семен. Аның күгелҗем бармаклары кәкрәешеп, тукмак булып оешкан, карарга куркыныч иде. Семен аларны килгән саен күрсәтә. Нурҗиһан эчкә узып, киштәдәге әйбер-караны актарырга кереште.

—Менә монда чиста майка да, трусик та, оекбашлар да табып куйдым,—дип сөйләнде үзе.

Бирегә килеп йөрүчеләр арасында аеруча кызганычлары, язмыш тарафыннан аерата нык җәберләнгәннәре бар. Күбесе явызлыгы, начарлыгы аркасында түгел, йомшаклыклары, кирәк чакта аяк терәп үз-үзләрен яклый алмаулары аркасында авыр хәлгә төшкәннәр.

Семенның да бөтен гаебе ныклык җитмәүдә, карусызлыкта, нәфессез-хөсетсез булуда иде. Илдә ип бар чакта әйбәт кенә яшәгән ул: заводта слесарь булып эшләгән, өйләнгән, квартир алган. Ләкин менә, болгавыр еллар килгәч, заводта да тәртипсезлек-башбаштаклык киткән, эшчеләр турында кайгырту беткән. Бер авария вакытында, пар казаны шартлагач, слесарьны цехка, кранны ябарга кертеп җибәргәннәр. Ә кран кислотага чумган булган. Шунда аның ике кулы да пешкән.

Семенны больницага салганнар. Ул арада завод тәмам таралган, эшчеләргә—чирлесенә дә, сәламәтенә дә—акча бирү беткән. Семенның шул ук заводта эшләүче хатыны баласы белән ач калган. Ачның ачуы яман, ди, хатын судка биреп, гарип ире белән аерылышкан, квартирны бүлешкәннәр. Семен ике бүлмәле квартирның кече бүлмәсенә күчеп, күрше белән яшәргә тиеш булган.

—Суд булдымы соң инде?—дип аның хәлен сораштыруын дәвам итте Нурҗиһан.—Өенә кайта алдыңмы?

Хикмәт шунда, Семен икенче тапкыр больницада ятканда, күршесе аны фатирдан сыздырып, тышкы ишекнең йозагын алыштырып куйган. Больницадан чыккач Семенны кертмәгән, әйбер-карасын баскычка чыгарып тондырган. Хәзер менә мескен гарип суд юллары буйлап законнан яклау эзләп йөри иде.

—Булды суд, булды...—диде Семен төшенке тавыш белән.

—Сине кире кайтаралардыр бит?

—Кайтарырлар, бар. Күрше көчле кеше. Көчленеке замана!

—Сине урамда калдырмаслар бит инде!

—Миңа башка җирдән бүлмә бирергә, дип язып куйдылар. Каян бирсеннәр аны? Кем бирсен?

—Шул кафеда кунып йөрисеңме һаман?—дип сорады Нурҗиһан.

—Аннан да кудылар! Кертмиләр! Эттән талаталар!

—Ай алла, Җәүһәрия синең хакта каравылчыларга әйтмәде микәнни соң? Бар әнә, баскыч астына чык та, өс-башыңны алыштыр, искеләреңне чүплек савытына ташлап китәрсең... Ул плащыңны да өстерәп йөрмә инде. Бу эсседә ничек чыдыйсыңдыр.

—Ансыз булмый! Кичләрен салкын.

— Ерак китмә. Хәзер Җәүһәрия килеп җитәр. Аның белән киңәшербез. Тиешле җирләргә тагын хат язар, бәлки, икәүләп шәһәр башлыкларына керә алырсыз... Гомер буе кафеда гына да яши алмассың...

—Бөтен өмет сездә генә инде,—дип сөйләнде Семен.—Үзем генә барып эләгә алмыйм шул мин аларга... Кабул итмиләр... Ишек төбендә утыручылары, монда буталып йөрмә, эшлә, морда кирпича просит, дип кенә төрткәләп чыгарып җибәрәләр.

Ул шулай, беләгенә киемнәр салган хәлдә, үзалдына сөйләнеп чыгып бара иде, ишектән аның каршысына, зур-зур өч кәрзин күтәреп, кызарынган-бүртенгән чырайлы ике ир-ат килеп керде.

—Хәер җәмгыяте шушындамы?

—Монда, монда. Ни йомыш?

—Ярдәм китердек. Ятимнәргә бирерсез. Бушлай. Кая бушатыйк?

—Менә монда куегыз,—дип Нурҗиһан почмактагы өстәлне күрсәтте, һәм андагы журналларны бер кырыйга шудырды.

Ирләрнең берсе кәрзиненнән өстәлгә куеп, өстендәге ак чүпрәкне ачты—анда ысланган тавык түшкәләре иде.

—Сез каян соң? Кош фабрикасыннанмы?

—Фабрикадан түгел, кооператорлар без. Урамда сата торган идек. Ә бүген сатарга рөхсәт бирмиләр, Мәскәүдән ниндидер түрә килә икән, урамнын ямен җибәрәсез, дип кудылар. Боларны озак саклап булмый бит, әрәм булмасын, дидек.

—Ә безне каян белдегез?

—Урамда хатыннар әйтте. Монда хәер җәмгыяте бар, килгән әйбернең валчыгын да әрәм итмиләр, бик гадел итеп, ятим-мескеннәргә өләшәләр, диделәр. Кая соң, бирәр документ бирәсезме?

—Барысын да бирәбез,—дип Нурҗиһан өстәл тартмасыннан бизмән тартып чыгарды, мөһер суккан кәгазьләр алды.

—Хәзер үлчибез. Марс улым, бир әле монда чутны!

Ул кәрзиннәрнең берсен бизмәнгә асып үлчәде дә, өстәлгә кәгазь җәеп, кызгылт-сары кетердәвек тиреле түшкәләрне шунда бушата башлады.

—Семенга да бирербез,—диде.—Тамагы туяр мескеннен.

Ирләр, тиешле документларын алып, өсләреннән тау төшкәндәй җинеләеп чыгып киткәч, Нурҗиһан уфылдап урындыгына утырды, ләкин шунда ук үзе өчен эшнең әле башланганын гына исенә төшереп, сынын турайтты.

—Боларны иртәгәгә калдырып булмый бит, саклар урыныбыз юк,— диде.—Бүген өләшеп бетерергә кирәк. Өй буйлап йөрми булмый. Бу Җәүһәрия кая югалды соң? Һаман кафеда сине көтә микән әллә?

—Мин бүген иртән Марсны врачка алып барган идем. Сәгать сигезгә. Чират зур иде, озак торылды,—диде Насибә.— Җәүһәрия кайткандыр инде, дип уйладым.

—Ни диде соң врач?

—Киләсе атнада больницага салырбыз, диде. Инде шуңа инвалидлык бирсеннәр дә тизрәк, пенсия түли башласыннар иде. Үзенә ашарга житәр иде ичмасам.

—Бирерләр, ник бирмәсеннәр,—дип юатты Нурҗиһан Насибәне.— Малаеннын тулы түгеллеге бер карауда күренеп тора. Бүгенгә син буш инде алайса. Тавыкларны өләшергә булышырсын. Кая соң, кул куйдырып тапшырырга исемлек әзерләп куйыйк.

Ул өстәл тартмасын ачып, кәгазьләр актара башлаган иде, алар арасыннан акчалар килеп чыкты.

—Бәй, кичә алган эш хакымны сейфка куймаганмын бит мин, монда тыгып киткәнмен,—диде Нурҗиһан.—Эштән кайтканда Муллаянга керәсе идем, акчаны үзем белән йөртәсе килмәгән иде. Тагын бутаганмын... И, бу башны!

Ул, күп нульләр төшерелгән акчаларны каршысына таслап салa-сала, пышылдап санарга кереште:

—Илле мен, йөз мен, тагын ун мен...

—Җәүһәрия кичә эш хакы бирдемени?—дип сорады Насибә. Аның тавышы кинәт карлыгып киткән иде.

—Әйе. Ике айга берьюлы бирде менә.

—Ә мина?

—Син кафеда бер генә атна утырасың бит әле. Эш хакын бер айлык итеп бирәләр. Ай узгач алырсың.

Нуржиһан, саташмаска тырышып, акчасын санавында булды. Башын күтәрмәде. Әгәр күтәрелеп караса, ул Насибәнең ияге ничек чөелеп, гадәттә тоныкк күзләрендә нинди хәтәр ут кабынганын күрер иде. Күрер дә тетрәнеп китәр иде. Ачтан шешенгән бәндә, ризык күрсә, нишләгәнен белми, тартып алырга үрелә, анын, үз-үзен белештермичә, гажизлектән зиһене чуалып, бер кыерчык ипи өчен кеше үтерүе ихтимал, диләр.

Фәкыйрьлек кеше күнелен, корт кебек, менә шулай кимерә, эчтән ашый, каралта. Әйе, Насибә үз-үзен тыя, кеше кулында күп акча күргәндә, кулларын корсагы өстендә кушырып, авырттырып кыса, кыска керфекләрен аска төшерә, карашын читкә төби, иреннәрен көчләп тибрәндереп:

—Аллага мен шөкер, жан биргәнгә жүн бирә,—дип гадәтләнгән сүзләрне әйтергә мәжбүр була иде. Эчендә ялкынланып ургыган көнчелекнен, ачунын, үченең эссесен тышка чыгармый түзә иде.

Ләкин кичә-бүген кичергәннәр анын ихтыярын сындырган, көчен алган иде шул. Керфекләре дә, теле дә, куллары да аңа буйсынмый, ул инде Нуржиһанга ташланып, анын алдында яткан бер өем акчаны умырып алырга тартылган иде.

Нуржиһан исә моны сизмәде:

—Менә, бик матур кофталар бар, Лианага сайлап алырсын,—дип сөйләнде.—Тавыкларнын да дүртесе сезгә булыр. Һәрберегезгә берәр. Ятимнәргә фарыз. Суыткычын бар, рәхәтләнеп ашарсыз.

Насибә сикереп торды да яшь аралаш:

—Акча кирәк мина! Акча!Акча!—дип кычкырды. Һәм әле кичә генә жәмгыятьтән алып кигән зәңгәр туфлиләре белән идәнгә тибенде.

—Әйе, акча бөтен кешегә кирәк шул инде ул,—диде ир кеше тавышы.

Алар сизми калганнар, ишектән ят ир кергән икән. Ачык зәнгәр күлмәк, бик пөхтә итеп үтүкләнгән куе зәнгәр чалбардан, гәүдәсе хәрбиләрчә төз, кулында сумка.

—Жәүһәрия Байбулатова бирсдә эшли идеме?—дип сорады ул.

* * *

Моргта эшне тәмамлап чыкканнар иде, Сашанын кесәсендәге пейджер зынлый башлады.

—Ә хәзер аэропортка киттек,—диде ул аны алып карагач.

—Ничек аэропортка? Мин милиция кешесе түгел! Ә бензинны кем сала?—дип карышып карады Даниф.

—Табарга туры килер.

Милиция каршында тел озайтып булмый. Харисның кесәсендәге соңгы акчаларга бензин салдылар да шәһәрдән аэропортка таба чыгып киттеләр.

...Пассажирлар залына барып керү белән, Харис аны әллә каян, ерактан ук танып алды. Ул тарафтан теге чактагы кебек үк ыжгырып котып жиле бәрә иде сыман. Шушындый эссе көндә дә кара күлмәк кигән, түгәрәк кара сакал, кара күзлек, хәтта кулындагы олы сумкасы да кап-кара. Самолетка утырырга әзерләнеп, регистрация өстәленә таба тезелгән чиратта басып тора. Жәүһәриянең пары, жәмәгате, гомер юлдашы.

Ләкин нинди юлдаш булсыннар алар? Нишләп берсе морг дигән салкын базда ята да икенчесе монда, йөзәрләгән халык арасында, кояшлы зәнгәр күккә күтәрелергә ашкынып йөри? Ерак юлга чыккан кешене хатыны озата килә бит гадәттә... Әллә...

Ә нинди пөхтә, ыспай, озын, төз сынлы үзе, чын заман кешеседәй горур, хәтта бераз тәкәббер басып торышы. Чәчен, сакал-мыегын көн саен затлы шампунь белән юа торгандыр әле, кыйммәтле лак белән катырадыр—шоп-шома, ялтырап тора. Анын тирәсендә сизелер-сизелмәс кенә борынны иркәләп французлар ясаган ислемай исе таралалыр. Әйе, мондыйларга тора салып кына якын килү дә, урамда туктатып, сәгать

ничә яисә бу урамга ничек узарга, дип сорау бирү дә мөмкин түгел. Ә бит ул үзен шагыйрь дип исәпли, шигырьләре "Эдуард Бакиров" имзасы белән урыс гәзит-журналларында басылып чыгып тора. Бу каткан кара кисәүдән ничек шигырь саркый ала икән? Шигырь—нур бит ул, чаткы бит ул, һич булмаса җылы дулкын бит ул! Шагыйрьнең була ялкын булып дөрләгәне, очкын булып чәчрәгәне, була хәтта ачы төтен булып күзгә кергәне. Ләкин бозлы кисәү шагыйрь түгел инде ул... Шулай уйлады Харис.

Баксаң, кара кисәүгә охшаган шагыйрьне күзәтүче бер ул гына түгел икән. Әнә, ике ягына ике таза егет килеп бастылар:

—Читкәрәк китик әле.

Ул кара күзлеге аша аларның әле берсенә, әле икенчесенә борылып карады. Куе кара төк арасындагы юка иреннәре кысылды, ләкин бер сорау да бирмәде. Әллә шушылай буласын алдан белеп торган инде?! Сүзсез генә егетләргә иярде. Алар тәрәзә янына барып бастылар. Саша да, Харис та аларга якынрак килде.

—Паспортыгыз... Фамилиягез, исемегез?—дип сорады егетләрнең берсе.

—Анда язылган.

—Ә сез үз авызыгыз белән әйтегез.

—Эдуард Артурович Букштейн.

—Сезнең хатыныгыз...

—Җәүһәрия Байбулатова,—диде Эдуард коры гына.

—Сез кая очасыз?

—Мәскәүгә, аннан Тель-Авивка. Израильгә.

—Хатыныгыз сезне озатырга килдеме?

—Юк. Күргәнегезчә.

—Хәзерге вакытта кайда ул?

—Белмим.

—Сез бергә яшисезме?

—Мин бирегә, Россиягә кайткан араларда... Сез мина ни булганын әйтәсезме, юкмы?—дип кызып китте ул ниһаять.—Кешенең шәхси тормышына тыгылыр өчен нигез булырга тиеш.

—Хәзер әйтербез. Сезгә безнең белән барырга кирәк булыр.

—Кая? Ник?!

—Танып белергә кирәк булыр.

—Нәрсәне?

—Опознаниенең нәрсә икәнен беләсезме?

—Опознаниега?! Ничек? Кемне?

—Баргач күрерсез.

—Сез... кем турында?.. Әллә... Жаннамы?..

—Сезнең шундый шигегез бармы?

—Сез нәрсә? Көләсезме әллә? Көлә торган сүзме? Әйдәгез тизрәк! Ул башын иде дә, үзалдына, ярымпышылдап:

—Шулай булыр, дигән идем аны...—диде.

—Ничек булыр, дигән идегез?

—Яхшылыкка илтмәс, дигән идем. Тыңламады! Бер сүземә дә колак салырга теләмәде... Ә билетны нишләтергә!

—Бирегез. Тапшырырбыз.

—Алайса, әйдәгез тизрәк!

Ул зур, ләкин буш, җинел сумкасын эләктереп алды да, ишеккә ташланды. Оперативниклар аның артыннан йөгерә-атлый иярделәр.

—Ну, гуд бай,—диде Саша Харис белән Данифка.—Ярдәмегез өчен рәхмәт. Мин хәзер үзебезнекеләр белән китәм.

—Ә без бирегә ник килгән идек соң?

—Кем белә бит кешенең мондый очракта ни кыланасын. Коралды булуы ихтимал иде, каршылык күрсәтүе. Мин биредә бер дә артык булмадым. Китердегез, рәхмәт. Очрашырбыз әле!

Ул шулай дип кулын болгады да төркем артыннан йөгерде.

* * *

“Ничек дип әйтте әле ул?—дип уйланды Харис Данифның машинасына утырып кире шәһәргә кайтканда.—Мин Россиягә кайткан чакларда бергә яшибез, диде. Димәк, ул анда, Израильдә, озаклап яши булып чыга”. Монда кайткач кына бергә, имеш. Ә бергә микән? Бүгенге иртәдә ул кайда иде дә, хатыны кайда иде? Моны ничек аңларга?

Тагын ни диде әле ул? “Шулай булыр дигән идем”,—диде. Әллә... фаҗига буласын алдан чамалаганмы?

Әйе, аларның аерым булулары бик аңлашыла, бик табигый. Ә менә бергә яшәүләрен Харис һич кенә дә күз алдына китерә алмады, аңлата алмады.

Җәүһәриянең уйламыйча кылган гамәлләре бәла-казага сәбәп булгалый иде шул. Аяк астындагыны күрмичә, күккә карап, үзенең татлы хыялларына чумып, ашкынып атлаган мәхлук иде бит ул, андыйлар абынмый-сөртенми, егылмый каламы?

Аның янәшәсендә, юлны карап, чокыр-кантарлар очраганда беләгеннән тотып, саклап бара торган берәү кирәк иде. Күренеп тора: бу Букштейн һич тә андый түгел иде шул.

Ничек, ни сәбәпле бәйләде икән Җәүһәрия язмышын аның белән? Нинди хисләр, вакыйгалар таныштырган, якынайткан, кавыштырган аларны? Мәхәббәтме? Юк, юк! Һич тә тирән, саф, матур хисләр түгелдер. Ни беркатлы булса да, Җәүһәриянең күзе ачык, җаны сизгер иде. Дөньяның керләрен күрә белмәсә дә кешенен җанын тоя белә иде ул.

Харис соныннан белде: алар бер әдәби берләшмәгә йөргәннәр. Үз туган теленә өйрәтелмәгән, урысча гына сөйләшә торган, аның да асфальт җәелгән юл кебек такыр бер шивәсен генә үзләштергән татар балалары күп бит безнең шәһәрләрдә. Алар арасында талантлылары да шактый. Татарстандагы урыс газеталарына язалар, телевидениедән, радиодан урысча тапшырулар эшлиләр. Җиң сызганып, җигелеп урыс мәдәниятен, әдәбиятын үстерүгә хезмәт итәләр. Менә шул мохиттә бөтерелә иде Җәүһәрия. Шунда бу адәм аны эләктерү җаен тапкандыр да. Ә инде тиз арада өйләнешүгә килсән...

Озак уйланганнан соң, Харис моны үзенчә аңлатты. Энже яңгыр астында Шотландия королевасы Мария Стюартның фаҗигага уралган мәхәббәте хакында сөйләшкәннәре, бәхәсләшкәннәре исенә төште. Күңеленә шул хәтле якын алган иде бит ул кыйссаны Җәүһәрия!..

Букштейн белән аның арасында да шундыйрак хәл булмады микән?! Әгәр ул ниндидер бер мизгелдә йомшаклык күрсәткән булса, бу кара адәм шуннан файдаланган булса? Җәүһәрия үзен хур ителгән, намусы пычратылган дип таныр идеме? Юк, әлбәттә! Ул ханбикә кебек үк горур, нык иде. Мине таптап уздылар, дип елап ятмас, сынып корымас иде. Бәс, шулай булгач, ул да, Мария кебек, мин бу кешене яраттым, үз теләгем белән аныкы булдым, дип үз-үзен ышандырырга тиеш булгандыр.

Чөнки шагыйрәнең үз язмышын Букштейн дигән ул кара адәмгә бәйләвен башка берничек тә аңлатып булмады.

Шуннан соң алар берничә ел очрашмадылар. Харис—сәламәт, таза егет, тәртипле тормышны ярата, хисләргә бирелеп, бөтенләй башын югалта торганнардан түгел. Бер сүз белән әйткәндә, аннан Мәҗнүн дә, Ромео да чыкмас иде. Берданбер гомерендә рәхәт яшәргә кирәк, дип саный ул. Үзләренең трестына институт бетереп эшкә килгән Гүзәлия белән танышты. Уртак тел таптылар, бер-берсен якын иттеләр. Бу кыз белән Җәүһәрия арасында шактый уртаклык бар иде. Гүзәлиянең дә буй-сыны килешле, йөзе ачык, холкы ипле. Шигырь генә язмый. Тик кысынкырак кара күзләре генә иләкле. Өйләнештеләр, уллары туды. Җәүһәрия дә сирәк кенә, яшьлеге искә төшкән чакларда үзәкне өзеп күз алдына килгәли, әчке сагыш белән өретелгән шигырьләре хәтердә янара иде.

Гомер язларынны кичкән чакта,
Очар кошлар кебек талпынып;
Синен барыр юлын уртасында
Мин кызыл гөл булып балкыдым.

Ул шулай күнел түрендә, яшьлектә, татлы һәм ачы хатирә булып кына калырга тиеш иде шикелле...

Ләкин алай булып чыкмады...

Берзаманны ул Харисның эшенә шылтыратты. Шул минутта дөньяның кинәт яктырганын, йөрәгенең үрсәләнеп типкәнен тойды Харис. Шагыйрәнең назлы тавышы бер дә үзгәрмәгән, һәр сүзеннән көләчлек бөркелә иде. Әйбәт яшибез, малай үстерәбез, ди. Харис та малае белән мактанып алды. Ә башта бер генә уй: "Ничек мине исенә төшерде икән? Сагынды микәнни? Яратты микәнни? Ә бәлки, чыннан да яраткандыр? Тик мин генә аңлап житкермәгәнмендер? Шуның аркасында ул ятны үзенә яр иткәндер?!"

Көзге салкын кереп оялаган кабинетта кинәт түзеп булмаслык эссе булып китте.

Жәүһәрия шаяргандай гына итеп аны... очрашуга, ягъни "свиданиегә" чакырды. Кичке сәгать жидегә, Эрмитаж бакчасына. Казанның үзәгенә якын булса да, бик аулак урын бу: бер ягында текә баскыч, икенче ягында тын урам.

—Озак тотмам, курыкма, хатынын белми дә калыр,—диде Жәүһәрия көлеп.

Ноябрь башының өшеткеч киче. Караңгы, болытлы, томанлы. Шәрә агачлар арасындагы багана башларында лампалар янмый, ә бәлки, аларны махсус бәреп ватканнардыр.

Харис Жәүһәриядә бер үзгәреш тә күрмәде. Озын, киң итәкле, кулдан бәйләнгән алсу пальтосы да таныш иде, иңнәренә төшкән эре бөдрәләре өстенә, баш түбәсенә кыйгачлап кигән береты гына башка. Алсу һәм ак жепләрне аралаштырып бәйләгән шарфының очлары билдән түбән жилпенә. Кулдан бәйләгән киемне ярата иде шул Жәүһәрия. Гадәтләре дә теге яздагыча, тавышы да, ярым шаярып сөйләшүе дә...

Харис аны бик-бик сагынганын аңлады. Күтәреп алып агачлар арасында бөтерелеп йөрисе, иләксез күзләренә текәлеп карап, күнел түренә узасы килде.

Жәүһәрия егетнең сузылган кулларын салкын бармаклары белән эләктереп алды:

—Ярый әле, вакытында килдең. Соңарырсың, дип курыккан идем. Алар биш минуттан монда булырга тиеш.

—Кемнәр?

—Белмим. Хәзер күрербез.

—Аңлатыбрак әйтсәнә.

—Өченче көн кич Черек күлдә дус кызым белән очрашкан идем... Эчкәрәк кереп, эскәмиядә бераз сөйләшеп утырдык. Шунда...

Шунда бер карак анын сумкасын тартып алып качкан икән. Менә бүген телефоннан өенә шылтыратканнар, сумкагыз бездә, шушы вакытта, шушы урынга килсәгез, бирәбез, дигәннәр. Жәүһәрия үзе генә килергә курыккан, иптәшкә Харисны чакырган...

—Ышанычын өчен рәхмәт инде,—диде Харис. Күнеленә исә: "Ә ирен кая?"—дигән сорау килде. Ләкин, ни сәбәптәндер, ул бу сүзләрне тел очыннан ычкындырмады. Ә бәлки, аерылганнардыр, дип тә уйлап куйды.

—Сумканны кемнән алганнарын әйттеләрме соң?—дип сорады Харис.

—Урамнан таптык, диделәр.

—Акчасы күп идеме?

—Миллионнарны сумкада йөртмибез, эчкәрерәк тыгабыз,—диде

Җәүһәрия көлеп.— Дус кызым әйтә, син, ди, сумкаңда чегәннәргә дигән акчаны йөртәсең, ди. Һәм дөрес эшлим, дим мин. Чөнки акча янчыгымны әледән-әле алгалап торалар. Шуна күрә анда трамвай белән ипигә дигәнен генә салам. Эре акчаны эчке кесәдә йөртәм... Боларга мәшәкать өчен күпме бирергә кирәк булыр икән?

—Маклашка төс аларга! Сумкаңны үзләре үк чәлдергәннәрдер әле. Милициягә әйтергә кирәк иде.

—Хәзер соң бит инде,—диде Җәүһәрия тыныч кына.—Күпме акча бирим икән?

—Егерме биш бик житкән.

Бакча юлында кинәт кенә өч кара шәүлә пәйда булды. Алар, күрәсең, баскычтан менгәннәрдер. Куртка якаларын күтәргәннәр, кара башлыкларын батырып кигәннәр. Йөзләре күренмәсә дә, бәдәннәреннән, тавышларыннан үсмерләр икәне беленеп тора. Ә андыйлар аерата куркыныч, аларның башына бер тиле уй керсә, унга-сулга карауны белмиләр. Бигрәк тә мондый бакчаларның караңгы юлларында йөргәннәре. Берсе озын баулы кара сумканы күрсәтте.

—Бар да урынында ,—диде тавышын юри карлыктырып.

Җәүһәрия ана егерме бишлек сузды.

—Арзанракка куймыйсызмы, мамаша?—диде икенчесе.

Селәгәйгә берне сыларга кулы кычыткан иде Харисның. Ләкин тегеләр өчәү бит. Куртка астында гәүдәләрен чамалау да кыен. Хәзерге үсмерләр мондый юлларга чыгар алдыннан спорт залларында, һич булмаса подвалларда көч җыялар—"мускулы качают". Салып таптарга да күп сорамаслар.

—О-ой! Нишләдем соң әле мин?! Акчаны өйдән азрак алып чыкканмын бит!—диде Җәүһәрия.

Харис кесәсеннән өч унлык чыгарып, тегеләргә сузды:

—Кара, документларың урыныңдамы?!

Ул арада малайлар баскыч ягына йөгереп, эрегәндәй юкка чыктылар.

—Бандитларны менә шушылай үзебез үстерәбез шул без, —диде Харис.

Җәүһәрия аның сүзләренә игътибар бирмәде, жинел сулап:

—Бар да урынында,—диде.— Паспорт та, өй ачкычлары да.

Инде хәзер иркенәеп бер-берсенең хәл-әхвәлен белешергә, ачылыбрак сөйләшергә мөмкинлек туган кебек иде.

Ләкин Җәүһәрия, рәхмәт әйтеп, китәргә ашыга башлады:

—О-ой! Баланы күршедә калдырган идем!

—Әйдә, озатып куям.

—Кирәкми, ашыгам. Бик җаваплы миссия бит минем жилкәдә, ике егеткә кичке аш әзерлисем бар!

Шулай диде дә, бакча капкасыннан чыгуга трамвай тарафына йөгерде. Хисләргә ирек бирергә дә, үткәннәрне искә алырга да вакыт калмады. "Димәк, ире үз урынында. Ләкин хатынының сумкасын алырга нигә соң ул килмәгән?"

Урам утлары яктысында йөгереп китеп барган нечкә сынлы хатын аңа кызганыч, ялгыз булып күренде. Ялгыз булмаса, ул мондый очракта Харисны эзләп табар идемени? Әгәр, мәсәлән, Гүзәлия сумкасын югалтса, Хариска әйтмәс идеме?! Хәер, аның сумкасын ала алмаслар! Алай да, зарланыр нәрсә табыла: йә базар сатучысы акчаны ким биргән, йә бакчадагы тәрбияче балаларның борын астын сөртмәгән. Һәммәсен кайтып сөйли, Харис "ие-ие" дип тора. Үзенең дә эч бушатасы, дөньяның рәтсезлегеннән зарланасы килгән чаклары була. Хатыны аның сүзен җөпли, башын сыйпый, алдына аш китереп куя. Өенә кайтып, шундый юаныч та тапмагач, ул нинди өй дә, нинди ир-хатын, нинди гаилә?!

Тагын Мария Стюарт кыйссасы хәтергә килде...

...Берәр айдан трест директорының секретаре Хариска бер конверт бирде. Аның эчендә өч унлык иде...

Сер бирмәде Җәүһәрия. Өендәге чүпне читкә чыгарасы килми иде...

...—Тамак ялгап аласы бар. Төш узып бара бит, ике тулып килә,— диде Даниф.

Харис хатирәләреннән авырлык белән айнып, тирән итеп көрсенде.

—Ике генәмени әле?..— Аннары, зиһенен туплагандай, бераз тынып торды да:—Шәһәргә кайтып житик инде, аннан карарбыз,—дип өстәде.

* * *

Әйе, сәгать телләре үз көе белән әйләнә дә әйләнә... Мизгелләрне саный да саный... Аларның үз үлчәве... Алар әле нибары ярты көнне генә санаганнар...

Ә Хариска бер гомер узган кебек. Әле иртән генә дөнья бөтенләй башка иде түгелме соң?.. Эшкә килгәндә нинди гамьсез, бәхетле булган икән ул. Белмәгәнгә... Бер сәгать эчендә кафены карап чыгарга, аннары төзелеп бетеп килә торган йорт янына барырга ниятләп куйган иде ул. Эш күплегеннән аптырап, ничек өлгерермен, ул кафеда нишли алырмын инде мин, дип, күңеле сыза иде. Җитмәсә, трестның ана беркетелгән "Нива"сы инде шактыйдан ватык, төзәтергә бухгалтерия акча таба алмый. Ярый, алдагы көнне Даниф шылтыраткан иде, машинасы белән кафега алып барырга риза булды... Дөрес, трест ишеге төбендә унынчы яртыда очрашырга вәгъдәләшкәннәр иде, ә ул ун тулгач кына килеп житте. Шул ярты сәгать эчендә Харис бик нык борчылып, эченнән дулаган иде... Нинди юк кына нәрсәгә кәефе кырылган булган икән лә!

Шуннан соң дөнья бер тын эчендә әйләнеп капланган кебек булды, алдан уйланган, бик мөһим тоелган эшләр кичерәеп калды, әһәмиятен югалтты... Харисның хәтерендә Җәүһәриянең уйчан тавыш белән шигырь сөйләгәне янарды:

> Өермәләр кинәт куба,
> Таулар кинәт ишелә...

Әйе, бөтенесе кинәт ишелеп төште. Харис өчен.

Ә менә Данифның сәгате вакытны иртәнгечә саный. Аның ашар чагы житкән. Карыны ачкан. Харисның эчендә дулаган ялкын аны көйдерми чөнки.

...Даниф, яшь кенә булуына карамастан, ә бәлки, шунадыр да, жилкәннәрен заман жилләре унаена тиз көйләгән егетләрнең берсе иде. Һәммәсенә өлгерергә тырыша: мәктәпне тәмамлауга өйләнеп жибәргән, аннары, эшне озакка сузмыйча, бер-ике елдан аерылып та куйган. Кооперативлар оешу шаукымы кубуга, "бизнесмен" булып киткән. Горбачевның "алкоголизмга каршы аяусыз көрәше" заманында, Казандагы шәраб заводын ябып, мал-мөлкәтен "Баллы күл" кафесындагы кебек пыран-заран китереп бетергәч, аның бушап калган бинасына шушы Даниф хуҗа булып алган иде. Ул яллаган таза беләкле егетләр, армиягә хас ала-кола күлмәкләренең жиңен сызганып, заводның жир астындагы иркен сарайларына кереп киттеләр. Бишәр йөз литр сыешлы имән мичкәләрне көл итеп ватып чыгарып ташладылар. Хәмер чөмереп исереп егылган күсе түшкәләрен себереп түктеләр. Бушаган урынга агач тартмалар ташып, аларга туфрак тутырырга керештеләр. Данифның кооперативы шунда шампиньон дигән гөмбә үстерәчәк иде.

Билгеле инде, бинадагы мондый үзгәрешләр яңадан коруны, ягъни, "реконструкция" таләп итә иде. Ул шушы эшләр белән төзү трестына килде. Харис белән шунда танышты.

Хөкүмәт предприятиесе булган трестның бөлеп килгән, ә кооперативларның, жылы базда үрчегән гөмбә кебек, сәгате белән ишәеп, бер-берсенә чәбәләнеп чорналган чагы. Егетнең кесәсе калын, чөнки кооператорларга эшне башлап жибәрергә мул итеп кредит бирәләр иде.

Банкирларның күзенә төтен җибәрерлек "бизнес-план"ың гына булсын. Ә андыйларга башы эшли Данифның, "бизнес" дигәндә тел тегермәне сүзләрнең югары сортын гына чыгара.

Ул чакта алар әйбәт кенә хезмәттәшлек итеп алдылар. Бинаны төзәткәндә шактый ташчы, штукатур-малярларга, түбә ябучыларга, эретеп ябыштыручыларга ярыйсы гына эш булды. Түбә ябучылар белән эретеп ябыштыручылар бергәләп эшләделәр, чөнки озынлыгы ундүртәр метрлы, эре сырлы, калын түбә калаен эретеп кенә кисеп була иде.

—Шифер гына ярамадымыни? Бу түбәнең хакын чыгару өчен күпме гөмбә үстереп сатарга кирәк булыр?—дип хәйран калган иде Харис.

—Ялтырап торсын, дус-дошманның күзе чагылырлык булсын!—диде Даниф.—Менә ичмасам, боларның эше гөрләп бара, дип шаккатып сөйләсеннәр. Эшебез чыннан да гөрләп барачак, чөнки һәммәсе исәпләнгән-саналган. Шәһәрдә гөмбә үстерүчеләр аз, халык егылып алачак. Кибетләргә ташып кына өлгер. Тиз үсә, ә хакы...

Һәм ул саннар белән Харисның башын дөнгечләп тутырырга керешә.

Ул чакта "бизнес-план"нарны белен урынына пешереп кенә торды Даниф. Аның "бөтенесе исәпләнгән-саналган" кооперативлары берничә иде. Кайдадыр ат үрчетеп, кымыз цехы ачып яталар, кайдадыр умартачылык белән шөгыльләнәләр. Тугыз катлы бер йортның идән астында "Мебель цехы" ачылган, урманнан әле генә кисеп алып кайткан чи усаклардан дөбердәтеп диван-кәнәфиләр укмаштыралар. Халык чират торып ала, чөнки кибетләргә әле чит илдән товар китереп өлгермәгәннәр, ә акчаның бәясе убылып төшеп тора. Инфляция! Кемнәргәдер дача йортлары салалар. Бәгъзеләренә— түрәләр тирәсендә кода-кодачалары булып, кредит эләктерә алганнарына—өчәр катлы "коттедж" торгызалар. Һәммәсенең планы расланган, барысына да кредит алынган. Тимер-бетон комбинатларында бетонга чират. Харисның танышлары Данифның машиналарын чиратсыз төйиләр. "Бизнесмен" исә үзенең кара "Тойота"сында, өч таза егет белән бергә, тегендә-монда ут капкандай чаба, машина эчендә әледән-әле телефон зыңгылдый. Артын кашырга да вакыты юк эшкуарның!

Харисны да бу агымга керергә нык үгетләгән иде ул:

—Нәрсәгә монда сөрсеп утырасыз? Дәүләт предприятиеләренең берниндн киләчәге юк хәзер. Тәҗрибәгез зур, танышларыгыз күп, абруегыз югары. Сезгә кредитны берсүзсез бирә хөкүмәт.

—Кымыз эчкәч бал ашарга ярамый бит, син шуны беләсеңме?—диде Харис.

—Нишләп?

—Эчкә тия. Шуңа күрә сак бул син. Буташтыра күрмә. Әле гөмбә базына, әле ат абзарына, әле умарталыкка чабасың. Башың әйләнеп, егыла күрмә!

Бизнеска башы каты эшләгән егет бу сүзләрдән югалып калды, аның аптыраганын күреп, Харис көлеп җибәрде.

—Синең арттан чабып булмас шул,—диде аннары җитдиләнеп.—Бия саварга осталыгым да юк. Төзү институтында андый һөнәргә өйрәтмәделәр.

—Бияне үзең савасы димени! Аны саудырта белергә кирәк... Менә, мәсәлән, сәүдә белән шөгыльләнергә уйласаң... Кредит аласың да, телевизорлар, суыткычлар кайтартып, складка тутырып, шартлатып бикләп куясың. Аннары берничә ай күккә карап, төтен өреп йөрисең. Ул арада синең малның хакы биш тапкырга күтәрелә. Кредитыңны түләгәч, үзеңә бер-ике ел дөньяның артына тибә-тибә яшәрлек кала...

Монысын ул сөйләмәсә дә белә иде Харис. Әнә, Кушагин дигән эшмәкәр шундый гамәлләре белән бөтен шәһәрне шаккатырды. Якындагы бер бистәдә бушап калган яшелчә базасына шыплап телевизорлар тутырган да, тирәсенә этләрне өйрәтә торган осталарны сакларга җибәргән. Этләре белән, билгеле. Акчаның кыйммәте упкынга мәтәлгәнен, товар хакларының күккә күтәрелгәнен көтә икән...

Гөмбә цехында төзү трестының эшләре беткәч, Даниф күздән югалды, йомышы төшмәгәч, Харис та аны эзләп маташмады.

Берзаман алар урамда очраштылар. Сәлам бирмәсә, Харис танымый узып та киткән булыр иде, мөгаен, шулкадәр бөрешкән иде бизнесмен егет. Өстендә төсен җуйган костюм, аягында иске кроссовка. Башын иеп, кырын басып тора. Ләкин барыбер ун янагы кызарып, җилсенеп, урыны-урыны белән хәтта чиләнеп чыкканы әллә каян күзгә ташлана иде.

—Ни булды сиңа?!—дип сорады Харис шаккатып.

—Батыр ярасыз йөрми,—дип җавап бирде теге елмаерга тырышып. Әмма елмаю галәмәте аның чыраен тартыштырып, авызын кыйшайтып, тәмам мескен хәлгә кертте.

—Ә нигә җәяү? Бизнеска тотынган идең ич. Барып чыкмадымыни?

—"КамАЗ" авариягә юлыкты бит минем. Эче тулы телевизор иде. Бөтенесе челпәрәмә килде. Хакын көчкә түләп бетердем.

"Ахыры шулай бетәчәге көн кебек ачык иде",—дип уйлады Харис. Ә үзе Данифка:

—Башың исән булсын,—дигән булды.—Бу заманда ниләр генә күрми бизнесмен башлары. Совет заманында тир түгеп алган квартирларын сатып урамда калганнары бар. Кайсыларын имгәтеп ыргыталар, күпмесен үтереп ташладылар. Син ансат котылгансың әле, шөкерана кыл. Моннан соң аң булырсың, алдыңны-артыңны карабрак йөрерсең...

Ләкин "бизнес" чиреннән кешене битен җимереп кенә терелтеп буламы?

—Зарар юк,—диде Даниф.—Менә яңа фирма ачарга йөрибез... Таныш егетләр белән берләштек, килештек... Озакламый тугыз катлы торак йортка нигез салабыз. Квартирларын сатачакбыз. Акчасын алдан түләгәннәргә хакы кимрәк куелачак. Андыйга ихтыяҗ зур бит ул. Бөтенесе исәпләнгән-саналган. Бик файдалы, табышлы эш булачак. Әйдәгез, мин сезне шунда тәкъдим итәм! Мин алып барсам, егетләр биш куллап кабул итәчәк! Алар мине белә!

—Ә шампиньоннар үсәме соң? Бияләр сөт бирәме? Ә умарталар...

—Сатарга туры килде... Теге "КамАЗ"дагы товар өчен...

Булгандырмы егетнең кыйммәтле товар тутырылган машинасы, юкмы, аугандырмы ул, юкмы, анысы томанлы калды. Һәрхәлдә, Харисның күңелендә, теге "Тойота"га үзе белән утырып йөргән таза егетләрнең йодрыгы уйнамадымы икән аның чыраенда, дигән шик калды.

Бизнес тәмен бер татыган адәм тимер кырмый, таш кисми шул инде. Таш кискәнгә баш булу җаен эзли ул. Ләкин ул җайны да таба белергә кирәк бит. Менә шул "җай" дигән нәрсә Данифның кулыннан шома балык кебек ычкынып тора иде, ахрысы. Теге йорт төзүчеләр дә никтер аны бик якын җибәрмәделәр. Һәрхәлдә, егет Хариска ул хакта бүтән сүз кушмады. Алай да үзенә каяндыр калтырча "Уазик" юнәткән, аңа менеп утыргач, хөртилеге дә кимеде, бите дә төзәлде. Янадан калкып бара, еш кына Харис янына килеп чыга, төзү кооперативы оештырырга үгетли.

Кафега барганда Харис: "Моның башы эшли бит, бу бинаны рәтләү турында берәр фикер әйтмәсме?"—дип тә уйлаган иде.

...Бардылар... Кайтып киләләр. Кыяфәтен күр инде Харисның!

—Өйгә сугылып, күлмәкне алыштырып чыгыйм әле,—диде ул Данифка.

—Харис Мирзаянович! Сез ничек уйлыйсыз: ул бинага хәзер кем хуҗа булыр икән?

Харис Данифка гаҗәпләнеп карады. Ул әле бина турында сөйләшә... Хәер, Җәүһәрия кем соң аңа? Аның өчен ник кайгырсын ул?

—Кем хуҗа дип... Җәмгыятьнеке бит ул.

—Кем соң ул "җәмгыять"? Андый шарашкин конторалар гадәттә шул бер кешедән тора инде. Җитәкчедән. Җитәкчесе киттеме—бетте,

дигән сүз. Монда да бүгенге хәлләрне ишетүгә, ач шакаллар өерелеп киләчәк. Беләсезме, бүгенге көндә күпме тора андый бина?

—Күпме?

—Шәһәр хакимияте ана ике миллиард сораячак!

—Ике... нәрсә?!

—Миллиард, Харис Мирзаянович.

—Шул хәрабәгәме?

—Анысы арттырып җибәрәләр инде. Ул хәтле акчасы булган кеше Казанда күп түгел. Андыйлар моның ише белән вакланмый, Мәскәү аша чит илләр белән генә эш итә. Монда берәр котырган акчалы кеше килеп чыкса гына. Оттырмаячак алар, киләчәктә зур табыш алачаклар. Аның ихатасы, җир мәйданы күпме... Бинаның зурлыгы. Санап карагыз, Харис Мирзаянович! Төзүче бит сез, биналарның хакын чамалыйсыздыр.

—Акчалар котырган, бәяләр саташкан бу заманда кем белеп бетергән аны. Ә син каян алып әйтәсең?

—Бизнес кешесенә бәяләрне белми булмый. Бина сорап күп таптарга туры килде инде чиновниклар бусагасын. Калҗа бик симез. Күрегез дә торыгыз, берәүләр бик нык мантып калачак ул бина янында.

—Кемнәр?

—Беренчесе менә шушы җәмгыятьнең пичәтен кулга төшереп, имза хокукын алган кеше булачак. Закон буенча, җитәкче юкта аның хокуклары урынбасарга күчә. Урынбасары кем икән соң аның? Ну ишелде бәхет берәүгә!

Харис кинәт гәүдәсенең кылдай тартылганын тойды, чырае кырысланып китте:

—Син кызурак тот әле. Мин хәзер минут эчендә өйгә кереп чыгам да Карл Маркс урамына китәбез.

—Анда нәрсә калган?

—Җәмгыятьнең бүлмәсе шунда.

—Ә кайда ашыйбыз?

—Мин күлмәк алыштырган арада, берәр чокыр кофе эчеп алырбыз. Эшкә дә шылтыратырга кирәк, мөгаен, бүген бара алмам.

Даниф, алдан җай гына барган зәңгәр "Ока"ны узарга чыгып, газга ныграк басты.

* * *

Җәүһәриянең хәер җәмгыяте оештыру артыннан йөргәнен белгәч, Харисның күңелендә, хәерлегә түгел бу, дигән шик туган иде. Тик ул моны шагыйрәнең күзенә туры карап, нык итеп әйтә генә алмады.

...Ул чакта, ике ел элек, телефоннан таныш тавышны ишеткәч, тагын берәр бәлагә тарыганмы әллә, дип уйлап өлгергән иде Харис. Бәхеткә, бәла-каза юк икән. Киңәшәсе бар, диде Җәүһәрия. Харисның эш бүлмәсендә очрашырга килештеләр.

Бу юлы ул шактый үзгәргән кебек тоелды. Ничектер кыюсыз елмаеп килеп керде, бәйләнгән пальтосын, беретын салып, ишек янындагы элгечкә элгәндә, чәч бөдрәләрен сыпырып, муенындагы озын ак шарфын рәтләгәндә—һәр хәрәкәтендә сагаю, кыенсыну сизелеп тора иде. Гадәттә зур начальниклар янына фатир сорап килгән кешеләр үзләрен шулай тота.

Кул биреп, исәнләшкәндә, салкынча бармакларын Харисның учыннан бик тиз тартып алды ул, озаклап хәл-әхвәл сорашырга да теләмәде. Сумкасыннан бер бит кәгазь чыгарып, өстәлгә салды. Анда сәер генә рәсем ясалган иде: яшел җирлектә кызыл урак-ай, аның эчендә ак лалә чәчәге. Баксаң, балаларча беркатлы бу сурәт—яңа бер оешманың тамга-символы иде. Оешма үзе—хәер җәмгыяте, оештыручысы исә Җәүһәрия икән.

Әлбәттә, хыялый шагыйрәдән төрлесен көтәргә мөмкин. Ләкин бу

каләресе... Харис ни әйтергә белми аптырап утырганда, Җәүһәрия, шигырь укыгандай канатланып, очынып, булачак җәмгыятьнең кирәклеге, мөһимлеге хакында сөйләргә кереште.

—Мондый оешмалар бөтен илдә бар. Чикләр белән дә санашып тормыйлар, кайда афәт-фаҗига булса, шунда барып ярдәм күрсәтәләр. Чечняда сугыш башлануга машиналар, самолетлар белән күпме илләрдән килеп җиттеләр, ә французлар госпиталь ачып җибәрделәр хәтта. Ә нигә безнең Татарстанның шундый госпитале юк анда? Нигә безнең флаг анда җилфердәми? Чечняга без французлардан якынрак! Татар халкы французлардан ким түгел!

—Неужели?—дип сораудан тыела алмады Харис. Ләкин үзенең тавышында ирексездән мыскыллау яңгыраганын сизеп алды да, сүзен шаяруга борырга ашыкты:

—Татар французлан артык ул, Җәүһәрия! Дүрт йөз ел буе башка милләт басымы астында яшәсә, белмим, француз исән калыр иде микән! Ә менә татар исән, яши. Тик бу—бик зур сер.

—Нәрсәсе сер?

—Татарның дөньяда барлыгы. Аны французлар белми бит.

—Соң белгертергә кирәк! Күзләренә китереп terәргә! Әйтик, шул ук Чечняда, яисә әнә җир тетрәгән Япониядә французлар белән янәшә без дә үзебезнең Татарстанның байрагын калап куйсак, ачларга ризык, ялангачларга кием бирсәк, яралыларны дәваласак, белерләр, танырлар иде, тиң күрерләр иде! Газеталарда язып, телевизордан күрсәтсәләр, бөтен дөньяга шаулар идек. Мокыт булып яшәргә ярамый! Менә кара әле!

Ул сумкасыннан таушалып беткән юка тышлы китап чыгарды.

—Төрек Кызыл Аеның тарихы бу. Оештыручыларын күр син аның.

Ул китапчыкның беренче битен ачты да, фәсле, мыеклы, горур карашлы гайяр ирләрнең сурәтләренә алсу тырнаклы нәфис бармагы белән төртте.

—Кара-кара! Моннан йөз ел элек Төркиянең шәфкать оешмасын булдырган кешеләр болар. Генераллар, бәйләр, пашалар. Алар кебек булсаң, ә? Синең портретны менә шушындый китапта басып чыгарсалар, шәп булыр иде бит!

—Каяле, кая!

Харис китапны үзенә табарак тартты да сурәтләрне дикъкать белән карап чыкты. Аннары:

—Карточкага дөрес төшермәгәннәр боларны,—диде.

—Ә ничегрәк кирәк, дип уйлыйсың?

—Фокуска кесәләрен алырга кирәк иде. Чөнки хикмәт фәстә дә, мыекта да, генералның түшендәге орденда да түгел, ә кесәдә, акчада. Китапта язганнармы, күпмешәр доллар биргәннәр алар бу оешмага?

—Аларда доллар түгел, лира!—диде Җәүһәрия үртәлеп, ләкин бирешергә теләмичә.—Инде сине дә шундый дип һич уйламаган идем!

—Нинди дип?

—Бөтен нәрсәне акчага илтеп тери торган!

—Гадәт, Җәүһәрия! Һөнәрем шундый бит минем. Төзүче кеше, эшкә керешкәнче, җирнең астын актарып карарга тиеш. Үлән үскән йомшак туфрак астында нинди катламнар ята, шуны белергә. Нигезнең төбен каты токымга терәп утыртырга кирәк. Шулай эшләмәсәң, корылмаң авып, ишелеп төшәчәк. Ә менә син әйткән җәмгыять өчен каты токым—акча бит инде ул. Ни диләр соң бу хакта безнең татарның пашалары-бәйләре... гафу, байлары?

Җәүһәрия башын тәрәзәгә борды. Ничектер гадәтиләнеп, кечерәеп киткәндәй иде ул, хәтта кызганыч иде. Ә кызганыч булу ана һич тә килешми. Мескенлек бераүне дә бизәми!

...Хәзер исенә төшкәч, бәгыре киселеп китте Харисның: алай өстән карап, баласытып сөйләшәсе түгел иде лә!.. Байлар ярдәм итә торган булса, Хариска килеп егылыр идеме ул?

—Узган айда төрекләр килгән иде, шуларны шәһәр читенә кунакка чакырдылар, алар янына үзебезнең кайбер артистларны, шагыйрьләрне дә дәштеләр, арада мин дә бар идем,—диде Җәүһәрия. Һәм соңгы вакытта калкып чыгып, исеме республикага танылган бер татар баеның исемен атады.—Табында утырганда хәер җәмгыяте оештыруыбыз турында сөйләгән идем. Ул миңа өстәл аша биш йөзлек акча ыргытты... Рәхмәт инде. Җәмгыятьне рәсми рәвештә теркәргә житте.

Харис зур залны, затлы ризык тезелгән табынны, андагы чит ил кешеләрен күз алдына китерде. Шунда, имеш, берәү өстәл аша акча ыргыта. Ярдәмме, сәдакамы?.. Бу хакта сөйләгәндә горур шагыйрәнең күңеле төшенке булуы бик тә аңлашыла.

—Эшне башлыйк әле, бер җае чыкмый калмас,—дип тәгәлләде Җәүһәрия сүзен.

—Хәер җәмгыятенең эше—бушка өләшү дигән сүз. Өләшү өчен башта табарга кирәк. Өстәгеләр ни әйтә соң, аларның фатихасын алгансыңдыр бит?

Бу сорау Җәүһәрияне калкындырып җибәрде.

—Син уен-муенга саныйсың, ә менә Хөсәен Гайфуллович бик хуплады,—дип, бик зур житәкчене атады ул.—Эшлә, Җәүһәрия, ди, моны фәкать син генә булдыра аласың, ди.

—Финанс ягыннан да ярдәм вәгъдә иттеме?

—Акча да акча! Һаман бер кадакка сугасың! Мигә батты инде кадагың! Хөкүмәт җәмәгать оешмасына акча бирә алмый, диде. Сиңа бирсәк, тагын әллә ничәү йөгереп киләчәк, урысы, яһүде, башкасы... диде. Ә болай кулдан килгәннең һәммәсен эшләячәкмен, теләсәң кайчан шылтырат, кил, диде.

—Кулыннан нәрсә килә соң аның?

—Мин аннан бина сорадым.

—Бирәм дидеме?

—Хәзер үк булмас, башта эшләп күрсәт, аннары биналы итәм, диде.

Әһә, җәмгыятьне оештырырга, аның эшен күрсәтергә кирәк икән. Бер тарыдан ботка пешми, бер кешелек оешма юк. Эшләүчеләр кирәк икән —бушка эшләүчеләр...

—Төзүче бик кирәк безгә,—диде Җәүһәрия.

—Гомерем буе хәер җәмгыятенең төзүчесе булу турында хыялланган идем,—диде Харис, уенын-чынын бергә кушып.

—Димәк, риза? Сине оештыручылар исемлегенә кертәбез. Фотосурәтеңне бир әле.

—Нәрсәгә?

—Җәмгыятьнең таныкнамәләрен ясатам.

Җәүһәриянең ишек алды буйлап китеп барганын ул тәрәзәдән карап калган иде. Язгы дымлы җил аның пальто итәген тарткалый, җилпендерә, гүя күтәреп алып китәргә омтыла иде.

Очыну килешә иде шагыйрәгә. Оештырсын җәмгыятен, кылансын, уйнасын, дип уйлады Харис. Ай эченә лалә чәчәге куелган матур тамгалы флагын болгап йөрсен, кесәсенә шундый ук тамгалы мөһерен, тәти катыргысын салып куйсын. "Президент Байбулатова" дип рәсми кәгазьләргә имзасын салсын. Аяк чалучылар, канатын сындыручылар, артыннан да, битенә карап та көлүчеләр Харистан башка да житәрлек булыр әле.

Тагын шунысы да бар: һәртөрле "ярдәм", "хәйрия" фондлары нык үрчегән чак иде бу. Харисны да чакыргалыйлар, тресттан әзрәк таммасмы, дигән өмет беләндер инде. Андый оешмаларга салымнар азрак салына дигән сүз йөри, алар тирәсендә кооперативлар булдыру бик уңай, диләр иде. Шуңа ымсыныптыр, ахрысы, оешалар, тик нилектәндер гомерләре кыска була, бер-ике елдан, иртәнге томан кебек, эреп юкка чыгалар.

Әмма ни гаҗәп, Байбулатованың "җәмгыяте хәйрия"се яши бирде. Җәүһәрия телефоннан шылтыраткалап эшнең барышын әйтеп тора, кинәштабыш итә. Кемнәрдер акча биргән, шул акчадан кемнәргәдер ярдәм

күрсәтелгән... Менә Хөсәен Гайфуллович та вәгъдәсен үтәгән—аның кушуы буенча хәер җәмгыятенә шушы "Баллы күл" кафесын биргәннәр...

Бу хәбәрне китергәндә, Җәүһәрия, чыннан да, канатланган иде. Теге беренче бию кичәсендәге кебек, башын артка ташлабрак, Хариска өстән карый, син миннән кичерәк, ләкин бер дә кыенсынма, егет кеше өчен кимчелек түгел бу, дигән кебек иде карашы.

Харис исә, бина турында ишетүгә житдиләнеп китте. Чөнки хәл шаярудан узып бара иде. Андый бинаны төзәтү, тоту, аннан табыш алу уен-муен түгел.

Җәүһәрия исә, әңгәмәдәшенең кашлары җыерылганын да күрми, үз хыялларына мавыккан. Ул ялангачларга кием-салым, ачларга азык-төлек өләшә торган иркен урын, йортсызларга кунып чыгар өчен бүлмәләр, медпункт булдыру турында сөйли. Складларга көзге уныш җыю чорында яшелчә, җиләк-җимеш китереп тутырачаклар икән. Инвалидлар өчен цехлар, шәфкать туташлары әзерләү курслары ачачаклар, имеш... Хәйрия ашханәсенең үзендә түләүсез сыйлау өстенә, аш, ботка пешереп, зур казаннар белән вокзал, базар тирәләренә барып, ачларны бушлай ашатачаклар икән.

—Моның өчен дәүләт бюджетына аерым статья булып керергә кирәк,—диде Харис коры гына.

Иң яраткан кешеңне дә гел башыннан сыйпап кына торып булмый. Кайчакта биш яшьлек Нәркизнең дә йомшак җирен "мәэ-мәэ" итәргә туры килә. Хыялларына мавыгып саташу дәрәҗәсенә җиткән шагыйрәне аңына китерергә кирәк иде.

—Хөкүмәт җитәкчеләренең фикере нинди соң?—дип сорады Харис.

—Әйттем бит инде—без җәмәгать оешмасы, хөкүмәт ярдәм итми, дип! Син акча турында гына уйлыйсың!

Җәүһәриянең аны чеметтереп аласы килә иде. Ләкин гомере төзелеш мәйданнарында узган егетнең тиресен алай гына чеметеп булмый.

—Кеше турында да уйлыйм мин,—диде Харис.—Ул бинада, беләсеңме, күпме кеше эшләячәк? Әллә ничә дистә! Ә синең зур коллектив белән җитәкчелек иткәнең бармы? Әллә син ана укыдыңмы?

Җәүһәрия дәшмәде..

—Шунысын да белеп тор: син рәтле ашханә директоры да, цех җитәкчесе дә, намуслы склад мөдире дә таба алмаячаксың.

—Әллә мине, үз тирәсенә җыен әтрәк-әләмне җыяр, дип уйлыйсыңмы?

—Тәҗрибәле, үткен, уңган директор йә мөдир хәзерге вакытта башка берәүнең кул астында кол булып эшли димени? Коммунистлар диктатыннан котылып, иркен сулыш ала гына башладылар, инде син башларына менеп басмакчы. Беләсең килсә, бу заманның бөтен рәхәте—ирекле булуда! Ә ирек ул—үзеңә кирәк кешеләрне генә эшкә алу, дигән сүз. Берсе онны-итне табып кайтара, икенчесе пешерә, өченчесе сата, дүртенчесе җыештыра, бишенчесе саный. Алтынчысы—ашханә директоры—шуларның эшен оештыра. Ә син аларга ник кирәк?

—Хәйрия җәмгыятенә салымнардан льготалар бирелә. Син шуны онытма.

—Их, Җәүһәрия, син законнарны ныгытып укып кара! Закон бер тиенлек ташлама ясаса, аның артыннан ун тикшерүчесен җибәрә, ничек тын алуыңа кадәр тикшереп торалар! Шуңа күрә эшем кешесе синеке кебек оешмалар белән бәйләнми. Тиешле салымын түлибез дә җан тыныч, диләр. Үзе тапканны, әгәр арттыра алса, үзе өләшә. Балалар йортына, хасталарга, картларга бирә... Әгәр синең тирәңдә болганучылар бар икән, белеп тор: кулларыннан эш килми, син тапканны каптырырга маташучылар булыр!

—Мин аннан чын шәфкать йорты ясыйм!—диде Җәүһәрия, күзләреннән ут чәчеп.—Түбәсенә Кызыл Ай бастырып куям. Шәһәрнең бөтен ягыннан күренеп, балкып торырлык итеп!

—Бик шәп булачак икән. Вокзалларда, идән асларында, канализация торбаларында кунып йөрүче йолкышларга эзләп торасы да юк. Шуның өстенә күпме төрмә кошы ябырылачак! Әдәбият түгәрәге түгел ул сиңа! Анда иң беренче эш итеп милиция пункты ачарга туры киләчәк әле!

Җәүһәрияне янакладыларммыни—ике бите алланып чыкты, күзләре боз кыйпылчыгы кебек ялтырады.

—Бер нәрсә дә җинел генә бирелми, һәр эшнең авыр яклары була,—диде ул Харистан да катырак итеп.—Хәер ашханәләре дә, кунып чыгу урыннары да бөтен дөньяда бар. Аларның барсын да хөкүмәт төзеп бетерә алмый, һәр ятимнең башыннан хөкүмәт сыйпый алмый. Мондый оешмалар булырга тиеш! Мин уйлап чыгарган нәрсә түгел. Бездә моңарчы эшләнмәгән, шуңа күрә әлегә рәтен белмибез. Өйрәнербез. Әгәр ярдәм итәсең килми икән, турысын әйт! Башкаларга ялынырмын!

Харисның "мәэ-мәэ" итәргә сузылган учына йодрыгы белән бәрде бу. Каты икән кулы! Харис аны мондый дип белми иде.

—Ә бүтәннәргә ни дип бармакчы буласың инде?

—Бина күптән хуҗасыз калган. Күз җиткәнче су торбаларын карарга, җылылык системасын тикшерергә кирәк.

—Анысын гына карарга була,—диде Харис тавышын йомшартып, килешергә теләгәнен нык сиздереп.

—Иртәгә унга килә аласыңмы?

—Алам.

—Мин уннарда булам. Без ул кафеда эшли башладык инде. Уннан икегә кадәр анда безнең кешебез утыра, мохтаҗларны кабул итә, ярдәм күрсәтә. Бүгенгә хуш.

Әйе, "бүгенгә хуш", диде ул чыгып киткәндә. Кулын бирмәде, ишек янына җиткәч борылып карамады, елмаймады. Ак кофта, аллы-аклы бәйләгән юбка кигән зифа сыны туры, нык, җәя кебек тартылган иде. Королева горурлыгы, тәвәккәллеге бөркелә иде аннан. Ләкин... королева беркайчан да япа-ялгыз булмаган. Хәтта Мария Стюарт та. Төрмәдә чагында да теләктәшләре, кайгыртучылары булган аның. Ә бу королева ялгыз иде. Хәзергечә әйткәндә, "команда"сы юк иде аның! Әгәр шулай булмаса, Хариска килеп егылыр идемени ул?

Җәүһәриянең артыннан карап калганда, Харисның күңелендә соклану белән кызгану айкалды. Ләкин нигә тәрәзәдән генә карап калды соң ул? Нигә аның артыннан йөгереп чыкмады?

...Ах, менә хәзер кичәге көнгә кулны сузасы иде дә, бүлмәдән чыгып барган Җәүһәрияне иңнәреннән тотып туктатасы иде! "Тукта, син мине анда көтмә! Телисеңме, мин сине өеңнән кереп алырмын! Кирәк булса, эшенә керәм..."

Ләкин үткәннәргә куллар сузылмый, мәрхүмнәргә сүзләр барып ирешми...

Ул минутларда Харис, иртәгәсен сөйләшербез, араларны җайларбыз, дип уйлады. Борчылырга сәбәп юк та кебек иде. Ялгыз булырга тиеш түгел иде бит Җәүһәрия. Кафеда җәмгыятьнең тагын бер кешесе булырга тиеш иде.

Кем ул? Ник килмәгән? Ә бәлки, килеп кире киткәндер? Әгәр шулай булса, кайчан, нишләп киткән?

* * *

Хәзерге заманда конторaларны яңача итеп, "офис" дип атау модага кереп китте. Ләкин Җәүһәриянең эш урынын болай атарга тел әйләнмәс иде. Бүлмә ишегеннән барып керүгә, биткә салкынча, дымлы тынчулык бәрелде, кояшлы ишегалдыннан соң шактый караңгы булып тоелды. Шагыйрәнең көлеп: "Без бит элеккеге ирләр туалетында утырабыз",—дип сөйләгәне искә төште. Туалет ук түгел, җыештыручының себерке-чүпрәкләрен саклый торган чолан булган бугай үзе.

Ак якалы зәңгәр халат кигән өлкән яшьтәге мөлаем апа ысланган тавык түшкәләре өелгән өстәл янында, ишеккә аркасы белән басып тора иде. Егетләрнең сәламен ишеткәч, тиз генә борылмады, ашыгып кульяулык белән күзләрен сөртте. Аннары җилкәсе аша гына карап, күз яшьләреннән арына алмыйча, бераз карлыккан тавыш белән:

—Исәнмесез?—диде.—Ни йомыш?

—Нурҗиһан апа, сез мине оныткансыздыр инде. Бер тапкыр кергәнем бар сезгә. Харис мин.

—Ә-ә, әйе шул... Гафу итегез, танып өлгермәдем. Күзем томанлана... Җәүһәрия сезне гел сөйли торган иде... Хәзер генә милициядән килеп киттеләр. Сез, бәлки, белмисездер әле.

—Беләбез.

Апа урындыкка утырды да гаҗизләнеп ике учы белән ботларын чәбәкләде:

—Көпә-көндез, эш урынында харап иткәннәр кешене, ә? Кемнен ни үче, ни ачуы булсын? Күпме кеше рәхмәт укый иде. Бер дошманы юк иде! Тартып алырлык байлыгы юк иде! Башка сыймаслык хәл! Шаклар катарсың!

—Анда ялгызы булмагандыр бит ул? Сезнен кешегез бар, диган иде...

—Әйе, Насибә утыра торган иде. Бүген анда бармаган шул ул. Балалары белән әвәрә килеп йөргән. Туры монда килгән иде.

—Кая соң әле ул?

—Менә, тавык китергәннәр иде, шунын берничәсен алып, фәкыйрьләргә илтә китте.

—Ә кафенын ачкычы кемдә иде?

—Ачкычны Җәүһәрия белән икесе белгән урынга куялар иде. Сакчыларнын үз ачкычы бар бугай.

—Анда сакчылар да бар идемени?

—Бар иде. Төнгелеккә. Ә көндез Насибә үзе утыра иде.

Апа кульяулыгы белән битен каплап, сулкылдый башлады.

—Кирәк түгел иде ул кафе! Йөрисе юк иде! Бер генә барып карадым мин анда, эчем жу итте. Хатын-кыз кулыннан килә торган эшмени андыйны торгызу? Ничә тапкыр әйттем мин Җәүһәриягә, болай да эш баштан ашкан, йөрмә, дидем. Син аңламыйсын, диде. Мин шул олы бинаны ялт итеп төзәттерәм дә, түбәсенә балкытып ай бастырып куям әле, диде. И хыялый! Хыялый! Шуны эшләргә ирек бирәләрме инде сина?..

—Хәзер кем хуҗа булып калды сон монда?—дип сорады Даниф.

—Мин Җәүһәриядән башканы белмим... Аптыраган...

—Документларны карарга кирәк,—дип, Даниф Хариска таба борылды.

—Менә, сейф ачкычы монда,—дип, Нурҗиһан өстәлнең аскы тартмасыннан ак бау бәйләнгән зур ачкыч алып бирде.

Харис, ишек катындагы сейфны ачып, тимер киштәләрдән ак папкаларны алды.

—Акчаны кайда тотасыз сон?—дип сорады Даниф.

—Акча сирәк була ла ул бездә. Дөрес, кичә бар иде. Мина ике айлыкны берьюлы бирде. Калганын үзе белән алып китте.

—Күп идеме?

—Тәп-төгәл алты миллион иде. Каршыма утырып санады. Бурычымны түлисем бар, диде. Аллага шөкер, котылам, өстемә бик каты басканнар иде, диде.

Аягөсте генә папкаларны караштырып азапланган Харис сискәнеп китте.

—Кемнәр?

—Исемен сорамадым. Әйтсә дә, мин кемне беләм?

—Димәк, ана янаучылар булган?

—Тыкырдатканнардыр инде. Зур акча бит.

—Кем икәнен бөтенләй чамаламыйсызмы?

—Аның танышларын ничек белеп бетерим мин!

—Бу юлы акчаны каян алганын да әйтмәдеме?

—Анысын әйтте. Ире биргән. Шушы арада гына Израильдән кайткан иде бит Эдигы... Иртәгә иртүк бурычымны түләргә барам, диде Җәүһәрия.

—Димәк, бүген, дигән сүз?

—Шулай килеп чыга.

—Кая барасын әйттеме соң?

—Кафега дип анладым мин. Ремонт турында да шунда сөйләшәбез, диде.

—Анысын кем белән сөйләшәсен дә әйтмәдеме?

—Аның кемнәр белән эш йөрткәнен каян белеп бетерәсең... Моннан күренми. Әйтсә дә, хәтерем начар, шундук онытам.

Харис, зур өстәлдә өелеп яткан чуар кофталарны читкәрәк шудырып, папкаларны куйды.

Нуржиһан кофталарны кочаклап алды да киштәгә урнаштырды. Папкаларда устав, шәһадәтнамә, бухгалтерия кәгазьләре—һәммәсе тәртип белән теркәп куелган. Берсеннән таныкнамә катыргылары килеп чыкты. Тышына җәмгыятьнең тамгасы—кызыл ай белән ак лалә чәчәге ясалган. Яшеле—мөселманнарның яраткан төсе, кызыл ае—халыкара шәфкать хәрәкәте тамгасы, ә ак лалә чәчәге—татарларның милли бизәге, дип анлаткан иде теге чакта Җәүһәрия. Харис, катыргыларны караштырганда, шуны исенә төшерде.

Таныкнамәләр буш иде. Ләкин арадан берсе тутырылган булып чыкты. Харис анда... үзенең фоторәсемен күрде. Әйе-әйе, аның сурәте. "Әхмәтнуров Харис Мирзаянович—җәмгыятьнең вице-президенты" дип язылган, айлы-лаләле мөһер сугылган, президент Байбулатованың имзасы куелган...

Харисның колагын кайнар сулыш пешерде. Аның артына Даниф килеп баскан икән.

—Сез... сез—урынбасар?!—диде ул.

—Шулай килеп чыга...

—Ә нигә...

—Нәрсә?

—Нигә монарчы әйтмәдегез?

—Менә, үзем дә әле генә белдем.

—Ничек алай?

—Шулай.

Даниф аңа чиксез гажәпләнеп карады.

... Теге чакта Харис шагыйрәнең сүзләрен житдигә алмаган иде шул. Әйе, җәмгыятьне оештырып йөргәндә: "Безгә төзүче бик кирәк!"—дип кенә калмаган Җәүһәрия. "Мин сине үземнең урынбасарым итәм әле!"—дип тә өстәгән иде. Ул чакта Харис моны шаяру дип кенә кабул итте, шунлыктан онытып та җибәргән. Ә шагыйрә үз сүзен иткән.

Хәер, житәкче исән чакта урынбасар кем булса да барыбер түгелмени? Кәгазьгә язылган килеш тора инде шунда! Харис ише күзгә күренерлек шәхесләрне нинди генә оешмаларга әгъза итеп кертмиләр дә, кая гына сайламыйлар! Эшләгән кешенең сыртына "общественное поручение"ләрне катлап-катлап өю гадәте коммунистлар заманыннан бирле яшәп килә. Җәмәгать эшләренең кайсына гомергә бер барасың, кайсында елына бер күренеп китәсең, кайсылары үзеннән-үзе юкка чыга, белми дә каласың.

Ә менә бу юлы юкка чыкмаган... Ташка басылып, тимер тартмада үз вакыты житкәнне көтеп яткан. Менә сәгате сукты, юри-мырый гына язылган бу җаваплылык, тартманың капкачы ачылуга, Синдбад жене булып калыкты да, Харисның сыртына менеп атланды. Гүяки каты тезләре белән аның муенын кыса, сулышын буа башлады...

—Әйбәт катыргы бит бу!—диде Даниф, анын пошынуын анламыйча.—Кара, бушлары да бар. Берсен миңа ясап булмыймы?

—Баш өсте... Яз гариза, мин сине эшкә алам.

—Хәзер язабыз аны. Таныкнамәсен бирегез, иртәгәгә карточкамны ябыштырып китерермен.

—Мә, ал,—дип, Харис бер катыргыны Данифка сузды.—Исем-фамилиянне дә язып кил. Иртәгә мөһер сугып, кул куярбыз. Пичәт кая сон әле?—дип Нуржиһанга борылды ул.

—Сейфта түгелмени?

—Юк, күренми,—диде Харис тимер киштәләрнен почмакларын кулы белән сыпыргач.

—Җәүһәрия үзе белән алгандыр,—диде Нуржиһан.

Харис оперативникларның сумканы табып алып килгәнен, анын эчендәге әйберләрне тәрәзә төбенә селкегәннәрен исенә төшерде. Ләкин анда мөһер юк иде! Бомжлар шул мөһергә кызыктылар микәнни? Бомжга мөһер нәрсәгә? Нишли ул анын белән?

—Сонгы көннәрдә, мөһерне сорыйлар, дип зарланган иде,—дип дәвам итте Нуржиһан.

—Кемнәр?

—Анысын мин анламадым. Телефоннан сөйләшкәндә дә шул мөһер аркасында пошаманга төшкән чаклары булды. Нуржиһан апа, бу мөһер дигән нәрсәнен бәһасе бик үсте әле. Минем имзаны ясап куя алалар, ә мөһернен чыны кирәк, документларны шунын белән генә ясап була, дия торган иде.

—Нинди документларны?

—Кафе кәгазьләредер инде. Гел шунын артыннан йөрде бит сонгы вакытта.

Сискәндереп телефон шылтырады. Нуржиһан трубканы алып, сөйләште дә, Хариска борылды:

—Министрлыктан,—диде.—Бүген үк коляска барып алырга кушалар.

—Нинди коляска?

—Инвалид коляскасы.

—Кемгә?!

—Бер инвалидка. Алырга да, илтеп бирергә. Бүген алып калмасак, иртәгә булмас та, диләр. Чөнки районнардан килүчеләр күп. И ходаем, күпме артыннан йөрдек, тагын коры калырбыз микәнни инде?

—Ник аны министрлык үзе илтеп бирми?

Нуржиһаннын борынын мышкылдатып, бутала-бутала сөйләвеннән шул анлашылды: министрлык инвалидларга колясканы илтеп бирми, аны шул гарипнең якыннары барып алырга тиеш икән.

—Апасы белән яши Муллаян. Алтмыштан узган апасы коляска юллаунын рәтен белми. Ансат эш түгел бит ул. Җәүһәрия белән без икәүләшеп әллә күпме йөрдек. Участок врачына гына да өч тапкыр бардым. Муллаяннын үзен китереп күрсәт, ди. Ничек алып барыйм мин аны? Әллә, дим, сез ана яна аяк үскәндер, дип уйлыйсызмы? Көчкә бирде белешмәне. Хәзер менә министрлыкка барып, язуын алырга кирәк, аннары шунын белән базага китәсе.

Нуржиһан Хариска мөлдерәп карады.

—Доверенностька кул куярга пичәт юк бит,—диде Харис. Ул бу мәшәкатьтән котылуны өмет итә иде.

—Пичәтле доверенность бар миндә. Эш кәгазьдән тормый. Колясканы берүзем күтәреп йөри алмыйм. Нишләргә инде?

—Апакай, сез хәзер Харис Мирзаянович кушканны эшлисез,—диде нык итеп Даниф.—Бүгеннән ул президент, приказларны ул бирә.

Харис сәгатенә карады: сәгать өч. Колясканы алып кайтырга өлгереп тә булыр шикелле.

—Әйдә киттек,—диде ул Данифка.

—Кая?

—Колясканы алып кайтабыз. Рас мин президент икән, син монда хезмәткәр бүгеннән. Стажын барыр ичмасам.

—Ә зарплата? Бетегез дә юк бит сезнен.

—Натурлата алырсын. Монда житәрлек,—диде Харис әржәләргә-капчыкларга ишарәләп.—Ысланган тавыклар бар әнә.

—Туктагыз әле,—диде Нуржиһан.—Тәмам башым каткан. Бу тавыкларны нишләтәбез соң?

—Ятсыннар шунда,—диде Даниф.

—Монда ятса, иртәнгә сасып юкка чыга бит алар. Җәүһәрия булсамы? Улмы? Исрафка юл кую юк ул бездә!—дип кинәт калкынды Нуржиһан.—Калдырмыйбыз. Төнлә булса да өләшеп бетерермен! Айлар буе ит заты күрмәгән гаиләләр бар.

Ул өстәлдән көрәнсу тышлы калын журналны алып, сумкасына тыкты. Халатын, җылы кофтасын салып, вак бизәкле күлмәктән калды, аягыннан җылы оекбашларын сыдырып алып, җиңел туфли киеп куйды.

Даниф белән Хариска, тавыкларны катыргы тартмаларга тутырып, машинага чыгарырга туры килде.

* * *

Ин элек Казансу күпере артындагы Короленко урамына киттеләр—социаль яклау министрлыгы шунда урнашкан иде. Ярый, анда Нуржиһанны беләләр икән, ике-өч бүлмәгә кереп, кайсыннан кәгазь яздырып, кайсыннан имза салдырып йөрергә туры килсә дә, беркайда да көттермәделәр.

База исә шәһәрнең бөтенләй икенче ягында икән. Кире Казансу күпереннән чыгып, шәһәр үзәге аша киттеләр.

—Зур җирләрдә беләләр икән үзегезне,—диде Харис.

—Дүртенче колясканы алуыбыз бит инде,—диде Нуржиһан.

—Ә ничек алып кайта идегез?

—Берүзем түгел. Җәүһәрия белән.

—Ул да коляска ташып йөри идеме?—дип сорады Даниф.

—Нишлисең. Кирәк бит.

—Кемгә кирәк?!

—Менә хәзер күрерсез кемгә икәнен,—диде Нуржиһан.

База бик зур икән, иркен ишегалдындагы озын-озын корылмаларның әле берсенә, әле икенчесенә йөреп, кирәкле кешеләрнең башка эштән бушаганын көтеп, кәгазьләр яздырганчы, шактый вакыт узды. Ниһаять, зур катыргы тартманы машинага салып, бөтен шәһәр аркылы кире Казансу артына кайттылар. Эшче районындагы өч катлы иске баракның икенче катына тартманы күтәреп менгезделәр. Ләкин кирәкле ишек бикле булып чыкты.

—Муллаян!—дип кычкырды Нуржиһан битен ишек ярыгына туры китереп.— Мин бу, Нуржиһан. Коляска китердек без сиңа! Сания апа өйдә юкмы әллә?

Ишек артыннан чәрелдек тавыш ишетелде, сүзләре аңлашылмады.

—Өйдә Муллаян үзе генә, ахры,—диде Нуржиһан Харис белән Дарифка борылып.—Ул ишекне ача алмый.

—Көтмәгәннәр, димәк,—диде Даниф иреннәрен кысып.

—Телефоннары юк бит, алдан әйтеп булмады,—диде Нуржиһан гаепле кеше сыман.

—Үзләре белешеп торса ярамаганмы? Соравын сораганнар бит.

—Сораган, дип... Мин аларны үзем эзләп тапкан идем.

—Үзегез?!

—Әйе. Инвалидларның исемлеген алдым да өйдән-өйгә йөрдем. Шунда Муллаянга юлыктым. Гомеренә бер тапкыр да коляска алганы булмаган. Чиратсыз алып бирдек менә.

—Ә чираттагы гарип утырып калдымы? Аның өлешенә кердегезме?

—Чираттагысы алыр анысы,—диде Нуржиһан тыныч кына. Данифның ярсуына аның бер дә исе китмәгән иде.—Менә Муллаянга без булмасак мәңге тәтемәячәк иде.

—Нишләп тәтемәсен? Аларны кайгыртыр өчен хөкүмәтнен махсус кешеләре бар! Акча алып утыралар! Ә сез шулар өчен эшләп йөрисез. Кем кушты сезгә?

—Җәүһәрия...

Даниф, юка иреннәрен чәйнәгәндәй итте.

—Беләсезме нәрсә? Монын өчен сезне хөкемгә тартып, утыртып куярга кирәк!

—Ну, син арттырып җибәрәсең инде,—дип йомшак кына каршы төште Харис.

—Күпме вакыт йөрибез инде без? Дүрт сәгать! Америкада, әнә, идән себерүче дә сәгатенә биш доллар ала. Безнен икебезгә кырык доллар, дигән сүз! Бер инвалидның арбасын икенчесенә бирер өчен! Кемнендер ахмаклыгы аркасында, нишләп әле мин алтын вакытымны юкка сарыф итәргә тиеш?

—Шулай килеп чыкты бит, нишлисең... Нурҗиһан апаның гаебе юк...—диде Харис теләр-теләмәс кенә. Дөресен генә әйткәндә, ярты көн буе болай болганып йөрү аны да нык туйдырган иде.

—Гаебе юк, дисен? Менә мондый эшләрне оештырып йөрүчеләр... алар... алар...—Даниф ярсуыннан сүз таба алмый торды.—Алар үз вакытларын, үз акчаларын гына җилгә очырып калмыйлар! Ул акчаларны файдалы эшкә тотсаң, ул бинада кирәкле әйбер ясасан, яхшырак булмас идемени? Юк, ана бушка өләшергә кирәк! Эш кешесенә аяк чалып йөрергә тапканнар сылтау! Өйләр буйлап, сезгә бирәр нәрсә кирәкмиме, дип сорашып йөриләр, имеш. Һәркемгә нидер кирәк! Әнә, бу ишекләрнен теләсә кайсын шакып карагыз: зарланмаган кеше булырмы?

Ул тузанлы лампочкалар белән яктыртылган озын коридорнын ике ягында тезелеп киткән, кыршылган, ямьсез ишекләрнең берсен ярсып төйде.

—Нормаль кеше шулай йөриме? Андыйларны сары йортка илтеп ябарга кирәк!

Ишек ачылып, базык гәүдәле, ак яулыклы апа күренде.

—Сания апа! Син монда икәнсең бит!—диде Нурҗиһан сөенеп.

Муллаяннын апасы булып чыкты бу. Күршесендә биләмдә утырган икән.

Ләкин аннан сон да тиз генә чыгып китә алмадылар.

Муллаян, карт чырайлы, үсмер малай хәтле генә арык гәүдәле, ике аягы корышкан адәм, үзе колясканы җайлый алмаячак иде. Тартмадан тимер көпшәләрне, тәгәрмәчләрне, утыргычны чыгарып, кәгазьләрен укып, җыярга, гарипне тимер караватыннан күтәреп алып, арбага җайлап утыртырга туры килде. Ул шундук коридорга чыгарга талпына башлады һәм арбасы белән ишек төбендәге зур шкафка барып төртелде.

—Өйдән чыга алмый бик тилмерде шул инде,—диде Сания.—Монарчы мин күтәреп йөртә торган идем дә, хәзер булдыра алмыйм, билем сызлый...

Данифның эчендә кайнаган ачудан күлмәгенә ут кабар кебек иде. Әмма Нурҗиһан шаккаткыч үзсүзле булып чыкты.

—Артыннан шулхәтле күп йөрелде, җиренә житкермичә беркая да китмибез,—диде ул.

Шкафны күчерергә, анын өчен караватны читкәрәк шудырырга кирәк булды.

Ниһаять Муллаян бүлмә ишегеннән чыкты. Арбанын зур тәгәрмәчләрен ике куллары белән әйләндереп, коридорнын аргы башына китте. Нурҗиһан—куанычыннан балкып, Даниф—ярсып, Харис талчыккан кыяфәт белән ана карап калдылар.

—Ай, онытып китмим тагын, күчтәнәчем дә бар бит әле!—диде Нурҗиһан Саниягә.—Хәзер икегезгә ике тавык алып менәм. Булгач-булгач чын бәйрәм булсын!

* * *

–Жәүһәрия исән булса, тавыкларның калганын аңа гына керткән булыр идек, иртәнгәчә суыткычына куеп торыр иде,—диде Нурҗиһан, ниһаять Муллаяннардан чыккач.—Өйләре әнә генә бит.

Һәм, биш катлы йортлар артыннан калкынып, еракган күренеп торган тугыз катлы бинага ишарәләде. Кояш нәкъ шул йорт артына кереп бара, аның нурлары кызыл кирпеч диварлар тирәли сирпелеп, сихри балкыш хасил иткән иде.

—Фатирны әйбәт йорттан эләктереп калганнар!—диде Даниф.—Блатлары зур булгандыр, күрәсең.

—Ничәнче квартир?—дип сорады Харис.

—Унсигезенче. Еш була идек без аларда.

—Өйләрендә кеше бар,—диде Харис.

—Каян беләсез?—дип сорады Нурҗиһан.

—Әнә, берәү тәрәзәне ябып, пәрдәләрен корып маташа.

—Ничек күреп алдыгыз әле? Мин ничә тапкыр кереп, тәрәзәләрен белми идем.

—Сез белмәссез. Ул төзүче бит,—диде Даниф.—Димәк, чыгарганнар Букштейнны. Ябып куймаганнар.

—Ә бәлки, башка берәүдер?—диде Харис.

—Кереп чыгарга кирәк,—диде Даниф.

—Нәрсә дип?

—Пичәт өйләрендә түгел микән.

—Мондый чакта кешене юк-бар белән борчу килешмәс бит,—дип икеләнде Нурҗиһан.

—Нинди юк-бар булсын. Пичәтсез президентыгызны күмәргә акча да юнәтә алмаячаксыз. Сез бу тавык үләксәләрен аткарып йөргән арада, кереп чыгабыз без анда.

...Унсигезенче фатирның кара дермантин белән тышланган ишеге ачылып, эчке якта кара спорт киеме кигән, кара күзлекле Эдуард күренде.

—Исәнмесез,—диде Харис.— Без хәйрия җәмгыятеннән. Кайгыгызны чын күңелдән уртаклашабыз. Безнең өчен дә бик зур югалту... Төзәтеп булмаслык...

—Ни йомыш?

—Бәлки, берәр төрле ярдәм кирәктер. Транспорт мәсьәләсендә...

—Сез белмисездер, бәлки, Харис Мирзаянович—җәмгыятьнең вице-президенты,—дип Харис янына килеп басты Даниф.—Ә мин шунда эшләүче.

Эдуардның кара сакал-мыегы арасында алланып торган иреннәре кысылды. Карашыннан сирпелгән салкынлык күзлек пыялалары аша да сизелә иде.

—Юкка борчылгансыз. Жаннаны кайгыртучылар житәрлек. Бар редакция, бар Язучылар союзы.

Ул тагын Җәүһәрияне "Жанна" дип атады. Бу янә Харисның күңелен авырттырып тырнап узды.

—Көндез өйдә туры китерә алмабыз, дип уйладык, шуна кич килдек, гафу итегез,—диде ул.

—Килдегез, әйттегез. Күңелегез булгандыр. Хушыгыз.

Ул ишекне үзенә таба тартты. Даниф ишекне үз ягыннан тотып алды:

—Туктагыз! Ә пичәт?

—Нинди пичәт тагын?

—Җәмгыятьнең пичәтен тапмадык,—диде Харис.—Җәүһәрия Газизовна үзе белән алып киткән булса кирәк. Бәлки, өегездә калдыргандыр. Сез безне гафу итегез инде, ләкин, үзегез беләсез, оешмада пичәтсез—ике кулсыз.

Букштейн бераз икеләнеп торды, аннары бер карарга килгәндәй:
—Хәзер өстәленнән карыйм,— дип өенә кереп китте. Ишекне ачык калдырды, әмма керергә чакырмады.

Даниф әллә ничә бүлемле, калькуляторлы, язу кенәгәле модалы сумкасыннан сигарет кабы чыгарды да Хариска сузды.

—Тартмыйм. Сина да кинәш итмим.

—Кинәшләргә мохтажлык юк анысы,—диде Даниф тирән сулап.— Кинәш мае янына акча боткасы булсын иде ул.

Ул хикмәтле сумкасыннан шундый ук әкәмәт зажигалка чыгарды да, сигаретын кабызып, йотылып суырды.

Лифттан зур пластик букча күтәргән, чигүле кызыл калфак өстеннән челтәрле ак яулык бөркәнгән, өстенә яшел жилән кигән, калын күзлекле әбекәй килеп чыкты. Соңгы вакытта, гарәпләр белән элемтәләр янарып, Татарстаннан хажга баручылар күбәйгәч, мәчет карчыкларынын кайберләре шулай хикмәтле киенә башладылар. Әби ачык ишеккә, аннан егетләргә карады да:

—Исәннәр генәмесез,—диде.—Кертмиләрме әллә?

—Чакырмыйлар шул,—диде Харис.

—Жәүһәриянең туганнарымы әллә сез?

Мондый апакайлар төпченүчән, һәрнәрсәгә кысылучан, күпне белүчән һәм күпкә өйрәтүчән булалар. Башка очракта Харис аның белән сүз куертып тормас иде. Ләкин монда Жәүһәрия турында сүз чыкты бит. "Бергә эшләдек",—дип әйтмәкче иде ул, тыелып калды. Жәүһәриянең һәлакәтен әбекәй, бәлки, белмидер әле?

—Эшеннән килдек,—диде ул.

—Эшеннән булгач, бусагасыннан атлатмас шул инде,—диде әбекәй.— Мин Рәзинә апагыз булам. Күршеләре. Сезгә кем дип эндәшергә инде?

—Мин Жәүһәрия Газизовнаның урынбасары, исемем Харис. Ә бу Даниф.

—Бик яхшы, бик яхшы. Мин анын эшенә еш баргалыйм. Сезне генә туры китергән булмады.

—Без бит анда даими утырмыйбыз. Төп эшебез башка урында.

—Шулайдыр шул. Анда зарплат түләмиләр бит. Ә тамакны ничектер туйдырырга кирәк... Шуна күрә дә инде Жәүһәриянең бу шөгылен бер генә дә өнәмәде Эдигы. Жене сөймәде. Бер уйласаң, аны да аңларга була. Хатынының бушка эшләгәнен кайсы ир яратсын?

Фатир эченнән аяк тавышлары ишетелде, карчык шым булды.

—Здрастуй, Эдик,—диде Рәзинә апа жыерчыклы ак йөзенә елмаю галәмәте чыгарырга тырышып. Һәм, яулык читен кайтарып, күз төпләрен сөртеп алды.—Какое горе, ай алла, какое горе!..

—Өстәлендә пичәт юк,—диде Эдуард коры гына.—Нишләп әле ул өйдә булырга тиеш? Эшегездән яхшылап карагыз.

—Мәрхүмәне жирләү кайчанрак...—дип Харис авыз ачкан иде, Букштейн:

—Кирәк булса, әйтерләр,—дип кырт кисте.—Хушыгыз.

Һәм ишекне шап итеп ябып та куйды.

—Адәм рәтле итеп гүргә дә индерә белмәс бу,—диде әбекәй каты пышылдап.—Сез ана гына ышанып тормагыз, женаза эшләрен үз кулыгызга алыгыз. Әйдәгез әле, әйдәгез, мина кереп сөйләшик. Милициядән дә килеп сорашып йөргәннәр иде иртәнге якта. Тик аларга барысын да әйтеп бетереп булмый бит. Свидетель итеп куйсалар, башын бетәр.

Ул шулай дип сөйләнә-сөйләнә, жилән кесәсеннән озын, сырлы ачкыч алып, янәшәдәге ишекне ачты. Егетләр ана иярделәр.

Ишек төбендә сандалиларын салып, әдәп белән эчкә уздылар. Бүлмә пөхтә итеп жыештырылган, тәрәзә төбендә кызыл яраннар чәчәк атып утыра иде. Чуар хәтфә жәелгән диванга утырдылар. Әби урындыкка урнашып, ике учын кушырып күтәрде:

—Йәгез, бер дога. Рабби әнзилни мөнзилән...

Егетләр дә, кушучларын бит турына күтәреп, иреннәрен кыймылдаттылар.

—Я раббым, мәрхүмәнең урынын җәннәттә кыл. Гөнаһларын ярлыка, раббым... Мәрхәмәтен киң... Изге җанлы кеше иде... Күпме мескеннәрнең хәлен җиңеләйтте, күпмесенә мәрхәмәтле кулын сузып, күңел җылысын бирде... Миңа кылган игелекләре дә санап бетергесез... Башымдагы яулыгым да аның бүләге... Ничек үтергәннәр соң аны?—дип, кинәт сүз сөрешен үзгәртеп, калын күзлек пыялалары аркылы бер Хариска, бер Данифка чәнчеп-чәнчеп карап алды әбекәй.

—Милиция әйткәндер бит?—дип сорауга сорау белән җавап бирде Даниф.

—Нишләп миңа әйтеп торсыннар, ди? Милиция җавап бирергә түгел, сорау алырга килә ул! Шул кафеда тапканнар икән мескенкәй генәмнең гәүдәсен... Мәете кайларда ята икән? Янында дога укучы бар микән?

—Моргка илттек,—диде Харис.

—Кая барып башына җиткән бит, ерткыч!—диде әби ярсу белән.

—Кем?!—дип икесе бер авыздан сораганнарын үзләре дә сизми калды егетләр

—Әллә каян килгән кеше түгелдер инде,— диде Рәзинә апа иреннәрен каты кысып һәм, кыяга кунган бөркет кебек, иңбашларын кабартып куйды.—Җәүһәрия моннан иртән генә чыгып китте бит.

—Каян?!

—Миндә кунды ул. Менә шушы, сез утырган диванда йоклады. Иртәнге сәгать алтыда торып, чәйләр эчеп, җидедә чыгып китте. Теге зөбани белән бер табактан ашыйсы да килми, диде. Өйгә кереп киенеп, кирәк әйберләремне алам да китәм мин, диде.

—Әйберләре өендә калган идемени?

—Өендә булмый, кайда булсын. Өстендә халат, аягында башмак кына иде кич килеп кергәндә. Бик ярсыган, гасабиланган иде мескенем. Күрәсең, ут ягып талашкан булганнардыр. Әллә бәреп үтерер, дип тә курыккандыр инде. Көчкә чыгып ычкынган төсле иде кыяфәте.

—Эчәме әллә Эдигы?

—Башын җуеп исергәнен күргәнем булмады булуын, гөнаһсына керә алмыйм. Әмма бәгыре таш мөртәтнең. Исеректән яман.

—Кыйный идеме әллә?—дип сорады Даниф.

—Шул кыйнар чиккә җиткәч, чыгып качкандыр инде Җәүһәрия мескенкәй. Теге мәлгун, телефоннан чылтыратып, households сездәме ул, дип тә сорады әле. Мин юк дидем инде, Җәүһәрия әйтмә дип ым какты чөнки.

—Ул сездә еш куна идеме?

—Булгалады инде, булгалады. Көн талаш, төн талаш, ничек чыдамак кирәк. Аерылышкан ир белән бер фатирда яшәүләре тәмуг шул инде ул!

—Низагның сәбәбе нәрсәдә иде соң?—дип сорады Харис.

—Бөтен хикмәт—тамырда, нәсел-нәсәптә,—диде әбекәй бик серле итеп.

—Нинди тамырда?

Әбекәй, шуны да белмисезме әллә, дигәндәй, егетләргә кистереп карады.

—Соң элегрәк халык нәсел-нәсәбен, телен-тамырын онытып бара иде бит. Һәммәсе бер иш урыс булып беткәннәр иде. Хәзер менә яна искән саф җилләр күп кешеләрнең күңеленә утырган тузанны туздырып алып китте, нәсел тамырларын ачты. Җәүһәрия электән үк бик татар җанлы иде үзе. Шәһәрдә үсеп, урыс мәктәбендә укып кына харап булган. Хәзер менә үз халкына хезмәт итәргә талпынды, хәер җәмгыятен оештыруы да шуңа бит инде. Эдигының җене каршы булса да, куркып тормады. Шуннан китте инде. Тормыш арбасын берсе мәшрикъкә, икенчесе мәгърибкә өстери башладылар...

Рәзинә апа бу хакта күп уйланган булса кирәк, эчен бушатасы

килә иде. Ул ара-тирә күзлек астына кулъяулыгын тыгып, керфекләрен сөрткәләп, борынын мышкылдатып сөйләде дә сөйләде. Аның кыйссасы дәвам иткән саен Хариска Җәүһәриянең тормыш фаҗигасы тирәнрәк ачыла барды.

—Мин ул Эдикны монарчы татар дип белә идем, шәһәр баласы булганга гына үз телен өйрәнмәгәндер, дип уйлый идем,—дип дәвам итте апа.— Гәзиттә дә шигырьләре "Кабиров" дип чыга торган иде бит. Берзаман яһүд ясады да куйды бу үзеннән. Илен, денен сатты да куйды, мөртәт! Израильдә акчаны күп бирәләр, имеш, шунда бара да байый, имеш!

—Баюын баегандыр бит,—диде Даниф.—Чит илдә акчаны күп эшлиләр.

—Аның баюыннан ни файда? Гаиләсен иркенәйтә торганмыни? Карунның да каруны, имансыз! Гомер буе акча санап Җәүһәриянең тенкәсенә тиде.

—Еш кайтамы соң?

Букштейн кыш та, көз дә кайткан. Алты яшьлек улы Маратны үзе белән алып китеп, яһүд мәктәбенә кертмәкче, шунда укытмакчы икән. Җәүһәриянең исә улын монда, үз туган телендә укытасы килә. Хәзер дә малай татар балалар бакчасы белән бергә урманда, лагерьда ял итә икән.

—Тоташ тарткалаш китте инде алар арасында. Бала өчен талашалар. Фатир өчен...

—Ә фатир өчен ник тарткалаштылар?

—Өйләре Җәүһәрия исемендә иде бит. Язучылар оешмасы ана биргән, чөнки ул анда әгъза иде, ә Эдикны ни йөреп тә кабул итмәделәр. Хәзер шул фатирны саттырмакчы да, акчасына Израилендә ит кибете ачмакчы.

—Ит кибете? Ул итчемени?

—Башына төшсә, башмакчы булырсың. Дуңгыз мае сатып баемакчы анда бу адәм. Аның эшләгән акчасы да харам!

—Булмас!—дип сүзгә кушылды Даниф.—Яһүдләр дуңгыз ашамый.

—Мин дә шулай уйлаган идем. Җәүһәрия әйтә, анда бездән киткән урыслар, украиннар бихисап икән, ди. Яһүд булып язылганнар, ә эчтән урыс булып калганнар. Дуңгыз маен тансыклыйлар, ди. Шундыйлар өчен аерым урыннарда махсус кибетләр ачканнар. Бик төшемле эш икән.

—Кара син аны, елгыр икән үзе. Болай карап торганда, бер дә андыйга охшамаган,—диде Даниф.

—Уклау йотканмыни, турыга каткан, башын борып сәлам дә бирә белми,—диде апа.—Ә менә тегендә баргач, гәүдәсе урталай сынып бөгелгән, дип сөйләде Җәүһәрия. Шаккатып кайткан иде.

—Ул Израильгә барып кайттымыни?!—дип сорады Харис гаҗәпләнеп.

—Барды-барды! Бер айга дип киткән иде, җаны түзмәгән, егерме көннән кире кайтып төште. Эдик бер кибетчегә ялланган, идәнен дә үзе юа, урамын да үзе себерә, ди. Имеш, моннан киткәннәр башта шулай түбән эштә бер-ике ел талкыналар икән дә, шуннан соң гына калкынып китәләр икән. Беркайда да бәлеш пешереп куймаганнар! Анда бит өр-яңадан тел өйрәнергә кирәк. Бөтенләй чит кавем теле бит ул! Танышлар юк, гадәтләре сәер, бер генә дә рәхәт түгел, дип кайтты инде Җәүһәрия. Иле кысынкы, ди. Җире тау да чүл, ди. Сыерларына хәтле безнеке төсле түгел, әллә нинди олы чырайлы ят хайваннар, ди. Озын чәчләрен баш артына пумала итеп бәйләп куйган егетләр сыер сава, ди. Шул безнең илдән акча эшлим дип киткән имансызлардыр инде алары да. Анда да шул бездәге кебек калхузлар бар икән, кибус дип атала диме. Сыерларына ашатырга үзләрендә үлән дә җитми икән, печәнне Иорданиядән китерәләр, ди! Фатирымны да сатмыйм, баламны да бирмим, дип, иренә дә, иленә дә бөтенләй арка белән борылып кайтты Җәүһәрия. Аерылышам дип судка гариза бирергә йөрде. Кече бүлмәсенең ишегенә йозак салдырды. И-и, анда бикләнеп кенә ул мөртәттән котылып буламыни!

—Алайса, бүгенге хәлләр Букштейн өчен әйбәт булып чыга икән...—дип сузды Даниф үзалдына уйлангандай.

—Үз дигәнен итәчәк инде хәзер,—дип аның сүзен шундук хуплады Рәзинә.—Баласын алып китә. Фатирын сата. Морадына ирешә болай булгач... Башына житте тәки, Ғлланың ачы каһәре төшкере!—дип почмакка карап, үзалдына сөйләнгәндәй әкрен тавыш белән, ләкин катгый итеп нәтижә чыгарып куйды ул кинәт. Аның бу сүзләреннән Харисның эче жу итте.

—Үз күзегез белән күрмәгән бит!—диде ул.

—Андыйны күрсәтеп эшлиләр, димени? Аннары ул бүген китеп тә барасы иде бит! Ничек туктатып калганнар әле! Ничек житешкәннәр! Милицияне эшләми димәссең!

—Жәүһәрия сездән ничәдә чыгып китте?—дип кабатлап сорады Харис.

—Жиде тулган иде. Хәзер киенәм дә китәм, тугызга барып житәргә кирәк, диде.

—Ничәгә диде, ничәгә?!.

—Тугызга,—дип, башын игәләде карчык.—Бик яхшы хәтерлим. Мин, диде, хәзер үз эшем белән китәм, Эдик үз ягына китә, диде. Котылам, Аллага шөкер, диде.

—Озатам, димәдеме?—дип сорады Харис.

—Юк, юк! Әйтәм бит, араларында боз тавы каткан иде!

—Кая ашыкканын ишетмәдеңме?

—Кафе тирәсенәдер, дип аңладым мин. Соңгы айларда шуның белән башы каткан иде бит инде. Шунда харап итәрләр, дип кем уйлаган!

Харис, тамагына тыгылган тыгыз төенне йотарга тырышып, урыныннан кузгалды.

—Тикшерерләр, белерләр,—диде.

—Ай Алла, сүзгә мавыгып, чәй куярга да онытып жибәргәнмен,—дип каударланып торып басты Рәзинә апа.

—Юк, рәхмәт. Вакытыбыз юк.

—Женазаны безнечә үткәрәсе иде бит, мөселманча. И ходаем, артыннан ныклап йөрер кешесе дә юктыр әле! Беләсездер инде, апасы Харьковта кияүдә бит аның. Аналары жәй торырга дип шунда киткән иде. Аларга хәбәр иттегезме соң? Кайтып житәрләр микән?

—Анысын ире кайгыртыр, бәлки,—диде Даниф.

—Ана гына ышанып торырга ярыймыни! Берүк күз-колак булыгыз!

Егетләр саубуллашып чыгып киткәндә, апа аһ-ваһ итеп калды. Баскыч янында Даниф янә тәмәке кабызды:

—Нәрсә, апасы мәсьәләсендә белешәбезме соң?

—Бәби түгел, аңа гына башы житкәндер,—диде Харис.

—Алай да исенә төшереп китсәк, зыяны булмас.

—Миңа кушма,—диде Харис. Аның Букштейнны күрәсе килми иде.

—Ә нәрсәгә аннан куркып торырга? Ул курыксын. Жинаять кылуда шикле кеше ул хәзер,—диде Даниф, авызыннан озын төтен тасмасын кара таплар сыланган түшәмгә өреп.—Ничек чыгарганнар әле үзен. Беркая да китмәскә, дип имза куйдырганнардыр, мөгаен. Шул була ул менә үз хатыныңа үзең хужа була белмәсәң. Акыллы кеше хатынын үтерми, акыллы кеше хатынын менә болай бөкләп учында гына тота.

Ул ак йодрыгын болгап куйды. Аннары төпчеген лифт ярыгына тыгып сүндерде дә, унсигезенче фатирның кыңгырау төймәсенә төртте. Ишек көттереп ачылды. Эдуард кулын тоткадан алмый гына:

—Нәрсә тагын?—дип сорады.

—Мәрхүмәнең әнисенә, туганнарына хәбәр иттелдеме?—диде сорау алгандай Даниф.

—Пошел вон, дурак!

Эдуард бер кулы белән аны этеп жибәрде дә, икенче кулы белән ишекне үзенә тартты. Эчке яктан аның:

—Үзләре шул эшкә тартып керттеләр, үзләре башына життеләр, хәзер монда килеп йөриләр!.. Нинди каһәр суккан ил бу! Нинди кабахәт халык бу! —дип үзалдына сөйләнгәндәй сукранганы ишетелде.

Харисның күз алдыннан яшен яшьнәгәндәй булды. Букштейнның да башы бар, ул да нидер уйлыйдыр. Кемнәндер шикләнәдер яисә... гаепне кемгә дә булса сылау чараларын эзлидер. Хариска түгел микән?! Данифның сүзләре аның зиһененә томан аша килеп ирешкәндәй булды.

—Тәмам ычкынган бу. Намусы тынгы бирмидер.

—Син инде кешене тотып ябып куярга әзер,—диде Харис.—Үз күзең белән күрмәгән. Аннары ана аэропортка барып житәргә кирәк иде бит әле. Ул арада каян өлгерсен?

—Аэропортка егерме минутлык юл ана...—диде Даниф.—Анысын гына санап куйгандыр инде. Бик акыллы күренә.

... Харис өенә соң кайтты. Каршына йөгереп килгән биш яшьлек улы Тәбризне кочагына алып, Гүзәлиягә, төзелешкә барган идем, тоткарландым дип авыз ачарга өлгермәде, хатыны:

—Милициядән шылтыраттылар,—диде.—Иртәнге сигезгә килеп житсен, пропуск әзер булыр, диделәр. Исемен, телефонын язып алдым әнә.

* * *

Трестта эш иртәнге сигездә башлана, әмма житәкчеләр ярты сәгатькә алданрак килергә күнеккән. Шәһәр хужаларының да күбесе сигез тулганны көтми, егерме минут алдан үз урынында була, нәкъ шул вакытта иң мөһим мәсьәләләр хәл ителеп куела. Харис та, сигезенче яртыда эшенә кереп, трест начальнигы белән сөйләште, бер атнага ял сорап гариза язды. Аннары тикшерүче янына китте.

Ул алданрак килгән булып чыкты, милиция бүлегенең ишек төбендә бераз көтеп торырга туры килде. Мансур Хужиевич аны ерактан ук күреп алса да, ашыкмады, салмак адымнар белән якынлашып, кулын сузды:

—Хәерле иртәләр.

—Исәнмесез?!

Ә иртә аяз, тыныч иде. Харисның каршысына килеп баскан кыска жиңле зәңгәрсу күлмәкле абзыйның саллы гәүдәсе, сирәгәйгән чәчле йомры башы авылдагы ил агасын хәтерләтә иде. Бу кояшлы жәйге иртәдә аның белән басуларда йөрергә, башак чыгарып, серкә очырып утырган иген кырларын инләргә, башны югары күтәреп тургай сайравын тыңларга, яисә, чәчкәләр исенә исереп, печән чабарга кирәк иде кебек. Алар исә, күкрәкләрен киереп сахраларның татлы һавасын сулыйсы, тиргә батып эшләп аргач, иелеп салкын чишмәнең суын эчәсе, һич булмаса, Казансу буеның кызу комына жәелеп ятып, табигатьнең шигырь белән генә әйтеп була торган гүзәллеге, тылсымлы кодрәте, яшәүнең, мәхәббәтнең ләззәте турында әңгәмә корып арганнан соң, салкынча суга сикерәсе урында, ярым-караңгы, тынчу бинага кереп, көрәнсу обойлары кыршылган коридор буйлап киттеләр.

Тикшерүче бүлмәсенең тәрәзәсенә юан, сырлы тимердән аркылы-торкылы китереп ямьсез рәшәткә кагылган иде. Анда-санда обойлары купкан стеналарны, идәннең ертылган линолеумын, иске урындыкларны күргәч, тәмам күңел төште. Сул як стена буендагы шкафның китап тулы киштәләре генә сулышны бераз иркенәйтеп жибәргәндәй итте. Мансур Хужиевич, рәшәткә аша кулын сузып, тузанлы тәрәзәне ачты. Ян стена буендагы өстәл артына утырып, каршысындагы урындыкны тәкъдим итте.

Харис утырды да, артына әйләнеп, тагын китап шкафына күз салды. Анда төрле кануннар, милиция, тикшерү эшләренә кагылышлы басмалар гына түгел, алырга уңайлы урында, урта киштәдә әдәби әсәрләр,

ә почмактагы тәбәнәк өстәлдә кечкенә телевизор тора, гәзит-журналлар ята иде.

—Җәүһәрия Байбулатованы сез күптәннән белә идегезме?—дип сүз башлады Мансур Хуҗиевич.

Харис, кыска гына итеп, студент яшьләр арасында еш була торган гадәти танышу тарихын, дуслашып китүләрен, Җәүһәрия кияүгә чыкканнан соң элемтәләре өзелүен, соңгы елда, җәмгыятьне оештыру чорында гына, берничә тапкыр очрашып, телефоннан сөйләшкәләп торуларын сөйләп бирде.

—Аз аралаштык, дисез инде алайса. Ләкин сез аның урынбасары икәнсез бит!

—Әйтсәм ышанмассыз, ләкин мин моны үзем дә кичә генә белдем.

—Ничек алай?

—Мин оештыру конференциясенә бармаган идем.

—Нишләп?

—Бирергә акча юк, эшләргә дәрт юк, киңәш итәрлек акылым юк, өйрәтергә тәҗрибә юк. Кеше арасында түмгәк булып утырудан ни мәгънә, дип уйладым. Урынбасар итеп сине сайладык, дип әйткән иде ул миңа. Мин аны житдигә санамадым, онытып ук җибәргәнмен. Кичә таныкнамәне күргәч кенә искә төште.

—Ничек инде... Исеме генә дә ни тора бит: вице-президент!

—Хәзерге заманда үзеңне Болак арты дәүләтенең ханы дип тә игълан итеп була,—диде Харис.—Мөһер сугылган катыргыларның нинди-ләре генә юк. Үзегез беләсез.

—Алай да... Җәмгыять эшенә бөтенләй катнашмагач, ничек түзгән ул сезгә?

—Нишләтсен ул мине... Кисәтү бирә алмый, эш хакын кисеп кала алмый... Чөнки юк бит ул эш хакы...

—Алайса, нигә соң ул сезне алыштырмаган? Нигә башка берәүне урынбасары итеп куймаган?

Харис башын иеп уйга калды. Чыннан да, нигә Җәүһәрия аның “вице-президент” дип язылган таныкнамәсен ертып ташламады икән?

—Кызыгыр урын түгел бит. Ризалык бирүче табылмагандыр,—дип мыгырданды ул башын иеп.

—Шулай микән?—дип шик белдерде Мансур Хуҗиевич.—Андый урынга гадәттә кеше табыла. Эш сораучы юк, җаваплылыгы юк. Ә менә файдасы тиеп кую бик тә ихтимал.

—Нинди файда?—диде Харис кичә генә тавыклар белән, коляска белән нужарганнарын исенә төшереп.

—Ни дисәң дә, кесәңдә матур гына катыргы барында, кирәкле кешегә күрсәтеп, тел тегермәнеңне эшкә җиксәң, берәр төрле ярдәм алып була. Яки үзенә кирәкле кәгазьгә кул куйдыру җиңеләя. Җәмгыять счетына акчалар да кергәләгән.

—Белмим... Кызыксынганым юк...

—Дөрес, кергән акча читкә китмәгән, тиешлегә тотылган. Әмма үз кесәсенә шудырса да, тиз генә якасына килепябышучы булмас иде. Казна акчасы түгел ич.

—Җәүһәрия карак түгел иде.

—Аны сез белгәнсездер. Ә без һәммәсен тикшерергә тиеш. Җәмгыятьнең шәһәр үзәгендә үз куышы, телефоны бар. Анда сыенып, рәхәтләнеп бизнес белән шөгыльләнергә була. Байбулатовага андый тәкъдимнәр белән килүче юк иде, дисәгез, сезне шыр ялганчы диячәкмен.

—Аның кемнәр белән ни сөйләшкәнен мин каян белеп бетерим?

—Авыллардан машина белән он, ярма китерү очраклары да булган, бигрәк тә көз көне,— дип дәвам итте Мансур Хуҗиевич.—Ярдәм алган фәкыйрьләрнең исемлеге калын бер журнал.

—Сез җәмгыять хәлләрен миннән яхшырак белеп алгансыз!—диде Харис.

—Инде менә бина биргәннәр. Зур байлык ул бүген.

—Нинди байлык ди ул? Хәрабә! Аны торгызу мондый җәмгыять кулыннан киләме?

—Сез Байбулатовага да шулай дип әйткән идегезме?

—Өлгермәдем. Кичә сөйләшергә тиеш идек.

—Әйе, икәүдән-икәү генәме?

—Әйе, икәүдән-икәү. Даниф очраклы гына туры килде. Минем машина ремонтта, шуңа аның машинасы белән бардык.

—Ә ул кемегез?

—Танышым.

—Ачыклабрак китегез әле—танышлыгыгыз ни дәрәҗәдә һәм кайчаннан бирле. Кем ул, ниндирәк кеше...

Хариска Даниф турында белгәннәрен кыскача гына сөйләп бирергә туры килде.

—Алар Байбулатова белән таныш иделәрме?

—Минемчә, ул аның шигырьләрен газеталарда укып, Жанна Баянова дип кенә белә иде.

—Безнен кебек икән,—диде Мансур Хужиевич.—Мин дә әлегә аның кемлеген шигырьләре буенча чамаларга тырышам.

Мансур Хужиевич өстәленнән юка тышлы кечкенә китап алды. Жанна Баянованың шигырь китабын...

—Бер шигырен укып карыйк әле,—диде.

Керфегенә юкә чәчәгенең
Бал тамчысы булып кунсамчы...

—Бусы мина авыл малае буларак нык тәэсир иткәндер инде. Ә менә тагын:

Гашыйк егет—горур бөркет,
Килмә минем каршыма,
Алып менәм, дип, күкләргә,
Йолдызлар арасына.
Әйтмә мина, карама, дип,
Дәрьяга, дулкыннарга,
Вәгъдә бирмә, ташламам, дип,
Суларга, чоңгылларга.
Чыгар җилләр, кубар давыл,
Аучы төзәп ук атар,
Йолдыз булып атылырмын
Күкләрдән упкыннарга.

—Мондый шигырьләр, гадәттә, кемгәдер багышлап языла. Ул кемнедер күз алдында тоткан. Букштейнны микән?

—Юк!—дип кычкырып ук җибәргәнен сизми дә калды Харис.

—Ә ничек алай кистереп әйтә аласыз?

—Аның бу җыентыгы студент чагында чыккан бит. Ул елларда китаплар озак чыга иде. Димәк, шигырь икенче-өченче курсларда укыган чакта язылган. Анда бернинди Букштейн юк иде әле!

—Шулай дисезме?

—Кичәләрдә бер булмаса бер күренер иде!—диде Харис кайнарланып. Ул яшьлек хатирәләрендә калган кыска гына вакыт эчендә булса да Җәүһәриянең бердәнбере булырга тели иде.

—Алайса, бәлки, сезгә багышлангандыр?—дип текәлеп карады аңа тикшерүче.

Харис башын иде. Әйе, Җәүһәрия аңа шигырьләрен укыштыргалый иде. Ләкин нәкъ менә монысын укыганы булмады. Ә бәлки, чыннан да "горур бөркет" ул—Харистыр? Ләкин Букштейн түгел!

—Бу эшне тикшерә башлагач, мин Баянованың ике китабын да укып чыктым,—диде Мансур Хужиевич уйланып.—Йөрәк очыннан өзеп язылганнар. Хисле, кайнар... Шигырьләрендә генә шундый дәртле идеме ул, әллә тормышта дамы?

Харис карашын өстәлгә текәде. Дәшмәде.

—Темпераментын, ни дәрәҗәдә тотнаклы булуын сизми калмагансыздыр бит,—дип соравын ачыклабрак әйтте тикшерүче.—Бәлки, ул шигырь язганда гына шулай хисләнгәндер? Чынлыкта исә ир затын артык

кирәксенмәгәндер? Кияүгә дә ата-баба йоласын үтәү йөзеннән генә чыккандыр? Азгыннар үрчегән бу заманда хиссез, ягъни фригидный хатыннар күп, диләр. Байбулатова шул кавемнән түгел идеме?

Харис куырылып килде. Күңелнең иң нечкә кылларын чиртә торган моңлы шигырьләрне укыганда, менә нәрсәләр турында уйлый икән кайбер кешеләр. Юкә чәчәгеннән коелган бал тамчылары, күкләр һәм чоңгыллар, атылган уклар һәм йолдызлар турындагы юллардан астыртын мәгънә эзлиләр... Аларга карап, эчке ялкыннан тәннен ничек бәргәләнгәнен күрергә, каннның ургып, акылны ничек томалаганын, зиһенне ни дәрәҗәдә чуалтканын үлчәргә маташалар. Талда тибрәлеп сайраган сандугачны тәпиеннән эләктереп, тавышы каян чыга икән, дип, тамагын актарырга маташалар. Тикшерүчеләр шул алар. Әнә, кичә оперативник Саша да ничек җинел генә итеп: "Фахишәме әллә?"—дип сорап куйган иде...

Харис тагын озак дәшми торды. Ниһаять, тикшерүче телгә килде.

—Шигырьләр күп укылды бу арада. Алар йогынтысында үзем дә илһамланып киттем, күңелдә шигъри рәткә салынган юллар яралды. Менә тыңлап карагыз әле милиция кешесенең иҗат җимешен:

Өзелеп сайраган былбылның
Тамагы бар, җәсәде бар;
Җәсәденен эчләрендә
Сайравының сәбәбе бар.

—Йә, ничек сезнеңчә, очы-очка ялганганмы?

Харис ана гаҗәпләнеп текәлде: шаяртамы тикшерүче, әллә инде чынлап сөйләшүеме? Сайрар кошның тамагы турындагы уйларны каян белгән ул?

Алай да тикшерүченең "шигыре" сагышлы кичерешләрдән бераз айнытып җибәргәндәй итте. Харис үзен кулга алырга тырышты. Мондый чакта үпкә-сапкага урын юк, үтерүчене эзләү турында сүз бара. Һәм ул хәтерен эшкә җикте. Инде бик еракта калган яңгырлы бер кичтә Җәүһәрияне күтәргәне исенә төште. Нинди кайнар иде аның тыгыз тәне! Харисның аягы таеп, кулы ялгыш шуып, тездән өскә менгәч, шома тиресе астыннан ялкын теле ялманып узгандай, бармакларны өткән иде...

—Ут иде,—диде Харис, кинәт кайнарланган иреннәрен көчкә тибрәндереп.

—Инде хәзер күз алдына китерик: чибәр, талантлы, дәртле хатын... Ире еракта, яртышар ел кайтмый. Аралары бозылган, аерылышу турында сүз бара. Хатын япа-ялгыз калган. Айлар-еллар буе, дигәндәй, ялгызы гына яшәде микәнни? Берәү дә аңа күз кысмаганмы? Үзе беркемгә дә омтылмаганмы? Эчендә җаны булган хатын бер генә дә уңга-сулга күз салмасмы? Һәр кич саен салкын түшәгенә ялгызы кайтып егылырмы? Шуна риза булырмы? Түзәрме? Ахыр чиктә бу бит табигать кануннарына каршы килә. Шулай түгелме?

Харис тикшерүченең сүзләре белән ризасызлыгын белдереп башын гына чайкый алды.

—Тере кеше ич ул! Аның урынына үзегезне куеп карагыз!—диде Мансур Хужиевич.

—Ире нәрсә ди сон?—дип, ихтыярсыздан тавышын күтәреп сорады Харис.

—Ирләр үз хатыннарының гөнаһын иң соңыннан гына беләләр. Бу—һәркемгә мәгълүм. Менә сез бөтенләй башка. Читтән караган кешегә яхшырак күренә.

—Мин аның танышларын белмим,—дип, башын иде Харис.

—Кызганыч ки, шагыйрәнең шәхси тормышында нык казынырга туры киләчәк. Сез бу мәсьәләгә бераз ачыклык кертә алсагыз, эш җиңеләер иде. Әйтүегезчә, аның битен сез үз кулъяулыгыгыз белән каплагансыз бит?

—Нәкъ шулай.

—Кульяулыкка мәрхүмәнең иннек таплары сеңгән. Каплап куйганга гына ул кадәр сенмәс иде, шулай бит?

—Аның бөтен бите кызылга буялган иде. Сөрттем,—диде Харис.

—Ә ник сөрттегез?

—Уйламыйча... Аңышмыйча...

—Сез ничек уйлыйсыз: нишләп алай бизәнде икән? Хатын-кыз тора салып битенә теләсә ничек иннек сыламый лабаса.

—Кемдер аны көчләп үбәргә маташкан булса кирәк,—диде Харис.

Һәм Харисның күңелендә кичәдән бирле бәгырьне кырып торган, әмма үзе ачыктан-ачык әйтергә базмаган сорау торып басты: көчләгәннәрме аны, юкмы? Әйе, үбәргә маташканнар, ә ул теләмәгән, боргаланган, карышкан... Ахыр чиктә үтерүче мәсхәрәли алганмы аның тәнен, юкмы?

—Судмедэксперт әйтүенчә, мәрхүмәне көчләмәгәннәр,—дип әйтелмәгән сорауга җавап бирде Мансур Хуҗиевич.

Харис җиңел сулап куйды. Аллага шөкер, гомеренең соңгы сәгатендә Җәүһәрия андый газапка дучар ителмәгән, тәне чиста калган!

—Үбәргә тырышкан, ләкин көчләүгә барып җитмәгән,—дип дәвам итте тикшерүче.—Очраклы бандит булса, алай гына туктап калмас иде. Ире яисә сөяркәсе түгел микән, дияргә кала. Әйтегез әле: Букштейн белән сезнең мөнәсәбәтләр ничек иде?

—Мин аны читтән күреп кенә беләм.

—Ә ул?

—Ул да мине шулай... Аэропортта гына күрде...

—Таныган икән, димәк, ул сезнең хакта белә иде?

Харис теге чакта аэропортта Җәүһәрияне кочаклап алганын, Эдуардның аларга читтән карап торганын исенә төшерде. Урыныннан купмады, торышын үзгәртмәде, тавыш-тын чыгармады. Ләкин эчендә нинди ут уйнаганын кем белә? Җәүһәрия ана Харисның кемлеген әйтергә, егетнең кыланмышларын ничектер аңлатырга тиеш иде. Нилэр сөйләде икән дә, Букштейн аның аңлатмаларын ничек кабул итте икән? Берне биш итеп, шашып көнләшкән, шуның аркасында башка сыймаслык нәрсәләр эшләп ташлаган акылсызлар азмыни бу дөньяда? Хәер, аннан соң күпме вакыт узды бит инде! Ә менә башка берәүдән көнләп...

—Сез... ире миннән көнләгәндер, дип уйлыйсызмы әллә?!

—Без төрлесен уйлыйбыз,—диде Мансур Хуҗиевич.

—Һәм ул көнләшүеннән...

Харис җөмләсен тәмамлый алмады. Ә нигә? Үзе дә Букштейннан шикләнмиме әллә? Бу хакта Рәзинә карчык та, Даниф та ачыктан-ачык әйтмәделәрме? Нишләп әле хәзер генә аның күңелендә ризасызлык туды?

Җәүһәриянең сафлыгын, чисталыгын саклау теләге тудырды бу ризасызлыкны. Сизгер күңелле, саф намуслы шагыйрә үтерүче кочагына кермәс, аннан бала тапмас иде. Димәк, Букштейн дигән кара адәмнең эчендә иман нурының чаткысы яшәгән. Харис күрә белмәгән, белергә теләмәгән яктылык... Ә эчендә иман нурының чаткысы булган адәм кеше үтерүгә бармас...

Ләкин бу уйлар гына тикшерүченең фикерен какшата алмаячак иде. Харис башка ышандырырлык дәлил табарга теләде.

—Сез нәрсә... Букштейн интеллигент, бандит түгел...—диде.—Шагыйрь бит ул. Шигырьләре басылып килә. "Кабиров" фамилиясе белән...

—Шагыйрь дисез инде алайса... Шигырь язган адәм кеше үтерә алмый, димәкче буласыз.

—Кеше үтерүчене иң элек таш күңелле бандитлар яисә психик авырулар арасыннан эзләү тиештер.

—Тиештер. Әмма андыйлар белән генә чикләнү дөрес булырмы? Әдәбият, сәнгать дөньясы гомумән бик катлаулы бит ул,—дип салмак кына, үзалдына уйлангандай сүзен дәвам итте Мансур Хуҗиевич.—Менә тыңлагыз әле!

Ул, урынынnan кузгалып, китап шкафы янына килде дә, бер журнал тартып чыгарды. Аны ачып, битараф тавыш белән укый башлады:

Күтәр керфекләрен, ялкын алыйм,
Куәт алыйм күзең нурыннан;
Бир кулынны, бәгърем, бергә булыйк,
Бергә атлыйк гомер юлыннан.

Аннары тырпайган кашлары астыннан Хариска сөзеп карады:
—Ну, ничек? Ошыймы?
—Мин әдәбият белгече түгел...—диде бераз аптыраштa калган Харис.—Болай очы-очка ялганган кебек...
—Бу шигырьнең авторы кеше үтерә алыр идеме, сезнеңчә? Кем ул, беләсезме?
—Кызганычка каршы, шигырьләр аз укыла шул,—диде Харис.
—Йозеф Геббельс шигырен укыдым мин сезгә.
Мансур Хужиевич, Хариска төбәп карап, бераз вакыт тынып торды. Аннары сузыбрак:
—Ишеттегезме, Геббельс,—диде.—Егерменче гасырның иң канлы җинаятьчеләреннән берсе. Фашистлар Германиясенең пропаганда министры. Икенче бөтендөнья сугышын әзерләшкән, концлагерьлар булдыруны идеологик яктан нигезләгән адәм актыгы. Нечкә күңелле кешеләрнең селәгәен агызырлык шактый күп шигырьләр чыгарган ул... Адольф Гитлер рәссам булу турында хыялланган. Рәсемнәре зур бер күргәзмә оештырырлык икән.
Харисның моны ишеткәне юк иде.
—Катлаулы мәсьәлә бу,—диде Мансур Хужиевич.—Атаклы композитор Сальеринын бөек композитор Моцартны агулап үтерүе хакында Пушкинның язганнарын мәктәптә үк укыдык. Җанындагы пычракны сәнгатьнең бизәкле ефәге белән капларга тырышучылар буа буарлык. Төрмәләрдә нинди генә җырлар чыгармыйлар!.. Ишеткәнегез бардыр?
—Төрмә тирәсендә таптанырга туры килгәне юк, Аллага шөкер,—диде Харис.
—Бауман урамында гына да шундыйларны күпме акырталар! И-и, аларны күңел биреп тыңласаң! Ирексездән зари-зари еларлык, күз яшьләрен чишмә булып агарлык,—дип үзе дә рифма белән тәмамлап куйды Мансур Хужиевич.—Шигырь яза дип кенә, кеше өстенә төшкән шикне алып ташлап булмый әле.
—Ләкин бу бер фараз гына!—диде Харис.—Җәүһәриянең сумкасы бомжлар ятагыннан табылды...
—Бомжларны тикшерәбез. Ләкин хикмәт шунда, соңгы төннәрне анда кунып-төнеп йөрүче булмаган. Чөнки бер атна элек каравылчылар ялланган, алар зур ишеккә йозак салып, башкаларын кагып куйганнар. Төнгә бина эченә овчарка җибәрә торган булганнар. Сумканы бомжлар ятагына махсус илтеп ташлаулары да ихтимал. Эзне адаштырыр өчен... Аннары Байбулатова анда ялгыз булмаган бит. Ул сәгать тугызда кем беләндер очрашып, алты миллион бурычын түләргә тиеш булган. Кемгә?
—Мина түгел,—диде Харис.
—Сезнең Байбулатовага бурычка акча биреп торганыгыз булдымы?
Харис теге чакта шпана малайлардан Җәүһәриянең сумкасын йолып алганда, утыз сум биреп торганын исенә төшерде. Бик кыенсынган иде ул чакта Җәүһәрия, акчаны бер дә аласы килмәгән иде! Һәм тизрәк кайтарырга да ашыкты.
—Ул гомумән әҗәткә акча сорый торганнардан түгел. Горур иде.
—Горурлык ипи түгел, тамакны туйдырмый. Алган бит! Һәм зур сумма алган. Кемнән? Безгә шул кешене табарга кирәк. Сумкада акча юк иде, димәк, Байбулатова ул акчаны биргән, дип уйларга була.
—Сумкада пичәт тә юк иде,—диде Харис.
—Пичәт? Ул сездә түгелмени?

—Без аны тапмадык. Нуржиһан апаның әйтүенә караганда, Җәүһәрия соңгы көннәрдә, пичәтне сорыйлар, дип сөйләнгән. Борчылган.

—Ләкин ул апа безгә бу хакта берни әйтмәгән иде.

—Онытып җибәргәндер.

—Ала-ай! Ләкин пичәт нәрсәгә?

Харис Данифның: "Ике миллиард тора ул!"—дигәнен исенә төшерде.

—Берәр документны расларга түгел микән? Кафега бәйле кәгазьне, мәсәлән.

—Кафе дисез... Ярый, ул йомгакны сүтәргә тырышып карыйк,—диде Мансур Хуҗиевич.—Хикмәт шунда ки, бәхәс яисә низаг ир-хатынсөяркә арасында барса, канны көнчелек кыздырса, кеше бик еш дуамаллана, акыл белән, һәр ягын уйлап эш итү сәләтен югалта. Ә инде бина турында сүз барганда, уйлабрак эш итү кирәк. Әйтик, сез бинага хуҗа булырга теләсәгез, Байбулатованың юкка чыгуы сезнең өчен файдага булыр идеме, әллә зыянгамы?

Тикшерүче Хариска төбәлеп, тынып торды. Аннары дәвам итте.

—Әгәр мин үземә шундый максат куйсам, бу очракта Байбулатова аша эш йөртер идем.

—Ничек?

—Иң элек җәмгыятькә әгъза булып керер идем. Бераз акча бирер идем. Эшләшкән булып, бөтен нәрсәгә кысылып йөрер идем. Шул бинада берәр кооперативмы, цехмы ачып җибәрер идем. Әкренләп ныгыр, киңәер идем, тамыр җәяр идем. Аннары, күпмедер вакыт узгач, хосусыйлаштыру юлын табар идем. Бушка. Район хуҗалары сораган ике миллиардны түләмичә генә. Бәс шулай булгач, бинаны бушка үзләштерергә теләгән бизнесменга Байбулатованы үтерүдән мәгънә юк. Киресенчә, андый кеше Байбулатовага каравыл ялларга тиеш иде. Беркемнән кул тидертмәскә. Алай-болай таеп егылмасын өчен, терсәгеннән тотып йөртергә. Шулай түгелме?

—Акыл белән уйласаң, сез хаклы кебек,—диде Харис.—Ләкин сез Җәүһәриянең холкын исәпкә алмыйсыз. Әгәр ул сезне гомумән якын китермәсә?! Сез әйткәнчә генә, кеше мәхәббәт, көнләшү аркасында гына башын җуямыни? Күпме адәмнәрнең акылын алган, күпме кан койдырган нәфес, баерга омтылу бар әле.

—Ала-ай!

Мансур Хуҗиевич урыныннан кузгалып, тәрәзә янына барып басты, тимер рәшәткә арасыннан урамдагы каенның тузан сарган салынкы тармакларына карап, бераз тынып торды.

—Димәк, без эзли торган кеше "Баллы күл" кафесын кулга төшерүне максат итеп куйган. Ул, әлбәттә, Байбулатова белән яхшы таныш. Ә бәлки, аның сөяркәседер.

Харис калкынып куйды.

—Бәлки, яраткан булып кыланганды р. Җәүһәрияне сөяркәсе итәргә маташкандыр,—диде.—Әмма максатына ирешә алмагандыр.

Ул моны бик ышанып әйтте. Әлбәттә, Җәүһәрия бирешмәгән, нык торган! Үз кадерен белә иде, горур иде бит ул. Беркатлылыгы аркасында мавыгып киткән булса да, яраткан кешесе белән очрашырга шакшы хәрабә эченә барыр идемени? Дөньяның сахрасын, гөлләр арасын сайлар иде ул очрашулар өчен! Фахишәләр йөри торган җиргә бара димени... Тәнен-җанын пычратуга юл куя димени...

—Сезнең сүзләрдә хаклык бар,—диде Мансур Хуҗиевич.—Ул кешенең, әлбәттә, бизнесмен булуы да ихтимал. Акчасы бар, күрәсез, зур гына сумманы бурычка биргән.

—Алты миллион.

—Ә бәлки, алганда алай ук булмагандыр. Процентлары белән күп җыелгандыр. Ни сәбәптәндер, Байбулатова бурычын түләп, ул кеше белән арасын өзәргә карар кылган. Кафеда очрашкач, алар арасында бик кискен аңлашу булган... Ул кеше пичәтне бик кирәксенгән. Нәрсәгә?

Мансур Хуҗиевич кире килеп урынына утырды.

—Һәрхәлдә шушы арада, бер зур урында, җәмгыять пичәте сугылган бик мөһим документ пәйда булыр, дигән өмет бар.

Ул өстәл тартмасыннан телефон номерлары яза торган куен дәфтәре алды. Харис аны таныды—Җәүһәриянең сумкасыннан килеп чыккан иде ул.

—Сез, вакыт табып, җентекләп карап чыгыгыз әле,—диде тикшерүче.— Берәр төрле шик тудырган, аңлаешсыз тоелган телефон яки фамилия яисә фирма очраса, игътибар итегез.

Харис дәфтәрне алып, иң элек "А" куелган битне ачты—мондый кенәгәләрдә татар хәрефләре юк, "Ә"гә башланган сүзләрне шул биткә теркәргә туры килә. Ләкин анда ул үз фамилиясен тапмады. "Язып та тормаган. Болай гына хәтерендә тоткандыр, ахры".

—Нәрсә, сез юкмыни?—дип сорады Мансур Хуҗиевич. Әңгәмәдәшенең уйларын укып утыра диярсең.

—Беләсез икән бит.

—Беләбез. Сез "Х" хәрефендә. Анда да телефоныгыз гына сыргаланган, исемегез язылмаган. Исеме күрсәтелмәгән телефоннар тагын бар. Ә бәлки, иң кирәкләрен язмагандыр да. Күңеленә генә теркәп баргандыр...

Харис "К" битен ачты. Ул хәрефкә билгеләнгән ике бит тә шыплап тутырылган булып чыкты. Шәһәр һәм район хакимиятләре, җир бүлеге, милек идарәсе, салым инспекциясе... Йә Алла, күпме кеше белән эш йөртергә туры килгән икән шагыйрәгә бу каһәр төшкән кафе тирәсендә!

—Мин сездән җәмгыятьнең барлык документларын карап чыгуыгызны үтенер идем,—диде Мансур Хуҗиевич.—Байбулатованы иртәгә җирләячәкләр. Җеназада, зиратта игътибарлы булыгыз. Бәлки, таныш кешеләрне очратырсыз. Яисә берәрсе үзен сәер тотар. Менә минем телефон,—дип визит кәгазен сузды ул.—Шикле нәрсә күзегезгә чалынса яисә нәрсәдер сагайтса, шундук хәбәр итегез. Көнме, төнме, эшкәме, өйгәме—бер нәрсә белән исәпләшеп тормагыз, тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә шылтыратыгыз.

Инде чыгып китәм, дип ишекне ачкач, Харис артына борылды да:

—Ә шулай да сез хаклы түгел,—диде.

—Кайсы мәсьәләдә?

—Шигырь мәсьәләсендә. Сез укыган теге ике такмак... Геббельсныкы һәм, гафу итегез, сезнеке... Ул такмаклар—шигырь түгел, чучело. Шигырь карачкысы... Кошның тиресен салдырып, эченә чүбек тутырып куялар бит? Монда да шулай: шигырь тиресенә чүбек тутырып куелган...

—Нишләп хаклы булмыйм, ди? Сез әйткәнне бик яхшы беләм мин. Тик минем тагын шуны беләсем килә: чын шигырьне шигырь карачкысыннан аерырга өйрәнсәң, кеше тышчасына яшеренгән ерткычны бер күрүдә танырга өйрәнеп булмас микән диюем.

...Харис бүлмәдән чыккач, коридордагы кыршылган урындыктан Даниф торып басты.

—Син дә мондамыни?—дип сорады Харис.

—Сәгать унга чакырдылар. Мин машина белән. Бераз гына көтегез, бергә кайтырбыз. Мине озак тотмаслар.

—Алла диген... Мондагыларның холкын белмәссең... Бушагач, җәмгыятькә килерсең. Ә мин бара торыйм әле.

Тизрәк урамга, яктыга, иркенгә чыгарга ашыкты Харис.

*Ахыры киләсе санда*



## Наис Гамбәр

### ИСӘН ЧАКТА...

Күкләреңне терәп торыр чакта
Ай-Кояшка җитәр кул булыр;
Исән чакта дусларыңны барла,—
Кабереңә парлак юл булыр.
Исән чакта!

Тузан күченә дә, вакытлыча
Күзне томалый да бер әлпә;
Югыйсә бит хисләр барбер шул ук,—
Йөрәк тибә, тибә дерелдәп.
Исән чакта!

Кемгә кирәк китеп югалгачтын,
Югалткачтын юлыңның очын,—
Үлә-үлә мин яраттым сезне,
Яшәү, ахры ... югалту өчен.
Исән чакта!

Аккан суларны да туктатырлык
Кабилият иңгән чагында,
Син, туктатма мине, туктатырлык
Көчең барда, сагын-сагынма...
Исән чакта!

Наис ГАМБӘР *(1947)—шагыйрь «Баш очымда—Кояш» , «Көзләрем яфрак коя» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Күзгә керер бер тузан да җитә—
Томаланып кала бар дөнья!
Яна-яна урман сүнеп бара—
Янган агачларга тотынма!
Исән чакта!

Кулларымны гына сузган идем,
Мәңгелеккә килеп бәйләндең;
Тоташ газап инде... гасабилы
Көн аралаш үткән бәйрәмем.
Исән чакта!

Юлларыма чыксам, юлларымда
Семофорлар яна—яшел ут!
Агач тамырлары абындыра,
Абынсам да барыбер мин шул ук.
Исән чакта!

Килер бер көн—кемгә генә килмәс!—
Соңгы сүзе—кайчысы белән:
Килер алар—Яшәү... Үлем,
Мин калырмын кайсысы белән?
Исән чакта!

Йөзәсең—йөзәр чагында,
Түзәсең—түзәр чакта;
«Далада яшәмибез» лә,
Яшибез бер кочакта.

Бары—бар, югы буладыр,—
Юксынуы бигрәк күбрәк:
Ничек чыдасын йөрәгем,
Күкрәүләр тулы күкрәк.

Яусын ла яңгыр яшенләп,
Күкрәп, яшен белән;
Җәй үтеп бара... июль—
Түләрмен яшем белән.

Кич иде... Киче июльнең,
Моннан бер илле еллап
Башланган сукмакның ахырын
Очыннан киләм очлап.
Кич инде!

Тау—тау инде... Тауларның
Күкрәгендә чишмә бар.
Кемнәр килеп сулар эчте?—
Килер юлы бигрәк тар.

Юл салыйм дисәң, сал икән
Тауларга илтсә генә...
Үләнгә абынып еларсың
Тауларның күкрәгендә!

Биектән тавыш иңә дә
Ерактан—еракларга!
(Сулар ага сикерешеп
Улактан улакларга.)

Күк тулып ишелде дә, Көн—
Энәдән-җептән үтеп
Чылатып китте... Җылытып—
Бер болыт тора көтеп.

Мәңгелеккә, дип, килсәң дә,
Шул бер гомереӊ белән
Яшисең... Таулар өсләтеп
Йөгерә соргылт үлән.

*

Кемеӊ кул сузар иде соң
Әгәр мин үлгән булсам!
Күзеңнең керфек очында
Гасырлар кичкән тузан.

Кем ирер—кемнәр кайгыртыр
Әгәр мин үлгән булсам.

Тузам да, киләм тәртипкә
Гөнаһлы бала сыман;
Күпме бал бирдем милләткә,
Һаман балавыз сыгам.
Кем ирер—кемнәр кайгыртыр
Әгәр мин үлгән булсам.

*

Болыты белән төшәр дә,
Яңгыры белән ишәр;
Түбәм тишек ... Исәнме,
Күкрәүле яңгыр, исәр!

Күчәр дә болыт, теләгем
Кабул бул иясенә;
Әйталмый калырмын, юкса,
«Рәхмәт!» диясемне.

Барыр юл озын булса да,
Әйтер сүз кыска, кыска;
Батышка карап китсәң дә,
Кайтасың көнчыгыштан.

Көнчыгыштан кайта кошлар
Таң алдыннан, төялеп...

Капка төбендә торадыр
Сөйкемлесе—сөялеп.

Кем себерер бу юлларны
Таушалсаң, тузан булсаң;
«Аһ!» дияргә өлгермисең,
Йөрәгең тузган була.

Юлым өсте—урман юлы,
Урманга чыгасым бар;
Нинди хуш дөнья!
Урманда
Каены, чаганы бер.
... Урманга чыгасым бар.

Киләсең дә китеп барасың син
Үләннәрне ерып, аралап;
Ике якка ауган үлән сыман
Дөньяларым тора таралып.

Аяк басылмаган тарафларга
Күләгәләр төшә, чүп үсә,—
Ай-Кояшка гына үрелеп лә
Яшисе лә иде, югыйсә.
Чүп үсә...

Түземлек кирәк,
Үземлек кирәк;
Юл чатында
Үсә бер тирәк.

... Җил иркендә тибрәлә
Ул да сирәк-мирәк.

Яшәвең изге булса да
Гөнаһың аска тарта;
Бүдәнә булып йөрисең,
Кычкыра: «Тартай!», Тартай».

Чигелде җилләр җилендә—күлмәгем яфраклары,
Кундылар инде иңемә—сафтан да сафраклары.

Таң гына ата, югыйсә—ә инде киче дисең;
Куркытма кош авазын—болында әрем исе!

Терәүгә терәп куелган
Юл-чатта баганасын
Урау көннәр бар иде;

Терәү дә юк, багана да—
Юллар хәзер тар инде.

... Уйнап үскән
Киндер кыры бар иде.

Кермисең дә, чыкмыйсың да:
«Йөзен дә каршыларбыз!»—
Диган идең дә; инде хәзер
Шактый ук каршылар без.

Хис-йөрәк шөшле булса да,
Чабата күзе саен—без!

Юлымда ятып егъладым... Дошманнар
Уйладылар: «Үлде!»,—дип;
Терелеп кайткач әйттеләр:
«Юк, ул үзе түгел»,—дип.

(Барабан кага-кага
Шатланышып көлештеләр:
«Бу егет кая таба!»)

Мин яшимен,
Ә үзләре
Нәкъ тере мәет кебек;
Денен вә кальбен югалткан
Мосафир сәет кебек.

... Алар юк инде, мин йөрим
Карадан кара көеп.

Бу сәгать йөри дә йөри,
Туктамастыр, ахыры;
«Туктамас Мәхмүт түгел дә,
Чиге юк бу аклыкның».

Туа да таң, кошларның
Ак канат җилләреннән
Өн килә: «Ташламасын ла
Дустыңнан, ишләреңнән!»

Урман бу!.. Җилләр тавышы
Капканы ача киереп;
Гайбәт сүз булса да, әйбәт дип
Үткәрә бел иелеп.

Сүнә яфрак, сүнәләр дә
Җилкән кебек җилкәмә!
... Мин китәрмен дә... ул калыр,
«Аны да шулай иркәлә».

Кереп утыра идең: «Ни хәлең бар,
Нинди хәлләр хәзер авылда;
Кемнәрең бар, кемгә сыенасың
Күңелеңә авыр чагында?»

Өйләндең дә, әйе, җиңелләйдең,
Җиңел юлда авыр сизелми;

Тәрәзәңне ачасың да, бәлкем:
«Югалдылар болар», дисеңдер.

«Дию» җиңел, «пәри» авыр була,—
Өермәсе белән сугылса;
(Дусларга да бер кирәгең калмый,
Өермәләр өереп, сыгылсаң.)

Барысы әйбәт... Сиңа кирәк чакта
Сүз дә килеп, җил дә сугылмас;
Шартлап-шартлап иманнәр дә ава,
Озак яшәр агач егылмас.

*

Үләнгә абынып егылгач—
Бик каты юкәгач та;
Нигә үкенү кирәк соң,
Юктан да елагач та.

Агачлар тамыры өстәрәк,
Өстәрәк икән лә шул;
Кайсы агачка абынсаң,
Шунсы үзәктә лә шул.

Йөрмә икән өскә карап,
Түмгәккә абынырсың;
Үзеңнән дә түбәнрәк
Тамырга табынырсың...

*

«Килүең дә авыр булды,—дидең,—
Яшәвең дә җиңел түгелдер».
Һәр сулышын тоеп яшим, әнкәй,
Өлешемә тигән дәвернең.

Әвернәгә үргән сүс җепләрен
Күкрәгемә үреп яшәдем;
(Югалтулардан соң аңлашыла
Бар мәгънәсе Олуг яшәүнең.)

Әйтер сүзең тамар-таммас чакта,
Өзелер чакта әйтер сүзләрең
Бик якында идең... Ә мин
Ерак кырлар түрен күзләдем.

Кизләүләрдә сулар кипмәс барбер,
Үзәннәрдә чыклар кипмәсә;
Сузылган кул булыр, әгәр инде
Вакытлыча барып җитмәсәм.

*

*Яңа исемнәр*

## ТЫЛСЫМЛЫ КӨЕҢ БУЛСА!



*Иҗат юлы башында ук үз калыбын-жанрын тапкан бәхетле язучылар була. Мәсәлән, Мәдинә Маликова романнары белән, Нәбирә Гыйматдинова исә повестьлары белән танылды. Ә менә Рәмзия Габделхакованың күңел түрендәге мөлдерәмә тылсымлы көен дөньяга чыгара торган төп әмәле-җае, миңа калса, ул—хикәя жанры. Тыгыз, кыска-җыйнак, фикри, эмоциональ-шигъри хикәя!*

*«Зирәк әдип хикәядә тасвирлана торган вакыйгаларга үз фикерен-уен көчләп такмый, ябыштырмый, ул вакыйганы шулкадәрле оста һәм уникаль дәрәҗәдә эффектлы итеп кора ки, аның ни әйтергә теләгәне үзеннән-үзе аңлашыла һәм укучы тарафыннан да тулы канәгатьлек хисе белә кабул ителә». Дөньякүләм атаклы новелла остасы Эдгар По фикере бу. Рәмзия Габделхакованың әсәрләрен укыганда, авторның бу киңәш-фикерләргә колак салуы сизелә. Аның татар, урыс һәм дөнья әдәбияты белән шактый ук таныш булуын да абайлыйсың. Иң мөһиме һәм иң куанычлысы: ул үз стилен, үз көен тудырып килә!*

*Рәмзия ханым, нигездә, заманыбызның гыйбрәтле күренешләрен тотып алып, арабызда яшәгән-аралашкан гап-гади кешеләр турында яза. Аларның хис-кичерешләрен, уйларын, гамәлләрен бербөтен образга туплап, эмоциональ накалда укучыга тапшыра. Авторның сезнең игътибарыгызга тәкъдим итә торган «Көмеш тун», «Зөләйханың ак күлмәге» һәм «Ана хакы» исемле хикәяләре, минемчә, моны тулысы белән раслый. Бер сулышта укыла торган бу тыгыз фикерле шигъри прозаның сәбәбен мин авторның шигырьләр язуыннан күрәм. Чөнки Рәмзия Габделхакова—берничә шигъри китап авторы да. Аның әдәби иҗат белән бик тә бәйле янә бер гамәле, вазифасы бар. Ул Лениногорски каласындагы Шамил Бикчурин исемендәге «Чишмә» әдәби иҗат берләшмәсен җитәкли. Иҗат ялкынында янучы талантлы яшьләребезне әнә шулай бергә җыеп, берләштереп, милләткә хезмәт итүче тынгысыз шәхесләребезнең берсе дә әле ул.*

*Рәмзия Габделхакова—Чирмешән төбәге кызы. Бүгенге көндә Лениногорски каласында яши, иҗат итә. Соңгы берничә елда аның хикәяләре «Идел» журналында, «Мәдәни җомга» гәзитендә дөнья күрде һәм бу басмалар оештырган хикәя конкурсларында җиңү дә яулады.*

*Рәмзия Габделхакованың бу заманда сирәк очрый торган, әмма чын иҗатчы өчен гаять мөһим бер сыйфаты бар: тыйнаклык, эчке хөрлек хисе белән сугарылган тыйнаклык. Әле хикәяләрен китергәч тә, «Казан утлары»ның мәртәбә-абруена ишарәләп, ул болай дигән иде: «Барырлык микән? Ошармы?» Бу хикәяләрне редакциядә эшләүче өлкән каләмдәшләребез дә ошатты. Алар да, миңа кушылып, Рәмзия Габделхакованың, киләчәктә дә күңел түрендәге тылсымлы көен югалтмыйча, берсеннән-берсе матур, мәгънәле әсәрләр иҗат итүен телиләр.*

**Марат ЗАКИР.**

## Рәмзия Габделхакова

### Көмеш тун

Шәһәр үзәгендә урнашкан ифрат бай бу кибеткә һәр көнне кичке якта өстенә көзге кара пәлтә кигән бер хатын керә. Кибетчеләр аны танныйлар, ул килеп кергәч ниндидер бер кинаяле, мыскыллы елмаю белән бер-берсенә карашып куялар.

Хатын аларга игътибар итми, сатучыларны да, кибет эчендә әйбер сайлап йөрүчеләрне дә гүя күрми, ашыга-ашыга затлы туннар сатыла торган бүлеккә таба атлый. Башкалар кебек эзләнеп, сайланып маташмый ул, чөнки үзенә нәрсә кирәклеген бик яхшы белә. Әллә кайдан игътибарны җәлеп итеп торучы, күз явын алырлык матур тун янына килә ул. Ак, зәңгәр, күк, көмеш төсләр белән уйнап торучы шул затлы тун, әйтерсең лә, һич тә җансыз әйбер түгел, ә бик тә якын танышы.

Аның янына килеп баскач та, хатынның арыган боек йөзе кинәт яктырып, балкып китә. Кан тамырлары, һәр буыны ап-ачык беленеп торган ябык куллары белән ул тунга кагыла, ярату, соклану белән аны сыпыра, гүя нәни песи баласын иркәли сыман. Бераздан хатын саклык белән генә тунлы элгечне кулына алып сатучы кыз янына килә. Әдәпле генә аңа көндәлек соравын кабатлый:

—Киеп карарга мөмкинме?

Тыркыша-тыркыша, йөзенә житди төс чыгарып, сатучы кыз: «Әлбәттә», ди. Һәм, хатын борылып китү белән, иптәшләренә күз кысып, йөзен учына яшерә дә, иңнәрен калтыратып пырхылдап көлеп җибәрә.

Хатын моны күрми дә, сизми дә. Ул бәрхет чаршау корылган киенү бүлмәсенә ашыга, әйтерсең лә, анда аны ниндидер зур шатлык, олы бәхет көтә.

Укучым, вакыйганы шушы урында туктатып, мин сине героем белән якыннанрак таныштырыйм әле. Кыңгыраудай зәңгәр күзле булгангамы, әнисе аңа Чәчкә дип исем кушкан. Кечкенә буена, җыйнак гәүдәсенә карап, хатынга күп дигәндә егерме биш-утыз яшь тирәсе биреп булыр иде. Әмма аксыл ябык йөзен, ирен читләрендәге тирән сызыкларны, бераз батынкы күзләрен әйләндереп алган вак-вак җыерчыкларны һәм дә шул күзләргә оялаган монсулык, арыганлыкны күргәч, бу хатын җирдә озак, бик озак яшәгәндәр кебек тоела. Утыз алты яшенә житсә дә, әле һаман тулай торакның кысан, шыксыз бүлмәсендә ялгызы яшәп ятучы Чәчкә: «Бәхетле кешенең әнисе исән була»,—дип кабатларга ярата. «Әниең булмаса, әтиең өчен урам эте, чүп үләне генә син»,—дип тә өстәп куя. Нишләтәсең, шулай диярге сәбәбе бар, һәркем үз тормыш тәҗрибәсеннән чыгып нәтиҗә ясый бит.

—Нигә һаман кияүгә чыкмыйсың?—дип сораучыларга да җавабы әзер аның:

—Хәерчеләр үрчетәсем килми!

Авыл мәктәбен тәмамлагач, шәһәргә килеп, эшкә урнашкан иде Чәчкә. Әтисенә, үги әнисенә артык кашык булмыйча, үз көнен үзе күрә башлаган иде. Дөньялар үзгәреп киткәч, заводның да, анда эшләүчеләрнең дә беркемгә кирәге калмады. Элек кесә тутырып акча алучы эшчеләр хәзер иң ярлы, иң кадерсез кешегә әйләнде.

Белеме булмаса да, кыскартылуга эләкмәде Чәчкә. Кислоталар белән эшләүче иң зыянлы, аз түләүле цехка килергә, аның урынына басарга атлыгып торучылар юк иде. Әмма барыбер акчага тилмерде кыз: бөлгенлеккә төшкән завод хезмәт хакын ачка үлмәслек итеп кенә бирә иде шул...

Шәһәр үзәгендә, элеккеге балалар бакчасы урынында калкып чыккан

бай, затлы кибеткә иптәш кызлары белән эштән кайтып барганда керде ул: «Аһ-аһ» итешеп, берсеннән-берсе матур, һәм берсеннән-берсе кыйммәтле, затлы җиһазларны, савыт-саба, кием-салымнарны карап йөрделәр. Әлеге тунны да шунда күрделәр, бәясенә күз салгач, алтын тун бит бу, диештеләр.

—Алтын түгел, көмеш ул!—диде шул чакта Чәчкә.—Нәкъ көмеш төсендә бит. Мин көмешне ныграк та яратам әле.

Менә шул тунга гашыйк булды ул. Беренче көнне читтән генә кызыгып сокланып карап торса, икенче көнне янына ук килде, курка-курка гына булса да, куллары белән кагылды. Шундый йомшак иде тун. Куе, озын мехка бармаклары кереп батты. Кыз ана гына риза булмыйча, тун җинен йөзенә китерде. Борынына әллә нинди хуш исләр килеп ягылды. Тун яныннан китәсе килмәде. Ул тагын, тагын шул кибеткә керде, үзенең «көмешенә» сокланды. Ә беркөнне, кыюлыгы җитеп, тунны киеп карарга сорады. Сатучы кызның каршы килмәве аңа көч бирде. Сәер, исәр кешегә санауларын аңлап торса да, үзен бу рәхәт, ләззәтле мизгелләрдән мәхрүм итәргә көч таба алмады ул.

Менә бүген дә Чәчкә үзе өчен гаять кадерле булган әйберне тотып, бәрхет чаршау корылган бүлмәгә таба юнәлде. Керү белән үк, ун ел буе көзен дә, кышын да кия-кия таушалып, төссезләнеп беткән пәлтәсен өстеннән салып атты. Иске пәлтәне санламавы шул хәтле көчле иде, хәтта аны элеп торуны да кирәк тапмады, нинидер бер ачу, нәфрәт белән келәм өстенә, идәнгә генә ташлады ул аны.

Аннары, кулына бәллүр савыт алгандай, саклык белән генә тунны элгечтән салдырды, иплән кенә, ашыкмый-кабаланмыйча гына кечкенә, җыйнак тәнен тун эченә урнаштырды. Әгәр кем дә булса шул вакытта чаршау эченә күз салса, гаҗәпләнер иде. Чөнки тун киеп караучы хатын көзгегә арты белән басып тора. Махсус шулай эшли Чәчкә, бәхет мизгелләрен юри шулай суза. Башындагы бәйләгән беретны иске пәлтә өстенә ташлый, күпереп торган сары чәчләрен иңнәренә таратып төшерә. Шуннан соң гына көзгегә борылып карый. Андагы кыз бик тә, бик тә ошый Чәчкәгә. Ул көзгедәге шәүләгә карап сокланып туя алмый. Шул тунны кию белән, әйтерсең лә, нинидер бер могҗиза була: күз-ирен тирәсендә эчне пошырып торучы ямьсез җыерчыклар юып алгандай юкка чыга, иреннәр үзеннән-үзе елмая башлый, күзләре очкынланып китә, бөтен йөзеннән шатлык нуры бөркелә. Менә бит ул нинди яшь, чибәр икән! Аһ, бу тун аңа шундый килешә! Нинди җылы, нинди йомшак, нинди матур ул! Һич тә саласы, аерыласы килми аннан. Менә шул тунны кигән килеш кереп китәсе иде көзге эченә, югаласы иде караңгы вә күңелсез, өметсез вә рәхимсез чынбарлыктан. Мескен булып, гел кимсетелеп яшисе килми лә бу тормышта.

Чаршау артында калган әнә шул тормыштан ишетелгән тавыш Чәчкәне татлы уйларыннан, матур хыялларыннан бүлә:

—Чыгасызмы сез, юкмы?

Теләмичә генә туннан аерыла Чәчкә. Аны үз урынына элеп куйгач та, тиз генә китәргә ашыкмый әле. Тагын бер кат сыпырып, иркәләп куя. «Иртәгә хәтле, көмешем»,—дип пышылдый. Чәчкә яхшы белә: көнне төнгә ялгап эшләсә дә, ашау-эчүдән калып, акча җыйса да, бу тунны түгел, аның җинен сатып алырга да хәленнән килмәячәк! Биш урынлы саннан торган бу бәягә кемнең генә буе җитәр икән? Юктыр ла андыйлар.

Бар икән шул! Бар икән...

Ял көне иде ул. Шәһәргә концерт белән Чәчкәнең иң яраткан җырчысы килде. Бер-берсенә игезәктәй охшаган соры көннәрдән туйган кыз, ялгызы гына булса да, театр бинасына юнәлде.

Пәлтәсен гардеробка тапшырып торганда күрде ул аны, гаҗәпләнүеннән чак кычкырып җибәрмәде: ишектән аңа таба... теге... кибеттәге тун кереп килә иде. Юк, әлбәттә, тун үзе түгел, ул кемнеңдер өстендә. Әмма Чәчкә аны күрми, аның карашы бары тунга төбәлгән. Бу аның туны иде! Үз күзләренә үзе ышанырга белмичә тораташ катып калды кыз. Менә тун аның янына килеп басты, менә хуҗасының иңнәреннән шуып төште,

менә гардеробчы хатын кулына күчте... Мондый матур, асыл тунны алгач, гардеробчы хатын өнсез калырга тиеш иде кебек, әмма ул исе дә китмичә житез хәрәкәтләр белән тунны чөйгә элеп куйды да, номер суккан калай кисәген илтифатсыз гына өстәлгә ташлады. Шунда ук тун турында да, аның хужасы турында да онытып, игътибарын чираттагы клиентына юнәлтте. Тун тапшыручы никтер номерны алмады, сумкасында актарынырга кереште:

—Ба, кайда соң бу тарак? Неужели алмадым инде?—дип сөйләнде.

Чәчкә аны ишетмәде дә. Аның карашы да, бөтен уе да өстәлдә ятучы бармак башы хәтле генә калай кисәгендә иде. Кинәт башына килгән уйдан хәтта үзе дә сискәнеп куйды. Шул уй аны ашыгырга мәжбүр итте. Барысы да бик тиз булды, күз ачып йомган арада үз номеры өстәлгә күчте, ә хатыннныкы тирләп чыккан учында урын алды.

Чәчкә шабыр тиргә батты, йөрәге күкрәк читлегенә сыймаслык булып бәргәләнде. Кыз ашыга-ашыга икенче катка йөгерде. Тәмам тынычланганчы, бер кирәкмәгәнгә бәдрәфтә утырып чыкты. Концерт башлангач, залда утлар сүнгәч кенә, үз урынына кереп утырды ул. Күзе сәхнәдә булса да, берни күрмәде, берни ишетмәде, бөтен уе учын яндырып торган салкын калай кисәгендә иде. Ә сәхнәдә төрле утлар уйнады, матур, затлы киемле биючеләр, жырчылар берсен-берсе алыштыра торды. Халык бирелеп жыр тыңлый, кул чаба. Беркемнең дә Чәчкәдә эше юк. Әмма кызның күңеле тыныч түгел, менә-менә аңа төртеп күрсәтерләр, «Тотыгыз, бу—карак»,—дип якасыннан алырлар кебек. Ул тынгысызланып ишек ягына күз салды. Нәкъ шул вакыт залга урындыклар күтәргән ике хатын-кыз килеп керде, аларның берсе—гардеробта эшләүче, Чәчкәнең киемен алган хатын иде. Димәк, ул концерт карый, ә гардеробта башка берәү дежур калган булырга тиеш. Ул Чәчкәне танымаячак. Чыгып китәр өчен иң жайлы мизгел иде бу.

—Нигә концертны карап бетермәдегез?—дип сорады кием бирүче кыз.

—Күңелем болгана, үземне начар хис итәм,—дип алдашты Чәчкә.

Ул каршысына таба «йөзеп» килүче затлы туннан күзен алалмыйча, сихерләнеп карап торды. Эчтән бәреп чыккан иләсләндергеч шатлык дулкыннарын көчкә тыеп, үзен тыныч тотарга тырышып, тунны кулына алды, тиз генә өстенә элеп, төймәләрен дә каптырып тормыйча, урамга атылды.

Бары театр бинасыннан ерагаеп, тулай торакка илтүче аулак урамга чыккач кына, тын алырга туктады. Үз бәхетенә үзе ышанмады кызый. Ничек шулай ансат кына, бер мизгел эчендә тигәнәктән гөлчәчәккә әйләнеп куйды соң әле ул? Аның өстендә ишек бусагасына салып, аяк сөртергә дә кызганыч булмаган иске пәлтә түгел, ә көмеш тун! Чәчкә, өнемме соң бу, төшемме дип, әле куллары белән өстендәге тунны коча, әле йөзен йомшак мех эченә яшереп уйный. Төне дә нинди матур икән бит. Тып-тын, һавада ялкау гына тирбәлеп, ап-ак күбәләктәй кар ява. Шундый жылы, рәхәт Чәчкәгә. Ул үз гәүдәсен хәтта тоймый да. Купшы тунга төренеп урам буйлап, әйтерсең лә, Бәхет үзе атлый. Чәчкәнең уенда әллә ничә төрле татлы уй-хыяллар бөтерелә: «Мин бу тунны эшкә кимәм, беркемгә дә күрсәтмәм. Бары авылга гына киеп кайтырмын. Урам буйлап нәчәлник кызы кебек тәкәббер генә атлармын. Авылдашлар шаккатып карап калырлар! Харис кызы бигрәк бай, көмеш туннар гына киеп йөри, диярләр. Үги анайның көнләшүдән йөзе күгәрер. Моннан ары: пешмәгән, булдыксыз, дип авыз ера алмас бүтән. Мондый тунны теләсә кем кими шул!»

Башын югары күтәреп горур атлый Чәчкә, гүя атламый, очып бара. Беркемне дә, берни дә күрми ул, әле һаман татлы уйлар дәрьясында йөзә...

... Аракыдыр, сырадыр сатыла торган киоск янында бер төркем егет басып тора иде. Кәефләре шәп иде аларның, кызык табасылары, күңел ачасылары килә иде. Чәчкә аларны күрми үтте. Әмма исерек төркем аны да, аның өстендәге шәп, затлы тунны да күреп алган иде...

* * *

... Тунын салдыруларын белеп-сизеп ятты Чәчкә. Ләкин каршылык күрсәтү түгел, кымшанырлык та хәле юк иде анын. Аяклары, куллары өшегәнен дә сизде.

Аннары исә берни тоймас булды. Шундый җинел, рәхәт булып китте ана. Туны да өстендә икән бит. Әнә бит, көзгедә чагыла. Чәчкә куллары белән ана үрелә һәм, ни гаҗәп, бернинди каршылык та сизми. Башта куллары, аннары үзе әкрен генә көмеш көзге эченә кереп югала. Ә анда күзләрне чагылдырырлык яктылык, һәр тарафтан җылы нур агыла. Кыз, аптырап, артына, көзгенен бу ягына борылып карый. Тик анда таныш бүлмәне дә, бәрхет чаршауны да күрми. Ни өчендер, әле генә үзе атлап килгән аулак урамны, ак кар өстендә ана карынындагы бала кебек йөзтүбән бөгәрләнеп яткан хатынны гына күрә. Әллә оятыннан, әллә салкыннан, әллә тормыштагы барча рәхимсезлек вә явызлыклардан гүя җир куенына кереп яшеренергә тели...

—Үлә бит ул!—дип кычкыра Чәчкә.

Әмма үз тавышын ул хәтта үзе дә ишетми...

## Зөләйханың ак күлмәге

—Син Зөләйханы беләсенме? Юктыр шул. Безнең авылныкы булмагач, каян беләсен инде? Минем яшьтәш ул. И син аны яшь чагында күрсән! Курчак та курчак, бу да—курчак. Авылда үскән димәссен, күктән төшкән диярсен. Тормышлары да яхшы иде шул. Әтисе—рәис, әнисе—укытучы. Зөләйха—берданбер бала. Уч төбендә биетеп, иркәләп кенә үстерделәр аны.

Мәктәпне бетергәч, шәһәрдә укып кайтты. Клубта эшли башлады. Вичырлар, танцылар оештыра, укытучылар белән театр куялар. Кызык иде. Яшь чак бит. Зөләйха авылда бер иде ул. Әкәмәт матур. Кигәне—ефәк кенә. Йөзенә карасан, тулган аен бер кырыйда торсын. Ул килештереп йөрүләре, дисенме. Кем әйткәндәй, төз-төз басып урамнан үткәндә, җәяүлеләр ятып, атлылар атларыннан төшеп ана карап калалар иде.

Ул хәзер дә матур әле. Авылда анын кебек фырт киенүче юктыр да мөгаен. Нечкә билле, кин итәкле күлмәкләр, үкчәле туфлиләр киеп йөри. Башында, кайчан карама, кин кырлы ак эшләпә булыр. Әле шундый чиста йөри, үзен бик карый инде. Кечкенә ридикюлен үзеннән бер дә калдырмый. Иннек-кершәне, хушбуе, тарагы-көзгесе гел кул астында. Тырнакларына хәтле кызарта. Яшьлектәге картлыкта икән ул. Алай дисән, картаймады да бугай ул. Әйтәм бит, һаман матур дип. Шулай унсигездә, яшьлегендә яшәп калды инде, мескенкәем. Үзеннән күпкә яшьрәкләргә дә, минем кебекләргә дә «абый-апа» дип дәшә.

Матур киемнәрен киеп, ясанып-бизәнеп кеше арасында йөрергә ярата да инде, харап. Кибеткә керде исә, күлмәк карый башлый. Берсен сала, икенчесен кия. Көзге каршысына килеп баса да: «Зөләйха матур! Зөләйханын күлмәге матур!»—дип, кулларын чәбәкли-чәбәкли сөенә. Әле биеп тә җибәрә. Бала да бала, бу да—бала.

Зыянлы түгел ул үзе. Авылда яраталар аны. Хәер биреп, хәлен белеп, ярдәм итеп торабыз. Ходай бәндәсе бит. Андыйларны изге, диләр. Яшьләр генә аңлап бетерми. Зөләйханың беркатлылыгыннан көләләр, үртиләр бичараны.

—Зөләйха, киявен кайчан кайта?—диләр.

Шулай дигәч, үзенен дә күзләре яктырып, чырайлары балкып китә бит әле.

—Кайта ул, кайта! Зөләйха матур күлмәк алды. Гаяз Зөләйханы зур шәһәргә алып китә. Зөләйханың туена килегез, яме,—дип, үз сүзләренә чын күңелдән ышанып сөйли, балакай...

Бигрәк яратты шул Гаязны. Анысы да бит дөньяда бер иде. Кәртинкәдән төшкән генерал диярсең! Сугыштан соң Германиядә хезмәт итеп калган иде. Авылга ялга кайтты. Өстендә—сәдәпләре ялтырап торган китель, күкрәгендә—медальләр. Бөркет тә бөркет, бу да бөркет. Матур чыраена бер генә карыйсың, егыласың! Зөләйха артыннан егетләр өерләре белән чаптылар, берсенә дә карамады. Гаяз бәхетенә булган икән. Бер-берсенә әкәмәт туры киләләр иде. Берсе—кояш, берсе—ай. Әй килештереп тә йөрделәр! Безнең авылда егет белән кыз култыклашып йөрү юк иде әле ул чакта, кача-поса, караңгыда гына очрашалар. Ә болар көпә-көндез кулга-кул тотынышып йөриләр. Матурларга килешә икән ул. Бүтән вакытта чебеннән фил ясаучы халык та гаепләмәде үзләрен, сокландылар гына.

Мәхәббәт йә бар, йә юк ул. Булгач, бер-береңне тапкач, ник сузарга? Гаязныкылар Зөләйханы сорап та кайткан, туйга әзерлек тә башланган. Зөләйхабыз шәһәргә барып туй күлмәге тектергән. Ул чакта ак күлмәкләр кию юк иде әле безнең авылда. Зөләйха бит ул! Аныкы кешечә генә түгел. Менә шулай гөрләшеп туйга әзерләнеп ятканда, Гаязны ашыгыч рәвештә хезмәт урынына чакырып алалар. «Кайтырмын, көт»,—ди кәләшенә. Көтә Зөләйха. Менә ничә ел көтә инде...

Кеше кинәт тилерми икән ул. Әкрен-әкрен акылдан яза икән. Күрәсең, уй басадыр шулай. Зөләйха да баштагы мәлләрдә боегып, уйга батып йөрде. Уйнамый, көлми. Аннары юлга чыгып баса башлады. Очраган бер кешедән сорый икән: «Гаязны күрмәдегезме? Гаяз кайтамы?»

Чәчәк кебек кызның кинәт сулуын Сәхибә апа әй авыр кичерде дә соң! Шул кайгы алып та китте инде аны...

Зөләйха әтисе белән генә яши иде. Көннәрдән бер көнне Әкрам абый да күзгә-башка күренми башлый. Тирә-күршеләре, әллә чирләп-фәлән киттеме икән, дип борчылып, хәл белергә кермәкче булалар. Зөләйха кертми. Ишекне бикләп куйган икән. «Әтиең исәнме?»—диләр, дәшми, ди. Аптырагач, тәрәзәне алып керергә уйлыйлар, Зөләйха боларның өстенә балта күтәреп килә...

Чирләгән генә түгел, үлгән булган Әкрам абый. Атна буе өендә шулай яткан. Әтисе белән аерылышасы, аны жиргә күмдерәсе килмичә, шулай кыланган инде Зөләйха.

Менә шунда, аптыраганнандыр инде, берсенең башына килеп, әйтә:
—Зөләйха, Гаязың кайта. Каршыларга чык!—ди.

Чыккан бит, бичаракай. Тузан да кунмаган ап-ак туй күлмәген, ак эшләпәсен киеп чыккан. Беркемне күрмичә, атыла-бәрелә: «Гаяз! Мин монда!»—дип кычкыра-кычкыра урам буйлап чаба икән мескенкәем...

... Күрәсе иде шул Гаязны. Чыраена бер карыйсы иде. Бәхетлеме икән ул? Зөләйхасы яныннан киткәндә үк, поездда бер урыс кызы белән танышкан, ди. Урыс кызлары әрсез бит алар, үзенә өйләндереп тә куйган егетебезне. Шуннан бирле авылга кайтып күренгәне юк. Маржасы жибәрмидер, күрәсең...

## Ана хакы

### I

Гөлүсә кайнанасын көтте. Бик көтте. Капка ачылган саен тәрәзәгә йөгерде. Ул киләм дигән иде. Гөлүсәнең әле беркайчан да кайнанасын шул тиклем көткәне булмады. Ә бу юлы ниндидер могҗизага өметләнгәндәй көтте. Бигрәкләр акыллы, төпле кеше шул аның кайнанасы. Әллә нинди четерекле кыен хәлләрдә дә аптырап калмый. Мөршидә апаның авызыннан чыккан һәр сүз гүя хакыйкатьнең үзе иде. Тирмәндә аны барысы да хөрмәт итә, кинәш-табышка гел киләләр. Гөлүсәгә дә ярдәм иткән иде ул.

Училищены тәмамлап, шул авылның балалар бакчасында әле эшли

генә башлаган чагы иде. Өч яшьлек бер сабыйны, әти-әнисе килеп алуын көтмичә, мәктәптә укып йөрүче апасына биреп җибәрде. Болар автобуска утырганнар да, күрше авылда яшәүче әбиләренә кунакка китеп барганнар. Кичен әти-әнисе, бөтен авылны ду китереп бала эзләп чапты. Нинди генә гаепләүләр, янаулар ишетмәде Гөлүсә! Акырып кына еламады! Мөршидә апага рәхмәт, ул тизрәк күрше авылларга шылтыраткан, балаларның кайдалыгын белеп, машина җибәргән, ике «качкын»ны аналары кулына илтеп тапшырган.

Бу вакыйгадан соң Гөлүсә эшен ташлап, китеп барырга теләгән иде.

—Ашыкма, сеңлем. Кайнар баштан кылынган эш хәерле булмый ул. Сабыр чыдый, сабырсыз елый, диләр. Авырлык килгән саен, елап кача башласаң, эшең дә, тормышың да уңмас. Ялгыша-ялгыша яшәргә өйрәнә кеше,—диде шул чакта Мөршидә апа.

Ирсез тормыш тарткан, утны-суны кичкән ялгыз хатын, бердәнбер улына ата да, ана да булган кеше, хезмәте белән хөрмәт казанган, ил каршында йөзе якты булган җитәкче сүзләре иде бу. Мөршидә апа башта укытучы, аннан мәктәп директоры булып эшләгән, ә хәзер—авыл советы рәисе. Ул Гөлүсәне үз кызыдай якын итте, ял көннәрендә өйләренә кунакка чакырды, улы Шәүкәт белән таныштырды. Ак күлмәкләр киеп, кайнанасы каршына килеп басуын үзе дә сизми калды кыз.

Югыйсә яратмады бит Шәүкәтне. Шәүкәт тә аңа битараф иде. Битараф кына түгел, бик сәер дә иде ул. Төннәр буе Гөлүсәгә Казанда калган Светасы турында сөйли. Әйтерсең, Гөлүсә хатыны түгел, ә дускынае. Урыс кызы белән чуалуын ишетүгә, институтта укып йөргән улын җилтерәтеп авылга алып кайткан Мөршидә апа, мәктәпкә эшкә урнаштырган. Ә укуын читтән торып тәмамлаган Шәүкәт. Казанда түгел, Чаллыда. Бигрәк ихтыярсыз, йомшак кеше инде үзе. Әнисе каршында аяк очына гына басып йөри. Бу гаиләдә яши-яши, Гөлүсә дә шундыйга әйләнде, иренә түгел, кайнанасына буйсынды.

Көтеп алган уллары тугач та, ире белән әллә ни якыная алмадылар. Аның каравы, Инсаф Гөлүсә өчен тормыш мәгънәсенә әйләнде, шул кечкенә генә бала аның дөньясын бәхет вә шатлык нурына күмде.

... Улы, бәгырь кисәге... Ни хәлдә икән инде ул балакай? Аның моңсу карашы хәзер дә Гөлүсәнең күз алдында тора. Моннан өч ай чамасы элек, өстенә кайнар сулы чәйнекне аударып, бик каты пешкән иде ул. Хастаханәдә озак ятарга туры килде. Өйгә кайтуларының беренче көнендә үк, кайнанасы Гөлүсәгә хат китереп тоттырды. «Әниең бик авыр хәлдә, карарга кеше кирәк. Ничек булса да кайт»,—дип язган иде әтисе.

—Баланы үзем карармын. Ә син кайт. Әниеңнең хәле, чынлап та, бик авыр, Казаннан да борып кына кайтарганнар. Әтиең белән телефоннан сөйләштек,—диде Мөршидә апа.—Җай булуга үзем дә барып чыгармын.

Әмма никтер һаман килми әле. Ул килсә, җиңелрәк булыр иде кебек. Әнисе күз алдында сулып бара, тире дә сөяккә генә калды инде. Гөлүсә көнен дә, төнен дә аның яныннан китми. Ә әтисе... Соңгы вакытта әллә нишләде ул. Гел өйдә тормый. Көндез эштә дә булсын, ди. Кичләрен дә биләмдә йөри бит, җитмәсә гел эчеп кайта. Телендә һаман бер сүз:

—Озак тормас, үләр бу. Күмгәндә буран булмаса ярар иде, кабер казучысы да табылмас...

Бигрәк ямьсез, мәгънәсез сүзләр. Аларны әйтергә ничек теле әйләнә икән әтисенең?! Юк, юк, үлмәс әнисе. Менә кайнанасы килсен әле, пыр туздырып сүгәр, акылга утыртыр әтисен.

Ә хәзергә... Эчпошыргыч кышкы озын төннәрдә, тынып калган моңсу йорт эчендә, хәлсезлектән йокымсырап, күзен йомып яткан чирле әнисе янында бер ялгызы утыра Гөлүсә. Урамда җил дулый, бозлы тәрәзәләргә шомлы караңгылык килеп сарылган. Өйдән җылылык, ямь качкан. Гөлүсә әнисенең ныгытып кысылган төссез иреннәренә, очлаеп киткән борынына, лимон төсенә кергән ябык йөзенә карап, бар йөрәге белән аны кызганып, бу хәсрәтнең чынлыгына, комсыз үлемнең бусагаларына килеп басуына әле

һаман ышанырга теләмичә, аптырап, гажиз булып утыра. Әле кайчан гына көлеп, бөтен өйне балкытып йөргән туп кебек йомры, алсу йөзле әнисеннән менә шул шәүлә генә калды. Бик авыр Гөлүсәгә, аны юатырдай, терәктаяныч булырдай беркем дә юк янында. Ичмасам кайнанасы тизрәк килсен иде, бераз булса да тынычландырсын иде Гөлүсәне!

Ниһаять, килде! Шаулап-гөрләп, бер олау күчтәнәчләр күтәреп килеп керде. Бөтен өйне гөрләтеп исәнләште.

—И кодагый, нишләп ятасың болай?! Килешмәгәнне! Әйдә тор. Бергәләп чәй эчәрбез. Сиңа дип атап, бавырсак та пешергән идем. И унды! Унды бит, кодагый! Болай булгач, тереләсең дә, тереләсең инде!—дия-дия, кодагый янында әверә килде. Күзләрен ачты әнисе, хәтта елмайды да! Өй эче нурланып китте, анда өмет кояшы балкыды!

Әнисе яткан олы якта табын корып, тәмләп чәй эчтеләр. Кышкы юлга ышаныч юк дип, Мөршидә апа Инсафны ияртмәгән. Үзе дә ана булгач, килененең күңелен яхшы аңлый: оныгы турында һич иренмичә бәйнә-бәйнә сөйләде, аның шуклыкларын көлеп искә алды. Гөлүсәнең кәефе күтәрелеп китте. Әле дә килде кайнанасы! Ничек күңелле, ничек рәхәт ул килгәч!

Чәй эчүләр тәмам булгач, Гөлүсә аш-су бүлмәсенә савыт-саба юарга чыгып китте. «Авыру кешене арыткандыздыр, бераз ял итсен» дип, әтисе белән кайнанасы да кече бүлмәгә чыгып утырдылар. Бүлмә белән кухня арасында фанер такта гына, шуңа күрә Гөлүсәгә аларның сүзләре ишетелеп тора иде.

—Хәле яхшы түгел, кода. Күзләрендә нур калмаган. Күп дигәндә ике атна торыр,—диде кайнанасы. Аның бу сүзләрен ишеткәч, Гөлүсә эшен онытып, катып калды.

—Өмет юк инде, юк.—Бусы әтисенең тавышы.

—Исәпләрең ничегрәк соң? Ялгыз яши алмассың, өйләнәсең булыр.

—Йөрәккә якын берәү бар да...

—Тормышыгыз нык, хужа булырга теләүчеләр табылыр. Гомер буе җыйган малны читкә җибәрмисе иде. Балалар бар бит.

—И кодагый, алар монда кайтып тормас ла.

—Йортыгызны сатасы булыр. Үзең бездә торырсың. Балаларны башка чыгарырбыз.

... Гөлүсәнең кулыннан юылмаган чынаягы төшеп китте. Ватылдымы, юкмы, хатын моны сизмәде, үзен-үзе белештермичә, урамга атылды. Бик салкын иде анда. Тик Гөлүсә моны да тоймады. Веранда ишегенә сөялеп, уйга калды. Нәрсә була инде бу?! Моны ничек аңларга?! Әнисе әле исән, ә болар инде мал бүлешеп, туйга әзерләнеп утыралар. Гөлүсә моңсу карашы белән балачактан таныш булган ишегалларын, карга күмелгән бакчаларны, кышкы йокыга талган алмагачларны айкап чыкты. Бар җирдә әнисенең рухы, бар нәрсәгә аның кул җылысы сеңгән. Кайсы якка карасаң да, елмаеп-балкып әнисе килеп чыгар төсле. Башка беркем дә түгел! Бары ул—әнисе генә! Бу йортта, бу ишегалларында, бу бакчаларда чит кеше йөри алмый, моны йөрәк кабул итми.

Шунда ул тәвәккәлләде. Моңа кадәр куркып, икеләнеп тора иде, инде тәвәккәлләде. Кухняга әйләнеп керде дә, шкаф артындагы кара шешәне кулына алды.

—Сеңлем, әниеннең чире дару белән генә дәвалый торган түгел, агу кирәк аңа. Минем ирне шул нәрсә аякка бастырды. Сак бул, тамчылап кына бир, бик зәһәр нәрсә бу,—дигән шешә хуҗасы.

Гөлүсәне «агу» сүзе куркытты. Әнисен агулап үтергән, дигән сүз куркытты. Кара шешәне «рәхмәт» әйтеп алып калса да, ачмады, бер тамчысына да кагылмады. Инде тәвәккәлләде, чөнки башка чарасы, башка өмете калмаган иде...

## II

Язны алар икәү генә каршы алдылар...

Йа Хода, былтыргы яз белән быелгысы арасында тулы бер гасыр ята диярсең! Бигрәк тә соңгы айлар бөтен тормышларын пыран-заран китереп ташлады.

Башта әтисе китте. Дәшми-тынмый гына, уйга батып йөрде-йөрде дә, кием-салымнарын юл сумкасына тутырды.

—Мин болай яши алмыйм. Була торган түгел. Рәнжемә, кызым,—диде. Кая таба юл алуын әйтеп тә тормады.

Беренче тапкыр гына югалуы түгел иде аның. Бер җәйне санаторийга киткән жиреннән гаип булды. Ике ай буе ана белән кыз, ни уйларга белмичә ут йоттылар. Ябыгып, каралып, кара күзлекләр киеп кайтып төште әтиләре... Аннары эше буенча Казанга укырга жибәргәч, югалды. Бу юлы төрле уйларга урын калдырмады: машина белән кайтып, әйберләрен төяп үк китте. Ярты елдан соң, кикриге шиңеп, башын иеп кайтты үзе тагын. Шуннан соң унга-сулга карамыйча, басылып яши башлаган иде кебек... Гөлүсә өчен иң авыры әтисенең шундый вакытта үзләрен ташлап китүе түгел, ә бу хурлыклы, күңелсез хәлне әнисенә сиздермәү иде.

—Әтиең кайда? Нигә күренми?—дип сорады ана шул ук кичне.

Гөлүсә теленә килгән беренче ялганны әйтергә мәҗбүр булды:

—Балниска төшеп китте ул. Грипп эләктергән. Сиңа ияртүдән курка.

Әнисенең борчылуы йөзенә чыкты. Иренең аяк юган суын эчеп яшәргә өйрәнгән хатын үлем хәлендә дә үзен түгел, хәләлен кайгыртты:

—Әтиеңә өчпочмак пешереп илт... Тамагы туймас... Балниста ашау ягы начар...—диде.

Бер ялган икенчесен тудыра. Пешерде Гөлүсә өчпочмакларны. Әти янына барам, диде. Кайнар өчпочмаклар салынган табакны тотып, шактый гына капка төбендә басып торды-торды да, күрше Миннисa әбиләргә кереп китте... Өчпочмаклар, кыстыбыйлар пешә торды. Миннисa карчык, рәхмәт әйтә-әйтә, сыйлана торды, тик әтисе генә «балнис»тан һаман кайтмады...

Начар хәбәрне әнисенә житкерүләреннән куркып, Гөлүсә өйгә кеше кертмәс булды. Система куярга, укол ясарга килүче медсестра Талияне яхшылап кисәтеп куйды.

—Талия кызым, Сәгыйтьнең хәле ничек анда?—дигән сорауга ана бары:

—Кайгырмагыз, апа, терелеп килә. Сезгә сәлам әйтеп жибәрде,—дигән яхшы җавап кына ишетте.

... Аннары Шәүкәт килде... Гөлүсә янында ярты сәгать утырдымы икән?..

—Атаң бездә,—диде.—Икәү яшәп яталар.

Бу сүзләрне әйткәндә, йөзе ачу-нәфрәттән шәмәхә төскә керде.

—Мин алар белән тора алмыйм. Китәм. Света янына, Казанга китәм. Син аерылырга каршы түгелдер бит?

—Юк,—диде Гөлүсә.

Шул хәтле тыныч, битараф булуына үзе дә гаҗәпләнде хәтта. Шәүкәт белән кушылулары, бергә яшәгән көннәре, инде менә үзен ташлап, сөяркәсе янына китеп барулары да, гүя бер төш, спектакль генә, ә ул—читтән күзәтеп торучы тамашачы. Ир бирмәк—жан бирмәк, диләр. Ә Гөлүсәнең жаны үлем кочагында сызланып яткан әнисе янында иде шул, ир өчен көяләнергә бушый алмады. Шәүкәт белән сөйләшү бик коры һәм рәсми килеп чыкты.

—Нигә Инсафны алып килмәдең? Күрәсем килә, шундый сагындым!—диде Гөлүсә.—Син аны Света янына алып китмисеңдер ич?

Җавап кыска булды:

—Инсаф турында әни белән сөйләш!

Икенче көнне үк Тирмәнгә телеграмма очты: «Инсафны кайтарыгыз!» Тик Инсаф урынына кайнанасыннан су буйлык хат килеп төште.

«Гөлүсә! Син мине гаепләмә. Әтиеңне тартып алмадым, үзе килде. Сәгыйть белән без таныш. Яшь чакта Казанда бергә укыдык. Өч ел буе яратышып йөргән идек. Сәгыйть укуны миннән алда бетереп, районыгызга кайтып китте. Шунда өйләнеп куйды. Соныннан аерылам, кушылыйк, дип килгән дә иде, риза булмадым. Баланны ятим итмик, дидем. Бик яраткан идем югыйсә әтиеңне. Оныта алмаммы дип кияүгә дә чыгып карадым, унмадым. Яратмаган кеше белән яшәп булмый икән.

Сәгыйть белән юлларыбыз аерылса да, хәбәрләшеп тордык. Сине безнең авылга эшкә урнаштыру турында да ул килеп сөйләште. Без бергә була алмадык, ичмасам, балалар кушылсын дигән идек. Анысы да барып чыкмады. Мәхәббәт населдән населгә күчми шул. Гомерем салкын мендәр кочаклап ялгыз узды. Минем дә кешечә яшисем, ир рәхәтен күрәсем килә. Шуна күрә, әтиеңне кире какмадым. Ул бик җилбәзәк кеше бит. Мин кусам, бүтәнгә китәр, йә эчүгә сабышыр иде...

Гөлүсә, күнеленә авыр алма, әниең бу дөнья кешесе түгел. Аның өчен үзеңне бетермә, яшьлегеңне корбан итмә. Сиңа әле яшәргә кирәк. Ошаткан кешең булса, кияүгә чык. Ә Инсаф бездә калыр. Ана монда яхшы. Сәгыйть белән уртак балабыз булмады, аның каравы, картайган көнебездә икебез өчен дә бик кадерле булган уртак оныгыбыз бар. Шуңа шатланып туя алмыйбыз. Син әле яшь, балаларың тагын булыр. Зинһар, Инсафны тартып алма бездән...»

Кат-кат укыды әлеге хатны Гөлүсә. Ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Юк, ул Инсафны беркемгә дә бирмәячәк! Закон аның ягында. Закон Гөлүсәне яклаячак! Тик законнан яклатыр өчен, башта суд юлында йөрергә, бәхәсләшергә, хаклыгыңны исбат итә-итә, көрәшергә кирәк булачак. Ә Гөлүсәнең моның өчен әлегә көче дә, вакыты да, мөмкинлеге дә юк. Ул әлегә монда, әнисе янында кирәк. Ана хакы атаныкыннан да, ирнекеннән дә, хәтта бала хакыннан да олырактыр, күрәсең.

Язны алар икәү генә каршы алдылар...

## III

Җирләр яшәреп, бакчадагы алмагачлар ак чәчәккә күмелгәч тә, Гөлүсә әнисен беренче тапкыр урамга алып чыкты. Аны одеалга төреп ишек төбендәге йомшак кәнәфигә утыртты.

Яз яз шул инде. Уйлар да, өметләр дә башка. Язның җиле дә мәрхәмәтле, җылы. Аяз күк йөзендә алтын нурларын бар тарафка кызганмый сипкән юмарт кояшның шул ук кояш, кышкы салкын буранлы көннәрдә болытлар артында кача-поса йөргән куркак кояш икәненә ышанасы да килми хәтта. Ул кояш гүя картаеп, яраксызга чыккан да, диңгез төбенә төшеп киткән, ә аның урынына өр-яңа, яшь, дәртле, якты кояш калыккан.

Айлар буе өй һавасы сулап, урында яткан авыру ана комсызланып тирә-юньне күзәтте, төшләренә кереп сагындырган матурлыкны күреп туймады. Озак вакыт сулаудан мәхрүм булган кешедәй, тирән-тирән итеп язгы саф һаваны сулады. Томан каплаган күзләренә яктылык, матурлык кереп тулды. Түзмәде:

—Дөнья бигрәк ямьле, кызым! Бер дә үләсем килми бит,—диде.

Гөлүсә әнисе каршына килеп тезләнде, аның агарып, нечкәреп калган кулларын җылы учларына алды.

—Яшибез, әни! Болай булгач, яшибез! Әҗәлне куып җибәрдек бит инде.

Әнисенең яшәү белән үлем арасындагы сызыкны үтеп, тормыш кырында басып торуына ул әз генә дә шикләнми, җәйләрне дә, көзләрне дә, яңа кыш-язларны да бергәләп каршы алачакларына чын күнелдән ышана иде.

❀



## Луиза Янсуар

### ӘЛЕ КОШ МИН—КҮКЛӘРЕҢДӘ

❋

Офыкларны иңләп оча кошлар...
Бәгырьләрне айкап, яңара моң.
Очар кошлар итеп яратмагач,
Ник иңдердең кошлар җаны,
Тәңрем?!

Дөньяларны сыйдырырдай булып,
Җилләр кочагына ташланамын.
...Үзәк өзгеч аваз—офыкларда...
Кошларгамы бирдең кеше җанын?!.

❋

Яз белән Көз бер кавыша икән...
Моңсу күктән шашып ләйсән ява.
... Юк, төш түгел!
Учларымны сузам
Тетрәп калган сары яфракларга.

Яз белән Көз бер кавыша икән...
Офыкларда иңри кошлар моңы.
... Юк, могҗиза түгел!
Мәңгелектә
Җаннар белән җаннар тоташуы...

*Луиза ЯНСУАР (1981)— шагыйрә, «Күзен ача умырзая» һәм «Мин Күкләргә кайтам» исемле шигырь китаплары авторы, Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Бер йотым Өмет бир җаныма.
Әрнүгә, газапка түзәрмен.
Мин сине ничә кат югалтып,
Җирдән дә, Күктән дә эзләдем.

Бер йотым Наз сирпе җаныма.
Шифасын сеңдерим—терелим.
... Аh, гүя җылыга сусаган,
Кояшка ымсынган бөре мин!

Бер йотым Сөю бир җаныма.
Яшәү бир бүгеннән—мәңгелек:
Моң булып агыла алырлык,
Тетрәтеп Күкләрнең бәгырен...

Кар өстендә учак яксаң,
Җылысына мине чакыр!
Хәтердә Төн: күзләр—йолдыз,
Куллар—камыш. Чәчләр—чатыр.

Яланаяк кар өстеннән
Йөгерермен кочагыңа...
Үткәннәрне салсаң утка,
Чакыр мине учагыңа...

Әле кош мин—күкләреңдә,
Әле таш—күкрәгеңдә.
Әле йолдыз—учларыңда,
Әле көл—учагыңда.

Әле биеккә чөясең,
Әле орасың җиргә
Җанымны... Тик сөюеңне
Алмыйсың барыбер җиңә!..

Җир астында үләннәр дә, бәлки,
Тамырлары белән берегәдер.
Аh, учларың назын өметләнмим,
Сине бары телим күрергә бер.

Һәм китәргә...
Үзәгемнән өзеп
Ничә еллар йөрткән газап өнен.
... Җир өстеннән киткәч,
адәмнәрнең
Җаннары бит, диләр, күрешә беркөн.



## Хәбир Ибраһим

# АРЫШ АРАСЫННАН ЙӨГЕРҮЧЕ БАЛА

*Илгизә ханымга багышлыйм*

ХИКӘЯ

Хәдичә Хәйдәрне яратмады. Яратмыйча йөрде. Хәйдәрнең армиягә китүенә бер ел да үтмәде, ул күрше авылдагы Кәрим исемле, үзеннән ун яшькә олы бер кешегә кияүгә чыкты.

Кай ягы белән алдыргандыр Кәрим, анысы билгесез, ләкин чибәр кызны бер тапкыр каптырып алгач, инде үзеннән ычкындырмады. Хәйдәрдән аермалы буларак, Кәрим кызлар күнелен аңлый иде. Яраткан, сайлаган кешесе белән тормыш корырга әзер ир булып чыкты ул. Тыгыз тәнле, таза беләкле, мөлаем кара чутыр чырайлы, буйсындыручан холыклы Кәрим тиз арада кызның башын әйләндереп атты... Барыннан да бигрәк ул Хәдичәнең әле яңа гына тәпи йөри башлаган кызын (бала Хәйдәрдән иде!) яратты. Һәрхәлдә шулай тоелды. Шуның белән каратты да ул үзенә Хәдичәне. Кунакка килә-киткәндә дә кечкенә Газизәне кулыннан төшермәде—иркәләде, сөйде, назлады. Тегесе да булачак атасын үз итте—киң җилкәсенә башын төртеп, рәхәтләнеп иркәләнде, нур тулы күзләрен төбәп ана карап елмайды. Мона бик нык күнеле булган Кәрим көлеп торган баланы сөя-сөя, һавага чөйде. Мона Хәдичә үзе дә, аның анасы Нәгыймә дә бик сөенделәр. Хәтта туй мәҗлесе барганда да ул Газизәне кулыннан төшермәде, табынның түрендә йөртте. Еласа—юатты, көлсә—шатланды. Моны күреп кунакларның да күңеле булды. Барча халык Кәримнең кешелеклегенә сокланып, чит-ят баланы да үзенекедәй якын итеп кабул кылганына чиксез сөенеп, аны яратып калды. Хәдичәнең шик-шөбһәләре бик тиз юкка чыкты. Ул Кәримнең ихласлыгына ышанды, үз язмышын дөрес итеп сайлый алуына инанды—Хәйдәрне онытып, Кәримгә кияүгә чыгуына үкенү хисләре кичермәде.

Туйлар узды. Хәдичә Кәримнеке булды. Ләкин туйлар үтеп, аз гына вакыт узгач та, Кәримнең кем икәнлеге ачыкланды. Дөресрәге, үзенең

---

Хәбир ИБРАҺИМ *(1958)—шагыйрь, драматург, прозаик; «Аһәң», «Йокыга талган гүзәл» китаплары, дистәдән артык сәхнә әсәрләре авторы. Казанда яши.*

нинди кеше икәнлеген бик тиз күрсәтте ул. Әйтерсең лә аны алыштырып куйдылар. Бала сөюче, бала өчен өзелеп торучы ата көтмәгәндә икенче кешегә әверелде. Кайчандыр сөеп, кулында иркәләп-чөеп кенә йөрткән кечкенә Газизәне ул күралмас хәлгә җитте. Кызны үз исеменә яздыру түгел, ул аны хәтта авылына, үз өенә алып кайтудан да баш тартты. Кәрим күрше Тәүгелде авылында, урман хуҗалыгында хезмәт итә иде. Анда аның яхшы нарат агачыннан салынган ике катлы зур йорты, каралты-курасы, бакчасы һәм мунчасы бар иде.

«Туган өемә, изге нигеземә, каяндыр җилдән туган адәм баласын алып кайтып, туганнарым, авылдашларым каршында ким-хур буласым килми әле»,—дип кенә аңлатты ул бу сәер кыланышын.

Ә бу таләп кырыс һәм катгый иде. Иренең астыртын яман холкын аңлап алган Хәдичә баштарак мона, кыюсыз гына булса да, карышып карады. Бу эшкә анасы Нәгыймәне җигеп маташты. Ләкин анасының:

—Кияү, кызымны яраткач, баласын да яратырга кирәктер,—диюенә каршы, Кәрим, бер дә исе китмичә:

—Мин бит синең оныгыңа өйләнмәдем, кызыңа өйләндем,—дип кенә җавап бирде.

Тарткалашуның мәгънәсе юк иде. Кечкенә Газизә әбисе янында калды. Кәрим яшь хатынны алып авылына кайтып китте. Барысы да бик тиз ачыкланды: Кәримгә бала кирәк булмаган икән. Ул иң элек Хәдичәне кулга төшерергә теләгән. Матурлыгы, пөхтәлеге белән бөтен тирә-якта дан тоткан сылу хатынны нишләп соң әле ул читкә ычкындырсын ди?! Ә яшь баланы «үчти-үчти» итүләр бары тик уен гына булган. Мескен баланы бусагасына аяк бастырмаска антлар эчкән, күрәсең, Газизәне өйгә алып кайту турында Хәдичәгә авыз да ачтырмады ул. Баласы өчен жаны әрнегән ана берни дә кыла алмады. Ирен артык яратканга, аңардан курыкканга да түгел иде бу. Хәдичә бу вакытта инде икенчегә авырлы иде. Бусы—Кәримнән. Шундый зур туйлар уздырып, халык алдында күренеп алганнан соң, ике бала белән ялгыз калудан курыкты ул. Тавыш чыгармады. Тешен кысып булса да көтте. Сабырланыр, тәүфигына килер дип көтте ул ирен. Тик юкка... Киресенчә, ул усалланганнан усаллана, ерткычланганнан ерткычлана гына барды. Иң элек көнләшеп үтерде: Хәйдәрнең исеме авызыннан төшмәде. Тәмам йончытты. Бер мәлне шулай Хәдичәнең сандыгыннан Хәйдәрнең армиядән төшереп җибәргән фоторәсеме килеп чыккач, көнләшүеннән кара янган, ачуыннан нишләргә белмәгән Кәрим аны башы белән сандык капкачына төйде, фотоны вак-вак кисәкләргә тураклап атты. Кәримнең беренче мәртәбә генә кул күтәрүе түгел иде бу. Юк нәрсә өчен дә бик тиз кызып китүе, Хәдичәнең һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән кыек мәгънә табып, тиктомалдан бозылып, ыжгырып торулары да көнләшүдән булган. Шул фотоны вакытында юкка чыгара алмаганына үкенгән Хәдичә бу юлы иренә бик каты үпкәләде, рәнжеде. Чөнки көнләшерлек урын юк иде. Ник дисәң, ул Хәйдәрне кияүгә чыкканчы ук онытырга өлгергән иде бит инде. Ул беркайчан да аның тарафына атлыгып тормады. Ә Хәйдәр исә армиядән кайткач та, йөргән кызының кияүгә чыкканын ишеткәч тә, чит якларга китеп барды. Озакламый ана, ул шунда кемгәдер өйләнгән икән дигән хәбәр дә ирештерделәр...

Ә кечкенә Газизә һаман да әбисендә яшәде. Дәүәнисенең иске чүпрәк-чапракларыннан курчакларына күлмәк-ыштаннар тектереп, шулар белән мәш килеп уйнап йөргән Газизәгә дә инде биш яшь тулды. Ак йөзле, кара көдрә чәчле кызга начар түгел иде әбисе белән. Ашарга-эчәргә житәрлек. Дәүәнисе кадерләп, көйләп кенә тора үзен. Ләкин болар гына аз иде шул аңа. Бала—бала шул инде. Әби назы гына аз ана, ата-ана назы да кирәк. Анасы исән булып та, аны үз янына алмаганына, шул сәбәпле үзен һаман да ятим бала итеп сизгәнгә күрә, моны сабый акылы белән аңлап та, төшенеп тә җиталмый иде. Шуңа да әбисен гел аптырата торган иде ул:

—Дәүәни, ә нишләп әнием кайтмый, нишләп ул мине үз янына алмый?!

Йә Алла! Оныгы өчен йөрәге әрнегән карчык ни дип җавап бирсен инде биш яшьлек балага?!

—Борчылма, кызым, кайтыр,—ди торган иде ул ана,—кайтыр, әниең урманга гына китте, албастылар алып китте аны, шулардан котылгач, кайтыр...

Газизә моңа баштарак ышана килде. Тик әзрәк үсә төшеп, акыл керә башлагач, шикләнә башлады. Әнисен, әтисен күрү теләге көннән-көн көчәйде генә. Колагына назлы сүзләр пышылдаган әнисе дә, күкләргә чөеп сөйгән «әти»се дә күз алдыннан китмәде аның. Ләкин Кәрим Хәдичәне авылга кайтармады. Төрле сылтаулар тапты. Сәлам хатлары, күчтәнәчләр килгәләде килгәләвен. Әниеннән урман күчтәнәчләре килде дип, дәүәнисе сыйлый торган иде аны. Ләкин тора-бара әбисенең әкиятләренә дә, әнисен урлаган урман албастыларына да ышанмый башлады. Ата-анасының күрше Тәүгелде авылында яшәгәнен белә иде инде ул. Ләкин ана анда барырга ярамый. Чөнки рөхсәт юк. Юл арасы да ерак түгел, югыйсә. Өч кенә чакрым. Аңа моны велосипедыннан төшмичә көн-төн урам әйләнгән күрше малае Илсур җиткерде:

—Тәүгелдеме? Һе!—дип аңлатты ул Газизәгә.—Кул арасы гына бит ул моннан—әнә теге арыш кырын гына чыгасы...

Күрше малаена ышана иде ул, бу юлы да ышанды.

Шулай беркөнне бакчадагы коелган алмаларны җыйнап, шуларны бер чүпрәккә төйнәп бәйләде дә (әнисенә күчтәнәч!) әбисенә әйтмичә генә юлга чыкты...

Арышның өлгергән чагы. Эссе, тынчу көн. Күктә ялтырап аҗаганнар уйнап ала. Аҗаган арышны камчылый, дип сөйли халык бу вакытны...

Төенчеген күкрәгенә кысып тоткан Газизә, артына борылып карарга да куркып, арыш кырыннан йөгерде дә йөгерде. Нәни йөрәге дөп-дөп тибә үзенең, өлгереп җиткән авыр арыш башаклары аның ялан тәнен чеметеп, чәнчеп-чәнчеп алалар...

Шулай да түзде Газизә. Читен булса да түзде. Анасы белән күрешү теләге тән авыртуыннан да, барлык газаплардан да өстенрәк иде шул. Бара-бара, йөгерә-йөгерә хәле бетте мескенкәйнең. Тыны кысылды. Сулуы капты. Эченә кату чыкты. Эчәсен китерде. Биек булып үскән арыш сабаклары Газизәдән күпкә озынрак, ул инде авыл юлын да, юлны гына түгел, хәтта кояшны да күрми башлады. Арыш кырына кереп батты. Аякларын тырнаткан, арыш сабакларына чорнаткан, адашканын сизеп алган бала, елый-елый, йөзе белән җиргә мәтәлде...

—Әнием! Әне-кәем! Кай...да... син... кайт... әни...

Тәннәре авыртудан түгел, җаны рәнҗүдән елады ул. Үкси-үкси елады...

Бәхетенә, юл ерак булмаган икән. Авылның тузанлы олы юлы...

Арыш сабакларына чорналып, иген арасында мәтәлеп яткан Газизә якында гына бер арба тавышын ишетеп алды. Ничек итеп кисәк кенә егылса, шулай ук тиз генә күтәрелеп, Газизә арба тавышы килгән якка йөгерде. Арыш кырын кичеп, бар көченә кинәт кенә юлга йөгереп чыккач, арбага җигелгән кызыл алаша куркып, тартылып читкә ыргылды. Арбада авыз эченнән көй сузып барган карт агай, чайкалып китеп, атны чак кына тотып кала алды. Әгәр дә ат ыргылып юл буенча чабып киткән булса, кызның арба астында калуы да бик ихтимал иде.

Чал чәчле, чандыр кара йөзле бу карт абзый Газизәләр авылыннан булып чыкты.

—Кем кызы соң син?—дип сорады ул кыздан.

—Хәдичә кызы,—диде Газизә башын аска иеп.

—Кайсы Хәдичә?

Газизә дәшмәде. Ул кадәресен аңлатуы читен иде аңа.

—Ә-ә!—дип сузып эндәште агай.—Син теге Тәүгелде лесничигына кияүгә чыккан Хәдичә кызымыни соң? Газизәме әле синең исемең?

—Ие...

—А-аңла-а-шылды. Арыш кырында нишләп йөрисең?

—Әнием янына барырга чыккан ием... әтием янына да тагын... Тәүгелдегә...

—Ә нишләп үзләре кайтмыйлар?

—Белмим шул... әйтмиләр...

Төенчеген күкрәгенә кыскан, йөзе кап-кара тузанга манчылган бу нәни кызның йөрәккә үтәрлек итеп әйткән беркатлы, эчкерсез сүзләреннән агай әллә нишләп китте. Гаҗизлекнең, ятимлекнең ни икәнен белгән, ата-ананы сагынудан да олырак, көчлерәк хис юклыгын аңлаган агайның бугаз төбенә нindидер төер килеп тыгылды. Кызганды ул кызны. Керфек очлары дымланып, бер мәлгә сүзсез калды.

—Бар, кызым, кайт, кире өенә кайт,—дип, ул бераздан телгә килде.— Тик арыш арасыннан кайтма—адашырсың, менә шушы юл буйлап кына кайт, яме...

—Юк, мин кайтмыйм,—диде кыз башын чайкап.—Мин Тәүгелдегә барам. Ә сез кая барасыз?

Агай нишләргә дә белмәде. Кызның үтенече куркытты да, шатландырды да аны. Берәр хәл була калса, аңа җавап бирәсе бит. Икенче яктан: «Барсын, күрсен әти-әнисен, миңа да юлда бер юаныч, иптәш булыр»—дип уйлады ул.

Агай кызны җәлт кенә күтәреп чыпталы арбага утыртты, аркасыннан сыйпап сөйде дә, акрын гына дилбегәне тартып, атка дәште:

—На, малкай!

Үтәр еллар... Газизә дә зур кыз булып үсәр, кемгәдер килен булып төшәр. Тик ул беркайчан да җәйге иләс җилдән болганган тук башаклы арыш кырын, рәхимсез кояш нурларыннан хәтсез кызган тузанлы авыл юлын, чал чәчле, чандыр кара йөзле юлдашын—кече күңелле агайны онытмас. Хәтеренең һәр мизгелендә бу шатлыклы вә шомлы сәяхәт, кылт итеп, аның исенә төшәр...

Агай Газизәне Кәримнәрнең өенә кадәр илтеп куйды. Ул хуҗаларга кул изәп сәлам бирде дә, атын куалап китеп тә барды. Газизә исән-сау гына әнисе янына килеп җиткәнгәненә сөенеп, шатланып туялмады. Ләкин хәлнең иң аянычы алда булган икән әле. Урман каршындагы җир кишәрлегендә Газизәнең әнисе Хәдичә, ире Кәрим кәтмән белән бәрәңге бакчасын эшкәртеп маташалар иде. Алар янында өч яшьлек Гамил да буталып йөри. Кояш кызуыннан әлсерәгән бала әле әнисенә, әле әтисенә килеп бәйләнә, көйсезләнеп аптырата иде...

Бакча башында басып калган Газизәне күреп алгач, Кәрим дә, Хәдичә дә өнсез калдылар. Кара тузанга баткан, күкрәгенә кечкенә төенчеген кысып тоткан Газизәнең, кинәт кенә алар каршында пәйда булуы, билгесез объектның күктән килеп төшүе белән бер булды.

—Нәрсә соң бу?—дип ыңгырашты Кәрим, сораулы күз карашын Хәдичәгә төбәп.

—Белмим, берни дә белмим, атасы,—диде Хәдичә, моңа үзе дә бик ныж исе китеп.

—Син китердеңме?

—Юк...

—Монда ничек килеп чыкты соң әле ул?

—Белмим... үзе килгәндер... атка утырып...

—Кайтарып куй!

—Калсын инде... иртәгә иртән илтермен...

—Юк, кайтарып куй! Баланның эзе дә булмасын монда!

Кабарынды, бүртенде Кәрим. Ачуыннан ияк aslары тартышты, күзләре ерткыч кошныкы сыман калайланды, очланды...

—Атасы...

Нәкъ шулчакны, бәрәңге буразнасыннан алпан-тилпән атлап килгән Газизә:

—Әнием! Әтием!—дип өздереп кычкырып җибәрде.

Кәрим шуны гына көткән сыман, аягына кигән дәү резин галушлары белән бәрәңге сабакларын таптый-таптый, Газизәгә каршы китте.

—Нигә килдең? Кем китерде сине?—дип кычкырды ул Газизәнең котын алып.

—Әнине... күрәсем килде...

Газизә Кәримнең усал, кырыс чыраеннан сискәнеп, имәнеп китте. Куркудан күкрәге катты, телсез калды.

—Ә бу нәрсә?!—диде Кәрим кызның түөнчегенә күрсәтеп.—Нәрсә бу?

—Күч...тә...нәч... ә...нигә.... сез...гә дә...

Ярсуыннан аңы томаланган Кәрим кисәк кенә аның төенчеген йолкып алды. Чишеп җибәрде. Төенчеккә бәйләнгән алмалар берәм-берәм буразна эченә коелдылар. Ярсуын тыялмаган Кәрим аларны берәм-берәм тибеп очырды...

—Кортлы алмаң белән безне агуларга булдың мәллә?! Кит, югал күземнән!!

Газизә куркуыннан елап җибәрде. Бу явызлыкны, кыргыйлыкны кырыйдан күзәтеп торган Хәдичәнең күнелендә нидер өзелеп киткәндәй булды. Ул кайда яшәгәнен дә, кем белән торганын да онытып, баласын коткарырга ташланды...

—Ерткыч! Кит бала яныннан! Мыскыл итмә баламны!—дип Кәримне читкә этеп җибәрде дә, кызының алдына тезләнеп, аны кочагына алды.

Кәрим әллә нишләп китте. Каушап калды. Дөньяны җимерердәй булып ташыган ярсуы шундук сүнде. Хатынына акырып күңелен тынычландырасы килсә дә, ул ана акыра да, сүгенә дә алмады.

—Күпме җанымны таларга була... шушы балам аркасында... Җир бит!—дип өзгәләнде Хәдичә.

Кәрим дәшмәде. Дәшәрлеге дә юк иде шул. Ул үзен гаепле сизде. Бер дә юкка, бер сәбәпсезгә сабый баланы рәнҗетте түгелме соң ул?! Монардан да зур гөнаһ юклыгын аңлаган Кәрим бер мәлгә унайсызлык, чарасызлык тоеп аптырады. Тик шул ук вакытта күнеле йомшара, нечкәрә барганын сизгән һәм шул хистән читенсенә, ояла башлаган Кәрим, сүзен сүз итеп:

—Бар... Кызыңны авылга кайтарып куй!—диде, һәм бераздан соң:—Берәр көн үзең дә авылда кунып килерсең,—дип өстәде...

Әнисе ике көн авылда булды. Беркайчан да онытмас ул көннәрне Газизә. Бәйрәм, тоташ бер бәйрәм булды ул аның өчен. Ике көн кызу итеп мунча якты лар, мунча керделәр, әнисе белән дәү әнисе бергәләшеп гөбәдия пешерделәр, соныннан күршеләрне кунакка чакырып сыйладылар. Анасы яныннан китмәде дә Газизә, аның белән бергә чишмәгә суга төште, туганнарына кунакка барды, аның белән сөйләште, серләште, йоклаганда да бергә йоклады—анасының кочагыннан чыкмады...

Тик бу бәхет озакка бармады. Ике көн үткәч, аны Кәрим кире Тәүгелдегә алып кайтып китте. Беркем белән дә исәнләшмәде Кәрим, хәтта капкадан да кермәде. Газизә кабат әнисез калды. «Әбиең белән әйбәт тор, аның сүзен тыңла, мин шулай кайтып, китеп йөрермен»—дия-дия, ышандырып китте аны әнисе...

Тик бер атна да үтмәде—кара кайгы хәбәре килде: Кәримнең улы Гамил суга батып үлде. Елга ярында балыкчылар куеп калдырган матур калкавычка кызыгып, шуны тартып чыгарырга дип кергән өч яшьлек баланы су агызып киткән. Хәдичә бу вакытта тавык караган булган, улының кая киткәнен күрмичә калган...

Бу кайгыдан чарасыз калган Кәрим үз-үзен кая куярга белмәде. Башта үзен тиргәде. Аннан: «Тавык караганчы, бала карар иден!»—дип хатынын сүкте. Туганнарына да эләкте... Хәдичә үзе дә кара сагышка батты...

Яшь баланы җирләгәч, туганнары Кәримгә им-томчы әбигә барырга киңәш иттеләр. Баштарак киреләнеп маташса да, соңрак барды ул. Әби ана: «Баланның үлеме—кылган гөнаһларыңның җимеше»,—дип әйткән. Кәрим: «Минем нинди гөнаһым бар соң?»—дип сорагач, ул: «Син кемнедер бик каты рәнҗеткәнсең һәм шул кешенең рәнҗеше хәзер сина төшкән, син аңардан гафу үтенергә, аның кичерүен сорарга тиешсең. Хатыныңның икенчегә йөкле, әгәр мин әйткәнне үтәмәсәң, анысы, яңа туганы белән дә шундый хәл булырга мөмкин»—дигән.

Карчыкның бу сүзләре Кәримне бик нык уйга калдырды. Кемне

рәнжеткәнен, кем алдында гаебе барын да ул яхшы белә иде. Гөнаһсыз бер сабый баланы рәнжетте ул, нык рәнжетте. Тик шуны аңламады, бала рәнжеше шулкадәр каты төшә микәнни ул?!

Шулай беркөнне Кәрим Хәдичәне машинасына утыртып Газизәләргә кайтып төште. Әзрәк кенә хәмер капкан, кызмача Кәрим нишләргә дә белмәде! Элеккегечә Газизәне иркәләп, күтәреп һавага чөяргә теләде. Кулына күтәреп чөйде, сөйде. Ләкин Газизә моңардан рәхәт табып көлмәде, тизрәк җиргә төшерүен, җибәрүен сорады. Ул аңа моңа хәтле күрмәгән, авыз итмәгән күчтәнәчләр тоттырды, тик Газизә берсеннән дә авыз итмәде. Дәүәнисенә сәхәр вакытында авыз ачарга булыр дип, күчтәнәчләрне өстәлнең бер читенә тезеп куйды. Кәрим аны төрлечә сөйләштереп тә, көлдереп тә, сораштырып та карады. Тик Газизә ачылмады.

Сабый дибез, бала дибез, баланың акылы кыска, явызлыкны тиз оныта, тиз кичерә ала, дибез. Баксаң, кыз бала Кәримнең явызлыгын оныта алмаган икән...

Кәрим түзмәде... Газизә алдына тезләнде...

—Бала,—диде ул күз карашын аңа түгел, ә каядыр читкә төбәп,—мин синең алдыңда гаеплемен, кичер мине... Менә күрерсең, мин башка андый булмам, төзәлермен... Миңа Ходай җәзаны бирде инде, минем баламны алды... Мин сине монда калдырмам, үзебезгә алып китәрмен... Кичер мине...

Ләкин Газизә аны кичерер, элеккечә аның муенына килеп асылыныр, дип өметләнгән Кәримнең бу юлы да өметләре акланмады.

—Мин кичерермен, тик Ходай кичерерме соң?—диде кыз туп-туры Кәримнең күзенә карап. Аңлаган кешегә аңлашыла, кыз үзенең сүзләрен сөйләми, ә башка берәүнең сүзен кабатлый иде.

—Кем әйтте сиңа моны?—дип сорады Кәрим, бер аңа, бер кайнанасына карап.

—Мин! Мин әйттем,—диде шулчак, бу хәлгә шаһит булып утырган Нәгыймә карчык.—Минем сүзләрне сүли ул, кияү, үзенең сүзләре түгел...

—Әһә!—дип кычкырып җибәрде кияү, кинәт кенә очкылык тоткан сыман.—Имәндә икән чикләвек! Сез барыгыз да миңа каршы, сез миннән көләргә уйлагансыз! Кемнән?! Миннән! Кә-рим-нән!! Кем соң сез?! Чүп бит сез, чүп—минем алда! Бетте! Мин бу йортка бүтән аяк басачак түгел, ишеттегезме, аяк та!!!

Кәрим Хәдичәне утыртып авылына кайтып китте. Көчләп алып китте ул Хәдичәне. Гәрчә, анда аягы тартмаса да. Кәрим атналар буе эчте. Хатыны белән җүнләп сөйләшмәде. Гомергә кешене рәнҗетерлек тупас, мәгънәсез сүзләр ычкындырды. «Син мине нииндидер маңка кыз алдында тезләнергә мәҗбүр иттең, катсаң иде!»—дип Хәдичәнең җанын талады. Бу мәхшәргә түзә алмыйча, авылына кайтып китәргә җыенган Хәдичәне эт итеп кыйнап атты. Берничә җирен сындырган, карарлык җире калмаган хатынны район больницасына озаттылар. Бу хәбәр авылга да килеп җитте. Нәгыймә карчык, тиз генә җыенып, район үзәгенә китте.

Әнисе өчен дулкынланган, күңеленнән зар елаган Газизә, әбисе китүгә үк, авыл башына йөгереп чыкты. Арыш кырын яртылаш суктырганнар иде инде. Анда-санда комбайннар йөргәли. Алар артыннан җыйнак кына салам көчләре утырып кала. Бормалы юл елан койрыгыдай офык читенә кадәр сузылган. Шул юлдан озак кына йөгерсә, әнисе янына барып җитәр кебек тоелды аңа. Тик анда җиткәнче әле арыш кырын кичеп чыгарга кирәк...

... Арыш башаклары тагын да тыгызрак тулган, сабаклары башак авырлыгына түзәлмичә сыгылып төшкән. Тәнне әчеттереп, маңгайга, биткә «шак-шок» итеп килеп бәрелә. Тик йөгерә башлаган Газизәне туктатырлык түгел иде, кыз йөгерде дә йөгерде...

—Әнием, үлмә, мин синең яныңа барам, үлмә, әнием,—дип ялвара-ялвара йөгерде ул...

Арыш арасыннан йөгерүче бала, ана назына сусаган, ата сүзен ишетергә зар-интизар булган сабый бала... Мескенкәем!

Әнисенең инде иртән үк аңына киләлмичә җан тәслим кылганын белми иде шул әле бала...

## ФИЗИК ТА, ЛИРИК ТА...

*Алтмышынчы елларда элеккеге СССР киңлекләрендә яшәүче халык телендә, бигрәк тә әдәбият, шигырь сөючеләр гыйбарәсе булып, бәхәс тудырган, ягъни шигъри полемикага сәбәп шундый сүзләр йөрде: «физиклармы, әллә лириклармы?» Ягъни кайсы—заманга лаек: төгәл фән, техника әһелләреме, йә булмаса шигырь сөючеләр, каләм ияләреме? Күпме шигырьләр язылды ул чорда бу темага! Безнең шагыйрьләр дә язды...*

*Әмәнә илленче елларда шигырьгә килгән Камил Әхмәди улы Мостафин бу полемика белән артык мавыкмады бугай. Әйе, 1932 елның 26 ноябрендә Зеленодольск шәһәрендә туып, Саба һәм Чүриле (хәзер Арчага керә) районнарында үсеп, урта мәктәп тәмамлаган егет Казан дәүләт университетының нәкъ менә физика һәм математика факультетында укый (1951—1956 еллар). Университет тәмамлагач, Мәскәүдә, аннан 1957 елдан бүгенге көнгәчә Уралда, элек Чиләбе-2 дип аталган, хәзер Снежинск исемендәге шәһәрдә яши: Бөтенроссия техник физикасы фәнни-тикшеренү институтында сектор начальнигы булып эшли (ул—физика һәм математика фәннәре кандидаты). Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары, медальләр кавалеры; 1991 елда исә СССР Дәүләт премиясенә дә лаек була. Чын мәгънәсендә физик, фән эшчесе шул, нәрсә әйтәсең!*

*Кызыклы бу фактларны безгә шагыйрь автобиографиясендәге белешмәләр сөйли. Калганы—шигырьләрендә, китапларында. Илленче елларда яза башлаган Камил шигырьдә И. Юзеевлар белән безнең буын шагыйрьләре арасындагы чорда калкып чыкты: дәртле, оптимистик, шул еллар романтикасы белән сугарылган, «Такташ томы һәм шаян җил» белән дус йөрәк һәм фән белән дә таныш бүгенге яшь кеше акылы кушыла иде аларда. Беренче китап исеме дә шундый ноталарда иде: «Жыр сафка чакыра» (1966)...*
*Русча да язды ул: ике телдә дә камил яза алырлык белеме, эрудициясе бар иде Камилнең. Татарстанда һәм Урал матбугатында гына түгел, Мәскәүдә («Юность» журналы һ. б., төрле альманахлар) дә басылды шигырьләре. Сигез китабының («Һәркемнең үз йолдызы», 1968, «Горур ташлар», 1972, «Хыял кошы», 1984 һ. б.) өчесе—урысча дөнья күрде (Чиләбедә, Мәскәүнең «Современник» нәшриятында). Балалар өчен дә язды ул, юмор-сатира шигырьләре, пародияләр белән дә күренде («Чаян журналы һ. б.). Тәрҗемә өлкәсендә дә көчен сынады, җөмләдән, М. Лермонтов һәм Маяковскийдан тәрҗемәләре безнең журналда да басылып чыкты.*

*1981 елдан Язучылар берлеге әгъзасы Камил Мостафин әле дә әдәбиятка, шигырьгә мөкиббән булып яши, яза,—яшьлегенә, татар шигыренә, аның төп магистраль юлына тугры кала, диясе килә.*

*Юбилее мөнәсәбәте белән тәкъдим ителә торган бу сандагы шигырьләре дә раслый моны: аларда да күпне күргән, кичергән безнең дәвер физигының мәңгелек сораулары белән әзләнүләре тулы ихлас лирикасы, фәлсәфи уйланулары. Нәкъ үзенә генә хас катгыйлык, фәнчә төгәллек һәм йөрәк яралары... Чын шагыйрьләрчә!*

*Олпат яшең белән котлыйбыз, яшьләрчә омтылышлы шигырьләрең өчен шатланабыз, Камил туган! Озак яшә, иҗат ит!*

**Рәдиф ГАТАШ**



# Камил Мостафин

## Юлчы турында баллада

Ташлы юлда хәле беткән кешенең:
максат—ерак, ә алдында—чүл дә үр...
Шунда кемдер бүләк иткән юлчыга—
бер яхшылык, бер җылы сүз, бер шигырь.

Алда—томан, алда—янгын, гарасат,
мондый юлда өч тиенлек—һәр гомер.
Ай-һай, ничек ярдәм итсен кешегә—
бер яхшылык, бер җылы сүз, бер шигырь?!

Авыр булган йөге, ә бу бүләкләр,—
һәркем белә,—һич кенә дә мал түгел.
Ә ул әйткән, «Үзем белән булсын,—дип,—
бу яхшылык, бу җылы сүз, бу шигырь».

Табаннары янган, битен җил өткән,
барып җиткән, сукмаклары—көл, күмер...
Ул югалган, ләкин калган дөньяда—
шул яхшылык, шул җылы сүз, шул шигырь...

Ул якларда яши гүзәл кешеләр,
уйлары—саф, эшләре гел—ал да гөл,
ә бит башта булган (калган юлчыдан)—
бер яхшылык, бер җылы сүз, бер шигырь...

## Казан төне

Казан төне! Ай да, калфак кебек,
кунаклаган шәһәр өстенә.
Ап-ак карлар яңа төсләр өсти
урамнарның иске төсенә.

Утлар сыек, күләгәләр тонык,
трамвайлар чыңлый сак кына,—
ярым-таныш дөнья гүя мине
серле очрашуга чакыра.

Ул чакыра мине тын бакчага,
анда сукмак карга күмелгән.

Ә кемнеңдер көләч күз карашы
һаман китми күңел түреннән.

Кем бәхетен карлар яшергәннәр?
Кем язмышы монда, кем даны?
Ник үртәли минем йөрәгемне
Казан төне, Казан бураны?!

❦

Этләнәбез, яши-яши, эшли-эшли,
ай-һай кыйбат яшәү хакы, сулау хакы.
Битарафлар, җансызлар күп, каршылар күп,
Йә Ходаем, ә кайсылар безнең яклы?!

Юлларыбыз күренә дә, күренми дә,
анда—газиз кешеләр дә, каберләр дә.
Бу без, дөнья,—хакимнәр дә, ятимнәр дә,
әйе, бу сез,—юләрләр дә, сәерләр дә.

Юлда үскән ак каеннар ни аңлата—
кайгынымы, бәхетнеме,—белми һичкем.
Ах, көн генә, бер яктырып, нидер көтә,—
әллә кемнән һаман көтә нидер бу көн...

❦

Ватан биргәнен дә сатабыз,
Ходай биргәнен дә сатабыз,
әнә шулай эшләп ятабыз без,
әнә шулай яшәп ятабыз.

Хәтерләрдә диңгез эзе бар,
күңелләрдә яңгыр исе бар,
ни арада малкуарлар булды
ай моңнарын тойган кешеләр?

❦

Бер баш иик әле
тол алдында,
кол алдында торыйк бер, тынып,
янган иреннәрдән үбик әле,
иске тәүбәләрдән котылып.

Сабыйларның чәчләреннән сыйпап,
мәңгелеккә китик кагылып,
җир йөзендә урын тапмый,
шашыйк,
күптән узган көнне сагынып.

Эзлик әле—
күктән, җирдән, көлдән—
чын мәгънәсен фани дөньяның.
Уйлыйк әле, җырлыйк, елыйк әле,
өзә-өзә күңел кылларын.

1

Очратканда оятсыз һәм җанҗал җанны,
без каушыйбыз, агарабыз, кызарабыз,
бу бәндәгә шаккатудан телсез калып,
өнсез калып,—аның өчен оялабыз.

Кызарабыз, чөнки без дә кайчандыр бер
булганбыздыр оятсыз да, әдәпсез дә...
Гаеп хисе безнең белән яши һаман—
безнең җанда, безнең канда, безнең мидә.

2

Очратканда гүзәл, якты елмаюны,
аңа карап, яктырабыз үзебез дә,
шунда күктән нурлар төшә йөзебезгә,
очкын керә, җылы керә сүзебезгә.

Яктырабыз, чөнки без дә кайчандыр бер
булганбыздыр ваемсыз да, бәхетле дә...
Шатлык хисе безнең белән яши һаман—
безнең җанда, безнең канда, безнең мидә.

Тирбәлә бер йолдыз тын аккан инештә,
чагылыр-чагылмас, күренер-күренмәс.
Кыек юл, тоных нур яктыра биектә,
югалыр-югалмас, сизелер-сизелмәс.

Төнге җил җилпенә караңгы болында,
басылыр-басылмас, киселер-киселмәс,
һәм ялгыз күкенең тавышы яңгырый,
тоелыр-тоелмас, өзелер-өзелмәс...

Кем җырыдыр,—әллә төште күктән,
әллә читтән килеп кагылды.
Кем моңыдыр,—әллә таңда туды,
әллә кырда кичен табылды.

Кемгә таныш? Кемнең җанын өзә?
Кемгә газиз? Кемгә кадерле?
Кемне офтандыра? Кемне өнди
һәм елата нинди бәгырьне?

Туктап торам, иеп башкаемны,
басып торам, кисеп юлымны,
торам, йодрыклатып кулларымны,
урталыкта өзеп уемны.

Менә шушы изге минутларда
хәбәр килә искән җилләрдән:
язмыш өткән бәгырьләргә генә
моңнар иңә биек күкләрдән!

Бик күп нәрсә инде беткән, киткән,
бик күп нәрсә төндә югалган,
тик йөрәккә сызылып, нидер калган,
һаваларга ашып, юл алган.

Чыклар төшкән. Төнге сәгатьләрдә
тынган чакта юлда тавышлар,
иң актыккы юлчы узып китә
һәм әйләнә соңгы сагышка.

Өйләр өнсез. Ә шәүләләр озын.
Утлар сүнгән. Дөнья интеккән.
Тик йөрәккә сызылып, нидер калган.
Исемнәре аның ни икән?..

Гүзәллек тә, садәлек тә, яктылык та—
җәйге көндә, синең җылы сүзләреңдә,
офыкларны кискән ерак яшеннәрдә,
төшләремә кергән серле йөзләреңдә.

Язлар узган, җәйләр киткән, кошлар очкан,
болыннарны, урамнарны түши карлар,
ә гүзәллек, ә садәлек, ә яктылык—
кемнән алар, нидән алар, кайдан алар?

Белмим, күрмим... Әйдә бүген мәйданнарда
әллә кемнең даны ашсын биек күккә,
тик барыбер аңа түгел—мин баш иям
яктылыкка, садәлеккә, гүзәллеккә!

## Ватан

Кешеләр, ирләр, исәннәр,
дусларым, якыннарым,
күптән бергә гомер иткән
җаннарым, алтыннарым,
минем кырыс юлдашларым,
уйчан фикердәшләрем,
күршеләрем, танышларым
һәм көләч иптәшләрем,
кинәт очрап куючылар
һәм газиз кордашларым,
минем сабыр якташларым,
кадерле чордашларым,—
күрегез!—юллар чатында
ваемсызлар йоклаган,
ә Ватан—баскан, ярсыган,
ул Ватан—безнең Ватан!
Ул биек күкләрне капшый,
әзләнә, ул интегә,
ул елый, ул өзгәләнә,
ул елмая, ул көлә!
Ул дәшә безгә! Дусларым,
әйдәгез,—җитте вакыт,—
яктыртыйк аның күкләрен,
җанны учакка атып!



**Рөстәм Мингалим**

# ДҮРТ КЕШЕЛЕК УТЫРГЫЧ

ДРАМА, ИКЕ БҮЛЕКТӘ

Катнашалар:

Карт
Килүче
Икенче килүче
Ир
Ханым

## Беренче бүлек

**Нарат урманы белән капланган тауга юл күтәрелә. Каядыр эчтәрәк—шәһәр каберлеге. Аста шәһәр... Каберлеккә китергән юл ахыры. Юл буенда—калын, нык, яңа утыргыч. Аны ясаучы Карт, инде эшен бетереп, соңгы кадагын кага. Үзалдына сөйләнә... Үзе белән сөйләшүче дөньяда берьялгызы гына калган сыман була. Ул бит кем өчендер сөйләми. Фикер үсешен уйлап тормый. Сүзләре, җөмләләре кабатлана. Бу карт та шул хәлдә.**

Карт. Ярар, хәлен белдем... хатыным һаман йоклый. Тыныч йоклый. Бүген тыныч көн булды. Югыйсә... Киләләр дә киләләр... Менә кадакларны да кагып бетердем. Тагын тып-тыныч калды. Алар бит бөтенләйгә килә, уянмаска. *(Чүкечен утыргыч астына куя.)* Аларны хөрмәт итәргә кирәк, шауларга ярамый. Каберлек янында кычкырырга ярамый. *(Кабат утыргычка утыра.)* Әкерен генә сөйләшергә ярый. Шуңа күрә дүртәү утырырлык итеп ясадым. Монда берүзең утырсаң да була. Икәү дә, өчәү дә. Ә мин дүрт кешелек итеп ясадым. Бишенче—кирәкмәс, ул ерак... Ерак була... Кычкырып сөйләшергә туры килә. Монда кычкырырга ярамый. Монда йөрәк кычкыра. *(Ул бераз тыныч кына уйланып утыра да әллә онытылып,*

Рөстәм МИНГАЛИМ *(1937) - шагыйрь, драматург; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; татар, урыс, башкорт телләрендә күпсанлы китаплар авторы. Драма әсәрләре республика театрларында сәхнәләштерелде. Казанда яши.*

*әллә белеп, әкерен генә моңланып ала.)*

Асларында ул йоклаган жирнен.
Өстендә соң ничек монланма?
Өстендә соң ничек монланма?
Бу монымны—ана багышланган
Догам санап кабул ит, Алла.
Догам санап кабул ит, Алла.

*(Сөйләнә-сөйләнә китә.)* Монда йөрәк кычкыра. Әкерен генә монланырга ярый. Тыныч утырсаң да була.

**Китеп барган Карт урынына тиздән башка берәү килә. Аны алда Килүче дип исемләрбез. Килүче утыра. Тынлык. Бераздан икенче берәү килә. Аны Икенче килүче дип атыйк. Ул утыргычның икенче башына утыра. Кыяфәте хәтергә сеңә торган таза кеше.**

Икенче килүче *(Килүче янынарак күчеп)*. Син ни өчен биредә?

**Пауза. Килүче эндәшми.**

Танымыйсыңмы?
Килүче. Таныдым.
Икенче килүче. Ник күрешмисең?

**Килүче күрешергә кул суза. Икенче килүче аны бугазыннан алып торгыза.**

Каберенә чәчәк китерденме?! Мескен кеше.
Килүче. Бүген китермәдем... Аның үлеме сиңа ник кирәк иде? Хатынын, балаларын күргәнем бар.
Икенче килүче. Ярый, үлгән, жиде ел үткән. Онытырга вакыт... Хәзер аның хатыны, абыйсы биредә килә. Мине беләсең, мин чиста калырмын. Сине үтерүчеләрне эзләүчеләр кулына илтеп тапшырабыз. Ризамы шуңа?
Килүче. Юк.
Икенче килүче. Юк булгач, бүтән күренмәссеңме монда?
Килүче. Күренмәм.
Икенче килүче *(Тагын Килүченең якасыннан алып)*. Сүзеңдә тормасаң—мин сине суям. Тиз бул, югал. Менә бу яктан ычкын. Әйдә.

**Китәләр.**

Икенче килүче *(Сөйләнә-сөйләнә бара)*. Бирегә үз аягың белән килмә. Вакыты житкәч, күтәреп китербез.

**Бераздан утыргычка илле яшьләр чамасындагы Ир һәм аңардан күпкә яшь күренгән Ханым килеп утыралар.**

Ир. Ул теге капкадан чыгып, безне көтеп тормасмы?
Ханым. Ана мин бу яктан чыгабыз, дидем. Төп капкадан.
Ир. Мин теге капкадан кергән идем.
Ханым. Мин дә теге капкадан кердем.
Ир. Ә ник бу яктан чыгабыз?
Ханым. Мин анысын уйламадым да.
Ир. Монда... Энекәшне китергән чак искә төшә. Хәер, артык уйлану файдасыз. Тормыш ул барыбызны да, сине дә, мине дә шушында китереп яткыра.
Ханым. Ирем янына.
Ир. Әйе... Яшь кенә кешене ансат кына үтерделәр.
Ханым. Мин аны чынлап ярат-канмын. Ә кияүгә чыкканда, яратаммыюкмы... белеп тә житкерми идем. Чыгарга кирәк иде. *(Пауза.)* Кире уйларга соң иде... Ул мине Түмәнгә алып китте. Яшәү шартларыбыз жайсыз. Мин йөкле. Квартирга чират зур. Ә бала чират житкәнне көтми, туарга жыена. Житмәсә көннәр салкынга бара. Мин нишләргә дә белми йөрим, ә ул юата... Тракторын куеп кайту белән, кабат чыгып йөгерә. Өй сала башлады. Барыбер безне больницадан яңа өйгә алып кайтты.
Ир. Бер уйласаң үзенең дә малай гына чагы бит әле. Унөч яшьтән—шәһәр кешесе.
Ханым. «Без авыл малайлары—кошлар кебек. Кая барсак та ояны үзебез корабыз», дип мактанырга да ярата иде ул.
Ир. Мактанчыклыгы бераз бар иде.
Ханым. Ә бер көнне—бер ярты аракы алып кайткан. Елмая, юлыбыз туган якка борылды, ди. Врачлар ана Төмән табигате килешми диделәр. Синең өчен эчәм, юеш борын, ди кызыбызга. Тизрәк әтиенә ияреп йөрерлек бул, ди. Кызы ияреп йөрерлек, инде малае алдан йөгерерлек, үзе юк.
Ир. Эчә күрмә, энем, дип хатлар яздым. Ә ул анда...
Ханым. Күп эчми иде. Кайчакта, кешечә генә... Кайту белән жинне сызганам, мондыйны гына түгел, сине шаккатырырлык өй салам, ди иде.
Ир. Сүзендә торды, өен өлгертте.

Мичен генә чыгарып өлгермәде.

Ханым. Куркакларча, арттан кададылар бит.

Ир. Арттан кадамасалар, ул биреш-мәгән дә булыр иде. Таза иде... Шундый зур куллары белән ул, сеңлем, кешегә сукмады. Бөтенесен якын итте.

Ханым. Бер бала күрсә, шуңа гашыйк. Чакырып ала, югары күтәрә.— Кояшка хәтле күтәримме?!—дигән була.

Ир. Бу иренне дә әйбәт кеше диләр.

Ханым. Әйбәт, ләкин ул түгел.

Ир. Ашыкмыйсыңмы дигән идем сиңа.

Ханым. Ә энегез миңа җүләр ди торган иде. Шаярып. Бәлки чынлап та әйткәндер. Миңа аның җүләр дию—башкаларның акыллым, сеңлем дигән сүзләренә караганда ныграк ошый иде.

Ир. Тел төбеңне аңладым.

Ханым. Сезнең миңа сеңлем диюегезне истә тотып әйтүем түгел.

Ир. Ике көннән китәм... Минем монда буласымны ирең әйттеңме?

Ханым. Мин бирегә киләсемне аңа әйтмәдем.

Ир. Егетне әйтәм, чыкмый әле... Килми.

Ханым. Ул килер...

Ир. Җиде елдан соң да онытмаган, үлгән дусының хәлен белергә уйлаган. Күрәсең, андый кешеләр дә бардыр. Әйтик, ишетелгән хәбәр дөрес булса һәм чәчәк китерүче—ул булса?

Ханым. *(Кинәт урыныннан ук торып.)* Мөмкинме бу?!

Ир. Ник мөмкин булмасын? Үзе үтергән дә хәзер каберенә чәчәк китергән, имеш. Дусы булган, имеш, диләр ләбаса.

Ханым. Ничек... аңа әйталасың? Кеше турында?!

Ир. Соңгы вакытларда кешеләр турында башыма әллә нинди уйлар килә.

Ханым. Болай түгел идегез.

Ир. Болай түгел идем... Җиде елдан соң да онытмаган... Мин бу кешене хәтерләмим.

Ханым. Туебызда булды.

Ир. Туйда кеше күп булды.

Ханым. Ул да бар иде.

Ир. Хәтерләмим.

Ханым. Аны бирегә мин алып мендем.

Ир. Ничек... Син алып менден?

Ханым. Очраштык та мин бирегә килергә чыкканымны әйттем. Теләсәң, алып барам дидем.

Ир. Син алып барам дигән өчен генә килде микән?

Ханым. Якын итеп килүедер, малай чактагы дуслар бит.

Ир. Сәбәбе шул микән...

Ханым. Дөрес, башка бер сәбәп булуы бар... Аңа сезнең монда булу ошап җитмәде кебек. Миңа гына әйтәсе сүзе бар сыман, ләкин...

Ир. Алайса ул теге капкадан киткәндер.

Ханым. Киткәндер, бәлки.

Ир. Энекәшне җирләгәндә ул катнаштымы?

Ханым. Инде һәркем хәтердә дә калмаган.

Ир. Сиңа ни сөйлисе булыр аның?

Ханым *(азрак уйланып торгач)*. Әле мин энегезгә кияүгә чыкканчы ук, ул минем белән аңлашырга теләгән иде. Мин аны тыңларга теләмәдем. Моннан өч ел элек, читтән илга кайткан вакытында, тагын аңлашырга теләде. Мин тагын теләмәдем. Хәзер хатыны белән аерылышканнар. Шуны гына әйтте.

Ир. Синдә мин белмәгән әллә ниләр бар икән.

Ханым. Яшерәсе серем юк. Сез—үз кеше.

Ир. Ярый, үз кешеләр булып калыйк... Минем күңелгә теге хәбәр тынгы бирми генә бит. Бәлки чыннан да үтерүче килгәндер. Шушы юлдан узадыр, шушында утырганы бардыр. Аны җиде ел таба алмыйлар.

Ханым. Эзләмиләрдер. Табарлар иде... Икенчедән, нинди үтерүче үзе үтергән кеше каберенә килсен? Ничек мин үтерүче дип йөрсен? Булмас.

Ир *(Икенче килүчене истә тотып)*. Бу кеше кайчан кайткан?

Ханым. Сорамадым... Сез чынлап та аңардан...

Ир. Кайтуыма кинәт ишетелгән сүз миңа нык тәэсир итте. Шикчел кешегә дә әйләнәм. Кешеләрне яратмый башладым, үземне дә... Без ата тәрбиясе күрмәдек, ул сугышта югалды. Әнкәй кирәгеннән артык йомшак, яхшы күңелле булды. «Улым, усал булма! Кеше рәнҗетмә! Ярдәмле бул! Кичерә бел!» Ул мине шулай богаулап дөньяга җибәрде. Синең ирең сигез айлык чакта атасыз калды. Өч яшендә

әнисез дә калды, аны да әнкәй богаулады.

Х а н ы м. Юкны сөйләмәгез, сөйләмә..,

И р. Юк түгел, бу дөреслек. Мин үзем дә һаман аны яхшы булырга өндәгән, аны богаулаган кешеләрнең берсе. Аның үлемендә гаебем бар, шуна утырам мин монда. Аны усал булырга, кеше белән артык исәпләшмәскә өйрәтсәм, әле ул яшәр иде. Синең балаларың үсә, усал булсыннар.

Х а н ы м. Усаллар да үлә. Гомерләре булсын.

И р. Усаллар үзләре үтерә.

Х а н ы м. Йа Хода! Үтерүчеләр тәрбияләргә кушасыңмы?

И р. Кушмыйм. Балаларыңны богаулама. Богаулыларны жигеп була, жинеп була. Безнең әнкәй шуны белмәгән. Шуңа күрә энекәшнең үлемендә аның да гаебе зур.

Х а н ы м. Әнкәнә карата... Шундый уй...

И р *(бераз тын торгач)*. Богаулылар алар—тышаулы атлар сыман. Богаусызларны да күрдем—арысланнарга, крокодилларга, әллә нинди ерткыч хайваннарга охшыйлар. Кайчакта аларга ачу килде, кайчакта кызыктым. Богауымны сала алмадым... Һәркем ниндидер бер хайванга охшый икән. Бабаларыбызга охшыйбыз, бабаларыбызга.

Х а н ы м. Ә мин нинди хайванга охшыйм?

И р. Бик яраткан энемнең хатыны булганың өчен, мин сиңа артык туры карамадым. Моннан соң карармын, әйтермен.

Х а н ы м. Кайчан?

И р. Бүген үк. Ә теге кеше мине ошатмагач, киткәндер. Кайсыдыр, рәхмәт төшкере, безгә утыргыч ясап куйган, утырыйк бераз. Ни әйтсән дә монда урман. Шәһәргә дә урман аша төшәрбез.

Х а н ы м. Рәхмәт.

И р. Урман аша озатырга уйлавым өченме?

Х а н ы м. Нинди хайванга охшавымны бүген үк әйтергә уйлавыгыз өчен.

И р *(Ханым янына утырып)*. Бәлки кешене хайванга охшату тойгысы кешеләрне яратмаган кешегә генә хастыр. Бәлки барлык кешегә дә хастыр, сиңа да.

Х а н ы м. Әлегә миндә андый тойгы юк иде.

И р. Димәк, бәхетле чагын.

Х а н ы м. Бәхетле чагым энегез белән яшәгәндә булган. Шуна күрә бүген биредә утырам.

И р. Бирегә сине мин чакырдым. Телефоннан.

Х а н ы м. Чакырдыгыз, әйе...

И р. Шуна күрә килден. Гаепләп әйтүем түгел, тормыш бу.

Х а н ы м. Сез гаепләгез дә... Тик алай ук күнелне авырттырып сөйләшмәгез. Соңгы көннәрдә гел килергә уйлап йөри идем. Сез шылтыратмасагыз да килер идем.

И р. Ә теге кешең үзе дә миңа ошамады.

Х а н ы м. Минем кешем түгел, энең кешесе.

И р. Кечкенә чагында энем миңа әти дип эндәшә башлады. Мин шуңа малайлардан ояла идем. Аннан кинәт үсеп китте. Бөтенләй үзгәрде. Бераз мактанчыклыгы калды. Мин фәлән итәм, мин төгән итәм. Үз көнемне үзем күрергә көчем житәр, ди.

Х а н ы м. Үзе өй салганда мина бурычка керде, бурычын да түли алмыйча үлде, дисеңме?

И р. Алай әйтмим. Һаман яшәргә жыенды. Әллә ни рәхәт күрергә өлгермәде.

Х а н ы м. Егерме алты яшендә ике йорт салырга өлгерде. Бер йорт сала алмыйча киткән кешеләр дә бар.

**Шулвакыт алар янына каберлек ягыннан Икенче килүче якынлаша. Утыра. Ир белән Ханым, аның килүен сизми дә калгандай, сүзләрен дәвам итәләр.**

И р. Ак биләү белән күтәреп йөри идем. Ак кәфен белән жирләдем. Энем кебек кенә түгел иде, тәнемдәге кан тамыры кебек иде шул. Шуны кемдер өзде дә мин начарландым. Әгәр ул кеше бирегә, әйтик, шушында аны күрсәм... *(Якында яткан ташка күрсәтеп.)* Әнә теге таш белән сугып үтерә алам.

И к е н ч е к и л ү ч е. Үтерүче килеп йөрмәс. Бәлки, берәр исерек, кем янынадыр килгәч, шулай шаярткандыр.

И р. Андый шаяру булырмы?

И к е н ч е к и л ү ч е. Юк сүзләр... Каян чыккан ялгандыр ул?

Х а н ы м. Мин дә шулай дим шул.

И р *(Икенче килүчегә)*. Шушында кемдер, имеш, кемгәдер шулай сөйлә-

гән. Шул сүз безнекеләргә җиткән.

Икенче килүче. Үлгән кеше артыннан имеш-мимешләр йөри инде ул.

Ханым. Үтерүче инде кайчандыр кеше үтергәнен дә онытып яшидер.

Ир. Йә һаман кеше каны коеп йөридер. Тотылмый да, тотыласы да юктыр.

Икенче килүче. Бәлки, тотылыр да ул, ләкин...

Ир *(үзалдына).* Утырыр да иреккә чыгар.

Ханым. Киткән кеше кире кайтмый... Әйтә алмады шул. Нидер аңлатырга бик тырышты. Аңлата алмады.

**Шул мәлдә болар янына Карт килә. Икенче килүче, Картка урын бирү нияте белән, урыныннан тора.**

Карт *(Икенче килүчегә).* Утыр, утыр. Монда урын җитә. *(Ир белән Ханымга ишарәләп.)* Аларга да, миңа да, сиңа да җитә. *(Ул утыргычның өч кешедән артып калган өлешенә утыра.)*

**Беразга тынлык урнаша.**

Ир. Урын җитә.

Карт. Киләләр дә киләләр. Киләләр дә киләләр.

Ханым. Кемнәр килә?

Карт. Үлгәннәр. Үлүче күп.

Икенче килүче. Үлемнән качып булмый.

Карт. Булмый.

Ир. Үтерүче дә күп.

Карт. Шулай шул.

Ханым. Әллә каберлек караучымы сез, бабай?

Карт *(нидер уйланып).* Каберлек караучының закунлаштырмаган ярдәмчесе мин. *(Үзалдына әйткән кебек.)* Капка башына мәрхәбә дип язылмаган. Барыбер киләләр. *(Бер мәлгә тын торгач, утыргыч астын карый. Чүкечен ала.)* Үзен үлгәннән соң, утырткан агачың калсын, диләр. Мин менә утыргыч та ясадым.

Икенче килүче. Әйбәт ясагансыз. Озын.

Карт. Шулай булмаса, мона бүген син сыймас идең. Йә мин сыймас идем.

**Ул уйланып, беразга тын тора.**

Гомер үтте әле, оланнар.

Ир. Ә яшисе килә.

Карт. Шулай... Яшәргә кирәк. Сез әле яшь... Монда киләләр дә киләләр. Кире китә алмыйлар. Соңгы юллары минем өй яныннан үтә. Мин дә киләм. Үзләрен урнаштырырга булышам. Башка ярдәм күрсәтеп булмый.

Икенче килүче. Каберлеккә килгәч, миннән сәлам булсын ятасы туфрагыма дип әйтү кирәк икән.

Карт. Әйтәбез инде аны. Өемә якын җир. Көн дә килеп әйтәбез.

Ханым. Мондый җиргә китерә торган юл буенда яшәү—җайсыз түгелме соң, бабай?

Карт. Юлдашларынны танымыйм микән, кызым? Күргәнем юкмы? Оныткангмын гына микән?

Ир. Без башка шәһәрдә торабыз.

Карт. Шулайдыр, шулайдыр.

Икенче килүче. Әкерен генә кузгалабызмы әллә? Бабай, әнә, салкын корал да чыгарды.

Карт. Курыксагыз, куябыз аны яткан урынына. *(Утыргыч астына куя).*

Ханым. Кузгалырбыз да шул инде.

Ир *(Ханымга).* Ашыкмыйк ул хәтле. Көн дә биредә утырмыйбыз. Әле биргән соравыңа җавабым да әзер түгел.

Карт. Шулай. Искә алып килгәнсез. Китәргә өлгерерсез.

Икенче килүче. Эшләр көтә, бабай.

Карт. Исән кешегә эш нәрсә? Кабердәгеләр—монда чыгып утыра алмый. Эшли дә алмыйлар.

Ханым. Монда килгәннәрне урнаштырырга булышып кына яшисезме, бабай?

Карт. Башка эшләрем дә бар, кызым. Күршемдәге бер чибәр әбиегез миңа бик булыша иде. Бер дә чирләмәс кебек күренә иде, бирешге. Аңа ярдәмем кирәк.

**Тынлык.**

Башта мин бер генә кешелек утыргыч ясаган идем. Үзем өчен генә.

**Дәвамлы тынлык. Карт башын иеп утырган. Әкерен генә моңлана башлый. Башкалар аптырашып бер-беренә карашалар. Икенче килүче чигәсенә төрткән бармагын борып тора *(Ахмаграк карт бугай, диюе).* Әмма Картның җырын тыңлыйлар.**

Гел таралып төшләремә керә
Каралардан кара толымы,
Каралардан кара толымы.

Гөнаһ булыр иде яратмасам—
Яратуым хатам булдымы,
Яратуым хатам булдымы?

**Көй һәм Карт моңы тынып кала.**

Ир *(Картка).* Мондый жирдә... Каберлек янында жырлау—нәрсә дигән сүз инде?!

Карт. Мин бит болай гына... Тыныч кына.

Ханым. Килешми бит, бабай.

Икенче килүче. Син, бәлки, монда тыныч кына биерсең дә?!

Карт. Гафу итегез.

Икенче килүче. Әнә, урман эченә китеп, иркенләп жырла!

Карт. Жинел сөйләдем—авыр уйладым, дигәндәй. Кинәт шушында, урман почмагында—бүре булып улыйсым килә башлады. Күккә карап, бүре булып уламас өчен генә моңландым инде... Гафу итегез.

Ир *(Картның йөрәгендә ниндидер яра барын сизенеп, аны юатырга теләп).* Бүре булып уларга кирәкмәс.

Карт. Кирәкмәс... Яшәргә кирәк... Безгә бүген... яшәргә кирәк, оланнар.

Икенче килүче. Сәер кеше син. Бүре булып улыйсың килә. Бүген яшәргә кирәк, дисең. Бүген белән генә яшәргә түгел. Кеше киләчәк өчен яши, иртәге белән яши.

**Беразга тынлык.**

Карт. Йорт кирпечләрдән төзелә, киләчәк—бүгеннәрдән. Шуны уйлап караганың бармы? Әллә уйлыйсы килмиме, әллә уйларга баш житмиме?

Икенче килүче *(үрталеп, кычкырып).* Синең баш житмәгән! Бүгенеңне уйлап, иртәгеңне онытып, шушы яшеңдә бүре булып улар хәлгә калгансың!

Ханым *(Икенче килүчегә).* Алай ук ярамас иде.

Карт. Монда кычкырырга ярамый... һай, бу кеше дигәнең... «Иртәгә» белән аклана, «иртәгә» белән юана. Яхшылык—иртәгә, бәхет—иртәгә, бөтен юллар шуңа илтә... Ә дөньядагы бөтен юллар каберлеккә кертә: анда—«Иртәгә», бәхет, ожмах—анда. Шуны да уйлагыз... Сез бүген ожмахта түгелме? Шуны да уйлап карагыз.

Ир. Мин нәкъ шуларны уйлап утырам әле.

Ханым. Тормыш төрлесен уйлата, төрлечә уйлата. Балалар бар бит.

Карт. Минем дә кызым бар иде. Әле ул кечкенә иде. Ап-ак тешләрен күрсәтеп елмая да елмая. Минем яшь чак, егәр бар. Үземчә, туры юлда таш ярам. Тарих фәннәре буенча кандидатлык якларга йөрим. Килеп чыкты бит шунда бер акыллы баш—Ганиев. Үзебез аралашып үскән кешеләр, минем хезмәткә каршы төшә. Сәяси хаталар таба... Институттагы кешеләр мине, мин аларны яратмый башладык. Шунда ул чакның бүгенелә төкереп, Ганиев белән иртәгә хисаплашырга уйлап, институттан киттем. Мәктәп директоры булып эшли башладым. Ганиевнең озын бармаклары һаман мине ашый торды. Минем жан белән кызыксынган тагын бер танышым—Әминев пәйда булды. Киләчәктә аңардан да үчне кайтаруыма өметләнәм. Жанны хәрәкәт юата. Яңа мәктәп салдырып йөрим... Шунда, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, акча эшләрендә ялгышлык чыкты. Мине кулга алдылар.

Ир. Яклаучы булмады?!

Карт. Яклаучылар да булды. Каршылар жиңде.

Ханым. Озаккамы?

Карт. Озакка. Ярый мин тиз арада тимергә әйләнеп өлгердем. Киләчәк белән яши торган тимер кеше!

Икенче килүче. Тимер булу—ярап тора ул.

Карт. Гомернең тимер чагы да бөгелә. Сынарга теләми. Барысы да күз алдында.

Икенче ир. Андый чаклар еракта калды.

Карт. Әнә теге агачлар артында гына сыман.

Ир. Кешеләр теләсә кайчан, теләсә нинди әшәкелеккә сәләтле. Мин кешеләрне яратмыйм.

Карт. Яратырга кирәк.

Ир. Ник аларны яратырга? Менә сез мине ник яратырга тиеш әле? Мин сезне ник яратырга тиеш?

Карт. Мине яратма.

Ир *(Икенче килүчегә күрсәтеп).* Аны яратыйммы?

Карт. Кешеләрне ярат.

Ханым. Шаярып сөйли ул.

Икенче килүче *(шаяргандай итеп).* Ул ярата белми.

Карт. Килгән бит. Ярата белмәсә, килмәс иде монда.

Ханым. Кыенлык күргән кеше икәнсез, бабай.

Карт. Әйтәм бит, мин тимергә әйләнеп өлгердем. Ул кыенлыкларны хатыным күтәрә алмаган. Еллар үткәч, сагынып кайтсам, хәлләр Хәсән Туфан язганчарак иде:

—Кайт!—дип хатлар килделәр...
Юллар озын иделәр...
Кайттым.—Бусы—алкалары,
Бусы—кабере,—диделәр...

Минекенең башта кабере дә билгесез, югалган иде. Кызым әнисеннән соңрак үлгән. Әнисенең кабере монда, кызымныкы авылда, моннан илле чакрым... Кайтсам хәлләр шулай. Шушы урынга бер кешелек утыргыч ясап куйдым. Үзем өчен генә. Килеп утырам. Хәлемне утыргычым гына аңлый сыман. Көннәр матур торса—киләм. Яңгырлар яуганда—киләм. Карлар яуганда—киләм. Мин узмас төн, чишелми торган төен булып йөрим... Берзаман күрә башладым—тирә-юнемдә кешеләр. Зур эшләр башкаралар. Берәүләре зурдан кубып, вак кына эшләр белән кайнаша. Миңа шулар кызык тоела башлады... һәм мин көлдем. Яшәү кызык икән бит. ...Ганиев доктор булган. Минем кандидатлык якларга йөргән хезмәт аның докторлык хезмәте нигезенә әйләнгән. Бу да миңа кызык тоела, монардан да көләм. Шулай чишелеп киттем. Яктырып киттем. Ләкин сизәм, күнелемдә бер кара тап калган. Анда теге ике яшьтәшемә ачу ята.

Ханым. Хезмәтеңне урласын да, ачуланма да...

Карт. Урламаган. Аның карашы үзгәргән.

Ир. Сез кайтуга үскән. Сезнеңчә уйлау дәрәҗәсенә ирешкән.

Икенче килүче. Үч алдынмы?

Ир. Кирәк иде шул.

Карт. Әйе, күнелдә шундый уй йөри. Докторлык хезмәте өчен түгел. Минем тегендә китүемә, хатынымның монда килүенә зур өлеше кергән өчен. Кызым өчен дә... Булмәсенә бәреп кермәдем. Үзәк урамнын биек күпере өстендә очраштык. Үзегез беләсез, аста су әллә ни булмаса да, яры хәйран тирән. Бер-беребезгә каршы якынаябыз. Бу мине таныды. Бер унгарак, бер сулгарак тартылганы сизелә. Мин туптуры барам. Нәкъ күпернен уртасына життек. Кесәсеннән нидер ала, валидол икән. Кул сузам, валидолы жиргә коелды. Миңа таба үрелергә дә, үрелмәскә дә белми торган кулын тоттым. Кулы салкын.—Нихәл, яшьтәш,—дим.—Үзең сау гынамы? Минем хәл начар,—ди. Авызы кипкән. Теле авыр әйләнә, йөзе нурсыз. Башы йодрык хәтле генә. Тагын бераз үзенә карап торсам, авып китәр кебек. Гайрәтле, ядрә сыман чагы бар иде.—Машина тотыйммы? Озатыйммы?—дим.—Кайтып життем инде,—ди. Күпер яңагына сөялеп калды.

Ханым. Курыккан, гаебен таныган.

Ир. Гафу үтен, югыйсә аска ыргытам, дияргә иде.

Икенче килүче. Тезлән, жиргә утыр, дип колагына кычкырырга иде. Кычкырсаң—шып итеп утыра. Чирле дә булгач, аңа дөнья белән саубуллашырга да шул житә иде.

Карт. Ярамый...

Ханым. Аңа яраган бит.

Ир. Аның гаебе каршында—бу шаяру гына булыр иде.

Икенче килүче. Юкка кызганасың син ул Ганиевне.

Карт. Якын булып китте. Бергә үскән чак искә төште. Шул очрашудан соң озак тормады. Монда ул. Каберен казыштым. Аны жирләгәндә... югалган кабер... хатыным кабере табылды. Әминев тә монда. Һәр кеше якты дөньяда бер генә шаярып ала да шушында килә. Яшәгәндә бер-береңне ничек аңламаска кирәк? Тимер булып кала алмадым. Барыгыз өчен дә борчылам. Югыйсә, бер уйласам, үз хәлем үземә житкән. Шушында гына килеп ятасым калган... Яшь кенә хатыным монда ята. Кара күзле кызым, бөтенләй бала гына, ул да күптән ята. Мин нинди кыяфәттә... Хәзер яннарына барып, кулым сузсам—кызым куркыр, хатыным да танымас... Кайчак миңа шулай тоела да... Шушы утыргыч янында карт бүре булып улыйсым килә башлый.

**Ул, торып, шәһәр ягына карап тора.**

Бөтен шәһәр каршында... Сузып-сузып улыйсы килә. Барлык шәһәр этләре качып беткәнче улыйсы килә.

Ханым. Бабай!

**Карт кесәсеннән кулъяулык чыгара. Акчалары жиргә коела, үзе кулъяулыгы белән маңгаен, битләрен сөртә.**

Ханым. Бабай, борчылмагыз инде?!

Карт. Аннан шәһәр эченә чабасы, урамнар буйлап, бүре булып чабасы, чабасы, чабасы... кешеләр атып алганчы чабасы килә...

Ир *(әкрен генә)*. Бабай...

Карт. Яралангач, җирдә—бөгәрләнеп чиныйсы килә. Бөгәрләнеп чиныйсы килә.

**Карт коелган акчаларын таптап бара, утыргычка утыра. Ханым аның коелган акчаларын җыя. Картка илтә.**

Ир. Минем кәеф тә, бабай, шулайрак әле. Сезнеке кебек.

Карт. Ярамый... яшь кешегә.

Ханым *(Картка коелган акчаларын бирә)*. Мәгез, кирәге чыгар.

Карт. Рәхмәт, кызым. Син нишләп монда озак килми тордың? Минем утыргычка утырмадың? Хәтерем начарланса да... сине хәтерлим. Соңгы тапкыр моннан ике ел элек күргән идем, килгән идең... Шулаймы?

Ханым. Әйе.

Карт. Ул көнне мин дә килгән идем. Шушы утыргычта тын гына елап алдың. Син елагач, мин юатырга уйладым. Ирем янына килдем, дидең.

Ханым. Мин аны онытканмын... Хәтерегезгә, бабай, күз тимәсен.

Карт. Зәһәр хәтерем—яшьлегемдә калды. Нишләп алай озак килми тордың?

Икенче килүче. Кайчандыр татар хатын-кызларына каберлеккә килергә ярамаган.

Ир. Күп гадәтләр онытылды. Кискен үзгәрешләр булды—унайга таба... Каберлеккә таба.

Ханым. Моннан ике ел элек мин кияүгә чыктым, икенче кешегә.

Карт. Шулайдыр дип уйлаган идем.

**Икенче килүче урыныннан тора. Китәргәме, калыргамы, дигәндәй йөри. Калса да, китсә дә уңайсыз кебек.**

Ханым. Мена тагын килдем. Ирем янына. Бу аның абыйсы. Иремнең әнисе белән бертуган абыйсы.

Карт *(Икенче килүче белән кызыксынып)*. Бу олан кемегез була инде?

Ир. Энемнең дусы.

Карт *(Икенче килүчегә)*. Утырып тор, олан. Монда шулай борчылдыра инде. Монда килгәч, һәркем борчыла...

Үзен күптән җирләгән идегезме әле?

Икенче килүче. Күптән инде, күптән.

Ханым. Җиде ел була.

Карт. Гөрләп яшәр чакта, ашыккан.

Ир. Аны ашыктырдылар, пычак белән.

Карт. Берәүләр үзен-үзе... икенчеләр—өченчене. Тегендә—тезелешеп яшьләр ята. Аннан аларны искә алырга киләләр. Абыйсы, хатыны, дусы... Алар башта еш килә. Соңрак атнага бер, айга бер, елга бер, ике елга бер. Искә алырга килүчеләр барыбер кимеми. Бүген мена гаҗәп, монда тыптыныч... Үзем өчен генә ясаган утыргычны алыштырдым. Зурайтырга уйладым, бәләкәй иде.

Икенче килүче. Юкка мәшәкатьләнгәнсең. Кеше бирегә кунакка килми. Утырып тормаса да була.

Карт. Бераз утырып торса—начармы?

Ханым *(Икенче килүчегә)*. Сез ашыгасызмы? Әшегез каламы?

Карт. Ул бүген дусы янына килүдән дөньяның бөтен эше тукталмас. Шулай бит, олан.

Икенче килүче. Бабай—үзе эшем күп дигән иде. Үзе шушында гомер уздыра икән. Кечкенә утыргычын алып, зурын ясаган. Мәшәкатьләнгән.

Карт. Анысына... Сез утырсагыз, мин сыймас идем. Соңгы елларда йомшадым. Тиз арыйм, еш утырам.

Икенче килүче. Шуңа күрә хәзер сиңа өйдә генә ятарга кирәк.

Карт. Өем якын.

Икенче килүче. Торыр урын сайлый белмәгәнсең.

Ханым. Бабай—хатыны янына якынрак булырга теләгән.

Ир *(Икенче килүчегә)*. Аның кая торуы сиңа барыбер түгелме?

Икенче килүче. Миңа барыбер.

Карт. Ана барыбер. Ә мин менә утыргычны зурайттым. Яхшысы, яманы утырыр, әллә зурайтмаскамы дип тә уйлаган идем. Зурайттым. Икәү генә булсагыз, килми идем. Өчәү булгач—килдем. Барыбыз да сыябыз. Утыр, олан. Киткәндә—китәрсең, дусың сине кычкырып туктатмас. Артыннан куып тотмас. Утыр.

Икенче килүче. Син миңа бәйләнмә әле. Дүртәү сыйгач—бик

яхшы. Өч кешегә тагын да иркен. Мин басып торам, бер урында озак утыра алмыйм.

Карт. Шулайдыр, шулайдыр.

Ир *(Икенче килүчегә)*. Чынлап та, ашыксагыз—барыгыз.

Икенче килүче. Миңа игътибар итмәгез.

Ханым. Хәзер бергә китәрбез.

Ир *(Ханымга)*. Син дә ашыгасың бугай. Ләкин сине әлегә мин җибәрмим. Ике ел килми торгансың. Моннан ары өч елдан соң гына килүен бар.

Ханым. Сез мине аңларга тиеш.

Карт. Сине без аңлыйбыз... Бергә гомер иткән әйбәт кешең булгач, ешрак кил.

Икенче килүче. Әйбәт кеше иде.

Карт. Җинаятьчене һаман тапмадылармы?

Ир. Ул хакта каян беләсез?

Карт. Кызым әйткән иде. Теге чакта. Шушында елап утырган чакта... Аны табу—киткәнне кайтару түгел, әлбәттә.

Ир. Шулай да күнелгә бераз җиңеллек килер иде.

Икенче килүче. Аны күрүче булмаган, бабай.

Ханым. Күрүче танып өлгермәгән.

Ир. Танып та әйтмәве мөмкин.

Икенче килүче. Берәүләрен бүген япсалар, икенчеләре иректә кала... Алар бит иртәгә...

Карт *(Икенче килүчегә)*. Минә әйтеп тә бирдең. Миңә ул ничек?!

Икенче килүче. Нәрсә—ничек?

Карт. Иртәгә.

Икенче килүче. Аңламыйм.

Ир. Аңламыйбыз да, күрмибез дә... Күрмәскә тырышабыз.

Карт. Әллә барын да күрәбезме?

Икенче килүче *(Карттан шикләнебрәк, аңа янабрак)*. Күрмибез, бабай. Күрмибез.

**Кинәт музыка тавышы ишетелә. Икенче килүче урыныннан тора.**

Ир. Кемнедер китерәләр.

Икенче килүче. Шушы тавыш миңа начар тәэсир итә.

Карт. Монда бүген кабер казымадылар.

Ир. Монда урын да юк бугай.

Карт. Бар әле бераз.

**Ишетелгән музыка әкренәя.**

Яңа каберлеккә илтәләр. Туфрак бер булса да миңа шушы каберлек якын.

Ханым. Бу тавыш миңа да авыр тәэсир итә. Куркып китәм. Ирем шуннан бер дә курыкмый иде. Бервакыт, икенче өебез өлгерүгә шатланып, эчтә тәртип урнаштырып йөрибез. Урамда шушы көй ишетелде. Ирем капка төбенә йөгереп чыкты. Озатуларын карап кала. Мин ишекне ачтым, чиләкләп яңгыр коя. Чыланасың бит, кер дип кычкырам. Ул мине ишетмәгән дә кебек. Янына йөгереп бардым. Әйдә керик, дим. Ул мине кинәт кулына күтәрде. Чәчләрендә, күзләрендә, бөтен йөзендә яңгыр суы йөгерә. Ул мине үбеп алды. Иреннәре су гына. Ул мине тагын үпте, кат-кат үпте... Ул шулай минем белән саубуллашкан икән. Шуннан соң күп тә үтмәде, үзен озаттык.

**Карт урыныннан тора. Музыка тынып калган якка таба атлый. Туктап тора.**

Икенче килүче. Тапканнар күмер вакыт.

Ир *(Ханымга)*. Ә бабай нидер белергә мөмкин. Чәчәк китергән үтерүче турында.

Ханым. Бабай! Ишетми. Бабай!

## Икенче бүлек

**Шул утыргыч. Ир, Икенче килүче, Ханым утыргычта. Карт читтәрәк басып тора.**

Ир *(Карт янына бара)*. Әйдәле. Утыр әле үзеннең утыргычка.

**Карт һәм Ир килеп утыралар.**

Ир. Бабай, шушы каберлеккә берәү килә икән дип ишеттек.

Ханым. Ул, имеш, үзе үтергән кешенең каберенә килә икән.

Карт *(уйланып)*. Әйе, әйе.

Икенче килүче. Әкиятләрдә паласлар да оча.

Ир *(Икенче килүчегә)*. Без бабай белән сөйләшәбез... Шундый хәлне ишетергә туры килмәдеме, бабай?

Карт. Андый хәлне ишетмәдем шул. Минем хәзер ишеткән белән түгел, күргән белән генә яши торган чак. Картлар яшәгәндә, яшьләргә ник яшәмәскә?! Ничек бер-беренә кул салырга кирәк?!

Икенче килүче. Бер кызны подвалдан тапканнар. Тәнендә егерме яра булган—ундүрт, унбиш яшьлек малайлар эше икән.

Ханым. Егерме биш яшьлек рәссам, бездән ерак түгел генә тора иде, жиденче каттан сикерде. Рәсем дәресе укыта иде, кызым анарда укыды. Бик гади кеше иде.

Карт. Үлеме катлаулырак булган икән.

Икенче килүче. Бусы куркаклар үлеме. Тормышның ниндидер авырлыгы каршында куркып калган.

Ир. Үзеңне үзең үтерү өчен дә батырлык кирәк.

Икенче килүче. Нинди батырлык?! Тоткан да сикергән.

Карт. Шулай жинел генә сикерерсең микән?

Икенче килүче. Ә мин сикермим... Ахыр чиктә, кеше шуны теләгәч, ихтыяры. Андыйларның кайгысы шул хәтле генә.

Карт. Андыйларны да озатып куючылар була.

Ханым. Үзен балалар бик ярата иде.

Ир. Юк сәбәп белән сикермәс.

Икенче килүче. Заман кирәкренке. Куәт, тизлек заманы. Берәүләр шуңа иярә алмый. Алар тормыштан үзләре теләп төшеп кала.

Ханым. Минем ирем гел яшәү турында, балаларын үстерү турында уйлады. Бу рәссам да жир астына ашкынып тормагандыр.

Икенче килүче. Тормыш законы кырыс. Иярә алмаган—төшеп кала. Бүген төшмәсә—иртәгә төшә. Бу мәсьәләгә шулай карау кирәк.

Карт *(Икенче килүчегә)*. Мәсьәләгә син шулай кара. Ләкин мәсьәлә сиңа ничек карый? Бүген төшмәсә, иртәгә төшеп кала, дисең. Синең шундый уй белән яшәвең, тагын кемнәрнеңдер шул—аларның төшеп калуына сәбәп түгелме? Алар яшәргә туганнар иде: үзе теләп тормыштан киткәннәрне әйтәм. Шушы рәссам кебекләрне. Менә бу кызымның ире кебекләрне дә аларга кушыйк. Яшәргә туганнар иде. Инде төшеп тә калганнар. Кеше гомерен өзүчеләр... үзләре дә тормыштан төшеп калган кешеләр. Әнә шулар барысы бергә зур югалту түгелме?

Ханым. Төзәтеп булмый торган югалту.

Ир. Ләкин югалганнар—төрлесе төрле кеше.

Карт. Югалту булгач, аларны жыеп карарга була.

Икенче килүче *(Картка)*. Син барын бергә жыеп, бутап бетердең... Юк... Бу мәсьәлә минем алда алай түгел.

Карт *(аны бүлеп)*. Ә мәсьәлә алдында син ничек? Алар синең янда торды, карасак, төшеп тә калганнар. Алар заманга иярә алмадылар, диярсең. Ник аларны заманга иярерлек итмәдең? Үзең яшисең, аларны ник үзеңә ияртмәдең?

Икенче килүче *(ачуы кузгалып)*. Сиңа ни әйтим?! Ияргә белмәделәр!

Карт. Ник өйрәтмәдең?

Икенче килүче. Син дә безнең белән. Алар синең һәм минем янда тордылар. Ә ник син өйрәтмәдең? Ник аларны заманга ияререрлек итмәдең?

**Күпмегәдер тынлык.**

Карт. Мин артык өлкән. Күптән астымнан ат киткән, ияр киткән. Йөгән югалган. Көч—сездә. Яшьләр сезнең янда. Подвалдан табылган кыз бала да, аның тәненә егерме яра

ясаучылар да сезнеке... Кайгыртырга—сезгә кала.

Ир. Сез, димәк, яшьләрдән ваз кичтегез?

Карт. Ваз кичмәдем. Шуны гына әйтәсем килә. Күпме яшьләр яшәргә әзер түгел. Өлгермәгәннәр. Бүгенге кояш нурын тәннәренә сеңдерә белмиләр, үзләренә тизрәк—киләчәк кояшы кирәк. Зуррак кояш кирәк. Менә... Кызымның ире исән чакта шушы кояш булган. Миннән соң да, сездән соң да шушы кояш калыр. Кояш моннан зур булмас.

Ханым. Кояшы зур ла аның...

Карт. Шуннан зурны эзләп ашыкканда—ялгыш басыла. Аяк каймыга.

Икенче килүче *(шаярырга тырышып)*. Аяк төзәлә ул.

Карт. Муеның сынса?! Күп муеннар сынды. Бихисап башлар ватылды.

Икенче килүче *(елмаерга тырышып)*. Тимер башлар ватылмады. Әнә, синеке дә ватылмаган. Ә тимер булып кала алмадым, дисең. Алдыйсың.

Ир. Ниндидер җүләр сөйләшү.

Икенче килүче. Шаярып кына.

Карт. Шаярдык инде... Хәзер шушында җыелып, узган шаяруларыбыз нәтиҗәсен карап утырабыз.

Ханым. Бәлки узган яраларны тизрәк оныту өчен дә киләчәккә ашыгабыздыр.

Икенче килүче. Бабайның бүгенгә һәм киләчәккә карата үз карашы бар. Ул әйбәт кеше, тик картайган гына. Киләчәк—яшь, матур сүз.

Ир. Матур сүз белән иркәләп-җайлап, юатып, әкрен генә кешеләрне буып та була. Каберләре өстенә дә матур сүз куеп була... Бабайның уйлануларын аның картлыгына бәйләп карамыйк.

Икенче килүче *(урыныннан торып, ирония белән)*. Әйдәгез, аның уйлануларын яшьлегенә бәйләп карыйк.

Ир *(Икенче килүчегә)*. Авызың ни әйткәнне колагың ишетсә иде.

Ханым. Үпкәләшмик, тормыш турында сөйләшү...

Икенче килүче. Тормыш кешеләрне төрле юнәлешкә илтә. Бабай, үлгәннәр өчен, исәннәрне гаепли. Без—исәннәр. Иртәгә дә исән яшәрбез: бу—максат, алга илтүче көч. Гел шулай булган, шулай булачак. Кеше карга баласы түгел ич.

Карт. Карәле, син, чыпчык баласы. Әйт әле, бу кызымның ирен яхшы беләә идеңме?

Икенче килүче *(ачуланып, урыныннан торып)*. Бу тагын нинди сорау? Аның дусы иделәр бит син. Яхшы белә идем. Ике ел бергә укыдык. Аралашып яшәдек.

Карт. Ачуланма син, утыр. Ачу бит ул сөйләшергә дә, уйлашырга да, дөрес нәтиҗә ясарга да комачаулый. Ә бу рәссамны белә идеңме?

Икенче килүче. Юк, белми идем.

Карт. Алайса, син сандугач дигән җан иясен беләсеңдер. Сайрый-сайрый ерактан килгән, еракка бара. Әнә кырмыска оясы, анда нишлиләр дип беләсең? Киләчәккә баралар. Кырмыска да барып житәсе киләчәк ул... Шуны да уйласагыз иде.

Ир *(шаярыбрак)*. Хайван да шунда бара, кеше дә... Хайваннар—хайван халәтендә генә бара. Кешеләрнең берәүләре—хайваннар, йә ерткыч җанварлар халәтендә бара.

Икенче килүче. Киләчәктә алай булмас.

Ханым. Киләчәге дә артык пакь күренми. Гаиләсе булгач, гарибе дә булыр, дигәннәр.

Карт. Үз иңнәрендәге йөкне ташлап калдыру өчен әйткәннәр алар. Башкаларга калдыру өчен. Хәзер үзләре юк, ташлап калдырган йөкләре жирдә ята. Шуны күтәрә алсак, бәлки, бу кызымның балалары чит ата кулында булмас иде. Бәлки минем дә хатыным белән кызым исән булыр иде. Яшәп карар идек гарипсез гаиләдә. Йөкләрен күтәрә алмадык шул.

Ир. Күтәрергә көч житмәде, ә күзләр күрә...

Карт. Күзне капласаң, колак ишетә, эчтә нидер әрни.

Ханым. Әрнетерлек хәлләр без генә, бүген генә бетерерлек түгел.

Икенче килүче. Бүген артык аз вакыт ул.

Карт. Син гомереңне—бүгенең дип уйла. Бу шактый күп вакыт, шулай ук аз да.

Ханым. Озак яшәүчеләргә—күп, берәүләр аз яшәп китә.

Карт. Жир дигән бу йортта даими яшәүче юк. Үтүчеләр керә дә чыга. Барысы да ашыга. *(Икенче килүчегә.)* Бергә укыган дусыңны монда, рәссам-

ны—тегендә, мине үзем ясаган утыргычта калдырып, барыгыз да—киләчәккә, алайса?

Ир *(ирония белән)*. Киләчәккә.

Карт. Йортны кем җыештырыр? Кем аңа хуҗа булыр? Әллә һаман шулай керербез, туздырырбыз да калдырырбызмы? Хуҗа да кирәкмәсме?

Ханым. Кирәк булыр, бабай.

Ир. Хуҗа табылыр. Ул да килер дә китәр.

Карт. Ул гел безнең белән барырга, башкалар белән калырга, кешелек гомеренең ахырынача шулай булырга тиеш.

Икенче килүче. Алай булмый, бар да үзгәрә.

Карт. Әле генә киләчәк—матур дидең. Инде килеп, бар да үзгәрә дисең. Бер тотрыклы таяну ноктаң булмагач, син нәрсәгә тотынып эш башлыйсың?

**Беразга тынлык.**

Ничек яшисең, дигәндәй.

Икенче килүче *(ирония белән)*. Узган тәҗрибәгә таянып башлыйм, киләчәккә таянып эшлим. Шулай яшим, башында акылы булган һәркем кебек.

Карт. Эшне йөрәкләрдән башларга иде бит. Йөрәкләргә таба йөз тотарга иде. Шунсыз акыл акылсызлыкка илтә. Йөрәктән башка, нәрсә ул акыл?! Аның кыяфәте дә юк, ул күренми. Күренсә, бәлки, котыбыз очып, егылыр идек. Акыл өчен аның булу-булмавы да барыбердер. Ә йөрәк яшәргә тели. Йөрәк тибә, туктамаска тели. Шуңа карамастан күпме яшь кенә кешеләрне бу минутта соңгы юлга озаталар. Калганнар узганга таяна, узганда—калкулык, чокыр, туфрак, каберлекләр... Киләчәккә таянабыз, анда әле йөрәкләр дә юк. Анда әле, бәлки, йөрәк тә, туфрак та булмас. Бәлки, булыр да... Әмма кешеләрнең игътибары әллә кайларга таралган. Бүгенге көннәрен күселәр кимерә. Мәйданнарда үзләренә ут төртеп яналар. Биек йортлардан сикерәләр. Атышалар, елыйлар, көләләр... Эчәләр. Атасы каршында—анасы, анасы каршында—баласы сүгенә. Баласы каршында—әбисе, бабасы... Дөнья сүгенә. Олы юк, кече юк, барысы да зур. Җир шарындагы шул зурларның берсе мин инде. Сезнең кебек зурлар янында утырам. Уйлаган, сөйләгән булам. Уйларым элек тә күп иде, шушы дүрт кешелек утыргыч кына башымда юк иде... Шуңа утырттты.

Икенче килүче. Утыртты?! Үзең ясагансың, үзең утыргансың.

Карт. Тормышны әйтәм.

Икенче килүче. Мин—утыргычны.

Карт. Ясыйм да утырам, ясыйм да утырам. Бу өченче утыргыч. Моннан ике ел элек бу кызым утырып елаганы искесе иде. Игътибар итмәгәндер. Хәтерләмидер.

Ханым. Хәтерләмим.

Карт. Менә мин аны алыштырдым. Үземнән соң яңа килеш калдырасы килә. Бусы матуррак та... Миңа килүче булмас. Сез килсәгез, мине дә искә алырсыз.

Ир. Утыргыч, бабай, бер тузар инде ул.

Карт. Әйе шул. Агач кына бит. Таралып кар астында ятар, җәйгә чыгар. Алыштыручы да булмас.

Икенче килүче. Кайгырмагыз, үзем алыштырырмын.

Карт. Синнән булмас, олан.

Икенче килүче. Ни өчен булмас?

Карт. Сөйләшүең шулайрак... Балаларың бармы?

Икенче килүче. Малаем бар.

Карт. Әнә шул малаең алыштырса гына. Ул да нинди юлдан китә, кем була? Үзең мондагы дусың язмышы көтә күрмәсен.

Ханым. Кайдан башланган ул яманлык, кайда туктар?

Ир. Эшләмичә ашыйлар. Киеналәр. Начарлык шуннан башлана.

Карт. Ул гына сәбәп түгел. Матур булсыннар.

Ир. Чәчәк кебекләр алар. Без аларны Алла иттек. Мәктәпкә йөгерәбез. Югары уку йортларына кертәбез. Укырга сәләтсез булсалар да.

Ханым. Күпләр укуны санламый хәзер. Белемле кеше белән белемсез кеше арасында аерма юк, диләр.

Карт. Үзебез биргән акыл.

Ир. Аларда акыл... зур. Язганнар иде бит. Бер банкирның кечкенә малае әтисеннән пистолет сорый икән.—Мин хуҗа кеше, зур кеше, шуңа пистолетым бар, син әле кечкенә,—дигән әтисе.—Барыбер акча табам, пистолет сатып алам. Шуннан соң

син хужа булмассың,—дигән малай.

Ханым. Үтерешнең чиге юктыр анда. Корал ирекле сатылган илләрдә.

Икенче килүче. Анда—башка дөнья.

Карт. Башка дөнья юк. Барыбыз да шушы бер дөньяда яшибез. Каберләр шушында. Үлүчеләр шушында, үтерүчеләр шушында. Акча, алтын... Барысы да шушында. Барысына да хужа булырга теләүчеләр дә шушында.

Икенче килүче *(шаярып)*. Менә... Шушындамы?

Карт. Әйе.

Ир *(елмаеп)*. Шушы утыргычтамы?

Карт. Әйе.

Ханым *(бу шаяру катыш сөйләшүне аңлап җиткермичә)*. Мин түгел. Хужа булырга уйлаганым да юк.

Ир. Мин дә юк.

Икенче килүче. Ә кем?

Карт *(урыныннан торып)*. Мин.

Ир. Алайса, боерыгыз. Туктатырга кирәк бу дөньякүләм безобразиены!

Карт. Ишетә һәм тыңлый белмиләр.

Икенче килүче. Ишеттерә, тыңлата алмагач, хужа булып чыкмыйсын шул инде.

Ханым *(шаяру катыш сөйләшүне аңлап)*. Логика шулай ди.

Карт. Минем логика алай дими. Йөрәгенне дөньяга хужа ит, ди.

Ир. Мин, бабай, йөрәкне нишләтим икән?

Карт. Дөньяга хужа ит.

Ир. Боерыйммы?

Карт. Киңәш бир.

Ир. Кемгә?

Карт. Үзенә.

Ир. Нинди киңәш бирим?

Карт. Киңәшне бишектән тыңлый башларга кирәк.

Ир. Безнен яшьтә соң булырмы?

Карт. Кемгәдер соң булмас. Кемгәдер соң булуы бар. Шулай да киңәш алу ярый.

Икенче килүче *(Картка)*. Син кемнән киңәш алдың?

Карт. Үземнән. Миңа гомерем киңәш бирде.

Ханым. Нинди киңәш бирде, бабай?

Карт. «Узганны башкалар якыннан күрде, чөнки ул аларныкы иде. Киләчәкне башкалар якыннан күрер, чөнки ул аларныкы... Син йөрәгең аша бүгенenә кара—шуна жир сыйган, ул синеке. Анда син тәрбиялисе йөрәкләр, шулар дөньяның мәрхәмәтле хужалары булырга тиеш!»—диде.

**Музыка. Карт көе.**

Укытылмый шул мәктәпләрдә мәрхәмәт фәне. Мәрхәмәт фәненнән өй эше бирелми. Мәрхәмәтле булырга өйрәткән хезмәтләр буенча кандидатлык, докторлыклар якланмый.

Ханым. Яклатырга иде.

Ир. Якларлар. Укулар үзгәрер.

**Музыка. Карт көе.**

Ир. Бүген бөтен илләр менә шулай без утыргычта сөйләшкән кебек сөйләшә ала. Сөйләшерләр, үзгәрешләр булыр. Тормыш яхшыга үзгәрергә тиеш дигән идея бар...

Карт. Идеяның төбе кин, гомере озын: бөтен кешелек гомеренә таяна. *(Пауза.)* Минем гомер бер генә булып чыкты бит әле. Анысы да матур гына тәгәлләнеп бара... Һаман бер карарга килә алмадым, хәл итә алмадым.

Икенче килүче. Нәрсә хәл итә алмадың?

Карт. Кызымның кабере авылда икәнне әйттем бит әле?

Ханым. Әйттегез, бабай.

Карт. Миңа авылга—кызым янына китәргәме, әллә бирегә—хатыным янына килергәме? Вакыт бик якынайды. Тизрәк шуны хәл итәргә иде: миңа кая барырга?

Ханым. Кызыгыз янына барыргадыр, бабай. Ул бәләкәй кеше.

Ир. Без катнашырлык эш түгел шул бу.

Икенче килүче *(узалдына сөйләнгәндәй)*. Хәл итәрләр. *(Инде турыдан-туры Картка мөрәҗәгать итеп.)* Тормыш турындагы кайбер карашларына гаҗәпләнеп торган идем. Гомер тәмамланганны сизгәндә туган төшенкелек кенә икән.

Ир. Нинди төшенкелек?!

Икенче килүче. Соң... Үзенне киләчәк белән бергә күзаллый алмау төшенкелеккә бирелүдән килә.

Ир. Син үзенне мәңгелек белән бергә күзалла. Синең кебек кешеләр мәңге яшәргә тиеш.

Ханым. Ярарыгыз инде.

Икенче килүче. Мәңгелек—күбрәктер. Бабай рөхсәт итсә, яшәргә исәп бар әле.

Карт. Миннән рөхсәт. Яшә син. Шуны гына әйтәм: узганында уң аягың, киләчәгеңдә сул аягың булса, бүгененә нәрсә булыр?

Икенче килүче. Син, бабай, сүгенеп утырма!

Карт. Аллам сакласын. Шушы яшемдә?!

**Дәвамлы тынлык. Әкрен генә Карт көе ишетелә башлый... Карт әкрен генә, үзе өчен генә жырлый башлый.**

Туры гына барсам—таулар биек,
Үзәннәрдән барсам—юл урау,
Үзәннәрдән барсам—юл урау.
...Күзкәйләре өчен баш жуярлык,
Түшкәйләре—көмеш кынгырау,
Түшкәйләре—көмеш кынгырау.

**Тынлык урнаша. Карт та башын иеп тып-тын утыра, башкалар да.**

Икенче килүче *(тынлыкны бүлеп).* Йоклый, йоклый ич бу. Төш күрә. Саташып жырлап утыра.

**Якын килеп, иелеп-иелеп Картны карыйлар.**

Ханым. Чынлап та йоклый.

Ир. Йоклый икән шул.

Икенче килүче. Әйтәм бит... Йоклап утыра.

Карт. Мин елап утырам.

**Барысы да үз сүзләре өчен кыенрак хәлдә калып, урыннарына утыралар.**

Ханым. Бабай, сиңа ничә яшь?

Карт. Әйтмим, күз тидерерсез. *(Узалдына сөйләнгән кебек).* Яратырга кирәк, яратырга. Ярату—йөрәкләр тәрбияләүнең башы.

Икенче килүче. Без китаплар укыйбыз. Аларның асылы шул инде—ярату.

Карт. Асылы шул дисең дә... Нәтижәсе—әнә, киләләр дә, киләләр... Малай чакта без дә көч сынаша идек. «Бергә—бер! Егылганны кыйнамаска!» Кагыйдәне бозмый идек. Авылда шул батырлыкка саналды... Хәзер?! Шәһәрдә?! Яманнар каршында егылсаң?! Күргәнегез дә бардыр... Яманнар белән аралашып, әйбәт кенә күңелле балалар да юкка чыга. Ялгыша да төрмәгә эләгә. Бөтенләйгә бозылып китә. Йә әйбәт күңеле бер мәлне баш калкыта да, вөжданы телгә килә дә—кешене үз йөрәге хөкем итә. Андыйларны да күрергә туры килде. Берсен шушында күрдем. Авылдан калага күчеп, яман дусларга юлыккан, ихтыяры сынган, үзен югалткан. Каберлектә йөри... Кемен янына килдең дисәм... Кеше үтергән идем, шуның янына килдем ди.

Ир *(Ханымга).* Ишеттеңме?

Ханым. Тукта!

**Карт беразга тынып кала.**

Ир *(Картка).* Шулай диме, шикләнеп тә тормыймы?

Карт. Шикләнми.

Икенче килүче. Жиденче каттан сикергән рәссам булгандыр ул. Үзенә урын карарга килгәндер.

Ханым. Рәссам урын карап килсә, аны монда күмәрләр иде.

Икенче килүче. Исәннәр көчлерәк. Кая теләсә, шунда күмә.

Ханым. Яшь кеше алдан үлемен уйлап, үзенә урын карап йөрер микән?

Икенче килүче. Ник йөрмәсен. Андыйлар бар. Әйбәт урын сайлап куялар.

Ир. Бәлки, ул урын карап йөрер дә. Кеше үтергән идем дип, ник алдар?

Ханым. Шулай шул.

Икенче килүче. Алламыйдыр, үтергәндер.

Ир. Алай булу да мөмкин... Рәссам кеше табигате белән йомшак күңелле булыр. Хатасы өчен газапланып яшәве һәм шундый чиккә житүе дә бар.

Карт. Каберенә килдем, чәчәк китердем ди. Шатланып әйтә. Шуңа мин аны башта бер гөнаһсыз дивана дип уйладым. Бераздан ул, акыллы кеше сыман, сиңа гына әйтәм, башкаларга сөйләргә уйлама, ди... Минем уйларлык башым юк инде, дим. Шунда теге нәкъ дивана кебек елмайды. Рәхәтләнеп яшәргә кирәк, син кырларда йөр, су буйларына бар. Кошлар шатланып сайраганны тыңла. Каберлектә кошлар елый гына. Монда килеп йөрмә, дим. Килми идем дә, хәзер киләм, ди. Нигә хәзер киләсең, дим... Мин килмәсәм, үзе миңа килә шул, ди.

Икенче килүче. Мескен кеше—дивана, тиле.

Ханым. Кем янына килгәнен белмәдегезме?

Карт. Белмәдем.

Ир. Сез ул кешене танныйсыздыр бит?

Карт. Танымыймдыр. Юктыр.

Ханым. Очратсагыз, бәлки танырсыз.

Карт. Юктыр.

Ир. Ничек инде шундый сүз сөйләгән кешене танымаска?

Карт. Бик соң иде. Игътибарым да житмәгән.

Икенче килүче. Игътибары житсә дә онытуы мөмкин. Картлык шулай инде ул.

Карт. Мин үзем дә хәзер ярты дивана.

Ханым. Алай димәгез әле...

**Әкрен музыка. Карт көе.**

Ир. Аны монда башкача күрмәдегезме?

Карт. Килмәгәндер. Йә килгәндер. Күрмәдем.

Ханым. Ул дивана сезгә башка берни дә сөйләмәдеме?

**Пауза.**

Карт. Караңгы төшкән булган. Мәрхүм ялгыз, тегеләр өчәү булганнар. Тыныч урамда, икесе анардан тәмәке сораган. Берсе читтәрәк торган. Мәрхүм тәмәке биргән. Шырпы сораганнар—шырпы биргән. Инде акча сораганнар. Шулай башланган. Читтәрәк торганы килеп, пычак белән кадаган. Мәрхүм болардан ычкынып йөгергән. Беркадәр ара киткәч, баганадан төшкән ут яктысында басып тора икән. Бәлки, хәле беткәндер. Йә котмәгәндә килеп чыккан хәлне ачыграк аңларга тырышып торуы булгандыр. Тегеләр яңадан килеп житкәннәр. Тагын кадаганнар... Шуларның берсе хәзер дөнья куйган икән, поезд астына эләккән. Икенчесе каядыр читтә икән. Өченчесе—әлеге дивана.

Ир. Дивана микән ул?

Ханым. Рәссам булмас.

Икенче килүче. Кемнеңдер эчкәч килеп чыгуы, шаярып сөйләшүе мөмкин.

Ир. Аның эчкечелеккә бирелеп, исергәч бер килеп, дөресен сөйләве дә мөмкин.

Карт. Исерек түгел иде.

Икенче килүче *(Картка)*. Әллә син моны безнең йөрәкләрне тәрбияләү максатыннан уйлап чыгардыңмы?!

**Карт эндәшми. Икенче килүче тора. Йөри. Сәгатенә карый.**

*(Картка)*. Әйт дөресен. Әйе, диген.

Карт. Бервакыт урамда үзенең артыннан мәрхүм килүен сизгән. Әйләнеп караса—беркем дә юк. Бу хәл ешайган. Бер төнне уянып китсәм, урыным янында ук—ул, миннән көлеп тора, ди. Кеше үтереп үзенә эш арттырдың, каберем янына кил. Килмәсән—үзем килермен, ди икән. Аннан чыгып китте: ишек ачылып, ябылды. Алдамыйм, шулай булды, дип ышандыра, диванакай.

**Икенче килүче сәгатенә карый. Ир дә урыныннан тора. Йөри. Тынлык.**

Ханым. Кем булыр ул—шундый кеше?

Ир *(Картка)*. Димәк, сез аны башкача күрмәдегез?

Карт. Килмәгәндер. Йә килгәндер. Күрмәдем.

Ир *(Картның нидер яшерүен сизеп һәм сизгәнен Картка да аңлатырга уйлап)*. Асылынып үлгәндер ул.

**Карт эндәшми. Ир арлы-бирле йөри башлый. Тормыштагы мәгънәсезлекләрдән көлеп сөйли.**

Жиденче каттан сикерүе дә бар. Дуслары үтергән булу мөмкин—соңгы мода үтерү юлы белән.

Ханым *(аптырап)*. Анысы тагын нинди үтерү инде?

Ир. Бер малай шуны әйтте.

Икенче килүче. Нинди малай?!

Карт. Кайда?

Ир. Минем бер танышым бар.

**Кул хәрәкәтләрен дә файдаланып, каберлек янында икәнен дә онытып, сөйли.**

Аның чәнчә бармак буйлы малае бар. Шуларга барсам, әтисе өйдә юк. Малай белән телевизор карыйбыз. Экранда яңалык. Мәскәүдә яшьләр театры оешкан. Бу театр эшкә фәкать бәләкәй малайларны, кечкенә кызларны кабул итә. Аларны тиз өлгертә—артистлар ясый икән. Экранда тиз өлгергән артистлар уенынннан өзекләр күрсәтәләр. Малайлар ирләр ролендә, кечкенә генә кызлар—хатыннар булып уйный. Яңа театрның заманча уенын күрергә килгән кунаклар—эшчеләр, инженерлар, укучылар, укытучылар, язучылар кул чаба. Тиз өлгергән данлы балалар, афәрин!

Карт. Әкренрәк.

Ханым. Ул тапшыруны мин күрдем.

Ир *(Ханымны бүлеп)*. Уеннары тәэсир итә. Тик алар ясалма рәвештә гариплэндерелгән яна кешелек кебек. Мин телевизорны сүндерәм, малай—кабыза. Экранда кунаклар кул чаба.

Икенче килүче. Карый алмадым...

Ир *(аны бүлеп)*. Бер мичкә күрсәтеләр, капкачы юк. Шуңа бер малай кереп утыра. Мичкәдән башы калкып кала да колаклары гына күренә. Икенче малай бу башны ак җәймә белән каплый, җәймәне калкытып торган башка селтәп-селтәп ике пычак кадый. Ат суя торган пычаклар!

Карт. Әкрен, дим...

**Әкрен музыка башлана—Карт көе.**

Ир. Бу хәлне карап янымда утырган малай:—«Оһо! Үтерүнең соңгы модасы!»—ди. Мин телевизорны сүндерәм. Малай—кабыза.

**Ирнең тавышы көчәя.**

Башта ике пычак һаман тора. Хәзер яшь актер ике кулы белән ике пычак сабын каера, ләззәтләнеп аларны селкетә, калкып торган башны айкый.

Ханым. Сөйләмә! *(Кинәт урыныннан тора.)* Булды!

Карт. Монда шауларга ярамый.

**Музыка көчәя.**

Ир. Телевизорны...

Икенче килүче *(аны бүлеп)*. Җитте!

Ир *(тагын да кычкырыбрак)*. Мин телевизорны сүндерәм, малай—кабыза.

Карт *(кинәт урыныннан тора)*. Җитте диләр сиңа!

**Музыка тына. Карт утыра.**

**Читтәрәк—Ханым. Ир, Икенче ир. Каберлек ягыннан Килүче күренә. Ул туры Карт янына килә.**

Килүче. Мин тегеннән генә, урман ягыннан, койма аша. Каберлектә бүген кошлар гына.

**Карт Килүчене күрмәгән дә, ишетмәгән дә кебек. Икенче килүче нишләргә дә белми тора.**

Исәнме, бабай!

Карт. Исәнме. Хәтер начарланды. Танымыйм.

Килүче. Мин бу, мин. Танысың инде. Мин хәзер чирләмим.

Карт. Бу дөньяда... Кайсыгыз чирли дә, кайсыгыз чирләми. Каян белим мин. Бар, юлыңда бул. Танымыйм бит.

Килүче *(Ханымга)*. Исәнмесез!

Ир. Син кем?

Ханым. Кем син?

Килүче. Мин сезнең ирегезне... үтергән кеше.

**Барысы да аптырашта. Тынлык.**

Икенче килүче. Әйдәгез, төшереп бирик милициягә.

Килүче *(Икенче килүчегә)*. Мин риза. Шуңа килдем.

Ханым. Син... Минем иремне...

Карт *(урыныннан торып, аптыраган кыяфәттә)*. Ялгышы булган бугай шул. Күзләрендә үтерүче дә күренми.

Килүче. Күренә. Мин үтердем.

**Карт ни эшләргә дә белми тора. Әле Килүчегә, әле башкаларга карый.**

Ханым. Син дөрес сөйлисеңме?

Ир *(ачулы кыяфәттә)*. Бу дөрес сөйли. Чирле түгел бу.

**Ул якында яткан ташны ала.**

Килүче *(Икенче килүчегә күрсәтеп)*. Әнә... Аның пычагы белән. Ул пычак бирде, үтерергә кушты.

Икенче килүче *(шаярган кебек итеп)*. Тиле, мин бит сине танымыйм, белмим.

**Карт чарасыз таптана.**

Килүче. Юк. Тиле түгел. Өчәү идек. Миңа пычак бирдең. Арттарак бар, арттан килерсең. Үлми калса, үзеңне үтерәм, дидең. *(Утыргычка барып утыра.)*

Икенче килүче. Тиле янында тиле булып торырга вакытым юк.

**Ул китә башлый. Ир аны туктата.**

Ир. *(Икенче ир ягына бара.)* Тукта! Китсәң—куып тотам.

**Икенче килүче туктала.**

Килүче. *(Икенче килүчегә.)* Китмә, син түгел, мин үтердем. Артыннан барып тоттык. Мин яңадан кададым... Үлми калса, үзеңне үтерәм, дидең. Ә ул минем дошман түгел, синең дошманың иде.

Ханым *(аптырау һәм гаҗәпләнү катыш)*. Алар дуслар иде.

Карт. Оланнар, кайтыйкмы әллә? Кайтыйк та...

И р *(Икенче Килүчегә).* Ник?

И к е н ч е к и л ү ч е. Белмим мин бу кешене.

К и л ү ч е. Ул син яраткан кызга өйләнгән.

И к е н ч е к и л ү ч е. Кайсыгызның кеме соң бу җүләр?!

К и л ү ч е. Кыз өчен бер сугышкансыз да.

Х а н ы м *(кинәт).* Сөйләде. Сөйләгән иде. Исемә төште.

И к е н ч е к и л ү ч е *(Ханымга).* Без аның белән килештек.

Х а н ы м. Аны да сөйләде.

К и л ү ч е. Килешмәдең. Аны очратыр алдыннан өчәү эчкәндә сөйләдең. Рәхәт яшәде, житте, дидең. Пычакны күпер астына ташладык. Әнә, үзең яраткан кызга әйт.

К а р т *(һаман чарасыз йөренеп).* Әллә кайтабызмы? Бергә кайтыйк та... Барыбыз бергә...

И р *(Картны бүлеп).* Без моннан барыбыз бергә кайтмыйбыз. *(Ханымга.)* Димәк, син үтерүгә катнашкан кеше. Җинаятьнең җебен белгән кеше. Энем исән чакта моның белән очрашып тордың?!

Х а н ы м. Очрашмадым. *(Икенче килүчегә)* Син бит ир кеше, ник эндәшмисең? Безнең арада ни булды?

И р. Ул сине фаш итүдән курка.

К а р т *(Ирга).* Бәр ташыңны!

И р *(Ханымга күрсәтеп).* Бусынамы? *(Икенче килүчегә күрсәтеп.)* Бусынамы? *(Килүчегә күрсәтеп.)* Тегесенәме?

К а р т *(Ир янына килә).* Җиргә бәр, ачуың басылыр.

И к е н ч е к и л ү ч е. Безнең арада берни дә булмады.

К а р т *(Икенче килүчегә).* Пычак синеке иде бит?

Х а н ы м. Синеке идеме?

И к е н ч е к и л ү ч е. Мин пычак йөртмим.

И р. Ә мин хәзер сине сугып үтерәм.

И к е н ч е к и л ү ч е. Килмә якын. *(Кесәсеннән револьвер чыгара.)* Мин менә шуны йөртәм.

Х а н ы м *(Ирне тота).* Зинһар, тынычлан?

И р *(аны төртеп җибәрә).* Кит янымнан!

К а р т *(Икенче килүченең кулын тотмакчы, ялына).* Яшер ул нәрсәне. Ялгышасыз. Туктагыз!

**Икенче килүче аны төртеп җибәрә. Карт егыла, тора.**

Кирәкми, балалар!

**Икенче килүче һәм Ир арасына Ханым керә.**

Х а н ы м *(Кемнәрнеңдер бирегә килүенә өметләнеп).* Ярдәм итегез!

**Ир һәм Икенче килүче Ханым тирәли күчеп, берсе сугарга, икенчесе атарга әзер кебек йөриләр. Карт та алар янында.**

К а р т *(ялына).* Ялгышасыз, туктагыз!

**Килүче утыргыч астындагы чүкечне күрә, кулына ала. Арттан барып, Икенче килүченең баш чүмеченә суга. Икенче килүче егыла.**

К и л ү ч е *(елмая).* Менә... *(Янындагыларның әле берсенә, әле икенчесенә карый.)* Менә... Шаярып кына суккан идем. *(Көлә башлый.)*

К а р т *(үзалдына).* Үлде бит. *(Килүчегә.)* Кеше үтердең бит.

**Ир кулындагы ташын җиргә бәрә. Ханым чүгәләп елый.**

К и л ү ч е *(Картка).* Ә син минем күзләремдә үтерүче күрмәдең. *(Барып Картны кочаклый.)* Бабай, үтерергә мине ул өйрәтте, үтерергә ул өйрәтте, ул өйрәтте...

*Пәрдә.*

*III Бөтендөнья татар конгрессы*

**Минтимер Шәймиев**

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ КИЛӘЧӘГЕНӘ ӨМЕТ БЕЛӘН КАРЫЙМ

Хөрмәтле милләттәшләр!

Кадерле кунаклар!

Өченче Бөтендөнья татар конгрессы делегатлары!

Ун ел элек без, татарлар, үз тарихыбызда беренче мәртәбә бөтен җир шарыннан Казанга җыелдык. Бер-беребез белән очраштык, күрештек, татарның милләт буларак исәнлегенә ышандык. Дулкынланып, горурланып «Туган тел»не җырладык. Бер җиргә бергә җыелып, бер җырны бергәләп җырлый алганбыз икән, димәк, авыр заманнарда милли үзаңыбызны югалтмыйча, бер-беребез белән бәйләнешне, телебезне, мәдәниятебезне саклап кала алганбыз. Ун ел элек безгә конгрессның җыелу факты мөһим иде. Беренче конгресс, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитетын оештырып, үз бурычын үтәде. Башкарма комитет үз эшчәнлеге белән өметләребезне аклап килә. Биш ел элек, Икенче бөтендөнья конгрессында, без үзебезнең милли проблемаларны тикшердек, һәм алдыбызга милләтебезне һәрьяклап үстерү бурычы куйдык. Ул чакта Татарстан тотрыклы үсеш чорына кергән иде. Татарстан үзенең статусын билгеләде, федераль үзәк белән Шартнамә төзеде. Дөньяның кайбер илләрендә республиканың вәкилләре барлыкка килде. Демократия татарларга Бәйсез Дәүләтләр берлеге илләрендә, Россия Федерациясендә тупланып яшәү урыннарында тормышларын үзләренчә җайларга мөмкинлекләр ачты. Татар телен, культурасын, динен торгызу башланды. Нәкъ менә шул чорда, республикада төпле милли сәясәт һәм икътисад реформаларын гамәлгә ашыруның халыкка кулай юлларын сайлау нәтиҗәсендә Татарстанның абруе күтәрелде. Ә иң мөһиме—хакимият структураларында һәм башка халыкларда безнең милләткә карата ихтирам артты.

Быелгы Өченче конгресс бөтенләй яңа шартларда уза. Татарлар төрле төбәкләрдә үз оешмаларын булдырдылар, мәктәпләр, клублар, күпсанлы гәзитләр барлыкка килде. Узган чор эчендә татар эшкуарлары ныгыды, аларның күбесе татар мәдәниятенә ярдәм итә. Федераль закон нигезендә татарларның милли-мәдәни автономияләре бөтен Россиядә төзелде. Бу куанычлы хәл, әмма ул бер үк вакытта татар дөньясын заманча коруны таләп итә. Минем фикеремчә, Өченче конгрессның төп бурычы—татар халкының бердәмлеген ныгыту юлларын билгеләү.

Яңа XXI гасыр илләргә һәм халыкларга карата кырыс һәм таләпчән. Без ул таләпләргә лаеклы җавап бирергә, үзебезнең башка милләтләр белән бер баскычта торып сөйләшә алуыбызны исбат

итәргә тиешбез. Глобальләшү процессы дөньяның барлык илләрендә дә каршылыклы вәзгыять тудыра. Бер яктан, әлбәттә, моңарчы күрелмәгән чиксез мөмкинлекләр дә ачыла. Спутник телевидениесе яки Интернетны гына телгә алу да җитә: алар ярдәме белән бөтен Евразия континентына таралган татарлар бер-берсе белән һич каршылыксыз аралаша ала. Әмма шул ук вакытта глобальләшү милли үзенчәлекләрнең югалуына, төссез масса культурасының тамыр җәюенә китерә. Дөнья ташкынына кушылып юкка чыкмас өчен, глобальләшүнең өстенлекле якларыннан—үз милли тамырларыбызны югалтмыйча—файдаланырга кирәк. Без һәркайсыбыз—үз иленең гражданы һәм дөнья гражданы, әмма барыбер татар булып калырга тиешбез.

Глобальләшү дәверендә, безгә иң элек үз республикабызны, үз дәүләтчелегебезне, үз Конституциябезне саклап калырга кирәк, чөнки тел һәм культура үсеше өчен тиешле структуралар бары тик Татарстанда гына бар. Дәүләтчелегебез булса—халкыбыз да исән калыр, телебез дә сакланыр. Шул чакта әдәбиятыбыз да, сәнгатебез дә, тарихыбыз да, мәдәниятебез дә алга китәр, гореф-гадәтләребез дә яшәр.

Гомуми проблемаларны хәл итү максатында безгә кардәш халыклар, иң элек башкорт туганнар белән бергәләп эш итәргә кирәк. Безнең тамырлар уртак: тарихыбыз үзенчәлекле охшаш, телебез дә, мәдәниятебез дә бер үк. Бер-беребезне аңлар өчен безгә тылмач кирәкми. Язмышларыбыз шулкадәр тыгыз үрелгән ки, арабызга чик тә сызып булмый, һәм моның кирәге дә юк. Хәзер бүлгәләнү заманы түгел, халыкларыбыз өчен хәлиткеч уртак гамәлләр заманы. Безнең халыклар бүген ничек бар, шулай калсыннар, ләкин яңа дәвердә лаеклы яшәр өчен безгә тагын да якынаю һәм уртак фикердә булу гаять зур әһәмияткә ия.

Тугандаш Башкортстан Республикасында яшәүче татарларның күпсанлы делегациясен Башкортстан Президенты Мортаза Гобәйдулла улы Рәхимовның үзе җитәкләве бу омтылышларыбызның чынбарлык тормышка ашачагына зур өметләр уята.

Хөрмәтле делегатлар! Мәгълүм ки, Россиядә хакимият вертикале кору сәбәпле, моңарчы төзелгән килешүләрнең күбесе яңадан карала. Яшерен-батырын түгел, бүген Россиядән унитар дәүләт ясарга омтылу законнарда да, финанс мәсьәләләрендә дә, башка өлкәләрдә дә сизелерлек чагыла. Федераль үзәк басымы астында төбәкләрнең һәм республикаларның күбесе элеккеге шартнамәләреннән баш тарта башладылар. Бүген «республика суверенитеты», хәтта «федерализм» дигән төшенчәләр сәяси сүзлектән әкрен-әкрен югалып бара. Гомумән, үзәк, кайбер очракларда, төбәкләр үзләре эш йөртергә тиешле хокукларга кул суза, шул рәвешле үзенә мөмкин кадәр күбрәк вәкаләтләр алырга тырыша. Табигый ки, мондый шартларда күпчелек татарларны гамәлдәге статусыбыз язмышы борчый. Республика элеккеге казанышларын саклап кала алырмы? Егерменче еллардагы кебек хокуксыз автономиягә кире кайтылмасмы, дигән сораулар туа.

Һич икеләнмичә әйтә алам: унитарлыкка авышу—вакытлы күренеш ул. Бу чорны да сабырлык һәм акыл белән кичерә белергә кирәк. Россиянең федерализмнан башка киләчәге юк. Бүгенге мәртәбәле җыен бу мәсьәләгә үз карашын ачык белдерер дип уйлыйм. Татарстанның киләчәктә дә республика булып калачагына беркемдә дә шөбһә булырга тиеш түгел. Минем моңа шигем юк, фикерем ныклы һәм нигезле дип саныйм.

Быел без Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр керттек. Чөнки узган ун ел эчендә илдә дә, республикада да җитди үзгәрешләр булды. Бу вакыйгага бәя биргәндә, без шуны да күз алдында тотарга тиеш, чөнки Татарстанның яңа Конституциясе Россия Федерациясенең хәзерге Конституциясеннән элегрәк кабул ителгән иде. Конституциянең кайбер маддәләре үзгәртелсә дә, без статус позицияләрен саклап кала алдык. Татарстан үз вәкаләтләре чикләрендә суверен республика һәм Россия Федерациясе белән ике яклы Шартнамә

нигезендә берләшә. Шул ук вакытта без Татарстан федерациянең ике дәүләт телле һәм халыкара багланышларны гамәлгә ашыручы субъекты булып тора дип яздык. Конституциянең яңа редакциясендә 14 нче маддә барлыкка килде. Аның буенча республика Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең милли мәдәнияте, теле үсешенә, милли үзенчәлекләрен саклауга ярдәм итүне үз өстенә алды. Хәзерге вакытта, Шартнамәнең, Татарстан Конституциясенә тәңгәлләштереп, берникадәр үзгәртелгән редакциясенә кул кую турында федераль үзәк белән сөйләшүләр алып барабыз. Шунысы хак: бу эштә тарихи гаделлек тә, халыклар мәнфәгатьләрен яклаучы халыкара хокук та безнең якта.

Билгеле булганча, ун ел элек Татарстан икътисадый үсешнең үз юнәлешләрен эшләде. Шуңа күрә дә республика иң мөһим мәсьәләне— акрынлап халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүне эзлекле хәл итеп килә. Икътисадый үсешнең төп күрсәткечләре буенча республика Россиядә алгы сафларга чыкты. Мәсәлән, тулаем региональ продукция җитештерү күләме буенча—дүртенче, бөртеклеләрдән алынган уңыш буенча—Краснодар краеннан кала—икенче, төп капиталга керткән инвестицияләр күләме буенча—Мәскәүдән һәм Төмән өлкәсеннән кала— өченче урынга чыктык. Бездә нефть һәм химия тармаклары гына түгел, авиация, автомобиль төзелеше дә уңышлы үсә. Барлык халыкара таләпләргә җавап бирүче ТУ-214 пассажир самолетын һавага күтәрүгә ирештек. Вертолетларның МИ-38, «Ансат», «Актай» кебек яңа төрләрен, яңа авиация двигательләрен конкурентлыкка сәләтле итеп ясауга ирешәбез. Республикада икътисадый реформаларны тормышка ашыруда безнең төп принцип—конкурентлыкка сәләтле товарлар җитештерү.

Татарстан бүген күпсанлы зур төзелешләр мәйданына әверелде. Быел Кама елгасы аркылы 14 километрлы күпернең һәм Түбән Кама нефть эшкәртү заводының беренче чиратлары кулланугa тапшырылачак. «Казан» халыкара аэропортын һәм Казан метросын төзү дәвам итә.

Соңгы алты елда Татарстанның 31 мең гаиләсе тузган торактан яңа йортларга күченде, быел тагын алты мең гаилә бушлай яңа фатир алачак. Тузган торакны бетерү программасы—Россия күләмендә тиңдәше булмаган бердәнбер социаль күренеш. Республикада яхшы сыйфатлы юллар челтәре төзү һәм халыкны телефон белән тәэмин итү буенча да гаять зур эшләр эшләнә. Татарстан—өйләргә газ кертү эшен тулы күләмдә башкарып чыккан бердәнбер төбәк. Халкыбызның бу мәңге пакь хыялы бүген тулысынча тормышка ашты.

Республикада халыкның реаль кереме арта бара, мохтаҗ гаиләләргә ярдәм итү программасы да гамәлдә. Халыкның эш белән мәшгульлеген нәтиҗәле тәэмин итү өчен дә шартлар тудырыла. Бездә эшсезлек дәрәҗәсе ил буенча иң түбәннәрдән берсе. Продукция сыйфатын күтәрүдән—тормыш сыйфатын күтәрүгә ирешү—безнең төп стратегик бурычыбыз.

Барыбызга да билгеле булганча, быел Россиядә халык санын алу үткәреләчәк. Кызганычка каршы, төрле, турысын әйткәндә, тышкы көчләр йогынтысында татарны аерым халыкларга бүлгәләү омтылышы барлыкка килде. Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты халык санын алу өчен халыкларның алфавит буенча исемлеген әзерләде. Анда татар керәшеннәрен, себер татарларын мөстәкыйль халык итеп күрсәтү тәкъдиме кузда тотыла. Бу мәсьәләдә без үз фикеребезне төгәл һәм ачык итеп әйтергә тиешбез. Без, татарлар—бер әдәби телле, гомуми культуралы бербөтен халык. Җирле мәдәни үзенчәлекләр, дини аерымлыклар яки татар телендәге төрле сөйләшләр— болар барысы да уртак милли асылыбызның төрле төсмерләре генә. Алар барысы да үзебезнеке, барысы да гасырлар буе татар милләте булып яшәгән һәм яши. Безнең милләт шушы төсмерләре белән күркәм, алар татарны бүлгәләми, бары тик баета гына.

Татарлар милләт буларак кичә яки бүген генә хасил булмаган. Урта гасырлардан башлап озак вакытлар милли туплану процессы барган. XIX гасыр ахыры—XX гасыр башында татарлар үзләрендә

мәдәни үсешнең алга киткән институтларын булдырганнар һәм алдынгы, белемле милләтләрнең берсе булуга ирешкәннәр. Алай гына да түгел, Урта Азия һәм Татарстанга күрше халыкларның мәдәниятенә шактый зур өлеш керткәннәр. Аларга заманча мәгариф, китап басу, газит-журналлар чыгару нәкъ менә Казанның һәм тулаем республиканың интеллектуаль мөмкинлекләре аша кергән. Татарлар теләсә кем, теләсә нинди кисәкләргә йолкый ала торган көпшәк милләт булмады һәм булмаячак. Халык санын алу алдыннан без үз ихтыярыбызны белдерергә һәм бу сынауны да лаеклы узарга тиешбез. Иң мөһиме—шуны истә тотарга кирәк: закон буенча һәркем үз милләтен шәхсән үзе теләгәнчә күрсәтергә хокуклы. Русча әйткәндә, тайна переписи гарантируется законом.

Культура мәсьәләләренә килгәндә, татарларны аеруча борчый торган тарих темасына кагылып үтәсем килә. Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Без бу хакта беренче татар конгрессыннан башлап күп тапкырлар сөйләштек. Әйтергә кирәк, ул вакыттан бирле безнең тарихчыларыбыз күп эш башкарды. Йөзләгән яңа тикшеренүләр дөньяга чыгарылды, тарих дәреслекләре язылды, дистәләгән халыкара конференцияләр үткәрелде. «Татары», «Татарлар» дип аталган фундаменталь хезмәт нәшер ителде. Анда безнең халыкның милли үзенчәлекләре, нигездә, лаеклы чагылдырылган. Болар барысы да, гасырлар узгач, безнең тарихыбызны дөресрәк итеп күрсәтергә мөмкинлек бирә. Бүген, бигрәк тә бәхәсле мәсьәләләр буенча, фән дөньясы, академиклар даирәсе Алтын Урданың, Казан һәм башка ханлыкларның үз вакыты өчен алга киткән һәм дөнья культурасына гаять зур өлеш керткән цивилизация икәнен тану юнәлешендә. Әлеге яңа фәнни мәгълүматларны киң җәмәгатьчелеккә җиткерү—четерекле һәм шул ук вакытта бик кирәкле эш. Бер яктан, бу яшь буынны тәрбияләү өчен әһәмиятле булса, икенче яктан, башка халыкларның безнең тарихыбызга, милләтебезгә мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртә.

Бу изге гамәлне тормышка ашыруда Казанның 2005 елда билгеләнеп үтәчәк 1000 еллыгын тулысынча файдаланырга кирәк. Башкалабызның меңьеллыгын бәйрәм итү комиссиясенең җитәкчесе Россия Президенты Владимир Владимирович Путин булуы һәм бу юбилейга Бөтенроссия статусы бирелү—безнең халык өчен зур хөрмәт һәм ихтирам билгесе ул. Без Казан Кремленең мәдәни әһәмиятен ЮНЕСКО оешмасына исбатлый алдык. Кремль—архитектура ансамбле буларак, бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде. Бу куанычлы вакыйга Татарстан һәм аның күпмилләтле халкы турында тарихи дөреслекне таратуга шулай ук яңа юллар ача.

Әмма бу мең елга бер килә торган юбилей шаукымы дип кенә кабул ителмәсен иде. Бигрәк тә татар мәктәпләре өчен тарихтан гына түгел, башка фәннәрдән дә заманча дәреслекләр кирәк. Алар глобальләшү процессларының мәгънәсен, аларга катнашу кирәклеген аңлап язылган булырга тиеш. Милләтнең киләчәгенә нигез мәктәптә салына. Безне алга чыгарачак яңа буын бүген мәктәптә формалаша. Алар—безнең таянычыбыз да, өметебез дә.

Наша непростая история во все времена связана, в первую очередь, с судьбой русского народа, многое зависело от взаимоотношений наших народов. В судьбоносные дни первых лет перестроечного времени мы вместе выдержали испытание на прочность нашей дружбы и на этом фундаменте обеспечиваем созидательную деятельность, укрепляя и дальше взаимопонимание и взаимоуважение. Пользуясь сегодняшней возможностью, я хотел бы от имени всех нас поблагодарить русское и русскоязычное население и представителей всех национальностей, проживающих в нашей республике, для большинства которых Татарстан является Родиной.

Мин сезнең игътибарыгызны милләт өчен принципиаль мәгънәгә ия булган тагын берничә мәсьәләгә юнәлдерергә телим. Соңгы елларда

җәмгыятьтә радикаль күренешләр барлыкка килде. Төрле сәяси һәм дини экстремизм, бөекдержавачыл шовинизм, үтә милләтчелек һәм башкалар. Кайберәүләр хәтта фашизмга кадәр барып җиттеләр. Без Татарстанда һәм үзебез яшәгән төбәкләрдә мондый коткыларга бирелмәскә һәм экстремистлык агымнарына юл куймаска тиешбез. Минем уйлавымча, хәзерге халыкара вәзгыятьтә без шушы уңай сыйфатлар белән башкаларга үрнәк була алабыз.

Узган конгресста без татар алфавитын латин графикасына күчерү турында карар кабул иткән идек. Латин графикасын торгызу турында закон бүген гамәлдән чыгарылмаган. Шулай да, мине бу күчешнең вакытын дөрес сайладык микән, дигән сорау һәрвакыт борчый. Сез барыгыз да беләсез, бу мәсьәлә чиктән тыш сәясиләштерелде. Россиянең Дәүләт Думасында беренче укылышта моңа кагылышлы закон кабул ителде. Аның буенча республикаларның дәүләт телләренә бары тик кириллицадан гына файдалану тиеш санала. Аңлашыла ки, әлеге закон проекты халыкара хокук күзлегеннән караганда бәхәссез түгел. Ләкин мәсьәлә монда гына түгел. Нәтиҗәдә болай килеп чыгуы мөмкин: Татарстан латинга күчәр, ә Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче татарлар кириллицада калыр. Бу хәл безнең милләтне какшатмасмы, без үз кулыбыз белән бер-беребездән ераклашу сәясәте уздырмыйбызмы икән? Мин бу проблемага шушы күзлектән дә чыгып фикер йөртерсез дип уйлыйм.

Соңгы елларда ислам дине дә, православие дә көчәйде. Татарлар яшәгән җирдә мәчетләр һәм мәдрәсәләр барлыкка килде. Шунысы кызганыч, бу өлкәдә уңай гамәлләр белән беррәттән тискәре күренешләр дә очрый. Бу турыда уйлану зыян итмәс иде. Беләсезме, мине нәрсә борчый? Исламның көчәюе аерым мәхәлләләрнең, имамнарның, мөфтиләрнең үзенчәлекле мәнфәгатьләрен китереп чыгарды. Һәм алар вакыт-вакыт бер-берсе белән сүзгә керә башладылар. Минемчә, менә мондый хәлләр милләтнең, мөселманнарның бердәмлеген чынлап торып какшата. Милли мәнфәгатьләрне ниндидер төркем мәнфәгатьләреннән яки шәхси тәкәбберлектән өстен куярга кирәк. Конгресс бу күңелсез күренешкә битараф кала алмас дип уйлыйм. Үз чиратыбызда, без Россиядәге исламның абруен күтәрүгә ярдәм итәчәкбез. Без Казанда Кол Шәриф мәчетен төзибез һәм шул ук вакытта Благовещение соборын төзекләндерәбез. Безнең принцип—диннәр арасында тигезлек саклау. Моның белән без исламның толерант һәм тынычлык яклы дин булуын дәлилибез.

Казанда Россия Ислам университеты оештырылды, аңа җәдидчелек традицияләрен дәвам итү бурычы йөкләнә. Россия мөселманнары арасында Казанның абруен күтәрү халкыбызның бердәмлеген ныгытып кына калмас, татарларның илдәге иҗтимагый процессларга уңай йогынтысын да көчәйтер дип ышанам.

Кайбер төбәкләрдә төрле татар иҗтимагый оешмаларының үзара тынышмавы да борчу тудыра. Әлбәттә, татар оешмаларының күп булуы бик әйбәт. Чөнки кешеләрнең мәнфәгатьләре дә, мөмкинлекләре дә төрле-төрле, һәркем милли ихтыяҗларын шулардан чыгып канәгатьләндерә. Милли оешмалар шуның өчен оештырыла да. Әмма шәхси мәнфәгатьләрне өстен куеп, юк-бардан ыгы-зыгы китереп чыгару сыйфаты бер милләтне дә бизәми. Әйтер идем, бигрәк тә чит төбәкләрдә яшәүче татарлар, мондый гамәлләр белән үзләрен башка халыклар алдында хур итәләр. Татар барда хәтәр бар, диләр. Безгә бүген бу әйтемнең уңай мәгънәсен ныгыту отышлырак булыр иде. Ләкин моның өчен төркемнәргә бүленеп, бер-береңә каршы торырга түгел, берләшергә кирәк. Әгәр инде бәхәсләшәсең икән, вак-төяк түгел, җитди мәсьәләләр турында бәхәсләшү һәм уртак тел табу хәерле.

Татарларны бер мәйданга туплаучы милли гореф-гадәтләребездән иң тәэсирлесе, иң күркәме—Сабантуй дип әйтсәм, моның белән барыгыз да килешер дип уйлыйм. Аның соңгы елларда дәрәҗәсе күпкә күтәрелде, колачы киңәйде. Сабантуе, әлбәттә, элек-электән үк

гомуммилләт бәйрәме иде, әмма бүген ул Россия күләмендә танылган бәйрәмгә әйләнде. Безнең Сабантуена Россия Президентлары Борис Николаевич Ельцин, аннан соң Владимир Владимирович Путин килеп хөрмәт күрсәтүләре әлеге бәйрәмнең мәртәбәсен тагын да күтәрде. Бүген безнең тарафтан Татарстан Сабантуен ЮНЕСКО оешмасына тәкъдим итеп, дөньяның рухи шедеврлары исемлегенә кертү мәсьәләсе карала.

Талантлы яшьләргә юл ача торган гомумтатар фестивальләренең гаять популярлашып китүен билгеләп үтәргә кирәк дип саныйм. Республика җитәкчеләре, иҗат эшлекләре күп төбәкләргә сәнгать бәйрәмнәренә бардылар. Нәтиҗәдә татарларның мәдәни тормышы җанланып китте. Татар телендә аудио һәм видеоязмаларның артуы да куанычлы хәл. Кыска дулкынлы радио белән берләштән «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе эшли башлады. Без аңа зур өметләр баглыйбыз. Ул үз тапшыруларын спутник каналы аша бөтен Россиягә җиткерә ала. Әлбәттә, бу телерадиокомпания коллективының үз эшчәнлеген оештыру юнәлешләре турында ныклап торып уйланасы бар. Чөнки аларга йөкләнгән бурыч тарихи әһәмияткә ия. «Яңа гасыр» компаниясе Татарстанда яшәүчеләрне генә түгел, бөтен татар халкын күздә тотып эшләргә, татарларны уртак мәгълүмат киңлегенә тупларга тиеш. Милләттәшләребез үзләре яшәгән төбәкләрдә «Яңа гасыр» тапшыруларын кабул итүне оештырырга булышсалар, телерадиокомпания эшчәнлегенә үз тәкъдимнәрен кертсәләр яхшы булыр иде.

Хәзерге компьютерлар заманында Интернет мөмкинлекләрен дә киңрәк файдалану зарур. Мәсәлән, күптән түгел оештырылган «Интертат» электрон газетасы Татарстан мәгълуматын планетаның барлык почмакларында яшәгән татарларга тарата. Аның татар телендә кириллицада һәм латин графикасында, рус һәм инглиз телләрендә чыгуы аеруча отышлы. Гомумән, татар газетларына үзләренең электрон версияләрен булдыру турында ныклап уйлар чак җитте. Бу—татар телен үстерүнең заманча ысулларыннан берсе. Өстәвенә татарларга бер-берсе белән аралашу күпкә җиңеләер иде. Әлеге мөһим эштә республика читтә калмаячак һәм ярдәм итәчәк.

Милли-мәдәни автономияләр төзүнең максатка ярашлыгы турында без берничә ел элек сөйләшкән идек инде. Бүген алар татарны берләштерүче кирәкле этәргеч көч булып тора. Күп кенә төбәкләрдә татар эшкуарлары ярдәмендә, кайбер җирләрдә җирле хакимият ярдәме белән алар шактый абруйлы оешмаларга әверелделәр. Татарстан Хөкүмәте белән тыгызрак бәйләнештә яшәсәләр, аларның эшчәнлеге тагын да нәтиҗәлерәк булачагына шигем юк. Безгә бергә һәм бер юнәлештә эшләүнең үтемле һәм күңелгә ятышлы рәвешләрен табарга кирәк. Әйтик, республиканың шәһәрләре һәм районнары татарлар яшәгән аерым төбәкләрне шефка алсалар, ике як өчен дә файдалы элемтә урнашыр иде.

Мин татар халкының киләчәгенә өмет белән карыйм. Әйе, яңа гасырның таләпләре югары. Шуңа күрә без, ирешелгән казанышлар белән мавыгып, туктап калмаска тиеш. Үз-үзебезгә тиешле тәнкыйть белән карарга, иң мөһиме—конструктив карарлар кабул итәргә кирәк. Гомуми лозунглар һәм өндәмәләр чоры инде узды. Төгәл һәм җитди гамәлләр вакыты җитте. Безнең халык сәләтле, талантлы, хезмәт сөючән, ләкин һәрвакыт шуны истә тотыйк: безнең көч—бердәмлектә!

Сүземнең ахырында конгресс эшчәнлегендә уңышлар, эшлекле фикер алышулар һәм милләтебезне ныгыта торган карарлар кабул итүегезне телим.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

**Индус Таһиров**

# БЕЗ БЕРБӨТЕН, БҮЛЕНМӘС МИЛЛӘТ

Хөрмәтле делегатлар!

Бөтендөнья татар конгрессын оештыру, һичшиксез, зур тарихи адым булды. Чыннан да, узган гасырның сиксәненче еллары азагына милләтебез инде шактый зәгыйфьләнгән, имгәнгән иде. Татар гаиләсенең күркәм традицияләре саеккан, юкка чыгуга йөз тоткан: аннан дин качкан, иман киткән, күпләребез телсез идек. Казанның үзендә дә берләнбер татар мәктәбе калган иде.

Ләкин, безнең халкыбыз шушы авыр хәлендә дә үзенең яшәү көчен исбатлый алды. Ул бернигә дә бирешмәде, «киселгән» саен яна шытымнар бирә торды һәм шуның белән үзенең мәңгелеген танытты. Шуна күрә дә инде, илдә демократия җилләре исә башлауга ук, татар дөньясы янарыш чорына кереп китте.

Кыска гына вакыт эчендә шактый үзгәрешләр булды. Өр-яңадан татар теле гамәлгә керә, татар мәктәпләре аякка баса башлады. Дистәләгән, йөзләгән милли оешмалар үсеп чыкты. Алар ныклап милли агарту эшен башлап җибәрделәр һәм бүген дә уңышлы дәвам итәләр.

Һәммә җирдә, хәтта ерак чит илләрдә дә, Җир шарының төрле почмакларында татар җыры яңгырый. Йөзләгән үзешчән сәнгать төркемнәре халыкның милли хисләрен уяталар. Халкыбызга милли рух һәм горурлык хисләре кайтты. Ул үзендә искиткеч, башкаларны таң калдырырдай яшәү көче таба алды.

Шулай да, ничәмә йөз еллар коллыкта яшәп, бихисап күп сынаулар үтү эзсез калмады. Халкыбызның җанында, рухында тирән җәрәхәтләр, коллык богавының эзләре бар. Шул вакытлардан килгән җәрәхәтләрдән, сырхаулардан тиз генә арынып булмаячак. Савыгу озакка бара торган процесс. Ул, гомумән, тарихи вакыйгаларга да, үзебезнең татарлыгыбызга да бәйле.

Татарлыкның нигезендә яткан мәсьәләләргә карашлар системасы милли идеологиябезнең нигезен тәшкил итә. Ул тел, мәгариф, мәдәният, дин һәм милли яшәешкә караган башка проблемаларга бәйле. Бүгенге милли идеологиябезнең асылында ике төп приоритет бар. Аның беренчесе—Татарстанның суверенлыгы, икенчесе—дөнья татарларының Татарстан тирәсендә рухи берләшүе.

1997—2002 елларда Башкарма комитет үзенең шушы вәкаләтләрен ничек үтәде соң? Куелган бурычларны ничек хәл итте? Нинди уңышларга ирешті һәм эшләнмәгән нинди эшләр калды?

Шушы сорауларга кыскача җавап биреп карыйк.

Татар иҗтимагый оешмаларын барлау, рәсмиләштерү, берләштерү эше хисап бишьеллыгында да тукталмады һәм ул бүгенге көндә дә бара әле. Чөнки яңа оешмалар туа тора, яңа кешеләр, яңа җитәкчеләр килә тора, рәсмиләштерү тәртипләре үзгәрә, бүгенге сәясәттән чыгып, оешмаларның яңа формалары—милли-мәдәни мөхтәриятләр оеша бара.

Өченче съездга 21 чит илдә, Россиянең 57 төбәгендә, Татарстанның 43 районында һәм Казанда яшәүче татарларның вәкилләре җыелды. Димәк, ким дигәндә, 122 рәсми оешма белән Башкарма комитет тыгыз бәйләнештә тора, якыннан торып эш итә. Күпчелек берләшмәләрдә берничә оешма булуын истә тотсак, бу сан икеләтә-өчләтә арта.

Төбәкләрдәге оешмаларның проблемаларын, анда яшәгән татар халкының милли мәгариф-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү мәсьәләләрен карау һәм

Индус ТАҺИРОВ—*1992-2002 елларда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе вазифаларын башкарды. Әлеге язма III конгресста яңгыраган хисап докладының кыскартылган варианты.*

нәтиҗәле чишү өчен беренче бишьеллыкта ук Башкарма комитет бюросының күчмә утырышлары үткәрелә башлады. Хисап бишьеллыгында бу механизмны куллану сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да камилләште. Барлыгы 21 күчмә утырыш үткәрелде: бишесе чит илләрдә (Белоруссия, Казакъстан, Украина, Төркия, Америка Кушма Штатлары), унбере Россия Федерациясе регионнарында (Санкт-Петербург, Мәскәү, Саратов, Омск, Әстерхан, Волгоград, Иваново, Төмән, Оренбург, Пермь), бишесе Татарстан Республикасы районнарында (Яр Чаллы, Азнакай, Түбән Кама, Яшел Үзән, Теләче). Утырышларның күбесе Россия Федерациясе төбәкләрендә уздырыла, чөнки, татар халкының күпчелеге Россиядә яши, һәм, әйтергә кирәк, күп кенә төбәкләрдә төп халык рәвешендә яши. Шулай булгач, анда яшәүче татарларның мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге ихтыяҗлары кирәкле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш. Алай гына да түгел: башка илләрдә яшәүче татарларны—РФ нең төп халыкларының берсен—аларның мәнфәгатьләрен Федераль хакимият күрергә, аларга ярдәм итәргә тиеш.

Күчмә утырышларны оештыру һәм уңышлы, нәтиҗәле үткәрү өчен ике якка да—Башкарма комитетка һәм урындагы татар иҗтимагый оешмасына—күп көч куярга туры килә.

Күчмә утырыш кебек олы җыенда—монда регионның төрле почмакларында яшәүче татарларның вәкилләре, югары җирле хакимият җитәкчеләре, Татарстаннан килгән министрлар катнаша—күп кенә проблемаларга уңышлы чишелеш табыла, аларны хәл итү кануни рәвеш ала. Мәсәлән, 1999 елның 28 июнендә Омск шәһәрендә уздырылган күчмә утырышта Омск өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясе тарафыннан әзерләнгән программалар—«1998—2000 елларда татар телен үстерү», «1998—2003 елларда татар халкының мәдәниятен үстерү» программалары—һәм Омск өлкә администрация башлыгының региональ татар милли-мәдәни автономиясе турындагы карар проекты хупланды һәм өлкә губернаторы Л. К. Полежаевтан алар буенча тиешле гамәл кылу соралды. 2000 елның 28 июнендә Төмәндә үткән утырышта «Россия Федерациясенең Себер регионнарында яшәүче татар халкының милли-мәдәни үсеше» программасының проекты хуплана һәм өлкә губернаторы Л. Ю. Рокецкийдан бу программа буенча тиешле карар кабул итү соралды.

Һәр күчмә утырыш кысасында Татарстанның мәгариф, мәдәният министрлыклары үзләренең җирле коллегалары белән килешүләр төзиләр, элек төзелгәннәренең үтәлешен тикшерәләр, аларга бүгенге көн таләпләренә туры килгән үзгәртүләр кертәләр. Хәзер мондый килешүләрнең саны мәгариф өлкәсендә егерме тугызга, мәдәният өлкәсендә егерме алтыга җитте. Аларның үтәлешен тикшерү өчен махсус доклад ясарга туры килер иде.

Татарстан Фәннәр академиясенең эшчәнлеге хакында да шул ук сүзләрне әйтеп булыр иде. Бигрәк тә татар халкының хак тарихын төзүдәге роле турында. Ел саен Академиядә яки аның җитәкчелегендә йөздән артык төрле дәрәҗәдәге—региональ һәм халыкара—фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләр уздырыла. Татар халкының тарихы, теле, әдәбияты, мәдәнияте, дәүләтчелеге мәсьәләләренә багышланган күпчелек фәнни чаралар БТК Башкарма комитеты белән бәйләнештә һәм, кагыйдә буларак, аның катнашы белән, Россиянең күп кенә регионнарында һәм чит илләрдә яшәүче татарларның вәкилләрен дәшеп үткәрелә. Мондый фәнни форумнарның берничәсен генә атап китик: «Борынгы төрки дөнья: тарих һәм традицияләр», «Казанның 1000 еллыгы: шәһәрнең тарихын өйрәнү мәсьәләләре», «Милли мәгариф һәм милли мәктәпнең теоретик-методологик нигезләре», «Идел һәм Урал буенда ислам цивилизациясе», «Татарстан дөнья цивилизация системасында», «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең бүгенге актуаль проблемалары», «Татар милләте бердәмлегенең цивилизацион, этномәдәни һәм сәяси аспектлары». Шуны да ассызыклап әйтергә кирәк, төрле регионнарда яшәүче күренекле татар галимнәренең гуманитар өлкәдә эшләмәгәннәре бу җыеннарга бик сирәк чакырыла. Ә бит татарлар арасында дөньякүләм дәрәҗәдә танылган физиклар, математиклар, табиблар, зур хәрби эшлеклеләр һәм башка белгечләр дә бар.

Алда әйтелгәннәрдән сизелгәнчә, күчмә утырышларны җирле татар иҗтимагый оешмаларының андагы дәүләт органнары белән берлектә эш алып бару кирәклегеннән чыгып үткәрә башлаган идек. Чөнки, «милли идея», «татар

идеясе», дип сөйләнеп йөрү дәвере узган, көндәлек конкрет эшләр эшләү вакыты житкән иде һәм ул эшләрне хакимият житәкчеләре һәм хакимият хезмәткәрләреннән башка, ижтимагый берләшмәләр үзләре генә нәтижәле итеп башкарып чыга алмаулары бәхәссез иде. Бу башлангыч, һичшиксез, уңышлы булып чыкты: татар халкының мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге ихтыяжларын канәгатьләндерүдә дәүләт даирәләренең ярдәме сизелә башлады.

Дәүләт органнарыннан ярдәм күрү өметен РФнең «Милли-мәдәни автономияләр турында»гы Законы яңартып жибәргән иде. Бу закон чыгу белән, төрле төбәкләрдәге татар ижтимагый оешмалары үзләрен милли-мәдәни мөхтәриятләр сыйфатында рәсмиләштерә башладылар. 1998 елның 20 нче маенда Санкт-Петербург шәһәре, Свердловск, Саратов һәм Ульяновск өлкәләре мөхтәриятләре, гамәлгә куючылар рәвешендә жыелып, Татар федераль милли-мәдәни мөхтәрияте (ТФМММ) оештырдылар, аның житәкче органына Совет билгеләмәсе бирделәр. Шуннан башлап, Конгресс Башкарма комитеты һәм Мөхтәрият Советы берләшеп эшли башладылар, төп юнәлештә—туган телне, милли мәгариф-мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау һәм үстерү, гомумән, татар халкын, татар милләтен саклау һәм үстерү юнәлешендә бергә атлап киттеләр. Мөхтәрият үзе Конгресска кабул ителде.

Мөхтәриятләр турындагы Законны гамәлләштерү жиңел бармый. Чөнки, РФнең күп кенә башка законнарындагы кебек, иң мөһим маддәләр ярым-ярты эшләнгән. Беренчедән, милли-мәдәни автономия милли үзидарә органы булып саналмый. Икенчедән, йөкләмәле финанслау каралмаган. Димәк, урыннардагы мөхтәриятләр үзләренең программаларын уңышлы үти алмыйлар. Шушы ике төп һәм Законга бәйле башка проблемаларны чишү мөмкинлеген эзләү һәм табу өчен 1999 елның 4 июнендә Казанда, «Татар халкының милли-мәдәни ихтыяжларын гамәлгә ашыруда дәүләт органнары һәм татар ижтимагый берләшмәләренең уртак эше турында» тәфсилләп сөйләшү максатыннан Бөтенроссия конференциясе оештырдык: һәрьяклап тикшерү, фикер алышу нәтижәсендә кабул ителгән һәм РФнең хөкүмәтенә жибәрелгән юлламада, «Милли-мәдәни автономияләр турында»гы Закон нигезендә, татарларның федераль һәм региональ мөхтәриятләрен даими рәвештә финанслау һәм Законга бәйле башка мәсьәләләрне уңай чишүне сорап мөрәжәгать иттек.

Алдагы көннәрдә дә бу Законны күз алдыбызда тоттык.

Шул ук елның 26 октябрендә РФнең Дәүләт Думасы рәисе Г. Н. Селезневка бу законга үзгәртүләр кертүне сорап хат юлладык.

БТК Башкарма комитеты бюросының әгъзасы, ТФМММ Советы рәисе Ильяз Мөслимов РФнең Милли эшләр министрлыгында узган «Милли-мәдәни автономияләр турында»гы Федераль Законга үзгәртүләр кертү хакындагы закон проектын тикшерүдә катнашты. Түбәндә үткәрелгән кучмә утырышта кабул ителгән программада, Урал федераль округы мисалында, федераль һәм региональ мөхтәриятләрнең бәйләнеше, хәтта жирле мөхтәриятнең структурасы (бүлекләре, белгечләре) билгеләнә. Законлаштыру гына кирәк.

Әлбәттә, «Милли-мәдәни автономияләр турында»гы Закон Россия Федерациясендә яшәүче барлык милләтләр өчен әһәмиятле. Шуңа күрә дә милли-мәдәни автономияләрнең күпчелеге берләшеп, даими рәвештә эшләүче ике даирә оештырдылар. Берсе аның—Дәүләт Думасының милләтләр эше буенча комитеты (рәисе В. И. Никитин) каршындагы Федераль милли-мәдәни автономияләр Советы, икенчесе—РФ хөкүмәте каршындагы милли-мәдәни автономияләр эше буенча Консультатив Совет (житәкчесе РФ министры В. Ю. Зорин). Әйтергә кирәк, Татар федераль милли-мәдәни мөхтәрияте бу ике даирәдә дә актив эшчәнлек алып барды. Мәсәлән, Федераль милли-мәдәни автономияләр житәкчеләренең Дәүләт Думасы рәисе Г. Н. Селезнев белән 2002 елның 24 гыйнварында үткән очрашуында безнең мөхтәрият түбәндәге проблемаларны күтәреп чыкты: милли-мәдәни автономияләрне финанслау, «Милли-мәдәни автономияләр турында»гы Законны камилләштерү мәсьәләләре, Россиядә халык санын алуны оештырудагы төгәлсезлекләр. Соңгы мәсьәлә Консультатив Советының 24 майда үткәрелгән 9 нчы утырышында да күтәрелде. Милли-мәдәни автономияләрнең вәкилләре халык санын алу бланкында «Туган теле» графасын төшереп калдыруга каршы чыктылар, тәкъдим керттеләр.

Әйе, тәкъдимнәр, юлламалар күп булды. Бәлки, көз көне Дәүләт Думасында янадан каралгач, яхшырак, милләтебезгә кулайрак закон кабул ителәр.

Хәер, бүген дә күп кенә автономияләрдә үз эшләрен җиң сызганып алып баручы йөзләгән милләтпәрвәрләребез бар.

Саратов региональ милли-мәдәни мөхтәриятенең җирле хакимият белән эшләү өлгесе тудыру нәтиҗәсе буларак, шәһәрдәге ел саен үткәрелә торган мәртәбәле татар мәдәнияте көннәре, бернинди исерткечсез үткәрелә торган Сабантуйлары, мисали рәвештә эшләп килә торган 300 бала сыйдырышлы татар классик гимназиясенең эшчәнлеге мона дәлил. Бу гимназиягә керү өчен ел саен бер урынга биш бала дәгъва кыла. Автономия җитәкчелеге, Конгресс Башкарма комитеты белән берлектә, гимназияне тагын 300 урынга киңәйтү мөмкинлегенә ирешге. Менә ни өчен Фәрит Рәшитов, Камил Аблязов, Зөфәр Хәкимов, Мөкатдәс Бибарсов, гимназия директоры Зәкия Саласкина һәм йөзләрчә милләтпәрвәрләрнең эшчәнлекләренә тиешле бәя бирмәү мөмкин түгел. Нәкъ менә шунлыктан, быелның апрелендә Конгресс Башкарма комитеты, Федераль һәм төбәк милли-мәдәни мөхтәрият җитәкчелеге, Татарстан мәгариф министрлыгы һәм өлкә мәгариф органнары белән берлектә, Татарстаннан читтәге татар мәктәпләре хезмәткәрләренең семинарын Саратов гимназиясендә үткәрделәр.

Мәскәү автономиясенең эшчәнлеге һәрвакыт игътибар үзәгендә. Аны мактыйлар да, юк-юк дисәң дә, тәнкыйтьлиләр дә. Бу аңлашыла, чөнки Мәскәү—Россиянең башкаласы. Андагы барлык гамәлләр дә ил күзе алдында. Монда халкыбызның зур интеллектуаль элитасы тупланган. Аларны оештыру җиңел эш түгел. Шулай да, эшләгән эшләр байтак. Ел саен оештырыла торган «Энҗе бөртекләре» балалар фестивале, Татарстанның атказанган артисткасы Роза Хәбибуллина җитәкчелегендәге балалар ансамбле, интеллектуаллар клубы эшчәнлеге, Лема Гыйрфанова җитәкчелегендәге татар этнокомпонентлы 1186 мәктәп һәм анда уздырыла торган чаралар һәм башка бик күп эшләр мөхтәрәм Рәсим Акчурин җитәкләгән Мәскәү шәһәр автономиясе ярдәмендә үткәрелә. Мәскәү Өлкә автономиясенең эшләре дә күркәм. Өлкә шәһәрләрендә татар тормышының җанлануы, «Соотечественники»—«Ватандашлар» газетасы, «Фатиха» фондының изге гамәлләре һәм башка эшләр—болар барысы да шуңа дәлил булып торалар.

Федераль автономия Советы рәистәше Ильяз Мөслимов шушы ике автономиягә дә зур булышлык итә. Ул һич кенә дә җиңел булмаган Үзәк хакимият белән арадашлык миссиясен дә уңышлы башкара. Аның тарафыннан чыгарыла торган «Татарские новости» газетасы, Федераль автономия Советы органы буларак, Мәскәүдән башка шәһәрләрдә дә тарала. Шушы кешенең матди ярдәмендә Волгоград шәһәрендә дә татар газетасы нәшер ителә.

Әгәр дә Пермь өлкәсендә Фәүзия Пак җитәкчелегендәге автономия эшләренә уңай бәя бирмәсәк, бу гаделсезлек булыр иде. Монда да губернатор администрациясе белән аңлашып эшләү мисалы барлыкка килде. Шәһәрдә һәм өлкәдә мәдәният һәм мәгариф учаклары эшли. Барда районында татар тормышы бөтен тулылыгы белән чагыла.

Ульяновск өлкә автономиясенә карата да шундый ук фикерне белдереп булыр иде. Бүген өлкәнең 19 районында милли-мәдәни автономия эшләп килә. Аларның җитәкчеләре булып абруйлы шәхесләр, өчесен район администрация башлыклары, күбесен мәгариф яки мәдәният бүлекләренең мөдирләре җитәкли. Алар милли тормышның уртасында торалар, милли яшәеш үрнәкләре тудыралар. Иске Кулатка районы тулысы белән диярлек татарлардан тора. Монда наркоманиягә дә, эчкечелеккә дә урын юк. Апрель аенда булып үткән Өлкә автономиясе конференциясендә губернатор Владимир Шаманов автономия рәисе профессор Азат Курчаковка тирән рәхмәтен белдерде һәм киләчәктә автономиягә ярдәмен арттырачагына вәгъдә бирде.

Иваново шәһәренең милли-мәдәни автономиясе инде күптән милли эшләрне оештыручы төп көчкә әверелде. Монда якшәмбе мәктәбе эшләп килә, Сабантуйлар традицион төс алды. Тиздән ул, автономия җитәкчесе Фәрит Ляпин тырышлыгы белән яңа бинага күчеп, стационар рәвештә эшли башлаячак. Шәһәрдә берничә үзешчән сәнгать коллективы эшләп килә. Ивановога эш тәҗрибәсен өйрәнү өчен Владимир, Мәскәү өлкәләрендәге автономия җитәкчеләре дә еш килеп торалар.

Түмән өлкәсендәге Хант-Манси автономияле округындагы автономияне унган Чистай мишәре Фәнис Гатауллин житәкли. Мондагы мәһабәт автономия бинасында Татарстан флагы жилферди. Өлкәнең күп шәһәрләрендә автономиянең бүлекчәләре бар. Берничә мәктәптә, шул исәптән Сургут һәм Нижневартовск шәһәрләрендә, татар төркемнәре барлыкка килде. Гомумән, монда милли мәгарифкә һәм мәдәнияткә зур игътибар бирелә. Автономия житәкчесе—губернаторның киңәшчеләреннән берсе һәм шул ук вакытта округта Татарстанның сәүдә вәкиле булып та тора.

Омск өлкә автономиясен абруйлы юрист Хәким Садыйков житәкли. Аның белән ингә-ин куеп, абыйсы—тәжрибәле педагог Хәлил бара. Бу автономия дә зур авырлыкларны жиңеп, барлык булган милли оешмаларны берләштерә алды. Өлкә автономиясенең 37 жирле бүлеге бар. Автономия, жирле хакимиятне әйдәкләп, татар теле укытучылары белән махсус эш алып бара. Татар балаларына телебезне өйрәтү, якшәмбе мәктәпләре булдыру эшләренә зур игътибар бирә. Өлкәнең үзешчән коллективлары Омск татарларына гына түгел, хәтта күрше өлкәләргә дә хезмәт күрсәтәләр. Автономия кысаларында Сания Мирхәлиева һәм Рузалия Сайганова радиодан татар телендә тапшырулар алып баралар. Шул ук вакытта, алар өлкәдәге татар тормышындагы яңалыкларны «Азатлык» радиостанциясе аша татар жәмәгатьчелегенә житкереп торалар.

Мордовия милли-мәдәни автономиясен Шамил Бикмаев житәкли. Ул—күп еллар губернатор киңәшчесе һәм республика парламенты депутаты булып торган тәжрибәле кеше. Бүген ул, эшмәкәр буларак, милли эшләрне башкаруга күп чыгымнар сарыф итә. Республикада татар телен өйрәнүгә, мәктәпләр эшен жанландыруга, бигрәк тә яшьләр, балалар белән эшләүгә зур игътибар бирелә. 2001 елның жәендә Кырымда үткәрелгән «Сөембикә варислары» фестивалендә Мордовиядән килгән балалар коллективы лаеклы урыннарны яулап алды.

Свердловск өлкәсенең күпчелек шәһәрләрендә һәм Екатеринбургның үзендә региональ автономия житәкчелегендәге бүлекчәләр эшләп килә. Первоуральск, Усинск шәһәрләрендә якшәмбе мәктәпләре бар. Барлык татарлар яшәгән шәһәрләрдә дә үзешчән сәнгать коллективлары милли моңнарыбызны, жыр-биюләребезне халыкка житкереп торалар. Татар телендә радио һәм телетапшырулар жайга салынган. Татарлар өчен рус телендә газета чыга. Өлкә автономиясенең житәкчесе Марс Шәрәфуллин күп чыгымнарны үз кесәсеннән чыгара. Татарстанның Уралдагы вәкиллеге белән берлектә татар теле укытучыларының семинарларын үткәрү традициягә әверелде. Урал университетында татар тарихын өйрәнү лабораториясе барлыкка килде. Июнь аенда Татарстан көннәрен үткәрү—шулай ук зур эшчәнлек нәтижәсе.

Юк-юк дисәң дә, кайбер вакыт газета битләрендә, радиотапшыруларда «Федераль автономиянең Советы өлкәләрдә региональ автономияләр оештыру эшен сүлпән алып бара»,—дигән сүзләр яңгыраштыргалый. Тәнкыйтьләүчеләр мәсьәләне жинел генә хәл итмәкче. Автономияләрне Россиянең 89 субъектында да матрицалау яки штамплау рәвешендә төзергә һәм бердәм идарә вертикале булдырырга кирәк, диләр. Беренчедән, берничә бөртек кенә татар яшәгән төбәкләрдә милләттәшләребез автономия рәвешендә түгел, башкача, мәсәлән, якташлык нигезендә оешуны кулай күрәләр. Аларга автономиянең хажәте шулай гына. Икенчедән, татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә дә дифференциаль караш кирәк.

Әйтик, әгәр дә Әстерхан татарларының Әнвәр Алмаев житәкләгән «Дуслык» жәмгыяте, БТК әгъзасы буларак, милли эшләрне гөрләтеп алып бара икән, нигә андагы татарларны көчләп автономия төзергә мәжбүр итәргә? Алар болай да хакимият органнары белән теләктәшлектә эш алып бару мөмкинлеген тапканнар. Әстерхан өлкәсе администрациясенең гомуми һәм һөнәри белем бирү, мәдәният һәм сәнгать, мәгълүмат департаментлары һәм «Дуслык» жәмгыяте ел саен берләштерелгән коллегия утырышлары үткәреп, мәктәпләрдә татар телен өйрәнү проблемаларын тикшереп торалар. Мондый бердәм эшчәнлекнең нәтижәсе буларак, Әстерхан педагогия училищесында һәр елны 10 татар теле укытучысы хәзерләнә, татар һәм рус телләрендә атналык «Идел» газетасы чыгарыла, атна саен татарча теле-радиотапшырулар алып барыла. Нәриман районы театрына Әстерхан татар халык театры статусын бирү һәм аны өлкә бюджетыннан финанслау турында

ассызыклап әйтергә кирәк. «Ялкын» халык ансамбле, күп кенә, шул исәптән халыкара бәйгеләрдә дә җинүче исемен яулаган «Нур» һәм «Мирас» балалар ансамбльләре, башка иҗади төркемнәр дә күпләргә билгеле. Шуна күрә дә алар, быелның 27 апрелендә Казанга килеп, Казан хакимияте, Башкарма комитет һәм Камал театры җитәкчелеге ярдәме белән зур концерт куеп, татар тамашачысын таң калдырдылар. Гомумән алганда, «Дуслык» җәмгыятенең 1999 елның июлендә уздырылган Башкарма бюросының күчмә утырышы карарын үтәүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге планлаштырылган чараларны мөмкин кадәр тулылыгы белән тормышка ашыру үрнәге булып тора.

Башында Мәсхүт Гаратуев һәм Фнүн Мирзоянов торган Удмуртия Иҗтимагый үзәге дә районнардагы һәм шәһәрдәге барлык милли оешмаларны үз канаты астына алган. Университеттa татар бүлеге, мисали рәвештәге татар гимназиясе, балалар бакчасы, район һәм шәһәрләрдәге мәктәпләр, татар телендә радио һәм телетапшырулар, газета—барысы да шушы оешма эшчәнлегенең җимеше.

Автономияләрне станоктан чыгаргандай матрицалап булмый. Чөнки иң беренче урынга кеше факторы, шәхесләрнең һәм мона кадәр яшәп килгән оешмаларның үзара аңлашуы чыга. Бу бик авыр эш һәм ашыкканны яратмый. Әйтик, Саратовта бу эш бик тиз хәл ителсә, Самарада ул сузыла төште. Шунлыктан, иң беренче җирле автономия Тольятти шәһәрендә төзелде. Ниһаять, үткән җәй Самарада шәһәр автономиясе барлыкка килде. Әлегәчә тулы аңлашу булмаганлыктан, өлкә автономиясен оештыру сузылып тора. Ә менә июньдә Тольяттидагы Җәмил Вәлиуллин җитәкчелегендәге автономия регионара Сабантуе үткәрде. Шуны да онытмыйк: өлкәдә элек-электән татар тормышы гөрләп торган Камышлы районы да, тагын зур татар авыллары да бар. Элек-электән үз җирләрендә төп халык булып яшәгән бу татар төркемнәре, аларның җитәкчелеге күпмилләтле өлкә үзәгендә урнашкан автономия кысаларында калса, монарчы үз кулларында булган идарә итү дилбегәләрен ычкындырмаслармы икән? Монда уйланырлык нәрсә бар.

Түбән Новгородта да шуна охшаш процесслар. Мондагы «Туган як» җәмгыятенең төп эшләре районнарда, бигрәк тә Кызыл Октябрь районы һәм Сергач районнарында алып барыла. «Туган як» газетасы Сергачта чыга. Монда татар китаплары да нәшер ителә. Редакция тирәсендә әдәби көчләр туплана. Күптән түгел «Без Тукай токымыннан» исемле бик күркәм шигъри җыентык чыкты. Татарлар күпчелек тәшкил иткән Кызыл Октябрь районында милли тормыш кайный. Иң зур һәм матур Сабантуйлары да шунда үтә. Әмма милли эшләрнең идеология үзәге Түбән Новгородта урнашкан. Андагы Алимҗан Орлов, Мансур Хафизов кебек гыйлем ияләре милли яшәешкә фәнни нигез биреп киләләр. «Туган як»ның башында торучы Совет җитәкчесе Марат Юнисов та милли эшләрдә зур фидакарьлек күрсәтә. Кыскасы, автономия төзү мәсьәләсе тулысы белән өлгергән кебек. Әмма ул автономияне кем җитәкләргә тиешлеге хакында активистлар арасында әлегәчә тулы аңлашу юк. Шунлыктан, әгәр дә без Нижнийда яки башка урыннарда, шартлары өлгермәстән, автономия төзүне ашыктыра башласак, үзара мөнәсәбәтләрне катлауландырыр гына идек.

Санкт-Петербургтагы хәлләр мона мисал. Монда берничә милли оешма бар. Күрәсен, автономия төзегән вакытта Татарстанның сәүдә вәкиле Шамил Әхмәтшинның һәм вице-адмирал Марс Искәндәровның абруйлары зур булса да, шәхесләр арасында тулы аңлашу булмау аның мөмкинлекләрен җәелдереп җибәрүгә киртә булган. Әхмәтшин тирәсендә шәһәрнең иң зур төзү оешмасы җитәкчесе Шамил Акбулатов, профессор Наил Газизуллин, эшмәкәр Ислам Гатин, дистәләгән галим, сәнгать эшлеклеләре тупланган булуына да карамастан, Петербургтагы потенциал тулысы белән милли эшләребезгә җигелгән, дип әйтеп булмый әле. «Нур» газетасы һаман җайга салынмаган, бер генә татар мәктәбе дә, хәтта автономиянен үз бинасы да юк. Шунлыктан, кайвакыт безнең алда автономия төзеп ашыкмадыкмы икән, дигән сорау да туа.

Менә ни өчен без берәүне дә ашыктырмыйбыз, ашыктырмадык та. Ашыккан ашка пешкән, диләр халыкта. Без татарларның үзара тату һәм аңлашып яшәүләрен беренче урынга куябыз. Татар конгрессы Башкарма комитеты, Федераль автономия Советы шәхесләрне һәм оешмаларны якынлаштыруны, дуслаштыруны үзенең төп эшләренең берсе итеп күрә.

Ә инде автономия төзелешенен төп нәтиҗәсенә килгәндә, региональ автономияләрнең саны егерме икегә житте. Аларның ике йөзләп жирле бүлекләре бар. Болар, Башкортстан һәм Татарстанны кертмәсән, 1,5 миллионга якын татар яшәгән жирләрне үз эчләренә алалар. Һәм автономияләр оештыру эше дәвам итә.

Автономия статусында булмаган яңа татар оешмалары да барлыкка килә тора. Әле быелның апрель аенда гына Калуга өлкәсенең Обнинск шәһәрендә беренче тапкыр татар мәдәнияте көне билгеләп үтелде. Шәһәрдә өч меннән артык милләттәшебез яши. Аларның күбесе төрле югары уку йортларын тәмамлап, махсус юллама буенча килеп урнашканнар. 100 мең халкы булган каланың ижтимагый-сәяси, икътисади, фәнни, сәнгати үсешенә татарлар үзләренең зур өлешен кертәләр. Тантаналы кичәне ачу алдыннан Татарстан президенты Минтимер Шәймиевнең котлау хаты укылды. Кичәдә катнашучы милләттәшләребез шәһәрнең «Туган тел» оешмасын төзергә дигән карарга килделәр. Һәм оешма төзелә дә, житәкчесе Рәйсә Юнусовна булган «Туган тел» кыска гына вакыт эчендә рәсмиләштерелә дә. Бүген Калуга өлкәсе татарларының вәкилләре хокуклы рәвештә Конгресс эшендә катнашалар.

Автономияләрнең һәм башка рәвештәге милли оешмаларның төп бурычы— ул милли яшәешебезне тәэмин итү, халкыбызның төп сыйфатларын, иминлеген һәм бөтенлеген саклап калу.

Һәм ассызыклап шуны да әйтергә кирәк: оешу рәвешләре нинди булуга карамастан, татар ижтимагый берләшмәләре бу бурычны бөтен тырышлыкларын куеп үтиләр. Моны чит илләрдә яшәүче татарларның оешмалары мисалында да күрергә мөмкин.

Әлбәттә, аларның проблемалары, РФ төбәкләрендәгеләр белән чагыштырганда, үзгәрәк. Бу аңлашыла да. Хәзерге Польша, Литва, Белоруссия жирләренә 600 ел элек күчеп урнашкан татар төркемнәренә, кайбер урыннарда укмашып яшәсәләр дә, туган телләрен саклап калу мөмкинлеге булмаган. Әмма алар милли рухны, изге динне саклый алганнар һәм бүген дә үстерә баралар. Милли рух, милли гореф-гадәтләре белән андагы татарлар күбебезгә үрнәк булып торалар. Атаклы кенәз Әсән токымыннан булган Адам Ибраһим улы Асановичюс бер чыгышында әйткәнчә, Литва татарлары арасында кеше үтерүчеләр дә, урлаучылар да, төрмәдә утыручылар да юк.

Әйе, бездән ерак чит илләрдә яшәгән милләттәшләребез дә татар рухын, татар яшәешен саклый алалар. Әгәр дә 30-40 елларда Сеул шәһәрендә яшәгән егерме алты татар гаиләсе мәктәп ачып, уку китаплары бастырып, мәчет салып, милли тормыш булдыра алганнар икән, бу инде күрсәткеч. Шул мәктәптә белем алган Сәгыйть Салахның АКШка килеп югары белем алуы, докторлык диссертациясе яклап, атом тикшеренүләре өлкәсендә күренекле галимгә әверелүе дә очраклы хәл түгел. Мондый шәхесләр халкыбызда байтак. Аның Надир Дәүләт, Шамил Юлай, Айшә Рорлих, Рифат Таби, Әдип Акчура кебек илдән читтә житлегеп тә, татар рухына, татар яшәешенә тугрылыклы булып калган зур галимнәре бар. Финляндиядәге бер мең татарның үз милли мәгариф системасын булдыра алулары, милли жыр-моң белән сугарылып яшәүләре, аларның жәмгыятьтә лаеклы урын биләүләре шулай ук халкыбызның яшәү көчен раслый торган мисал.

Мондый мисалларны күпләп китереп булыр иде.

Әлбәттә, чит илләрдә, бигрәк тә СССР таркалгач барлыкка килгән дәүләтләрдә, татарларга мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге ихтыяжларын канәгатьләндерү жинел бирелми. Каршылыклар, проблемалар житәрлек. Шуна күрә дә БТК Башкарма комитеты, Татарстан Президенты Аппараты, Дәүләт Советы һәм Министрлар Кабинеты белән берлектә, «Россия Федерациясеннән читтә яшәүче татарларның милли мәдәнияте үсешенең мөһим мәсьәләләре» дигән Халыкара семинар-киңәшмә үткәреп, бу проблемаларны жентекләп тикшерде.

БДБ, Балтия һәм ерак чит илләрдәге татар ижтимагый оешмалары житәкчеләренең киңәшмәдә кабул ителгән мөрәжәгате XXI гасырдагы татар яшәешенең программасы булып янгырады. Аны монда искә төшерү бик тә урынлы булыр:

«Яңа меңьеллыкка аяк басканда татар жәмәгатьчелеге үзенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйлана.

XX гасыр кешелек тарихында сугыш, инкыйлаб, явызлыклар чоры гына түгел, ә милли үзаңның үсүе, яңа дәүләтләрнең төзелүе, төрле илләрнең бәйләнеше һәм халыкларның берләшү дәвере булды. Бу катлаулы тарихи шартларда татар халкы, үзенә хас сабырлыгын, түземлеген, әдәплелеген саклап, милли мәдәниятен, телен, гореф-гадәтләрен үстерергә омтылды.

Язмыш җилләрендә төрле илләргә сибелгән милләттәшләребез үзләре яшәгән дәүләтләрнең, өлкәләрнең икътисадына, фәненә, мәдәниятенә зур өлеш кертәләр. Татарлар, халыкара хокук нигезләренә таянып, үзләренең милли мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырышалар. Безнең милләттәшләребез үзләре яшәгән илләрнең кануннарына ярашлы рәвештә хәрәкәт итеп, һәркайда иминлек саклап, тарихи ватаннары булган Татарстан Республикасы белән һәрьяклап хезмәттәшлекне киңәйтергә омтылалар.

Татарстан Республикасы төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә булыша. Бу мөһим эштә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм аның канаты астындагы иҗтимагый берләшмәләр гаять зур роль уйныйлар. Татар җәмгыятьләренең бердәмлеге, милләттәшләребезнең татулыгы, Татарстан белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе төрле төбәкләрдә тотрыклылык саклауга, илләр һәм халыклар арасында икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләрнең киңәюенә ярдәм итә.

Без барлык дәүләтләрне һәм халыкларны, тормышыбызны ямьсезләгән бөтен тискәре күренешләрне, яман гадәтләрне узып барган гасырда калдырып, киләсе меңьеллыкка бары уңай тәҗрибәне генә алып керергә чакырабыз. Ызгыш-талашлар, явызлыклар артта калсын. Бөтен дөньяда, татар халкы яшәгән барлык илләрдә тынычлык, татулык, муллык һәм бәхет тантана итсен».

БТК Башкарма комитеты тарафыннан Казанда үткәрелгән мондый зур җыеннарның саны егермедән арта. Алар Башкарма комитетның яки аның бюросының киңәйтелгән утырышы, семинар-киңәшмә, фәнни-гамәли конференция яки түгәрәк өстәл рәвешендә уздырылдылар.

Россия халыкларының милли яшәешенә нык кагыла торган тагын бер кануни документны Башкарма комитет шулай ук читләтеп үтә алмады. Ул—«Россия Федерациясенең милли сәясәте турында»гы Закон проекты. Башта без 2001 елның февраль аенда Дәүләт Думасында бу проектны тикшерү буенча үткәрелгән парламент тыңлауларында катнаштык, чыгышлар ясадык, мөнәсәбәтебезне белдердек. Аннары 26 апрельдә РФ республикалары, крайлары, өлкәләренең татар иҗтимагый оешмалары җитәкчеләрен җыеп, Башкарма комитетның киңәйтелгән утырышын уздырдык. Башкарма комитет рәисенең беренче урынбасары Разил Вәлиевнең доклады тыңланды, күп чыгышлардан соң кабул ителгән резолюциядә Закон проектына кертелергә тиешле 31 үзгәртмә-тәкъдим ясалды.

Мөһим проблемаларның берсе—Россиядә халык санын алу проблемасы да гел күз алдында булды. Беренче мәртәбә бу мәсьәлә 1997 елның 19 ноябрендә Яр Чаллыда уздырылган күчмә утырышта күтәрелгән иде, аннан соң да игътибар итә тордык. 2002 елның 12 апрелендә үткәрелгән Бөтенроссия киңәшмәсендә бу мәсьәлә бөтен нечкәлекләре белән каралды.

Төбәкләрдәге татар оешмаларының вәкилләре белән аерым очрашулар да еш булып торды. Чөнки кайбер мәсьәләләрне оператив рәвештә хәл кылырга яки берәр чараны оештыру эшен кичектермәстән башлап җибәрергә кирәк иде. Башкарма комитетта узган мондый очрашулар, сөйләшүләрнең теркәлгән саны гына да елына илледән артык. Ә Башкарма комитет аппараты хезмәткәрләре белән узган очрашулар, консультацияләр, алар биргән оештыру-методик күрсәтмәләр, төбәкләргә—татар иҗтимагый оешмаларына да, хакимият башлыкларына да—җибәрелгән хатлар, информацион материаллар санап бетергесез. Башкарма комитетның һәм урыннардагы оешмаларның эшчәнлеге турында тулы мәгълүмат тупланган «БТК хәбәрләре»—«Вестник»ны чыгару да кирәкле гамәл булды.

Җыеп кына әйткәндә, үткәрелгән очрашулар, утырышлар, киңәшмәләр вакытында татар яшәешенә кагылышлы проблемаларның күпчелеге каралган, ачыкланган, тиешле чаралар тәкъдим ителгән, аларның үтәлеше тикшерелгән.

Кызганычка каршы, соңгы елларда халкыбыз арасына күпләп заман чирләре дә үтеп керә башлады. Эчкечелек, наркомания, йогышлы авырулар, шул исәптән СПИД. Боларга каршы көрәшне тик дәүләт һәм киң җәмәгатьчелекнең бердәмлеге

нигезендә генә алып барып булачак. Әгәр дә без шушы эшләрне башкаруда дәүләт, җәмгыять һәм гаиләне бер җепкә тезә алмаса, заман тискәрелекләреннән тиз генә арына алмаячакбыз. Телебезне дә, гореф-гадәтләребезне дә, гомумән милли яшәешебезне бөтен тулылыгы белән гәүдәләндерә алмаячакбыз.

Әлбәттә, беренче урынга гаилә мәсьәләләре чыгарылырга тиеш. Чөнки сан һәм сыйфат, тел, логать вә әхлак проблемаларын хәл итү гаиләдән башлана. Халкыбызның «кош оясында ни күрсә, очканда шул була», дигән сүзләре үз эченә гасырлар тәҗрибәсен сеңдергән. Адәм баласы гаиләдән җәмгыятькә әдәпле һәм тәүфикълы рәвештә, туган теле белән чыгарга тиеш. Телебезне юкка гына «ана теле» димәгәннәр. Тел кешегә тумыштан бирелә. Тел ачылу төшенчәсе юк җирдән бар булмаган. Ана сөте, бишек җыры, гаиләдәге милли аһәң тел ачылуга юл сала. Гаилә, ата һәм, бигрәк тә ана—ул телне матур итеп ачарга бурычлылар. Тел ачкычы аларда. Шул ук вакытта, балага халкыбызның гүзәл сыйфатларын, милли горурлык хисләрен, гореф-гадәтләрен сеңдерү дә гаиләнең изге бурычы булып тора.

Форсаттан файдаланып, БТК Башкарма комитеты рәисе урынбасары Роза Туфитуллова җитәкләгән Конгресс Башкарма комитеты каршындагы «Ак калфак» җәмгыятенең, аның төрле шәһәрләрдәге бүлекчәләренең, күпсанлы активистларының изге эшләрен күрсәтеп, берничә булса да исемне әйтеп китү урынлы булыр.

Австралиянең Аделаида шәһәрендәге «Ак калфак» оешмасын Гайшә Маски җитәкли. Моннан дүрт ел элек алар Австралиядә беренче тапкыр татар Сабантуе уздырдылар. Австралиянең дәүләт музеенда халкыбызның яшәү рәвеше, күркәм гадәтләре, кием-салымы, аш-су осталыгы хакында сөйләүче күргәзмә оештырдылар. Атнага өч тапкыр эшли торган татар мәктәбе ачтылар. Латин хәрефләрендә әлифба һәм башка дәреслекләр булдырдылар.

Түбән каласында эшләп килүче «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Бибинур Сабирова «Ак калфак» исемле газета, аннан соң журнал чыгарырга керешге. Башкортстан «Ак калфак» җитәкчесе Кифая Фазлетдинова, Екатеринбургтан Таңчулпан Жданова, Санкт-Петербургтан Мөхлисә Зарипова һәм Роза Гущина, Түбән Камадан Лира Ямалиева, Яр Чаллыдан Әнүзә Еремина кебек булдыклы, җиң сызганулы ханымнар тирәсендә милләтенә турылыклы булган хатын-кызларыбыз тупланды.

Бөтендөнья татар конгрессының аерылмас бер өлешен, бер канатын тәшкил итүче «Ак калфак» берләшмәсе «Евразия» Ассамблеясына кергән тугандаш халыкларның хатын-кыз оешмалары, Ливан, Төркия, Һиндстан, Сәгуд Гарәбстаны, Финляндия хатын-кыз оешмалары һәм, әлбәттә, «Татарстан хатын-кызлары», «Мөселман хатын-кызлары» оешмалары белән элемтәдә эшли.

Гаиләдә ачылган тел тулысы белән мәктәптә гамәлләшә, туган телдә белем алганда милли горурлык һәм татарлык хисләре ныгый. Шуңа күрә дә хәл ителәсе мәсьәләләр арасында беренче булып милли мәктәп мәсьәләсе кала бирә. Татар мәктәбен яки гомум мәктәпләрдә татар төркемнәрен булдыру иң авыр эшләрнең берсе. Беренчедән, ата-аналарны балаларын татарча укытуга күндерү проблема булса, икенчедән, моңа җирле хакимиятнең мөнәсәбәте дә тәэсир итә. Нигездә, күпчелек төбәкләрдә моңа администрация тарафыннан каршылык юк кебек. Ләкин күп вакыт «кебек» кенә шул. Татарстан Мәгариф министрлыгы мәгълүматларыннан күренгәнчә, регионнарда татар мәктәпләре дип саналганнарында да барлык фәннәр русча алып барыла, татар теле фән буларак кына укытыла. Базис укыту планында татар теле һәм әдәбияты, татар халкы тарихын өйрәнү өчен сәгатьләр саны атнага 1-3 сәгать, шунлыктан программаларны үтәргә мөмкинлек юк. Авыл җирлегендәге татар мәктәпләренең (бигрәк тә Чувашия Республикасында) материаль-укыту базалары бик ярлы. Мәктәпләр дәреслекләр, методик әсбаплар белән бик начар тәэмин ителә. ТР Мәгариф министрлыгы регионнар өчен махсус китаплар бастырса да, алар тиешле күләмдә һәм вакытында сатып алынмыйлар. Татар укучыларының, татар балаларының саны урыннарда төгәл билгеләнми, шунлыктан ихтыяҗның күпме икәнен якынча гына күзалларга мөмкин. Татар теле укытучылары, финанслау булмаганлыктан, Казандагы һәм Яр Чаллы шәһәрендәге укытучыларның белемен күтәрү институтларына килә алмыйлар.

Татар яшәешен тәэмин итүдә балаларга һәм яшьләргә милли тәрбия бирүне,

аларга телебезне, гореф-гадәтләребезне, рухи-мәдәни байлыкларыбызны мирас итеп тапшыруны, тарихи һәм үзаң үстерүне Башкарма комитет һәм аның төбәкләрдәге оешмалары иң мөһим бурыч дип санадылар. Башкарма бюросының 1998 елның 3 декабрендәге утырышында кабул ителгән «БТК БКның яшьләр белән эшләү сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары»ның үтәлеше әледән-әле тикшерелеп торды. Иҗтимагый берләшмәләр кысасында яки мөстәкыйль рәвештә эшләп килүче татар яшьләре оешмалары туган телдә укыту, ял кичәләре, төбәкара элемтәләр оештыру мәсьәләләрен хәл итәр өчен зур тырышлык куялар. Мәсьәләләрне һәрьяклап чишү максаты белән кайбер төбәкләрдә (Удмуртия, Башкортстан республикалары, Томск, Иваново өлкәләре) татар яшьләре берлекләре оештырылды. Әзербайҗан, Белоруссия, Латвия, Төньяк Осетия, Мәскәү шәһәре, Төмән, Киров һәм башка төбәкләрнең берләшмәләре яшьләрнең төрле-төрле чараларын (якшәмбе мәктәпләре, студент клублары, Интернет челтәрендә сайтлар, түгәрәк өстәлләр, җыр фестивальләре) оештыру буенча уңай тәҗрибә тупладылар. Башкарма комитет каршындагы «Зыялы татар яшьләре» клубы уңышлы гына эшләп килә.

Шулай да, бу юнәлештә эшләнмәгән һәм эшлисе нәрсәләр күп әле. Иң мөһиме—Бөтендөнья татар яшьләре конгрессын уздыру. Тырышып та карадык, хатлар да яздык, елын да билгеләдек—әлегә бу җыенны үткәреп булмады. Дөрес, объектив сәбәп тә бар иде—күпчелек төбәкләрдә татар яшьләре оешмалары рәсмиләштерелмәгән. 2001 елның 28 ноябрендә үткәрелгән семинардан соң төзелгән һәм яшь галим Фәрит Гәрәев җитәкләгән Координацион Совет бу мәсьәләне Башкарма комитет ярдәме белән хәл итә алырга тиеш.

Яшьләрне борчыган мөһим проблемаларның берсе—туган телдә һөнәри югары белем алу. Озак вакыт күпләр үзләренең өметләрен Татар милли университеты белән бәйләп килделәр. Кызганычка каршы, мәсьәлә әлегәчә хәл ителмәде.

Шуңа күрә гамәлдә булган югары уку йортларын мөмкин кадәр файдаланырга кирәк, дигән фикер өстенлек ала килде. Чөнки моңа ныклы дәлилләр табыла торды. Казан авыл хуҗалыгы, архитектура-төзелеш академияләрендә, Кама политехника институтында мөгаллимнәр татар төркемнәре оештырып, рус һәм татар телендә профессиональ эш алып барырлык белгечләр хәзерли башладылар, татар телендә дәреслекләр һәм методик кулланмалар, сүзлекләр һәм белешмәләр бастырып чыгардылар. Башкарма бюросының әгъзасы һәм «Татар мәгарифе һәм фәне» даими комиссиясе рәисе, Казан архитектура-төзелеш академиясе деканы Вагыйз Фәтхуллин җитәкчелегендә бер төркем галимнәр «Татар телендә югары белем бирү концепциясе»н төзеделәр. Бу изге эштә энтузиастларга ТР Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан халыклары телләре турында»гы законны гамәлгә ашыру комитеты нык ярдәм итә. Татарстан фәннәр академиясенен Гуманитар бүлеге каршында оештырылган «Югары уку йортларында фәннәрне татар телендә укыту» исемле фәнни-методик советның эшчәнлеге дә игътибарга лаек.

Татарларны рухи берләштерүнең иң зур чараларыннан берсе—мәгълүмат чыганаклары. Бүгенге көндә Татарстаннан һәм Башкортстаннан читтә 25 татар газетасы нәшер ителә. Ләкин күпчелек төбәкләрдә өлкәкүләм татар газеталары юк. Сәбәбе шулай ук җирле администрацияләрнең аларны финанслау мөмкинлеген таба алмауда. Санкт-Петербургта шәһәр администрациясе «Нур» газетасын өлешчә финанслауга ризалык бирсә дә, Татарстан хөкүмәте ярдәм кулын сузган булса да, үзара аңлашылмаучылык аркасында газета үле дә, тере дә түгел.

Якын чит илләргә килгәндә, Латвиядә «Чишмә» вестнигы чыгарыла. Литваның Каунас шәһәрендә 1995 елдан башлап литва телендә «Летувос тоторей» газетасы нәшер ителә. Хәзер ул рус телендә «Татары Литвы» дигән исем астында Интернетта чыга башлады. Бөтенукраина татар мәдәни үзәге 2000 елдан алып «Дуслык» газетасын чыгара.

Татарстанда һәм башка төбәкләрдә яшәүче татарларга милли тормыш турында мәгълүмат туплау һәм ул мәгълүматны тарату эшен республикабызның газета-журналлары, радио-телевидение хезмәткәрләре, мәгълүмат агентлыклары алып бара. «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан» газеталары, «Казан утлары», «Сөембикә», «Мирас», «Идел», «Мәгариф», «Фән һәм тел», «Мәйдан» кебек журналлар татар дөньясының иң фәһемле басмалары булып торалар. БТК БК әгъзасы Римма Ратникова җитәкләгән «Татар-Информ» агентлыгы, Шамил Хамматов җитәкләгән «Татарские края»—«Татар

иле» газеталары татар темасын тирән эчтәлекле итеп яктырталар. Күптән түгел ачылган «Intertat.ru» Интернет газетасы компьютер кулланучылар, журналистлар арасында зур абруй казанды.

Читтә яшәгән татарлар өчен Казаннан кыска дулкыннарда «Татарстан авазы» тапшырулары оештырылды. «Татарстан» телерадиокомпаниясе белән Башкарма комитет оештырган бу каналда «Дөнья» студиясе татар тормышын яктыртуда зур тәҗрибә туплады. Башкарма комитет рәисе урынбасары, мәгълүмат чаралары, телевидение һәм радиотапшырулар даими комиссиясе житәкчесе Римзил Вәлиев һәм журналист Гөлназ Шәйхи алып барган репортажлар, әңгәмәләр тыңлаучылар тарафыннан жылы кабул ителә. Төбәкләрдә дә (10 шәһәрдә атнасына 15-30 минутлык) татарча ридиотапшырулар алып барыла. Спутник системасы аша—«Татарстан—Яңа гасыр!» исемендәге телерадиоканал эшли башлады. Шуңлыктан, татарлар яшәгән күпчелек төбәкләрдә Татарстан телевидениесен карау һәм радиосын тыңлау мөмкинлеге барлыкка килде. Татар дөньясы өчен Интернет системасы бик кулай. Аның аша милләттәшләребез хат языша, хәтта махсус Real-audio режимында радио тыңлыйлар.

Төбәкләрдәге мәгълүмат чараларына ярдәм күрсәтү максаты белән Башкарма комитет дәүләт органнары белән бергә татар журналистларының 3 семинар-кинәшмәсен үткәрде.

Хыялланган, уйланган, планлаштырылган чараларның барысы да тормышка ашмаса да, Башкарма комитет тарафыннан да һәм, әлбәттә, төрле илләрдә, төбәкләрдә гамәлдә булган татар оешмалары тарафыннан да шактый эш эшләнгән.

Алда әйтелгәннәрдән үк сизелгәнчә, ирешелгән уңышның күбесендә Татарстан житәкчелегенең, беренче чиратта, Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең өлеше зур. Дәүләтебез күрсәткән ярдәм нәтижәсендә хисап бишьеллыгында Башкарма комитетның офислары жиһазланды, компьютер техникасы алынды. Беренче бишьеллык белән чагыштырганда, Башкарма комитет үткәргән чараларның саны арту, аларның чикләре киңәю, әһәмияте үсү шуңа да бәйле булды. 1999 елның 4 июнендә БТК Башкарма комитеты, Россия татарларының мөхтәрияте һәм Татарстан Министрлар Кабинеты арасында төзелгән килешү дә милли оешмаларның дәүләт органнары белән уңышлы хезмәттәшлек итү юнәлешендә этәргеч булды.

Президент аппараты, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты, Казан шәһәре Администрациясе һәр эштә теләктәшлек күрсәттеләр. Төбәкләрдәге оешмалар белән эш итүдә Мәгариф, Мәдәният, Яшьләр эшләре һәм спорт, Элемтә министрлыкларының, «Татарстан» телерадиокомпаниясенең, «Казан» милли-мәдәни үзәгенең ярдәме аеруча зур иде. Татарстан Конституциясенең яңартылган вариантындагы 14 нче маддә гамәлгә кереп китсә, республикадан читтә яшәүче татарларның милли оешмаларына да сизелерлек ярдәм күрсәтү мөмкинлеге туар, дигән өмет бар.

Татар Конгрессы Берләшкән Милләтләр Оешмасының информацион Үзәгендә теркәлгән. Конгресс үткәргән чаралар турындагы мәгълүматның шактые шушы Үзәккә жибәрелә. ЮНЕСКО белән эшләү Казанның тынычлык культурасы шәһәре итеп игълан ителүенә, аның һәм берничә шәһәребезнең «Пальма сабагы» исемендәге алтын медаль белән бүләкләнүенә китерде. Казандагы ЮНЕСКОның БТК БК бюросының әгъзасы Энгель Таһиров житәкләгән Тынычлык культурасы институты белән берлектә башка күркәм чаралар үткәрелде. БТКның Казан бүлеге конференциясендә хупланган, халык депутатларының Казан Советы һәм Казан шәһәре хакимияте Сабантуй милли бәйрәмен ЮНЕСКОның дөнья халыклары рухи мирасы жәүһәрләре исемлегенә кертү турындагы тәкъдиме дә эзсез калмас, дигән өмет бар.

Башкарма комитет Бәйсез Дәүләтләр Парламентара Ассамблеясенә дә күзәтүче рәвешендә кабул ителде, аның Мәдәният, мәгълүмат, туризм һәм спорт даими комиссиясе эшендә активлык күрсәтә. Татарстанның Санкт-Петербургтагы даими вәкиле Шамил Әхмәтшин Конгресс Башкарма комитет исеменнән комиссиянең карарларын әзерләүдә катнаша.

Күренгәнчә, Бөтендөнья татар конгрессының, аның Башкарма комитетының, урыннардагы татар оешмаларының эшчәнлеге күпкырлы, чөнки алда торган проблемалар да күпкырлы һәм шактый катлаулы. Шуңа күрә Конгресс

Башкармасының эшчәнлегендә кимчелек вә житешсезлекләр дә аз түгел. Планлаштырган эшләрнең барысын да тормышка ашырып булмады. Татар журналистлары, татар галимнәре ассоциацияләрен булдыру эшен дә ахырына кадәр житкереп булмады. Әле безнең татар яшәгән кайбер төбәкләрдә йогынтылы оешмаларыбыз да юк. Булганнары да сүлпән эшли. Күрше Мари-Эль, Чувашстанда да милли тормыш сүлпән бара. Ярославль, Кострома шәһәрләре белән дә тотрыклы элемтә урнаштыра алмадык. Ә БТК Берлегендә теркәлмәгән кайбер милли оешмалар үзләренең барлыкларын съездга әзерләнгән көннәрдә генә белдерделәр.

Берләшмәбез арасында һәрьяклап ихтирамга лаек булган Башкортстан татарлары конгрессы эшчәнлегенә дә игътибар житеп бетмәде.

Дөрес, бу очракта Россиядә барган сәясәтне дә истән чыгарырга ярамый. Күпләрне Татарстан һәм Башкортстан арасындагы махсус мөнәсәбәтләр, татар һәм башкортлар арасындагы тамырлары ерак гасырларга тоташкан туганлык һәм якынлык борчый. Чөнки бу ике республика соңгы ун ел эчендә Россияне чын федератив дәүләткә әверелдерү юлында башка республика һәм регионнарны әйдәп баручы көч икәнлекләрен күрсәтә алдылар.

Ләкин, гадел булыйк: шушы катлаулы шартларда да Башкортстан татарлары конгрессы зур гына эшләр алып барды. Ул, иң беренче чиратта—татар җәмәгатьчелеге һәм республика, район, шәһәр хакимиятләре арасында элемтәләр җайлау. Башкортстан татарлары милли мәгариф, мәдәният белән кызыксына. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил кичәләре, «Нәүрүз чибәре» конкурслары үткәрелә, китаплар басыла, Казанда Нажар Нәҗми, Марат Кәримовның иҗат кичәләрен Г. Камал театры, «Казан» милли-мәдәни үзәге белән берлектә Рәиф Әмиров, Алик Локманов, Суфьян Сарданов һәм башкалар оештырдылар...

Киләчәктә Башкортстанда да БТК Башкарма комитетының күчмә утырышлары үткәрелер дип өметләнергә кала.

Кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерүгә тиешле игътибар бирелмәгән очраклар да бар. Боларның объектив сәбәпләре булса да, бөтен мөмкинлекләр тулысы белән файдаланыла, дип әйтеп булмый. Бу—Икенче конгрессыбызда латин язмасына күчү турындагы карарга да кагыла. Кызганыч ки, Дәүләт думасы беренче укылышта «Россия халыклары телләре турында»гы канунга «илдә тик кирилл алфавиты гына кулланышта булырга тиеш» дигән өстәмәне беренче укылышта кабул итте. Шуның белән һәм моңа кадәр булган башка гамәлләр белән латин имласына күчү эшенә сәяси төс бирелде. Без исә Конгресс карарын һәм Татарстан Дәүләт Советы кабул иткән Законны халыкка ныклап аңлату эшен бик сүлпән алып бардык, кайбер даирәләрдәге икеләнүләрне җиңә алмадык. Тик, шулай да, бу эш туктатылмады. Һәм безнең үзебез кабул иткән карардан баш тартырга бернинди дә хакыбыз юк.

Безнең Милли университет ачу турындагы карарыбыз әлегәчә тормышка ашмады. Монда гаеп атта да, тәртәдә дә. Җәмәгатьчелек таләпчәнлеген күрсәтмәде, галимнәр кулай концепция төземәде, нәтиҗәдә хакимият тиешле карарын чыгара алмады. Тик бу—эш тукталды, бөтенләй сүнде, дигән сүз түгел. Университет ничек кенә аталмасын, ул барыбер булыр. Сайланачак Башкарма комитет бу өлкәдәге эшчәнлеген максатка ирешкәнче дәвам итәргә тиеш булачак.

Җитешсезлекләр һәм хаталар бар һәм булыр да. Чөнки тормыш шунсыз була алмый. Безгә тик шуны аңлап, бер-беребезнең хата ясаганын гына көтеп торып, аны мәкерле максаттан файдаланудан тыелу гына кирәк. Кызганыч ки, мондый фактлар әле еш очрый. Әгәр дә беренче урынга шәхси мәнфәгатьләр түгел, милләт, аның язмышы куелса, бу болай булмас иде.

Яңа сайланачак Башкарма комитет һәм аның җитәкчелеге, ун ел дәверендә кылынган гамәлләргә таянып, эшне тагын да уңышлырак алып барыр, дип ышанасы килә. Без исә аңа һәрвакыт ярдәм итәргә әзербез. Милли эшләрне кем генә башкарса да, аның максаты бер—ул милләтебезнең мәңгелеген, аның үрнәк булырлык яшәвен тәэмин итү.

## Зөлфәт Хәким

# ҺӘР ЗАМАНА БЕЗНЕ СЫНЫЙ

«Суверенитетны ала алмадык, дәүләтчелек дип лаф ору безгә нәрсә бирде соң?»—дип сораганнарын еш ишетәбез. Бу сорауны бәлки кайвакыт урыны-урыны белән бирергә кирәктер дә. Әмма ләкин, шул ук вакытта, һәркем үз-үзеннән: «Ә мин үзем Татарстан мөстәкыйльлеге өчен нәрсә эшләдем, нинди көч сарыф иттем?»—дип сорарга тиеш.

«Үсеп килүче буыннарга мирас итеп нинди ил-көн тапшырыла?»—дип сорау куйгач, үзеннән-үзе «Җаваплылык» дигән төшенчә калкып чыга. Әлбәттә, тере мантыйк буенча, телне, мәдәниятне, тарихны, фәнне, мәгарифне күтәрер өчен, хәтта милләтнең яшәү рәвешен саклар өчен дә сәяси бәйсезлек, мөстәкыйльлек кирәк. Ләкин, телибезме-юкмы, без бүгенге чынбарлыктан чыгып эш итәргә, хәрәкәтләнергә мәҗбүр. Кайсы яктан карасаң да, милләтебезнең язмышы, аның киләчәге һәрбер аерым кеше факторына килеп тоташа. Көтмәгәндә килеп кергән базар икътисады, яңа техникага ияргән чит-ят сүзләр, дөньяның төрле тарафыннан тәэсир иткән башка халыкларның яшәү рәвеше—болар барысы да татар халкы бетүгә уңай шартлар тудырды. Шуңа күрә милләтне саклап калуда һәрберебезнең роле гаять зур. Суверенитетның аерым кешедә дә булуы мөмкин. Манара да иң элек кешенең үз күңелендә калкырга тиеш. Аллага үзенә кирәк чакта гына ышана торган кешеләр белән диннең абруен күтәрү мөмкин түгел. Үз корсагының һәм кесәсенең колы булып, миңа нәрсә бирде бу, дип йөрүче кешеләр белән дәүләтчелекне торгызу мөмкин түгел.

Язмыш безне сынавын дәвам итә. Һәммәбез җаваплылык тойган сурәттә генә милләт буларак сакланачакбыз.

Шулай да дәүләт җитәкчеләребездән бик күп нәрсә тора.

Килешерсезме-юкмы, минем уйлавымча, ил-көннең һәм халыкның язмышы хәл ителгән чорда бөтенесе диярлек коллективтан түгел, шәхестән тора. Тарихны халыкның элитасы ясый. Барлык формацияләрдә дә җәмгыять зур шәхесләрнең,лидерларның калкып чыгуына, аларның хезмәтчәнлегенә бәйле.

Бай тарихлы, мәдәниятле, мәгърифәтле халык буларак, без барыбер акылыбыз, интеллектыбыз белән хәрәкәтебезне дәвам итәчәкбез.

Үткәннәребез, ерак бабаларыбызның каһарманлыгы һәм зирәклеге белән генә мактанудан туктарга вакыт. Үткәннәре генә түгел, бүгенгесе дә бөек булырга тиеш халыкның!

Тарихыбыз бай безнең. Ләкин үсеп килүче буынга тәкъдим итәрдәй уку әсбаплары әлегә юк. Минемчә, татар тарихының матур бизәлешле дәреслеге иң әһәмиятле 6-8 тарихи вакыйгадан торырга тиеш—гомуми күзаллау һәм истә калдыру өчен шулай җайлы. Тегеннән-моннан йолкып алынган, ни башы, ни ахыры булмаган язмалар белән без тарихыбызны өйрәнә дә, кирәкле вакыйгаларны истә дә калдыра алмаячакбыз. Тарихи әһәмияте ягыннан берничә төп вакыйга турында матур проза язылсын, фильмнар, тамашалар куелсын, бәйрәмнәр үткәрелсен. Шулай итеп кенә тарихыбызга үсеп килүче буыннарның игътибарын юнәлтеп булыр.

Без—яшь милләт. Тарихыбызны мәңгелекнең теләсә кайсы ноктасыннан яза башларга хакыбыз бар. Үзебез аермачык хәтерләгән вакыйгалардан тотынсак та, безне беркем хөкем итмәс.

Тел мәсьәләсенә дә караш чак кына үзгәрергә тиеш. Туган телен белмәүчене ачуланудан, сүгүдән ни мәгънә! Ярдәм итү юлларын эзләргә кирәк.

Монда да һәркем җаваплы. Һәр татар гаиләсенең бурычы—балаларын туган телдә тәрбияләү.

Кызганыч ки, бездә урысча сөйләшүче режиссерлар, татарча белмәүче рәссамнар, татар телен инкарь итүче композиторлар, компьютерчылар, музыкантлар һәм әллә кемнәр, әллә кемнәр шактый. Без алар белән эшлибез. Алар белән бергә иҗат итәбез. Аларның туган телен белмәүләрендә безнең дә гаебебез бар. Монда да җаваплылыкны үзебездән алып ташларга ашыкмыйк. Кайвакыт алар аңласын дип үзебез дә туган телдә сөйләшмибез һәм шулай итеп, алар моңа күнегәләр.

Татар халкы дөньяга бик күп олы шәхесләрен бирде. Татардан чыгып башка милләтләргә хезмәт иткән зыялыларыбызны санап бетергесез. Без хәзер, инде бүгенге акыл ияләребезнең, шәхесләребезнең халкыбыздан читкә тайпылмавын, үзебезгә интеллект игелеген күрсәтүләрен кайгыртырга тиешбез. Кайберәүләр «интеллект» сүзен үзләренчә кабул итәләр, аны эрудиция, гыйлемлелек диебрәк аңлаталар. Интеллект ул—бәйсезлек. Кыюлык һәм Яшәүчәнлек. Интеллект ул кешенең, кайвакыт җәмгыять фикеренә дә карамыйча, конформизмны инкарь итеп, үз фикере һәм таянган нигезе өчен көрәшә алуы. Менә нәрсә ул интеллект! Интеллектның капма-каршылыгы—аңгыралык. Бу—ирексезлекнең, каушап-югалып калуның, мескенлекнең нәтиҗәсе. Ниһаять, аңгыралык ул әкрен генә бара торган әчке үлем. Интеллект ияләренә уңай шартлар тудыру, матди ярдәм күрсәтү хәлле милләттәшләребезнең бурычы. Дөресен әйтергә кирәк, милли мәсьәләгә килеп төртелгәч, татар байлары киң колач җәюдән куркалар. Милләтне милли җанлы, көчле рухлы зыялылар, байлар, бизнесменнар күтәрә ала. Кызганыч, татар байлары арасында милли җанлыларны бармак белән генә санарлык. Милли хәрәкәт тә җирдә туа, җирдә яши, шуңа күрә финанс мәсьәләсе иң мөһимнәрнең берсе. Акчасыз бернинди оешма, бернинди партия, бернинди хәрәкәт тә яши алмый.

Милли хәрәкәттә татар байлары ник катнашмый? Беренче сәбәп. Үзләренең шәхси амбицияләреннән арына алмаучы, үзләрен милләтче дип атап, юеш тавыклар сыман ары-бире чабып йөрүче әтрәк-әләмнәрнең милли хәрәкәткә тап төшерүләре. Халык әйтмешли: «Иген—кибәксез, ил тинтәксез булмас». Халыкны әйдәр өчен куелган трибуналарны кайберәүләр арзан алкышлар һәм кырын балкышлар сәхнәсенә әверелдерде.

Эшмәкәрләребезнең милли хәрәкәттән читтә калуларының тагын бер сәбәбе итеп коллык психологиясенең хөкем сөрүен атар идем. Алар куркалар. Милләтчелектә гаепләрләр дип котсыз калалар. Эшләренә хилафлык килер дип борчылалар.

Нишлик?

Гап-гади сүзләр белән генә булмый. Дөп-дөрес сүзләр сөйләп тә алга китү мөмкин түгел. Идеяләр кирәк! Яңа фикерләр кирәк!

Телевизор экраныннан, гәҗит битләреннән шул ук берничә абзый бер балык башын чәйнәделәр дә чәйнәделәр. Бер үк табаны уйнаттылар да уйнаттылар. Бер яңа сүз, бер яңа фикер әйтелми. Багана ава, багана ава дип кырыенда елап торсаң, багана кайчан да булса авачак. Аны аудармаска кирәк! Кайда безнең яшьләр? Мин яшьләргә мөрәҗәгать итәм: эшмәкәрләр, зыялылар! Әйтегез сүзегезне! Оешыгыз! Хәрәкәтләнегез! «Хәрәкәттә—бәрәкәт»,—ди халык. Татарның укымышлы кешеләре, яшь юристлары, икътисадчылары, сез кайда? Әллә инде сез планета гражданнарымы? Әллә инде сезнең Ватаныгыз Җир шарымы? Ә туган җирең, үз Ватаның хакында кем кайгыртыр? Сез тыңлап үскән бишек җырларын, әкиятләрне, шигырьләрне киләчәктә кем сөйләр дә кем тыңлар?!

Кемдер милләт өчен, Ватан өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш.

Нишлик дигән сорауга шундук: «Яңа милли хәрәкәт кирәк!»—дип җавап бирәсе килә.

Шуны дә әйтергә кирәк, Мәскәү тарафыннан шомлы авазлар ишетелгән, аннан салкын җилләр искән бу чорда халкыбызның мәнфәгатьләре өчен көрәшкәндә үзебезнең республика җитәкчеләребезгә булдыра алганча ярдәм итәргә бурычлыбыз. Ләкин шуның белән беррәттән аларга таләпләр дә куярга

хаклыбыз. «Башсыз илдә бәрәкәт булмас»,—ди халык. Коммунистлар чорындагы кайбер түрәләрнең татар язмышына битарафлыгы нәтиҗәләрен без бүген татыйбыз. Татарстанның хәзерге җитәкчеләре Мәскәү белән сөйләшкәндә халкыбыз өчен нык торсыннар иде. Артка чигенүдән туктарга иде, ниһаять! Без хәзер үзебездә яңа партияләр терки алмыйбыз. Киләчәктә Татарстанның яңа Президенты татар телен белмәсә дә ярый икән. Бөтенләй телсез кеше дә Татарстанның Президенты була ала дигән закон чыкса, мин гаҗәпләнмәм, мөгаен.

Россия уртасында халыкның яшәү рәвешен саклау, әлбәттә, авыр. Милләтне яшәү рәвеше саклый бит. Шул милли мохиттә рухы калка кешенең.

Җаваплылык хисе дә көчле рухка ия кешеләрдә генә буладыр. Татар халкының шундый шәхесләре оешкан сурәттә генә киләчәгебез турында хыяллану мөмкин.

Әйе, һәр заман безне сыный.

Тиздән халык санын алу уздырылачак. Шушы чара ярдәмендә татар милләтен төрле төркемнәргә бүлеп таркату сәясәтен алга сөрүчеләр дә бар.

Юк! Без—татарлар! Без—татар халкы! Мишәр дә, нугай да, типтәр дә үзен татар дип яздырырга тиеш! Бу, минемчә, ерак бабаларыбыз алдында тагын бер кат сыналуыбыз һәм имтихан тотуыбыз.

550 ел дәүләтсез яшәп көн күргән һәм сакланып калган, бетмәгән халык—барыбер бөек халык! Безнең үзебезне татар дип язарга да хакыбыз бар! Хөррияткә дә хакыбыз бар! Мөстәкыйль дәүләткә дә хакыбыз бар!

Без—җәбер-золым кичергән һәм җан газабына чыдаган татар халкы—үз-үзебезгә карата булган битарафлыкны җиңәргә көч-куәт табарбыз, иншалла.

Дөнья—вәхши һәм рәхимсез, әмма вә ләкин чарасыз чорларда да барыбер гаделлек калкып чыгып хөкем сөрә башлый. Шуны да әйтергә кирәк: гаделлек—дәүләтнең какшамас нигезе булып тора. Хөрмәтле Президентларыбыз да моны һәрвакыт исләрендә тоталардыр дип ышанасы килә.

Һәм кинәт урыс философы Н. Бердяевның сүзләре искә төште: «Азатлыктан башка бернинди гаделлек булалмый».

Моны инде без барыбыз да беркайчан онытмыйк!

Без исән!

Милләтебезнең киләчәге өчен без җаваплы!

Татар халкы өчен, Татарстан өчен һәркем хәленнән килгәнне эшләсен иде.

# БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ III КОРЫЛТАЕ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

2002 елның 28-29 августында Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә Россия Федерациясе төбәкләреннән, БДБ дәүләтләреннән һәм ерак чит илләрдән килгән җәмгыятьнең төрле катлауларын һәм сәяси агымнарын чагылдыручы делегатлар һәм кунаклар катнашында узган Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае, илдә һәм дөньяда иҗтимагый-сәяси хәлләр үсешенең төп тенденцияләрен, татарларның XXI йөз башында дөнья җәмәгатьчелегендә тоткан ролен һәм урынын тикшергәннән соң, татар халкының алга таба да милли-дәүләти һәм мәдәни үсеш, берләшү юлларын билгеләде.

Бөтендөнья татар конгрессының II корылтаеннан соң узган биш ел вакыт эчендә Россия Федерациясендә һәм дөньяда татар халкы язмышына да кагылышлы җитди үзгәрешләр булды. Бу җирлектә татарларның милли үзаңы үсеше көчәйде, көн кадагында торган мәсьәләләрне бергәләп хәл итү нигезендә мәгълүмати-мәдәни багланышлар активлашты, милли мәктәпләр, сыйныфлар, мәдәният учреждениеләре, төбәкләрдә басыла торган газеталар, теле-радио программалар челтәре киңәйде, татар халкы тарихы буенча объектив фәнни хезмәтләр язылды. Бөтендөнья татар конгрессының төбәкләрдәге бүлекләре, татарлар яши торган җирләрдәге хакимият органнары, фән, гомуми белем бирү, мәдәни-агарту учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек итеп, Татарстан учреждениеләре һәм предприятиеләре белән эшлекле һәм мәдәни хезмәттәшлекне киңәйтәләр; бу үз чиратында татар халкын берләштерүгә ярдәм итә.

Татарстан Республикасы, татар халкының рухи яңарышы һәм үсеше үзәге буларак, гамәлдәге законнар кысаларында, үзенчәлекле милли мәдәниятне, белем бирү системасын саклау һәм үстерү, шулай ук гомуммилли мәгълүмати киңлек булдыру буенча тәгаен чаралар күрә.

Конгресста катнашучылар Татарстан Республикасының яңа редакциядә кабул ителгән Конституциясенә кертелгән республикадан читтә яшәүче татарларның милли-мәдәни үсешендә Татарстан Республикасының роле турындагы 14 нче статьясын тулаем хуплыйлар һәм бу статья Россия Федерациясендә сан ягыннан икенче урында торган халыкның этномәдәни бердәмлеген саклауның хокукый базасын төзи, дип саныйлар.

Шуның белән бергә соңгы елларда Россия җәмгыятенең сәяси тормышында дәүләт төзелешендәге федерализм принципларыннан читкә китү тенденциясе күзәтелә. Бу, беренче чиратта, федерация субъектлары вәкаләтләрен нигезсез чикләргә һәм Россия халыкларының аерылгысыз хокукларын инкарь итәргә омтылуда чагыла.

Хакимият вертикален ныгыту кысаларында кертелгән байтак үзгәрешләр Россия Федерациясенең гамәлдәге Конституциясенә каршы килә. Кайбер төбәкләрдә Россия Федерациясе халыклары телләре, мәгариф, мәдәният турындагы федераль законнар үтәлми, ә бу исә татар милләтенең хокукларын чикләүгә китерә.

Татарларның белем бирү системасын, мәдәниятен, иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген, рухи һәм дини тормышын катгый регламентларга тырышучы федераль хакимият структуралары, гадәттә, әлеге мәсьәләләргә игътибар бирмиләр.

Алда торган халык санын алуга бәйле рәвештә, Конгресс инде алдан әзерләнеп куелган «2002 елда Бөтенроссия халык санын алу материалларын әзерләү өчен милләтләр исемлеге» проекты өчен шулай ук хәвефләнә, чөнки бу исемлек узган халык санын алу формасыннан нык аерыла: анда татар халкы бернинди сәбәпсез һәм нигезсез берничә мөстәкыйль этноска бүлгәләнә, бу нәрсәне галимнәр дә, җәмәгатьчелек тә кабул итә алмый.

Татар халкы, кайда яшәүләренә һәм нинди конфессиягә карауларына бәйсез

рәвештә, бербөтен һәм уртак тарихи тамырларга, югары үсеш алган мәдәниятка ия. Конгресс, 1989 елдагы халык санын алудан соң узган вакыт эчендә, нигездә, татарлар базасында яңа халыкларның барлыкка килүе мөмкин түгел, дип саный, чөнки татарлар югары үсеш алган милләт буларак инде XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында ук барлыкка килә.

Бер үк вакытта безне аерым төбәкләрдә халык санын алуга әзерлек барышында халыкка басым ясарга тырышулар шулай ук борчый, бу Россия халыкларының милли составының дөрес күрсәтелмәвенә китерергә мөмкин. Халык санын алуның ышанычлы тәэмин итү буенча өстәмә чаралар күрү максатка ярашлы булыр иде.

Бөтендөнья татар конгрессы II корылтаеның татар халкының эчке эше булган һәм бары тик лингвистик сыйфатка ия татар язуын латин графикасына күчерү турындагы карары берниндн нигезсез сәясәтләштерелә һәм кайбер даирәләр тарафыннан Россия дәүләтенең иминлегенә куркыныч тудыра, дип күрсәтелә.

Боларның барысы да татар җәмәгатьчелегендә нигезле хәвеф, борчылу уята, Россиядә яшәүче һәм илнең икътисадына, фән һәм мәдәниятенә шактый өлеш кертүче татарларның зур иҗат куәтен гамәлгә ашырырга комачаулый.

Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае, Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиевнең чыгышын, Конгрессның башкарма комитеты хисабын һәм корылтайда катнашучыларның тәкъдимнәрен тыңлаганнан соң милләтара килешеп яшәү идеалларына үзләренең тугрылыгын, барлык халыклар һәм милләтләрнең аерылгысыз хокукларын тануларын раслый, милләтнең берләшүе, Россия Федерациясе һәм бөтендөнья татарлары арасындагы бәйләнеш-ләрнең алга таба да ныгуы һәм киңәюе мәсьәләләрен күтәреп чыга. Корылтай ана телен, милли мәдәниятне саклау һәм үстерү, XXI йөздә халыкның гасырлардан килә торган этник һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклап калу һәм үстерүгә сәләтле яңа буынны тәрбияләүне бөтендөнья татар бергәлегенең өстенлекле максатлары, дип саный.

Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае делегатлары һәм катнашу-чылары, кайда яшәүләренә һәм нинди дин тотуларына, төрле этномәдәниятка һәм конфессиональ төркемнәргә карауларына бәйсез рәвештә, барлык татарлар— уртак тарих, мәдәният, тел һәм үзаң нигезендә берләшкән, бербөтен һәм бүленмәс халык, дип белдерәләр. Шул ук вакытта безнең халкыбыз дуслык һәм бер-беренне аңлау рухында, хезмәттәшлек һәм толерантлыкны саклау шартларында гына яши торган күпмилләтле җәмгыятьнең бер өлеше дә булып тора.

Бөтендөнья татар конгрессы Татарстан хакимияте органнарының, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының ана телен һәм халыкның үзенчәлекле мәдәниятен саклау буенча тырышлыгын хуплый һәм ана ярдәм итә, аларны дөньякүләм процессларны глобальләштерү чорында татар милләтенең яшәп калуы өчен кирәкле шартлар, дип саный.

Татар милләте һәм иҗтимагый берләшмәләрнең «Бөтендөнья татар конгрессы» халыкара бердәмлеге алдында торган мөһим бурычлар итеп түбәндәгеләрне санарга:

**—Россия Федерациясендә дәүләтнең бөтенлеген, барлык халыкларның хокукларын, илнең базар икътисады һәм федерализм юлында үсешен гарантияләүче демократик реформаларга тайпылышсыз ярдәмне;**

**—Татарстан Республикасының Россия Федерациясе составында күпмиллэтле демократик хокукый дәүләт буларак конституцион статусын һәм татар халкының үзбилгеләнү формаларын яклауны;**

**—Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында ике якка да караган эшләрне һәм вәкаләтләрне тапшырышу турындагы Шартнамә нигезендә бөтен татар милләтенең милли-мәдәни үсешендә Татарстан Республикасының әйдәп баручы ролен һәм җаваплылыгын гамәлгә ашыруны;**

**—Россия Федерациясе, Татарстанның һәм башка субъектларның дәүләт хакимияте органнары белән берлектә, татарларның милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында татар халкын үстерү буенча 2002 - 2007 елларга исәпләнгән гомумфедераль программа эшләүне;**

**—Россия Федерациясендә һәм башка илләрдә татар мәдәни-белем биру учреждениеләре челтәрен саклап калу һәм үстерүгә ярдәмне; халыкның рухи кыйммәтләренә һәм гореф-гадәтләренә җәмгыятьнең барлык катлавын, беренче чиратта, яшь буынны тартуны, якынайтуны;**

**—эшкуарлык традицияләрен кайтаруга ярдәм итүче эшлекле хезмәттәшлекне активлаштыруны, татарлар яшәгән төбәкләрдә сәүдә йортлары, хезмәт күрсәтү предприятиеләре челтәрен (шул исәптән ял итү, китап, аудио-видео продукцияләре сәүдәсе һәм җәмәгать туклануы өлкәсендә) киңәйтүне;**

**—Татарстан һәм татарлар яши торган төбәкләр арасында даими мәдәни багланышларны җайга салу һәм гомуммилли мәгълүмати киңлекне булдыру максатларында, ясалма иярчен аша эшли торган телевидение, радио һәм интернетны да кертеп, заман таләпләренә туры килә торган мәгълүмати технологияләрне киң файдалануны;**

**—Казан шәһәренең 1000 еллыгына гомумроссия бәйрәме буларак һәрьяклап әзерлекне;**

**—Татарлар яшәгән төбәкләр өчен милли кадрлар әзерләүне;**

**—Бөтен конфессияләргә дә толерантлы мөнәсәбәтне, татарлар арасында таралган традицион диннәрнең гуманистик кыйммәтләренең тәрбияви ролен күтәрүне;**

**—«Сабантуй» милли бәйрәмен ЮНЕСКОның кешелекнең авыз иҗаты һәм матди булмаган мирасы җәүһәрләре исемлегенә кертү турында мәсьәләне хәл итүне;**

**—ана телен белүне, татарлар тупланып яши торган төбәкләрдә телне үзләштерүне, милли мәгарифнең торышын төрле яклап өйрәнүне, татар язуын латин графикасына кайтару эшләрен дәвам итүне;**

**—Бөтендөнья татар конгрессының структур бүлекчәләре һәм төбәкләрдәге милли оешмаларны оештыру эшчәнлеген камилләштерүне, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, иҗтимагый оешмалар, мәдәни агарту учреждениеләре белән татар халкының милли-мәдәни мәсьәләләрен хәл итү өчен үзара нәтиҗәле хезмәттәшлекне дәвам итүне;**

**—милли-мәдәни автономияләрнең тагын да нәтиҗәлерәк эшләве өчен шартлар тудыруны, шул исәптән, милли-мәдәни автономияләр турындагы законнарга тиешле үзгәрешләр кертүгә ирешүне, дәүләт тарафыннан финанс ярдәм механизмын булдыруны, бу законның Россия Федерациясенең барлык төбәкләрендә дә үтәлешенең җәмәгать тикшерүендә тотуны җайга салуны;**

**—бербөтен татар милләтен этник һәм конфессиональ төркемнәргә бүлгәләүнең татарларның этномәдәни бөтенлегенә чынлап торып куркыныч тудыруын гаепләүне.**

**Мөнир Абдуллин**

# АВЫЛ ЯШӘСӘ, ИЛ ЯШӘР

БИЛГЕЛЕ булганча, Россия Федерациясе төбәкләре арасында Татарстан бөртекле ашлык, ит, сөт һәм башка төр авыл хуҗалыгы ашамлыклары җитештерү буенча беренче өчлеккә керә. Республика халыкны нигездә үзендә җитештерелгән азык-төлек белән тәэмин итеп тора. Ләкин тагын да күбрәк, арзанрак, конкуренциягә сәләтле продукция җитештерү өчен тырышыбрак эшлисебез бар әле. Россия хөкүмәте һаман да, үзебезнең товар җитештерүчегә зыян китереп, читтән продукция кертүне арттыра бара. 2002 елның беренче кварталында чит илләрдән ашамлыклар кертү тагын 30 процентка артты. Россия чит илләрдән ел саен 1 миллион 200 мең тонна ит сатып ала. Мондый шартларда күмәк хуҗалыкларга үзенең җитештергән продукциясен урнаштыру кыенлаша, әлбәттә.

2001 елны һәр дүрт хуҗалыкның берсе зыян белән тәмамлады. Рекордлы уңыш үстереп тә күмәк хуҗалыкларның финанс һәм икътисади хәле яхшырмады. Күп кенә хуҗалыклар хезмәт хакын айныкын айга түләп бара алмый. Күбесе муеннан бурычка баткан.

Кайбер белгечләр, сәясәтчеләр агропромышленность комплексындагы кимчелекләрне җирнең хуҗасы, хосусый милекче булмау белән аңлаталар. Республикада бу юнәлештә эш алып барылса да, авыл хуҗалыгы өлкәсендә реформа үткәрелсә дә, өлегә ул көткән нәтиҗәне бирми. Пай җирләрен бүлеп биргәч, фермер хуҗалыклары төзелгәч, колхоз һәм совхозлар урынына акционерлык җәмгыятьләре, кооперативлар, ширкәтләр оештыргач, эшләр тиз хутка китәр, дип уйлаган идек. Ләкин базар икътисады шартларында, Россия хөкүмәте һаман да читтән азык-төлек кертеп, үзебезнең җитештерүчеләрне язмыш кочагына ташлаган бер заманда авыл хуҗалыгы күп кенә проблемалар алдында калды.

2002 ел Татарстан тарихына тагын бер рекордлы уңыш җыеп алу елы булып кереп калыр. Һәр гектардан 35,4 центнер уңыш чыкты, ашлыкның тулай җыемы 5 миллион 700 мең тонна тәшкил итте. Авыл хуҗалыгын үстерүгә Президентның һәм хөкүмәтнең финанс ярдәме булмаган булса, без шул кадәр уңышны үстерә дә, җыеп ала да алмаган булыр идек. 2002 елда агропромышленность комплексы 1700 комбайн, 3000 трактор алды. Авылда техника тузган, искергән бер вакытта машина-трактор паркының шулай яңарып торуы күңелле хәл. Татарстанда сөрү җиренең һәр гектарына минераль ашлама Россиядәгедән алты тапкыр күбрәк кертелә. 2001 елда кыр эшләрен уңышлы үткәрүне тәэмин итү максатында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләргә 2,8 миллиард сум акчалата кредит, ә агропромышленность комплексын үстерүгә барысы 8,2 миллиард сум акча

бирелде. Безнең терлекчелектә нәсел эшен, игенчелектә элита орлыкчылыгын үстерү буенча үз программаларыбыз бар.

Башка күп кенә төбәкләр белән чагыштырганда, 2001 елда Татарстан авыл хуҗалыгының тулай продукциясе үсеше 2000 ел дәрәҗәсенә карата 126 процент тәшкил итте.

Авыл хуҗалыгының нәтиҗәле үсешен тәэмин итү заманча фикерли торган, алга карап эш йөртә торган кадрлардан башка мөмкин түгел. Шуны искә алып, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев 2001 елның мартында авыл хуҗалыгында кадрлар сәясәте турында указ чыгарды. Аны үтәү йөзеннән Хөкүмәт республика агропромышленность комплексын җитәкче кадрлар белән ныгыту хакында карар кабул итте. Бу программа авыл хуҗалыгы белгечләрен торак белән тәэмин итүне дә күздә тота. Эш стажы зур булган күмәк хуҗалыклар җитәкчеләренә өстәмә рәвештә җир пае, шулай ук 10 елдан алып 30 елга кадәр эшләгәннәренә ел саен 30-50 мең сум акча түләү каралган.

Авыл хуҗалыгы кадрларына карата шундый сәясәт үткәрү үзенең уңай нәтиҗәсен бирми калмас. Республика авыл хуҗалыгы предприятиеләренә оста идарә итү үрнәген күрсәткән күп кенә җитәкчеләр бар. Андый хуҗалыклар югары рентабельле эшли, продукцияне күп җитештереп зур табыш ала, кешеләренә вакытында, айныкын айга хезмәт хакы биреп бара. Чүпрәле районының «Цильна» күмәк хуҗалыгы, Теләче районының Ленин исемендәге тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы, Буа районының «Коммуна», «Марс», Биектау районының «Урак һәм Чүкеч», Балтач районының Тимирязев исемендәге, «Татарстан» күмәк хуҗалыклары, Кукмарадан «Яңа тормыш» арендаторлар берлеге, Нурлаттан «Киекле» авыл хуҗалыгы кооперативы һәм башка кайбер хуҗалыклар әнә шундыйлардан санала. Әйтик, Теләче районының Закирҗан Бикмөхәммәтов җитәкчелек иткән Ленин исемендәге тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы кассасына елга 48 миллион сумнан артык акча керә икән, рентабельлек 53 процентка җиткән икән, бу инде хезмәт хакы түләргә дә, техника алырга да, төзелеш алып барырга да, ягулык-майлау материаллары юнәтергә дә, салымнарны вакытында түләргә дә җитә. Мондый хуҗалыклар югары уңыш ала, мал-туарны күп асрый. Алар бүгенге кыен шартларда да үз көнеңне үзең күрә алу мөмкинлеген раслыйлар.

Ләкин күп кенә күмәк хуҗалыклар очын-очка ялгап бара. Араларында инде банкротлыкка чыкканнары да бар. Алар да гомер-гомергә иген иккән, терлек асраган, шуның белән тормышын алып барган. Шуңа күрә республика җитәкчелеге 2002 елда 400гә якын авыл хуҗалыгы предприятиесенең хуҗалык итү формасын һәм милек формасын үзгәртергә карар кылды. Тагын ширкәтләр, крестьян-фермер хуҗалыклары, акционерлык җәмгыятьләре төзелә. Бездә зыянга эшләүче хуҗалыкларның җирен эре промышленность предприятиеләренә бирү тәҗрибәсе дә бар. Мәсәлән, «Таттрансгаз» инде 50 мең гектардан артык җиргә ия. Түбән Кама «Нефтехим», «Татнефть»нең дә ярдәмче хуҗалыкларында тормыш кайнап тора. Тагын бер юл—икътисади яктан хәлсез хуҗалыкларны эрерәк, көчлерәк хуҗалыкларга кушу. Бу юнәлештә дә республикада эш алып барыла.

Авыл хуҗалыгы үз гомерендә уңышлы һәм уңышсыз тәҗрибәләрне күп күрде, шуның өстенә аны табигый бәла-казалар да өледән-өле сынап карады. Соңгы еллардагы агрореформалар болай да күпне күргән колхоз-совхозларның өстенә авыр йөк булып төште. Россия дәүләте һәм хөкүмәте башына килгән, авыл хуҗалыгында бер көн дә эшләмәгән һәр патша, үзенә команда туплап, авылны үзгәртеп корырга тырышты, игенчеләрне ничек һәм кайчан нәрсә чәчәргә өйрәтеп маташты. Авыл хуҗалыгында башланган реформа күккә чөеп макталды, аны тормышка ашыргач, авылда эшләр хутка китәчәк, халык балда-майда йөзәчәк, дигән фикер алга сөрелде. Ләкин соңыннан күп акча түгеп, зур хезмәт куеп эшләнгән эшләр барып чыкмагач, ялгышканбыз икән, менә болай булырга тиеш ул, дип авылны яңадан үзгәртергә тотындык. Мәсәлән, «перспективасыз» авылларны бетерү, үлән чәчүлекләренең тамырын корыту һәм башка шуныңише гамәлләрне үкертеп мактадык та, патшалар алышынгач, кирәкле эшләр булмаган икән, сукыр бер тиен дә файдасы булмады, дип үз гаебебезне үзебез танырга мәҗбүр булдык.

Гомумән, безнең авыл хуҗалыгы тарихы реформалардан гына тора

да. Столыпин реформалары, күмәк хуҗалыкларны эреләндерү буенча Н. Хрущев экспериментлары, туксанынчы еллардан колхоз һәм совхозларны үзгәртеп кору, фермер хуҗалыклары төзү буенча демократлар башлаган эшләрнең барысы да күз алдында. Петр Столыпин реформасы турында төрлечә яздылар, сөйләделәр. Берәүләр аны мактый, икенчеләр хурлый. Күпләр Столыпин реформасының чын асылына төшенмәде, аның кылган гамәлләре турында үзләренчә сукалады. Ә чынлыкта Петр Столыпин бай, хәлле, үзенең шәхси, хосусый хуҗалыгын алып барырга сәләтле авыл агаена исәп тоткан. Крестьян теләсә кайсы общинадан чыга алган, үз җире белән үзе теләгәнчә эш итәргә хакы булган. Ул үз җирен сата да, процентсыз кредит та ала алган. Тик Столыпин фермерлары община белән тынышып яши алмаганнар, буш җирләргә күчеп киткәннәр.

Петр Столыпин турында ни генә дисәләр дә, ул крестьянга җир мәсьәләсен хәл итүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтергә әзер торган. Россия авылындагы зур үзгәрешләрнең башы нәкъ менә аның исеме белән бәйле. 1907 елның маенда П. А. Столыпин Дәүләт думасы депутатлары алдында хөкүмәт башлыгы сыйфатында чыгыш ясый. Шуннан бер өзек китерик әле. Аның сүзләре бүген дә бик актуаль: «... Хөкүмәт крестьянның җир алуын тели, аның бай булуын, муллыкта яшәвен тели, ә муллык булган җирдә, әлбәттә, мәгърифәт тә, чын ирек тә була. Әмма моның өчен сәләтле, хезмәт яратучы крестьянга, ягъни рус җиренең тозына хәзерге вакытта ул яшәгән кысымнардан, хәзерге тормыш шартларыннан арынырга мөмкинлек бирергә кирәк. Аңа үз хезмәтенең җимешләрен үзенә беркетеп калдырырга һәм аларны үзенең аерылгысыз милкенә әйләндерергә мөмкинлек бирергә кирәк. Бу милек община әле бетмәгән урыннарда уртак булсын, ә община яшәргә сәләтле булмаган урыннарда ул аерым кешенеке булсын, ул нык булсын, нәселдән-нәселгә калсын. Шундый милекче-хуҗага хөкүмәт киңәш белән, кредит белән, ягъни акча белән ярдәм итәргә тиеш...»

Хәзер менә безнең авыл хуҗалыгын артталыктан чыга алмауда гаеплиләр. Күмәк хуҗалыкларга берләшү, колхоз һәм совхозлар төзелү елларын эт итеп сүгәләр. Бу сәясәт туксанынчы еллар башында башланды. Ләкин Россия реформаторлары, демократлары шул колхозлар һәм совхозларның дәһшәтле сугыш елларында фронтны ашлык һәм башка азык-төлек белән тәэмин итеп торганнарын оныттылар. Шул ук вакытта алар Россиядәге күп кенә күмәк хуҗалыкларны, авылларны таратып бетерүгә, кешесез калдыруга ирештеләр. Инде моның нинди нәтиҗәләргә китерүен аңладылар аңлавын, тик терсәкне тешләп булмый. Бүген Россиядә 30 миллион гектар җирдә котырып чүп үлән үсеп утыра. Күп кенә авылларда балалар тавышы ишетелми, йортларның тәрәзәләренә такта кадакланган. Ярый әле, Татарстан җитәкчелеге шул шаукымга ияреп, колхоз һәм совхозларны бетереп ташлау юлыннан бармады. Дөрес, колхоз һәм совхоз сүзеннән котылу өчен аларның исемнәрен үзгәртү башланды. Элеккеге күмәк хуҗалыклар күмәк предприятиегә, кооперативка, ширкәткә, берләшмә һәм ассоциациягә әйләнде, исемнәре үзгәрсә дә, җисемнәре шул килеш калды. Күбесе хәлсезләнде, элеккеге йөзен югалтты. Шулай да колхоз исемен саклап калган хуҗалыклар да бар. Алар республикада күп булмасалар да, аякларында нык басып торалар, аларны башкаларга үрнәк итеп китерәләр. Алексеевск районының «Родина», Актаныштан Шәймәрданов исемендәге, Балтач районының «Якты юл», Тимирязев исемендәге, Саба районының «Беренче Май» һәм башка колхозлар, шулар кебек үк шартларда яшәүче кайбер авыл хуҗалыгы предприятиеләре әҗәттән башлары чыкмыйча көчкә сөйрәлеп барганда, болар икътисади яктан көчле хуҗалыклардан санала.

Ләкин Никита Сергеевич Хрущевны ничек кенә хурласалар да, ул дәүләт сәясәтен авыл хуҗалыгына йөз белән борылырга мәҗбүр итте. Ул чакта агропромышленность комплексының артталыгы сәбәпләре ачылды. Илнең бөтен проблемаларын авыл исәбенә генә хәл итәргә омтылыш авыл хуҗалыгын уңайсыз хәлгә куйды. «Таяк»ка, бушка эшләп йөргән крестьян үз хезмәтенең нәтиҗәсен тоймады. Аннан күп алдылар, ләкин үзенә бик аз бирделәр яки бөтенләй бирмәделәр. Н. Хрущев хакимлек иткәндә бу киртә җимерелде. Колхозларда хезмәткә акчалата түләү кертелде. Колхоз һәм совхозлар өчен уңайлы сатып алу бәяләре кулланыла башлады. Салым

сәясәтендә тәртип урнашты. Колхозларның экономикасы күтәрелүгә йөз тотты. Колхозчыларга пенсия бирелә башлады. Авылдан китәргә теләүчеләр паспорт алды. Кешеләр авылдан китү ягын карады. Республиканың кайбер колхоз һәм совхозларында эшләргә кеше калмады. Чөнки авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү артса да, социаль мәсьәләләргә игътибар итүче булмады. Әлбәттә, соңгы елларда Татарстанда бу юнәлештә гаҗәп күп эшләр башкарылды: авылларга газ керде, юллар салынды, социаль көнкүреш объектлары, торак йортлар төзелде.

Дәүләт ярдәменнән башка хәзер күмәк хуҗалыкларга социаль мәсьәләләрне хәл итү бик авыр. Кая ул, саткан продукциясе хезмәт хакы түләргә дә җитмәгән хуҗалыклар бар. Андыйлар елга бер трактор да сатып ала алмый. Авыл хуҗалыгы продукциясе бик арзан, аны җитештерү бик кыйммәткә төшә, чөнки зур чыгымнар тотыла. Киләчәктә дә әле әллә ни зур эшләр майтарырга өмет бик чамалы. Ник дигәндә, техникага, төзелеш материалларына бәяләр арта тора, электр энергиясенә, газга да хак көнләп кенә түгел, сәгатьләп арта. Ә күмәк хуҗалыклар үзләре җитештергән продукцияләрен сата алмый азаплана, яки юк кына бәядән биреп җибәрә. Әле җитмәсә, сөтнең хакы бер менеп, бер төшеп тора. Бер литр сөт сатып, бер литр бензин да алалмагач, ничек күмәк хуҗалыкның финанс хәле яхшырсын да эшләр алга китсен. 2001 елда республиканың авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә соңгы өч елда хезмәт хакы өч тапкыр артса да, әле ул промышленностьтагыдан өч тапкыр кимрәк булып кала.

Менә шуңа күрә хәзер авыл хуҗалыгын алып баруның төрле формалары турында күп сөйлиләр. Хәер, бу эш бездә күптән башланды башлануын, ләкин шуны онытырга ярамый, нинди генә форма сайлап алынмасын, авылда хуҗалык итүнең нинди генә формалары макталмасын, авыл хуҗалыгы дәүләт ярдәменнән башка яши алмый. Ул чит илләрдә дә шулай. Аларда хөкүмәт фермерларга, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүче корпорацияләргә зур кредитлар, субсидияләр, ссудалар бирә. Россия Фәннәр Академиясенең АКШ һәм Канада институты сектор мөдире, экономик фәннәр кандидаты Борис Черняков болай дип яза: «Фермерлар һәм хосусый милекнең роле, базар турында ни генә сөйләмәсеннәр, экономиканың бу секторы җитештерүне интенсивлаштыруның төрле факторларын файдалануга, прогрессның яңа оештыру, техник һәм технологик казанышларына, һәрьяклы дәүләт ярдәменә таяна». Әлбәттә, Америка һәм Канада фермерының да эше гел-гел гөрләп кенә бармыйдыр. Андый чакта аларга дәүләт зур ярдәм күрсәтә. Соңгы өч ел рәттән Америка Кушма Штатларында фермер хуҗалыкларының табышы кимеп китә. Авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр төшә. Фермерлар өҗәткә керә. Шул чакта дәүләт аларга нык кына матди ярдәм күрсәтә. Өч елда АКШ хөкүмәте фермерларга 60 миллиард долларга якын акча бирә.

Тик шуны онытырга ярамый, нинди генә милек формасын сайлап алсак та, башта хуҗалык итә белергә өйрәнергә, нәтиҗәле эшләргә кирәк. Шул хакта сүз кузгалса, кайберәүләр җирнең хосусый милектә булмавын сәбәп итәләр, авыл хуҗалыгындагы кимчелекләрне шуның белән аңлаталар. Хосусый милек булгач, җирне сатарга да мөмкин, дип саныйлар. Бериш кешеләр, белер-белмәс, әнә чит илләрдә җир хосусый милекчеләр кулында, дәүләт теләгән кешегә теләгән кадәр җир сатып бирә, дип сөйлиләр. Ләкин алай дип раслаулар дөреслеккә туры килеп бетми. Үзәк матбугат язмаларыннан, кайбер белгеч-галимнәрнең сөйләвеннән күренгәнчә, сату-алу рөхсәт ителгән илләрдә дә җирнең зур өлеше дәүләт кулында. Бу мәсьәлә буенча элек тә бәхәсләр булып торган. Хәтта Лев Толстой җиргә хосусый милек урнаштыруга, җирне сатуга каршы чыккан. Ул патша галиҗәнапларына крестьянны яклап хат та язып җибәргән. Хәзер Татарстанда Җир кодексы нигезендә җирне сату-алу рөхсәт ителә. Россия Дәүләт Думасында нәкъ менә шушы мәсьәлә буенча бик күптәннән бирле бәхәс барды. Ниһаять, бердәм фикергә килделәр. Россиядә дә җирне сату-алу рөхсәт ителә.

Җирне сатып җибәрү ансат анысы. Ә анда бүген, иртәгә кем эшләр? Шулай бәхәсләшүгә җитди сәбәп бар. Җирнең чын хуҗасы булырга тиеш, дигән фикер тынгылык бирми күпләргә. Бериш кешеләр моңа аяк терәп каршы тора. Аларның дәлиле шундый: җирне сатып алган акчалы байлар

алпавытка әйләнер дә авыл халкы аңа батрак булып хезмәт итәр. Икенчеләр, җир сатылып бетәр дә авыл хуҗалыгы әйләнешеннән чыгар һәм иген игәргә яраклы уңдырышлы җирләрдән колак кагарбыз, диләр. Җир кешесе, авыл кешесе бүген дә җирдә бил бөгә. Кара тиргә батып эшләмичә генә берәү дә уч тутырып акча бирмәячәк. Ә авыл кешесенең җирне сатып алырлык акчасы юк. Читтән килеп җир алган абзый шунда иген үстерсә, терлек асраса—начармыни? Авыл хуҗалыгы максатлары өчен файдаланылмый торган җирләрне сатып алып, халыкка кирәкле әйберләр җитештерү өчен кечкенә генә фабрика-завод салып куйса да, ни булган?

Әмма шуны белеп тору зыян итмәс, бер илдә дә җирне иректә рәвештә теләсә кемгә сатып җибәрмиләр. Сатыла торган илләрдә дә чикләү кертелгән. Ә милек формасы төрлечә. Моны һәр ил үз мөмкинлекләреннән, халык ихтыярыннан, табигый шартларыннан чыгып хәл итә. Мәсәлән, Израильдә җиргә хосусый милек юк диярлек. Авыл хуҗалыгы җиренең 91 проценты дәүләт кулында. Анда бездәге колхозлар тибындагы кибуцылар җир шарында конкуренциягә сәләтле, югары сыйфатлы продукция җитештерә. Германиядә исә авыл хуҗалыгы җиренең 95 процентган артыгы хосусый милекчеләр кулында. Калганы—дәүләтнеке. Немецлар җирне саталар сатуын, тик теләсә кемгә түгел. Җир сатып алыйм дисең икән, син җирдә ун ел аны арендага алып эшләргә тиеш буласың. Голландиядә җир тулысы белән хосусый милекчеләрдә һәм арендаторларда. Швециядә авыл хуҗалыгы җиренең 2,5 проценты дәүләт милке булып санала. 60 проценты фермер хуҗалыкларында, 20 проценты арендага бирелгән. Канадада җирнең 9,8 проценты, Бельгиядә—70, Франциядә—50, АКШ һәм Англиядә 40 проценты арендага бирелгән. Ә бит бу илләрдә авыл хуҗалыгы алга киткән. Димәк, хикмәт милекнең нинди формада булуында гына түгел, җирдә ничек эшләүгә, хуҗалык итүгә дә бәйле икән. Тик җиргә хосусый милек кертү, җирне сату-алу базары булдыру авыл хуҗалыгын кризистан чыгаруның бердәнбер юлы түгел. Бөтен бәла шунда, авыл хуҗалыгында, җирле шартларны, халыкның холкын, фигыльен исәпкә алмыйча, чит илләргә ияреп, шуларча эшләргә омтылу белән генә әллә ни майтарып булмый. Америкага карап кына Америка булып булмый. Без аны куып җитеп узып та китмәкче идек. Әнә АКШ 2000 елда 335 миллион тонна ашлык җитештергән. Бу—бөтен җир шарында җитештерелгән ашлыкның 18 проценты. Һәр гектардан уңышны 58 центнерга җиткергәннәр. Ә Россиянең җире АКШныкыннан күбрәк, югыйсә, Россия 2001 елда 83 миллион тонна ашлык җитештерде, әле шуны да күккә чөеп мактыйбыз. Билгеле, Америка җире белән безнекен чагыштырып булмый. Без ашламаны да мыскаллап кына кертәбез. 2001 ел уңышы җиренә Татарстанда һәр гектарга 75 килограмм минераль ашлама кертелде. 2002 ел уңышы җиренә 50 килограммга да җитмәде. Монда республика хуҗалыкларын минераль ашлама сатып алу өчен акчалары юклыкта гаепләргә яки бюджеттан акча бүлеп бирелмәвен сәбәп итәргә ашыкмыйк. Гаепне Мәскәүдән эзләү урынлы булыр. Чөнки Россия җитәкчеләре, авыл хуҗалыгын үстерү турында күп сөйләсәләр дә, практик эшкә килгәндә алай бик селкенмиләр. Россиядә ел саен 16 миллион тонна минераль ашлама җитештерелә, шуның 15 миллион тоннасы чит илләргә сатыла. Шуңа да Россия үзе җиргә нибары 10-12 шәр килограмм минераль ашлама кертә.

Бу яктан чит-ятларга тиңләшерлек чама булмаса да, алардан хуҗалык итә белү осталыгына өйрәнү зыян итмәс. Әйтик, Америка Кушма Штатларында эре фермерлар күбрәк файда китерә, ди. Ә кечкенәләрендә уңыш азрак. Эре фермалар, ягъни агропромышленность предприятиеләре җирне арендага алып эшли. Менә шушы эре хуҗалыкларны специальләштерү дә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттырырга мөмкинлек бирә. Соңгы 20 ел эчендә фермер хуҗалыклары ике тапкыр диярлек кимегән. Ә тулай продукция җитештерү арткан. Пенсильвания штатындагы бер ферма, мәсәлән, 2450 баш сыер асрый икән, һәрберсеннән ел саен 11800 килограмм тирәсе сөт савып ала. Җире дә артык зур түгел—840 гектар. Шушы кадәр мал-туарны нибары 20 кеше карый.

Менә шулар турында укып, ишетеп белгән кешеләр, әнә Американы фермерлар туйдыра, дип сөйләргә яраталар. АКШның аграр мәсьәләләр

буенча белгече Джон Кристал болай ди: «Американы фермер туйдырмый, ө эре җир биләүче кооперативлар туйдыра». Американың танылган экономисты, Нобель премиясе лауреаты В. Леонтьев болай дигән: «Бездә төп җитештерүчеләр—зур корпорацияләр, ө аерым фермер түгел. Корпорацияләр читтән килгән кешеләрне яллап эшләтүче эре фабрикаларны хәтерләтә. Аларның машиналары күп, җирләре, югары технологияләре бар. Кечкенә фермалар исә читтән кеше ялламыйлар, илдәге бөтен авыл хуҗалыгы продукциясенең нибары ике проценты чамасын җитештерәләр».

Немецлар исә авыл хуҗалыгын алып баруның иң отышлы варианты дип Көнчыгыш Германиянекен сайлап алганнар. Монда да эре күмәк хуҗалыкларга өстенлек бирелә. Шул ук вакытта фермерлар да бар. Җирнең нибары 5 проценты алар кулында. Калганы кооперативларда, ширкәтләрдә, алар җирнең 80 процентын (кайбер чыганаклар буенча 90 процентын) арендага алып эшлиләр.

Чит илләрнең авыл хуҗалыгына тукталуымның тагын бер сәбәбе бар. Бу—алардагы табигый-климат шартлары, уңдырышлы җирләр, җәйнең, көзнең бездәгедән озаккарак сузылуы. Табигый факторларның ролен һич тә сызып ташларга ярамый. Шулай да монда да бәхәсләшмичә генә нокта куеп булмый. Әлбәттә, АКШта да, Көнчыгыш Европа илләрендә дә җирләр, табигый шартлар бездәгедән яхшырактыр. Әмма, бии белмәгән аюга урын тар, диләр. Без авыл хуҗалыгын алып барудагы, җирдә хуҗалык итүдәге ялгышларыбызны һава шартларына сылтарга өйрәндек инде. Татарстан климаты да кырыс, җәй кыска. Ләкин безнең лимон, банан, виноград, әфлисун үстерәсебез юк. Җирләребез дә тулаем алганда уңдырышлы. Һаман гаепне җирдән, һава шартларыннан эзләмик инде. Әйтик, кайбер районнарда урак ике ай-ике ай ярымга, шикәр чөгендере алу ноябрь урталарына кадәр сузыла икән, монда бары тик кешеләр үзләре генә гаепле. Шуңа күрә дә Россиянең кайбер түрәләре, авыл хуҗалыгы—ул «кара тишек», аңа күпме салсаң да файдасы юк, дип үзләренең булдыксызлыкларын яшереп калырга маташтылар.

Бигрәк тә бөяләрдәге тигезсезлек авыл хуҗалыгын тәмам аяктан екты. Россия хөкүмәте моңа төкереп карады, хәлне җайга салырга теләмәде. Ә



*Журналыбыз турында*

## Аяз Гыйләҗев,

Татарстанның халык язучысы

*Татар әдәбиятының язмышы кебек үк, журналның язмышы да җиңел булмады. Әгәр ул хөр фикерләрне чыгара башласа, йә Мәскәүдән, йә Казаннан чукмар белән аның башын төеп тордылар, хәтерен җимерделәр. Әдипләребезне 37 елларда бер кырсалар, сугыш елларында алар икенче мәртәбә чалгы астында калып харап булды. Ләкин журнал чыга килде, журнал яшәде, журнал ул, хәтәр җилләрнең уртасыннан барган очкыч кебек, давылларга-җилләргә бирешмәде. Бу очракта без үзебезнең халыкны, татарны бер зур хөрмәт белән искә алыйк әле. Журналны әдипләр генә түгел, сәяси белгечләр генә түгел, шагыйрьләр генә түгел, журналны татар яклады, халык яклады. Журналны татар ясады, татар рухсытты, татар яшәтте. Хәтерлим, сугыш елларында журнал ике мең, өч мең тираж белән чыга иде. Уйга калып, кайвакытта күз алдына китерәм, кемнәр язылды икән, кемнәр алды икән ул журналны, нинди хисләр, нинди уйлар белән кулларына тоттылар икән алар аны? Ничә буын татар «Казан утлары» журналын үзләренең канатлары итеп яшәп килде, татарлыкларын арттырдылар, татарлыкларын расладылар, журналны яшәттеләр һәм үзләре дә яшәделәр. Шушы уңайдан бер хәвефле уем белән уртаклашасы килә. Менә бүген—журнал юбилее. Әйдәгез әле, тагын бер 70 еллыкка сикереп уйлап карыйк, 60 еллыкка, 50-30 еллыкка, 10 еллыкка. Дистә*

бит промышленность товарлары белән авыл хуҗалыгы продукциясе арасында бәяләр аермасы элек тә булып торган. Ләкин хөкүмәт кыен хәлдән чыгу чарасын күргән. Мәсәлән, алтмышынчы еллар башында авыл хуҗалыгында кризис чаткылары күренә башлады. Нәкъ менә шул вакытта, ягъни 1965 елның мартында дәүләт илнең авыл хуҗалыгын тагын да үстерү буенча кичектергесез чаралар комплексын эшләде. Анда колхоз һәм совхозлардан сатып алына торган продукциягә бәяләрне күтәрү төп максат итеп куелды. Ул авыл хуҗалыгы һәм промышленность продукциясенә бәяләр тигезлегенә, крестьяннарның азык-төлек җитештерүне арттыруда матди кызыксынуына китерде. Колхоз һәм совхозларның өҗәтләре бетерелде, авыл хуҗалыгы продукциясе сату планнары киметелде, ә планнан тыш өзерләнгән продукция өчен күтәренке бәяләр белән түләнде. Шуннан соң озак та үтмәде, 1966—1970 елларда авыл хуҗалыгын техника һәм минераль ашламалар белән тәэмин итү турында карар кабул ителде. Колхозларга һәм колхозчыларга керем салымы киметелде. Ниһаять, авыл хуҗалыгы кризистан чыкты.

Башка илләр дә кризис кичергән, ләкин алар аннан чыгу юлларын таба белгәннәр. 1929—1933 елларда Америка Кушма Штатларында авыл хуҗалыгының кризис кичерүен тарихтан укып беләбез. Аны кризистан чыгару эшен дәүләт үз кулына ала. Президент Ф. Рузвельт авыл хуҗалыгына дәүләт заказын нык арттыра. Бер үк вакытта шушы заказлар буенча продукциягә бәяләр дә арттырыла. Кредит бирү системасы яхшыра, кредит алган өчен процентлар киметелә. Шуның белән бергә, дәүләт юллар төзү, сугару системалары кору, кыр ышыклау урман полосалары утырту кебек эшләрне дә үз бюджетына ала. Дәүләтнең авыл хуҗалыгына турыдан-туры катнашуы аны кризис хәленнән чыгарып кына калмый, АКШның авыл хуҗалыгын күтәрә һәм аны үстерә бара.

Инде кайберәүләрдә, ихтимал, сорау туар: Россия авыл хуҗалыгы да алтмышынчы елларда кризистан чыккач, ник соң Татарстанда итләр, майлар, колбасалар талонга калды? Ул елларда ите дә, мае да хәзергедән ким җитештерелмәде. Әмма итләр, майлар Мәскәүгә китеп барды. Мәскәүгә, башка кайбер төбәкләргә ит җибәрү

*елларда буыннар алмашына, буыннар үзгәрә... Менә күз алдына китереп карыйк. Бүгенге татар кем ул? Нинди ул? Без күбрәк бит тынычландыру сүзләре әйтергә яратабыз. Имеш, татар йоклаган иде, менә хәзер, имеш, татар уянды... Нинди татар уяна? Карт татар уянамы, яшь татар уянамы?.. Нигездә, татарлыгы аның канында калган, тамырларында ага торган өлкән буын татар уяна. Әле дин аны беркадәр саклап калган, әле ул элеккеге замандагы яхшы, игътибарлы, мәрхәмәтле, шәфкатьле изге татарларны күреп үскән. Ә хәзерге татар нәрсә күрә? Ул татар 10 елдан соң ничек булачак? Димәк, «Казан утлары» алдында бик күп бурычлар тора. Милли аңны үстерүдә ул бик зур эш башкарырга тиешле журнал. 20 елдан соң татарлар нинди булырга тиеш, 30 елдан соң нинди булырга тиеш, барысы турында кайгырту журнал өстендә. Без ваемсыз һәм гамьсез татарлар булмыйк инде. Дөнья безне нык өйрәтте бит. Без юанырга һәм бер-беребезне юатырга яратабыз, хәтта иллән кенә шомартырга, алдашырга да. Ләкин милләт язмышы бервакытта да шомартуга мохтаҗ түгел һәм безнең алдагы мәсләгебез— еракка китеп карау. Шул ерактагы татарны күрә алсак, без татарны яшәртәбез, һәм милләтнең дә эзе тарихта беркайчан да суынмас!*

планы бар иде ул заманда. Май башка өлкәләргә дә китте. Үзебезгә калганын өлешләп бүлеп бирделәр. Ә халык Мәскәүдән ел әйләнәсенә ит, май, колбаса ташыды. Аннан соң, хәзерге кебек шәхси хуҗалыкларга мал-туар асрарга ирек бирелмәде. Хрущев вакытында абзарыңнан бозауыңны кычкыртып талап алып чыга торган иделәр. Сарыкларны абзарга кереп санап йөрделәр, артыгын асрамыйсыңмы, янәсе.

Бүген терлекне теләгән кадәр тот, күмәк хуҗалык печәнен, саламын, ашлыгын биреп тора. Бу урында тагын бер нәрсәгә ачыклык кертәсе бар. Татарстанда күмәк хуҗалыклар итен дә, сөтен дә, ашлык һәм бәрәңгесен дә күп җитештерә. Тик алар биргән генә җитми шул әле. Авыл кешесенең шәхси хуҗалыгы яшәсен. Хәзер авылда өч-дүрт баш мөгезле эре терлек асрыйлар, бәрәңгене дә теләгән кадәр утырталар. Хәлеңнән килсә, теләсә никадәр терлек симертеп сат. Ник сатмаска, чөнки моннан шәхси хуҗалык гаиләсенә күмәк хуҗалыкта эшләп алган акчадан күбрәк керем керә. Шәһәр халкы табынындагы ризык өчен күмәк хуҗалыкларга бер рәхмәт, авыл кешесенең шәхси хуҗалыгына мең рәхмәт.

Хәзер күмәк хуҗалыкларда авыл кешесенең пай җире бар. Бу җиргә хосусый милек булдыру ниятеннән чыгып эшләнгән бер чара булса да, ул форма өчен генә эшләнгән эш булып калды. Беркем дә җир паен алып, әерым бер хуҗалык булып яшәргә теләмәде. Ул анда техникасыз нишләсен, аның йорт яны бакчасы да үзенә җитә. Тик менә күмәк хуҗалыклар авыл кешесенең җирен файдаланган өчен дивиденд түләргә теләми. Җир хосусый милектәме, дәүләт арендага бирәме яки пай җирләреме—ул авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен хезмәт итәргә тиеш. Җир—алма түгел, аны теләсә кемгә, нинди максатларга алуын белми торып, тиктомалдан гына сатып җибәрергә дә ярамый.

Шушы уңайдан бер гыйбрәтле мисал китереп үтик. Бу хакта «Сельская жизнь» газетасы язып чыкты. Кытай үзенең 1 миллиард 200 миллион халкын туйдырып тора. Заманында ачлык-ялангачлык күргән Кытай халкы артык продукциясен хәзер башка илләргә дә сата. Бу ил ничек шулай авыл хуҗалыгында югары үсешкә ирешкән дисезме? Генерал Дэн Сяопин Кытайның Үзәк провинциясенә килгәч, крестьяннарның җирдә ничек эшләүләрен күзәтеп йөри. Алар үзләре җитештергән продукциянең бер өлешен дәүләткә саткан, бер өлешен базарга чыгарып саткан да акчасын кесәсенә салып куйган. Шул акчага йортлар, юллар һәм башкасын төзегән. Шунда җаен туры китереп Дэн Сяопинга әйткәннәр: күрәсезме, кулак үсеп килә, хосусый милек чәчәк ата. Генерал карап-карап торган да: мәченең нинди төстә булуы мөһим түгел, иң мөһиме—ул тычкан тотсын, дип әйткән ди. Менә шул заманнарда Кытай алга ыргылыш ясый. Аның экономикадага бүгенге уңышларын Дэн Сяопин исеме белән бәйлиләр. Билгеле, монда дәүләт тә авыл хуҗалыгы белән идарә итүне кулыннан ычкындырмый, ләкин ул крестьянга ирек биргән, аңа даими ярдәм итеп тора.

Кытай менә шулай үзен-үзе азык-төлек белән тәэмин итеп торса, Россия читтән ташып ашый. Әгәр читләр безгә шулай ярдәм күрсәтүне туктата икән, Россиядә хәлләр бик үк җиңелдән булмаячак. Моның тискәре йогынтысы безне дә читләтеп үтмәскә мөмкин. Азык-төлекнең күпләп читкә китеп баруы ихтимал. Үзебез җитештергән продукциябезне урнаштыру кайбер кыенлыклар белән барса да, өлегә, шөкер, үзебезнеке үзебезгә җитеп тора.

Инде дә күмәк хуҗалыкларыбызны саклап калыйк дибез икән, бүген һәм якын киләчәктә берничә проблеманы хәл итәргә кирәк. Беренче чиратта—төпкә җигелеп тартучы кадрлар мәсьәләсе. Бу проблема бүген бик кискен тора. Кайбер авылларда механизаторлар, терлекчеләр җитми. Авыл җирендә күп кенә социаль проблемаларның хәл ителмәве яшьләрнең гайрәтен чигерә. Авылларыбыз пенсионерлар авылына әйләнеп бара. Күп кенә хуҗалыкларда читтән килеп, ялланып эшлиләр. Авыл картая, гаилә кормаган егетләр күбәя.

Билгеле, авыл хуҗалыгында хезмәткә түләүдә тәртип урнаштырмый торып, авылда кадрларны төпләндереп калдыру проблемасы уңай хәл ителмәс. Әле ярый кайбер гаиләләр шәхси хуҗалыгында эшләп, тормышын алып барырга тырыша. Ләкин бит һәркем дә алай эшли алмый. Мал-туар асрап, бәрәңге утыртып көн итүчеләрнең дә күбесе инде өлкән яшьтәге

кешеләр. Аларга шәхси хуҗалыкларын алып бару кыенга туры киләчәк. Уллары, кызлары, оныклары шәһәргә яки район үзәкләренә китеп тормыш кора.

Мондый хәл тагын бер проблеманы алга куя. Авылда хуҗалык итү, милек формалары үзгәргәч, яки хосусый милеккә бөтен җиреңә, техникаңа, башка мөлкәтеңә хуҗа булып алгач, ул артык кашык тотмаячак. Эшче көчләр бармак белән генә санаулы булачак. Әле авылга эшсезлек янау ихтималы да юк түгел. Чит илләр тәҗрибәсе күрсәткәнчә, аз көч белән дә шәһәр халкын туйдырып була. Әнә Америка Кушма Штатлары халкын илнең 4 процент кешесе ашатып, эчертеп тора.

Әлегә бездә күмәк хуҗалыкларның икътисадын ныгыту, финанс хәлен савыктыру турында сүз күбрәк бара. Шулай икән, тагын берничә проблеманы хәл итүдән башка да авыл хуҗалыгының хәлен яхшырту икеле. Чит ил крестьяны иген үстерә, терлек үрчетә. Ә юллар салу, газ кертү, йорт яки мәдәният йорты төзү—аның эше түгел. Бездә исә барысы да шул күмәк хуҗалыкларга йөкләнгән. Югыйсә, бу—җирле үзидарәләр эше. Акчалары юк, диярсез. Үзидарәләрнең гомер-гомергә акчалары булмады, берәр чара үткәрәсе булса да, күмәк хуҗалык җитәкчесенә барып ялындылар. Ул хәзер дә шулай. Элек-электән социаль мәсьәләләр җирле үзидарәләргә тапшырылган булса, бүген мондый хәлгә калмаган булыр идек.

Тагын бер җитди мәсьәлә, ул да булса, күмәк хуҗалыкларның бирәчәкләрен йә гамәлдән чыгару, йә түләү вакытын чигереп тору.

Тагын бер перспективалы юл—инвесторлар табу. Моның мисаллары республикада шактый. Мәсәлән, Спас районында шушы юнәлештә эш алып барыла. Гомумән, бу районда күмәк хуҗалыкларны үзгәртеп кору, аграр реформа үткәрү буенча башланган эшләрнең инде кайбер уңай нәтиҗәләре дә бар. «Ямбакты» һәм Абдулла Алиш исемендәге авыл хуҗалыгы кооперативларын берләштереп, «Иген» агропромышленность комплексы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте оештырыла. Эшне яңача башлап җибәрү, җирнең чын хуҗасын булдыру, шушы агропромышленность комплексын аякка бастыру өчен 60 миллион сумга якын акча салынган. Моның инвесторы—Мәскәүдәге «Корус» холдинг компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең «Корус-агро» предприятиесе. Җитәкчелек итү «Иген»нең Казандагы вәкиле—башкаручы директоры Марат Гәрәевкә һәм аның районда урынбасары Рафис Мөхәммәтовка йөкләнгән.

Башта авыл халкының бер өлеше мондый үзгәрешләргә бераз сагаебрак караган, берише яхшыга юраган. Инде агропромышленность комплексы төзелеп, анда эшләүчеләр еллар буе алмаган хезмәт хакын да ала, хуҗалыкка яңа техника, минераль ашламалар да кайта башлагач, аларның бу яңалыкларга карашы үзгәрә.

Агропромышленность комплексының житештерү буенча начальнигы Илшат Галәветдинов болай дип сөйли:

—«Иген» агропромышленность комплексы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 2002 ел башында гына оешты. Ә инде шактый үзгәрешләр бар. Халык та канәгать. 330 гектарда рапс, зур мәйданда азык бодае үстерәбез. Америка чәчкечләре белән чәчкән идек. Алар бик уңайлы. Бу чәчкечләр берьюлы берничә операция башкара. Үзләре җирне дисклый, тырмалый, чәчә, катоклый, ашлама кертә. Мондый чәчкечләр җирне сукаламыйча чәчәргә мөмкинлек бирә. Җир «Корус-агро»га арендага бирелде. Пайчылар белән килешү төзелде.

Менә ничек! Ә кайберәүләр, җирләребез Мәскәүлеләр кулына китеп баргач, нишләрбез, дип юкка хафалана. «Иген» агропромышленность җәмгыяте тәҗрибәсе шуны күрсәтә: хуҗалык итү һәм милек формасын үзгәртү, инвесторларның булышлыгы—авыл хуҗалыгын кыен хәлдән чыгаруның аеруча ышанычлы һәм нәтиҗәле юлы. Иң әһәмиятлесе—салымнар районда кала. Быел гына башланган бу эшнең ахыры да уңышлы тәгәлләнәчәгенә ышаныч зур. Иген яңа технология буенча үстереләчәк. Юкка гына Америкадан кыйммәтле чәчкечләр алынмаган. Болар барысы да чыгымнар азрак тотылсын, продукция күбрәк җитештерелсен, аның үзкыйммәте кимрәк булсын, дигән нияттән чыгып эшләнә. «Иген» алга таба яхшы токымлы сыерлар алырга да уйлый. Социаль мәсьәләләр дә игътибардан читтә калмаячак.

Әмма әлегә эшләргә кешеләр җитеп бетми. Гомумән, Спас районында кадрлар белән хәл җиңелдән түгел. Язгы кыр эшләре, урып-җыю вакытларында читтән килеп эшлиләр. Ләкин моннан киләчәктә Спас районы авылларында эшләргә кеше калмас, дигән ашыгыч нәтиҗәләр ясарга ярамый. Чөнки алга таба авыл хуҗалыгы җирләре шәхси, хосусый хуҗалыклар, фермерлар кулына күчә барган саен эшче кулларга ул кадәр үк кытлык сизелмәс. Ник дигәндә, хосусый милекчеләр аз көч белән күбрәк эш майтарырга яраталар. Әйтик, белгечлеге буенча агроном Юрий Семушкин элек «Балымерский» совхозына җитәкчелек иткән. Хуҗалыкның икътисади-финанс хәле шактый ук какшый башлаган. Кешеләр күп еллар буена хезмәт хакы ала алмаган. Шуннан соң Юрий Анатольевич җир алып, фермер хуҗалыгы оештырырга карар кыла һәм тәвәккәлли дә. Элеккеге совхоз җиреннән дә күбрәк җир белән эш итә башлый. Күрше авылдан халыкның пай кишәрлекләрен дә куша. Ә эшләүчеләр саны элеккедән күпкә кимрәк кала. Аның каравы, алар, кем әйтмешли, җиргә ябышып ята. Хәзер «Волгарь» фермер-крестьян хуҗалыгы иген үстерә. Лизингка «ДОН-1500» комбайны алып җибәргән. Эш күләме элеккедән берничә тапкыр артык булса да, аз көч белән дә Ю. Семушкин хуҗалыгын уңышлы алып бара. Монда хәзер айлык уртача хезмәт хакы 3500 сум тәшкил итә. Үзләренең тегермәне, пекарнясы бар, аларын да фермер үз акчасына сатып алган. Җитештергән ашлыкны урнаштыруда кыенлыклар килеп чыккач аптырап калмаганнар. Бу заманда ашлыкны очсызга сатып җибәрүдән табыш юк. Ю. Семушкин аны онга әйләндереп, ипи пешереп сатудан күбрәк файда күрә.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Александр Васильевич Выжлов кабинетында район картасы эленеп тора. Анда кайда ничә фермер хуҗалыгы барлыгын чамалап була. Алар 67 икән. Райондагы җирнең яртысына якыны шулар карамагында. «Антонов», «Измерский» авыл хуҗалыгы кооперативлары да хосусый затларга бирелгән. «Танкеевский» совхозы «Шанс» хуҗалыгына әйләнгән. Равил Бакиров бу эшкә кыю тотынган. Ул әле «Полянский» кооперативындагы пай җирләрен дә «электерген». Эшче куллар кимегән, җир мәйданы арткан, шуңа карамастан, бөтен авыл хуҗалыгы эшләрен вакытында һәм җиренә җиткереп башкарып баралар.

Вәгыйз Мөхәммәтов элек «Екатериновский» авыл хуҗалыгы кооперативына җитәкчелек иткән. Шуннан ары эшнең алга китмәслегенә төмам ышангач, ул 500 гектар җир алып, «Сирень» фермер хуҗалыгы оештырган.

Татарстан хөкүмәтенең агропромышленность өлкәсендәге бурычлары мәгълүм: ул республика халкын сыйфатлы, экологик яктан чиста, мөмкин кадәр арзанрак азык-төлек белән тотрыклы тәэмин итеп торудан һәм шул нигездә Татарстан хезмәт ияләренең тормыш дәрәҗәсен күтәрү өчен авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләргә уңайлы шартлар тудырудан гыйбарәт. Алай да республикабыз үз-үзен авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итеп тора, дип тынычланып ятарга да ярамый. Әлегә безне гел сүгелеп килгән шул күмәк хуҗалыклар туйдыра. Алар хуҗалык итүнең нинди генә формасын сайламасыннар, авыл хуҗалыгы предприятиеләрен саклап кала алсак, дәүләт тә ярдәменнән ташламаса, чит-ятлар кузенә карап тормабыз. Әле шәхси хуҗалыклар да авыл хуҗалыгы продукциясенең төрлесен базарга чыгарып тора. Алар да яклауга мохтаҗ. Әгәр дә хөкүмәт үзенең шәхси хуҗалыгын үстерү юлыннан баручы авыл агаена ярдәм күрсәтә икән, авылда, һичшиксез, халыкның тормыш-көнкүреше яхшырачак, кешеләр эш белән тәэмин ителәчәк.

Кайберәүләр уйлаганча, авыл хуҗалыгы—ашлык, бәрәңге, ит, сөт, яшелчә җитештерүче тармак кына түгел, ул—үзенә генә хас гореф-гадәтләре белән шул төбәктә гомер итүче халыкның яшәү рәвеше дә. Шулай булгач, дәүләт, хөкүмәт авыл хуҗалыгын үстерүне өстенлекле юнәлеш дип санын икән, бу шулай булып калырга тиеш. Чөнки бер сорауга бүген-иртәгә җавап бирергә туры киләчәк: безнең ата-бабаларыбыз җирендә киләчәктә кем эшләр? Хәзергә авыл яши, ул яшәсә, ил дә яшәр.

# Лирон Хәмидуллин

## «БӘР, МЫЛТЫГЫМ, БӘР...»

ЭССЕ

Туган авылым Иске Төгәлбуга Татарстан чигеннән егерме чакрым чамасы көньяктарак урнашкан. 1943 елга кадәр Куйбышев өлкәсенә керә, Кошка районына карый иде. Олы Чирмешән буенын «карурманы» безнен авыл очында башлана да Әлки, Нурлат районнары чигенә кадәр дәвам итә. Ике арада урманчыларнын Каракүл исемле кечерәк торак пункты гына бар иде. Нурлат районынын Биккол, Фома авылларына бездән утыз биш, кырык чакрымнар булыр... Авылдашларым элек Нурлаттан чак кына арырак булган Кизләү мәдрәсәсенә муллалыкка укырга йөргәннәр. Хупжамал әбиемнең туганы Закиржан да революция өермәләре башланган чорда шул мәдрәсәдә белем алган. Әмма ана башына чалма урап авыл халкына вәгазь укулар насыйп булмый. Гомере фаҗигале рәвештә өзелә. Китап тотып шәм тирәсендә озаграк утырган чакларымда әбием:

—Шәкертҗан агаң кебек укымышлы булырсын ахрысы,—дип үсендереп куяр иде. Бик дини карчык, авылнын оста мөнәҗәтчесе иде, мәрхүмә. Алтмышынчы еллар башында Габделҗаббар Кандалый китабын укыгач та әбием мөнәҗәтләрен очратып хәйран калган идем...

Иске Төгәлбуга—бик зур авыл. Совет дәвере килгәнче анда жиде йөз унбиш йорт исәпләнгән. Биш мәхәлләле булган. Без үскәндә дә әле берничә мәчет манарасы авыл манзарасын бизәп утыра, тик олы мәчет кенә клубка әверелдерелгән иде. 1939 елда мәшһүр авылдашыбыз Фәйзулла Туишев мәчет рәвеше сакланган шул бинада ике көн төрле гармуннарда уйнап киткән иде. Советча яшәргә иртәрәк жайлашкан күрше Урта Исәнтимер авылы белән чагыштырганда Иске Төгәлбуга динлерәк саналган, район, өлкә житәкчеләре карашынча «кадимче», «кара авыл»лар рәтендә йөртелгән. Мондый караш әле алтмышынчы елларда да үзен сиздерә иде.

Безнен район чикләрендәге төбәкнен төп халкы татар диярлек. Чуаш, мукшылар да анда ишле генә яши. Аерым рус авыллары юк дәрәжәсендә. Алар элекке волость үзәкләрендә һәм тимер юлга мөнәсәбәтле урыннарда гына күмәкләп яшиләр. Гасыр башында төзелгән Сембер—Бөгелмә—Уфа тимер юлы Кошка, Яна Малыклы (икесе дә зур мукшы авыллары) районнарын икегә бүлеп үтә. Иске Төгәлбугадан биш чакрым көнбатыштарак Урта Исәнтимер, аннан арырак Әбдери, Зирәкле Куак, Лабид, Төплистан ише зур-зур авыллар. Алардан чак кына төньяктарак шундый ук зур Өчкаен һәм берничә кечерәк авыл. Көнчыгышта, район үзәкләре Кошка, Нурлатлар тарафында Иске вә Яна Жүрәйләр (хәзер Иске һәм Яна Фәйзулла), Карамалы һәм бер-ике кечерәк авыл. Төньяк тарафта Иске Исәнтимер һәм бер мукшы, бер чуаш авылы аша бездән утыз чакрымдагы Пәрау булыр.

Иске Төгәлбуга тирә-як авыллар арасында «сәнәкчеләр бунты» үзәге буларак та дан алган. 1920 елнын жәй башында яңа оешачак Татарстан Республикасынын картасы басылып чыга. Безнен төбәк авылларынын ул мохтарият чикләренә кертелмәве ачыклана. Гражданнар сугышыннан күкрәкләрендә Кызыл Байрак орденнары балкытып кайткан вәкилләрне авыл жыеннары Самарага юллый. Алар: «Безне Татарстаннан аермагыз! Бездә күпчелекне татар, чуаш, мукшылар тәшкил итә»,—дип, милли жөмһүрияткә керергә хакларын расларга тиеш булалар. Ләкин Самарада халык таләбен үтәргә теләүчеләр табылмый. Яна түрәләр вәкиллек таләбенә «арестовать» дип жавап бирәләр. Шуннан инде авылларда шау-шулар

башлана. Кошка районы комиссарын кулга алып, безнең авылга китереп биклиләр. Аны Самарадан берничә атлы гаскәри белән килгән «баш комиссар» азат итә... Сембердән алып Бөгелмәгә кадәр чик буйлап сузылган татар авыллары, шул рәвешле, мохтарияттан читтә калалар. Алар бүген дә Татарстан канаты астына сыену хыялы белән яшиләр. Татарстан чигеннән кырык-илле чакрымлы бер буйны тәшкил итүче зур бер мәйданда, нигездә, ике кардәш халык—татарлар, чуашлар күпләп яши. Мондагы авыллардан татарның күренекле шәхесләре Габделҗаббар Кандалый, Төгәлбай Галәүтдин, Фәйзулла Туишев, Габдулла Шамуков, Латыйф Җәләй, Ибраһим Нуруллин, Демьян Фәтхи, Сәхаб Урайский, Зыя Ярмәки, Әнвәр Давыдов, Рәшит Шамкай, Рөстәм Мингалимнәр чыккан.

Татар дөньясына мәгълүм шәхесләрдән кемнәр дә булса Иске Төгәлбугада яшәгәнме соң? Дөресен әйтим, авыл тарихы тиешенчә барланмаган. Егерменче елларда туган-үскән жиреннән сөрелгән Хафиз Шәкүревтә нииндидер документларның булганлыгын сөйлиләр. Биләмәсе безнең ызаннан башланган бер рус алпавыты белән жиргә кагылышлы бәхәсләрдә шуларга таянганнар. Шул ук кешедә борынгы бер китаптан күчермә дә булган, имеш. Ике гасыр чамасы элек немец фамилияле бер сәяхәтче авылда кунган һәм соңыннан истәлегендә шул хакта язып чыккан икән. Аның күчермәсе дә әлеге Хафиз байда булган. Тарихчы галим Җәмил ага Гыйльманов та андый фактны раслаган иде. Ул сәяхәтнамәне табарга дип тә вәгъдәләшкән идек. Ләкин Бөек Ватан сугышына багышланган «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» китабын минем тәржемәдә чыгаруга ул үзе арабыздан китеп барды...

Утызынчы еллар урталарында Нәкый ага Исәнбәт Татарстан чигеннән көньяктарак урнашкан татар авылларында халык ижаты жәүһәрләрен туплап йөри. «Туган авыл хатирәләре» дәфтәремә аның әйткәннәрен язып куйганмын: «Авыл картларыннан күп нәрсә язып алган. Соңыннан архивта эшләгәндә дә ана Гаделша, Гобәйдулла исемле Иске Төгәлбуга кешеләре күчереп язган кульязмалар очраган. Төгәлбай Галәүтдин исеме белән узган гасырда ижат иткән шагыйрьнең дә безнең авыл кешесе булуы ихтимал», дигәнмен.

Төгәлбай Галәүтдиннең «Мәгъшукнамә» исемле шигырь җыентыгы 1880 елларда Казанда ике мәртәбә басылган. Дөрес, аны тәгаен безнең авыл кешеседер дип расламыйм. Шул ук төбәктә Татар Төгәлбае авылы да бар. Элек алар икесе дә Самара губернасына караганнар. Унсигезенче йөзнең беренче яртысында нигезләнгән сиксән-туксан йортлы ул авыл хәзер Татарстанның Әлки районы Кошки авыл советына керә. Алтмышынчы елларда шундагы мәктәп мөдире белән очрашып сөйләшкәнем булды. Ул исә үз авылларының көньяктарак урнашкан шул исемдәге бер «карья»дан күчкән булуын бәян итте. «Тәгаен Иске Төгәлбайдан булу-булмавын картлар белергә тиеш»,—диде. Нишләптер ул якларга барып чыгылмады.

Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишев—тумышы белән безнең авылдан. Ана унбер яшьләр булганда Кәбир абый гаиләсе Олы Чирмешән буенча кырык чакрым түбәндәрәк урнашкан Мәләкәс шәһәренә күчеп китә. Гореф-гадәт кушканча, төп йортта энесе Туктаров Хөснетдин кала. Аның варисларыннан кайберәүләр әле исән. 1941 елда туган Туктаров Дамирның хәзер Арчада яшәвен әйттеләр. Күрше авылда Кәбир аганың кыз туганы варислары да бар бугай.

Мәгълүм тарихчы Җәмил Гыйльманов та жиде яшьтән Иске Төгәлбугада тәрбияләнә. Аның әтисе, Тәплистан авылы хәлфәләре нәселеннән чыккан Ибраһим абый бездә бик абруйлы укытучы иде, чирек гасыр дәвамында мәктәпнең укыту бүлеге мөдире булды. Кайчандыр миңа исем сайлашуда Баян апа белән Ибраһим аганың да катнашуын әйтәләр иде. Сугыш алды елларында ук мәктәп каршында балаларга һөнәри белем үзләштерү түгәрәген оештырган кеше. Без анда агачтан чана, арбалар, авыл очындагы кизләү ярыннан алынган йомшак балчыктан курчак, сыбызгылар әмәлләп маташкан була идек. Зуррак малайлар исә тәгәрмәчле тракторлар, жилгә каршы куйсаң канатлары шыгырдап әйләнә торган тегермәннәр ясап, бездәй бала-чаганы үз тирәләренә жәлеп итәрләр иде.

Ул яна мәктәптә миңа ике кыш та ике ай гына укырга насыйп булды. Соңрак гомер буена андагы укытучыларны сагынып яшәдем. Ул мәктәпне бүген дә үрнәк итеп алырлык. Анда башлангыч класслар өчен аерым бина, аерым ишегалды. Өлкән класстагыларга ясалган ишегалды белән ике арада тәбәнәк

койма: тәнәфестәге уеннар аерым-аерым уздырыла. Кизү торучы укытучылар ул уеннарны оештырып җибәрәләр. Дөрес, әтиләр яшәгән Урта Исәнтимер авылы мәктәбе дә һәрчак мактаулы булды. Сугышка хәтле үк анда «хәзерлек» сәгатьләре кертелгән иде. Дәрестән соң, колхоз исәбенә җинелчә тамак ялгап алгач, балалар шунда ук өйгә бирелгән эшләрне кизү укытучы күзәтүендә башкаралар. Урамга чыгып күмәкләп уйнап та алалар иде. Олы Чирмешән борылышына сыенып үк утырган Иске Исәнтимер балалары да Урта Исәнтимергә йөреп укыдылар. (Үзләрендә башлангыч класслар гына булгандыр, күрәсең.) Кичке якта аларны алып кайтырга дип берничә атлы килә. Алмачуар көр атлар җигелгән арба-чаналарда заманча рухлы җырлар җырлап үткән ул яшьләр артыннан сокланып карап калмыйча мөмкин булмагандыр. Үкенеч ки, сугыш афәте ул яшьләрнең күбесенең гомерен пыран-заран китереп ташлады. Алмачуар атларда «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр!» җырын яңгыратып җырлап үткән яшь җилкенчәк тиздән чын мылтык тотып утка керде, шул ут өермәсе эчендә янып-үлеп, арабыздан китеп барды. Туган җиремдә, туган авылымда исән-сау калганнарының да тормышы, тормышка булган мөнәсәбәте нык үзгәрде. «Бу Рәсәйдә көр тормыш корып булмый. Алда безне җүнле язмыш көтми»,— дигәндәйрәк уй-фикерләр кеше күнеленә һаман тирәнрәк сенә барды. Җинү байракларына ияреп кайткан аракыга табыну гадәте дә көннән-көн күбрәк корбаннар җыйды. Сугыш алды балалары күреп калган көр атлар, җитешлеккә ирешеп килүче колхозлар, таза-аек яшәешле, аек фикерле, киләчәккә өмет белән караучы ир-атлар авылда көннән-көн кими барды. Ул заманнарда һәр авыл карты иман сагында торыр, һәркемгә үрнәк булырга тырышыр, балаларга шул рухта йогынты ясауны изге бурыч итеп санар иде. Кем баласын очратса да: «Һәрвакыт шулай тәртипле бул, балам. Намусың сакла»,—дип җылы сүз әйтеп, күнелен үсендереп китәр иде. Бик үк тәртипле дә, намуслы да булмаган бүгенге заман картларының күпчелеге хәзер үз баласына да җылы тәрбия сүзен әйтә алмый шул...

Авылымның мулла-мәзиннәре, байлары-кулаклары хакында да берничә сүз әйтеп үтим. Без үскәндә инде алар кыерсытылган, юашландырылган яисә чит-ят җирләргә озатылган иде. Урта хәлле крәстиян Хәмидулла бабамның нәселе— Шәкүрев, Туктаров фамилияләрен йөртүче «зур кулаклар» да шундый язмышка дучар ителде. Иске Төгәлбуганың ике мәхәллә имамы Пәраудагы ишан нәселеннән булган. Әнисеннән яшьли ятим калып, ишан йортында тәрбияләнгән Хупҗамал әбиемә ботак очы кардәш тиешле иделәр. Курай урамы мулласы Әхмәтҗанны әбием аеруча үз итә, якын күрә иде. Манарасы җитмешенче елларда гына киселгән шул мәчет мулласының язмышы да аяныч. Утыз тугызынчы елда сөргеннән кайткач аның ишле гаиләсен авылга кертмиләр. Алар өч землянка казып авыл читендә яшәделәр. Шул җәйдә әбием авылдан читтәге Сыза кизләвенә суга йөрергә һәвәсләнеп китте. Чөнки чишмә сукмагы әлеге землянкалар янәшәсеннән үтә. Чиләк төпләренә сөт-катык, ипи, йомыркаише әйберләрен сала да, өсләрен әрекмән яфрагы белән томалап, чишмә суына дип бара. Мин дә ана ияреп. (Җәй айларында авылда без икәү генә яшәдек.) Чиләктәге күчтәнәчләрне бушатып, ике-өч авыз сүз алышуга без Сыза ярыннан төшеп тә китәбез. Сөргеннән кайтучылар белән озак аралашырга ярамый. Бервакыт мулла бабайның: «Бик еш йөрмә, улына зыяны булмасын»,—дип әйткәнен хәтерлим. Элекке муллалар өендә, мәктәп-мәдрәсә биналарында фельдшерлек пункты, китапханә, балалар бакчасы яки «бригада йортлары» урнашкан иде. Авыл очындагы кирпеч заводы кайсы «кулак»ныкы булгандыр, сорашмаганмын. Аның иркен биләмәсе, Чирмешән буеннан китерелгән аксыл ком өемнәре, кирпеч киптерә торган озын-озын ачык сарайлары, янәшәсендәге тирән күле бала-чаганың иң яратып уйный торган урыны булгандыр, мөгаен. Көн-төн ут бөркеп торучы дәү мич янына гына безне якын җибәрмәсләр иде. Сугыштан соң бер кайтуымда ул тирәләрнең ташландык хәлгә килгәнлеген күреп күнелем сыкрады. Кирпеч тә бит авыл кешесенә бик кирәк. Элек аны бездән күрше авыл халкы да олау-олау ташып торыр иде.

Сугыш алды елларында еш җырлана торган бер җыр бар иде. Аның аеруча басым ясап кабатлана торган ике юлы гына хәтеремдә калган:

> Бәр, мылтыгым, бәр, бәр,
> Явыз дошман йөрәгенә утынны җибәр...

Мен тугыз йөз кырык, кырык беренче елларның җәй айлары. Туган авылымда

да, ара-тирә барып чыгылган Урта Исәнтимердә дә, ир-ат еш кына авыл читендәге мәйданга җыела. Анда алар аркаларына биштәрләр асып йөгерешә, сикерешәләр. Аннары биштәрләрен казыкка элеп куялар да, йөгереп килеп шуна таяк-мылтыкларын калаган булалар. Раз, два.. раз... када!... Шундый әмерләр биреп торучылар авыл түрәләре, укытучылар. Алар арасында Гаяз абый Зәйнуллов та бар. Әтигә туганнан-туган тиешле, ыспай хәрби киемнәр киеп шул язда гына хәрби хезмәттән кайткан кече командир. Авыл халкы шулай хәрби хәзерлек курсларын үтә. Байтак вакытлардан соң Гаяз абый: «Ул елларда хәрби хәзерлек үтәргә дүртәр йөз сәгать билгеләнде»,—дип әйткән иде. Икенче герман сугышына хәзерлеккә менә ни дәрәҗәдә әһәмият бирелгән булган икән! Уеннар беткәч тә ир-егетләр сафка тезелеп әлеге мәйдан тирәли бер-ике мәртәбә әйләнәләр. Яки «раз, два» әмеренә атлап бер урында таптанып торалар. Кемдер: «Җыр башла!»—дип боера. Йокыга талып баручы авыл өстендә «Бәр, мылтыгым, бәр!..» яки шуна тартым берәр заманча рус җыры авазлары янгырап калыр иде.

Ә кайбер көннәрдә иртән безне самолет гөрелтесе, аларның атышу тавышлары йокыдан уята. Дөрес, мотор гөрелтеләре, ату авазлары бик тонык—суга таш аткандагы кебек «палт-полт» итеп кенә ишетелә, шуңа күрә олылар аңа игътибар да итми шикелле. Ә безнең өчен ул бер зур тамаша: тавык кыткылдаган, абзарга бәйләнгән бозаулар мөгрәгән өй тирәләреннән ераккарак китәбез дә, чирәмгә чалкан ятып, һавада барган хәрби уеннарны күзәтергә керешәбез. Зәңгәр күк йөзендәге аксыл болыт кисәкләре арасында бөтерелгән «ераплан»нарның кызыл йолдыз сурәтләре ап-ачык күренеп тора. Гадәттә ул очкычларның берсенең «коерыгына» көмештәй ак түшле «вагон» тагылган була. Ак түшен кояш нурында йолк-йолк уйната-уйната ул «вагон» анда-монда талпынып очкан арада башка аэропланнар чиратлашып аны куып житәләр дә, «полт-палт» китереп шуңа ата башлыйлар. Кайбер көннәрдә андый атышлар кичкә кадәр кабатлана иде. Бер төркеме авыл өстеннән китеп өлгерми, күк йөзендә башка очкычлар пәйда була.

Дамир дустымның әтисе, укытучы Нур абый, авыл яшьләренең хәрби уеннарын оештыручылардан берсе:

—Очучылар Ворошиловча төз атарга өйрәнәләр. Алгы очкычка тагылган зур куык мишень була,—дип аңлатып бирер иде.

Безнең авыллар өстендә сугыш күнегүләрен үзләштерүче ул өйрәнчек очучылар кай тарафтан булганнардыр. Хәрби очучыларны Казанда да, Куйбышев һәм Ульянов шәһәрләрендә дә укыталар иде бит. Соңгы ике шәһәр безгә якынрак: икесенә дә төгәл йөз егерме чакрым дип сөйлиләр иде олылар... Сугыш башланган елның кышында ике канатлы шундый бер очкыч, бала-чаганы сөендереп, авыл очындагы «төзем»гә дә «егылып» төшкән иде. Ерактан ярдәм килеп өлгергәнче, авыл халкы кардан арындырган мәйданчыкта талпынгалаганнан соң, ул кабат күтәрелеп китә алды.

Бала чакта күрелгән «һава сугышлары» хатирәсен янарткан бер вакыйгага 1984 елның август азакларында тап булдым. Татарстанның Нурлат районы «Игенчеләр» колхозында урып-җыю эшләре белән танышып йөрибез. Колхоз рәисе Сәлим ага Гафуров, аның урынбасары һәм мин ерак кырдан кайтып килешли зур буа буенда тукталдык. Фома авылыннан ерак түгел бер урында. (Исем-атамасы ятрак булып ишетелсә дә, мөселман динле татарлар яшәгән мәчетле авыл ул.) Тирә-юньдә тынлык. Көн буена тамак төбенә утырган тузан катламын юып төшерерлек йомшак һава. Аяз күктә бихисап йолдызлар җемелдәшә. Офык читендә генә ай күренә. Һавада янарак урылган камыл исе... Һәм иң гаҗәбе—балачактан таныш әчкелтем-төчкелтем кычыткан исе аңкый. Әйе, балачакны искә төшергән, күңелгә якын бу татлы ис борынны ярып керә. Коры һавалы дала якка тартым бу төбәк авыллары өчен уртак бер билге ул.

Шул рәхәткә чумып, онытылып күктәге йолдызларга карап торам. Җете зәңгәр нур бөркеп балкыган ике йолдыз кинәт кенә бер-берсенә якыная башлады. Каяндыр өченчесе дә килеп чыкты. Болар күктә бердәй тигез кырлы өчпочмак хасил иттеләр, бераз торгач тагын да якыная төштеләр, аннары бер сызыкка тезелделәр дә бераздан зур тизлектә өчесе өч якка атылдылар. Аңлашылды ки, болары инде Ходай Тәгалә кодрәте белән барлыкка китерелгән күк җисемнәре түгел, нинди дер тиз йөрешле яна төр очкычлар иде. Юлдашларым да алар очышын күзәткән икән.

—Төнге күктә алар шулай әледән-әле күренәләр... Сугыш уеннары уйныйлардыр инде,—дип куйды Сәлим ага. Аннары сугыш чорында үзе күргәннәрне сөйләп алды. Ул да «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр...» җырын җырлап тәрбияләнгән буын кешесе. Унжиде яшеннән иненә чын мылтык аскан солдат...

Тып-тын тирәлек һәм... сугыш уеннары. Ерак басуда комбайннар иген ура, авыл халкы тыныч кына көнкүреш мәшәкатьләре белән шөгыльләнә. Ә кемнәрдер шул вакытта тыныч халык өстенә ничек бомба ташлау һәм аларны күпләп юк итү хәстәрен күрә...

Әйе, элек-электән Рәсәй түрәләренең иң яраткан шөгыле сугышка әзерләнү булган. Рәсәй патшалары һәрвакыт хәрби кием киенеп йөргән. Ходай Тәгалә бүләк иткән һәр көннең бер өлешен махсус плац-мәйданнарда хәрби уеннар уйнап уздырган. Совет хакимияте вәкилләренең дә яратып кигән киемнәре хәрби френч, галифе булды. Сугыштан соңгы җитәкчеләребезнең күпчелеге генераллар иде.

Туган авылымны кабат күз алдына китерәм. Бөек Ватан сугышына чаклы ук анда бер кулсыз, бер аяксыз кешеләр байтак иде. Яу кырында тән җәрәхәте алып та, җәрәхәтләре күзгә бәрелеп тормаучылар күпме булгандыр?! Без таяк «атларга» атланып, таяк «кылычлар»ыбызны болгап «Чапай» булып уйнаганда олыларның капылт кына: «Эх, балалар, белмисез шул әле сез сугышны!»—дип әйтеп куюлары гына күнелгә сенеп калган.

Безгә фамилия бүләк иткән Хәмидулла бабабызның өч улы, бер кызы үскән. Улларының өчесе дә—сугыш афәтен кичергән кешеләр. Иң олысы Шакирҗан «действительный» хезмәтне тутырып кайтам дигәндә генә рус-япон сугышы башлана. Яу кырына ук барып җитмәсә дә, төрле михнәтләр күреп, җиде елга якын иңендә солдат киемен йөртә. Шул михнәт чигүләр нәтиҗәседер инде, илле яшьтән чак кына ашып, 1934 елда үз өендә капылт кына вафат була. Кечеләре Әхмәтҗан Гражданнар сугышында катнаша. Кайларда һәм ничек сугышканын олылардан белешеп калмаганмын. Хәер, ул картны яхшы хәтерлим. Барлык төс-кыяфәте белән әбием аны Нурыйҗан бабама охшата иде. Уртача төз буйлы, аксыл йөзле, аксыл сары чәчле. Бик каушамый гына эшли, җай-сабыр гына сөйләшә иде. Ул төп йортта калган, Искавыл очында, олы урамда яши. Ә безнең өй янәшә зур урамда иде. Авылның калган урамнары безнекеләр кебек үк өчәр чакрымга сузылган булсалар да, йә өзек (Янавыл белән ике арадагы иске зират бүлеп тора), яки тулы түгел, шунлыктан Сынар канат дип йөртеләләр иде. Күрше урамдагы Әхмәтҗан бабайларга йомышка күп йөрдем: мал чаласы булса да, йорт эшен башкарырга ир-ат кулы кирәккәндә дә әби мине аларга йөгертә иде.

Арада Нурыйҗан бабам—иң бәхетлесе дә, иң фаҗигале язмышлысы да. Шуңа ул бәхетле: дүрт бала белән ятим калган Фәтхия әби фәкать ана гына авылның кечерәк мәдрәсәсен тәмамларга мөмкинлек бирә. Үзе дә укуга, белемгә хиресрәк кеше булгандыр, күрәсең. Үзлегеннән русча сөйләргә һәм беркадәр рус язуын танырга өйрәнгән. Шунлыктан атасының хәллерәк ага-братлары кыш айларында аны үзләре белән базар-ярминкәләргә йөртә торган булганнар. Өйләнеп, үз йортын торгызганчы, Туктар байның «кече ызбасы»нда әби белән бер-ике кыш яшәгәнлекләре мәгълүм. Атлар яраткан. Бер эш, бер юртак аты булган. Урта хәлләләр исәбендә йөргән. Яшен тәгаен белмим. Әтинең сеңлесе әйтүенчә, әбидән ике-өч яшькә олы булган. Ә Хупҗамал әбиемнең «метрика»сын 1943 елның августында Пәрауга үзем барып алыштым—ул 1879 елда туган.

Нурыйҗан бабам ике зур сугышта катнаша, икесеннән дә исән чыга. Беренче Бөтендөнья сугышына 1915 елда алына, 1917 елның көзендә унбер иптәше белән авылга кайта. Мылтык, кылычлары белән кайттылар, дип сөйли иде әби. Шул кышта ук Гражданнар сугышына алына, 1920 елга чаклы кай тарафлардадыр сугышып йөри. Шуннан кайткач үзен авыл түрәлегенә дә кыстыйлар, ризалык бирми. Әби дә, туганнары да каршы булган шикелле. Шуннан соң аны авылдан билгеләнгән артельгә баш итеп Сембер—Бөгелмә тимер юлын төзекләндерү эшенә билгелиләр. Атна саен аннан мунча керергә кайтып йөриләр. Гаиләгә әз-мәз ризык кайтарып торалар. 1921 елның апрель башында шуннан кайтышлый вафат була. Ачлыкның һәм ваба чиренең көчәйгән вакыты. Иптәшләре әйтүенчә, биштәрендә ун калак ярмасы һәм ипие булган. Әбигә аларын кайтарып бирмәгәннәр.

Әтием Хәйдәрҗан һәм сеңлесенең ире Шакирҗан—иң аяныч язмыш ияләре.

Аларның икесен дә бер чордарак, мина ике яшь булганда, ике еллык хәрби хезмәткә алалар. (Ул заманда егетләр армиягә егерме ике яшьтә китә). Өч ел читтә укып йөргән әти шактый соңлап, егерме алты яшьтә генә хезмәт итә башлый. Фин сугышына да беркадәр соңлабрак алына. Алар эшелоны Ленинград янына житкәндә ул сугыш язмышы хәл ителгән була инде. Шулай да тиз генә кайтарып жибәрмиләр үзләрен. Ә Шакир жизни Алиев һәм аның яшьтәшләре бу сугышның башыннан ахырына кадәр катнаша. Барлык михнәтләрдән, шул исәптән әсирлектән котылып өенә кайта алган кордашы һәм авылдашы Миңлегали абый Әхмәтов үз башларыннан кичкән хәлләрне болайрак сөйләгән иде. Яу кырында алар ротасы ике мәртәбә бик хәтәр хәлдә калган. Соңгы мәртәбәсендә бер атна чамасы чолганышта сугышканнар, байтак кына иптәшләре шунда ятып калган. Шакир жизнинең дә беләге жиңелчә яраланган булган. Финнәр белән килешү төзелгәч тә никтер алар дивизиясен тиз генә кайтарып жибәрмәгәннәр. «Сугышны мартта тәмамладык, безне уракка төшәр алдыннан, июньдә азат иттеләр»,—дигән иде әңгәмәдәшем.

Ульянов шәһәренә дивизияләре белән кайталар. Бер ел үтмәстән, 1941 елның апрель аенда, авылдан унике кешене, шул исәптән жизнине «кырык көнлек хәрби хәзерлек жыенына» дип алып китәләр. Барысы да 1912—1914 елларда туганнар. Кырык көннән соң аларны алыштырырга тиеш булалар. Миңлегали абый хатирәләренең дәвамы мондый: «Июньнең егермеләреннән соң без үзебезнең 154 нче дивизиягә барырга тиеш идек. Сборга барысы да әзер—сохари киптерелгән, башка кирәк нәстә биштәргә салып куелган. Чакыру көнен көтәбез. Атна башыннан да соңга калдырмаслар шикелле иде. Базар көнне яңа хәбәр килә, сугыш башланган! Егерме өчендә кичке якта без инде дивизиядә идек. Башкаларны элеккечә пехотага билгеләделәр. Берничә кешене бер майор, үгетләп, үзенә алып китте. «Кем ат ярата, алга чыгыгыз»,—диде. Мин буйсындым. Шулай итеп 77 нче тупчы полкка ездовой булып элэктем: инендә авыр мылтык урынына карабин, ерак юлга чыкканда ат өстендә барасың. Барысы да әйбәт кебек, тик авылдашларның күбесеннән аерылу гына борчый иде. Июль урталарында Днепр аръягындагы Жлобин шәһәрен немецлардан азат итәргә боерык алдык. Безнең дивизионнарны укчы полкларга беркеттеләр, һөжүмгә бергә бардык. Билгеләнгән шәһәрне, берничә авылны азат иттек. Шуннан соң инде немец зур һөжүм башлады. Чолганышта калгач та берничә атна сугыштык. Барлык полкларны берләштереп, бер иттеләр. Чынлыкта бер батальоннан кимрәк булганбыздыр. Командирыбыз бер татар. Батталов фамилияле. Исән калган авылдашлар белән тагын шунда очраштык. Шакир жизнәң дә анда иде, шуннан соң инде аерылышмадык... 13 октябрьдә безне әсир иттеләр. Лагерьда тагын бер авылдашны—Гомәр Вәлиуллинны очраттык. Ул да, мин дә жиңелчә яралы. Жизнәннең аягы без очрашканчы ук яраланган иде. Лагерьдан лагерьга йөри-йөри бөтенләй аякка баса алмас хәлдә калды. Без аны Бобруйскидан башлап култыклап йөрттек. Варшава янәшәсендәге лагерьда ашаудан баш тартты, паекларын безгә бирә башлады. «Исән-сау илгә кайтсагыз, балаларымны багышыгыз»,—дип ялварды. Хәлдән килгәнчә булышуымны беләсең».

Татарстанда һәм ана чиктәш Ульянов өлкәсендә оешкан дивизияләрне берләштергән армиянең бу контрһөжүменә зур әһәмият бирелү, безнең якташларның яу кырында исәпсез-сансыз кырылуы исәбенә дошманның һөжүме күпме вакыткадыр тоткарлану хакында соңыннан маршал Г. К. Жуков китабыннан укып белдем. «Генерал Ф. И. Кузнецов командалык иткән 21 нче армия 13 июль таңында Днепр елгасын кичте, Рогачев һәм Жлобин шәһәрләрен яулап алды... Нәтижәдә немецларның сигез дивизиясе шул тирәдә тоткарланды. Ул дәвердә безнең өчен аның әһәмияте бик тә зур иде», диелгән анда.

Шул нәтижәгә ирешү өчен кан койган, башын салган дистә меңнәрчә сугышчы, аларның гаиләсе язмышы гына, галәттәгечә, игътибардан читтә кала килде. Сугышта алган ярасыннан 1943 ел башында Варшава янәшәсендәге әсирләр лагерында вафат булган Шакир Алиев язмышы да мона дәлил була ала. «Билгесез югалган» мөһере сугылган сугышчының ятим калган өч баласы, хатыны хакимият житәкчеләренең шикле карашын тоеп яшәргә мәжбүр ителде. Аларга дәүләттән берниндн дә ярдәм булмады диярлек. Билгесез югалучының әсирлектә үлеп калуын, туган авылында шуны раслардай шаһитлар барлыгын белдереп 1972 елда

ук Яна Малыклы районы хәрби комиссариатына хәбәр иткән идем. Сиксәненче елларда шундый ук хатны Затия апа да илтеп бирде. Үлеменә сәбәп булган каты яраны яу кырында алган сугышчыны соңгы көннәргә кадәр качкыннар исәбендә йөрттеләр. «Хәтер» китабына да исемен, авылдашларыннан һәм яудашларыннан аерып, өстәмә томга гына урнаштырганнар. Ә бит андый язмышка дучар булганнар бер Шакир Алиев һәм аның гаиләсе генә түгел!

Бөек Ватан сугышы һәм ана бәйле вакыйгалар безнең буын кешеләре күңелендә мәңге сакланачак, онытылмаячак. Сугыш башланган көннән, сигез яшемнән, мин дә төрле михнәт һәм кимсенүләр кичердем. Чөнки ятим калган өч баланың иң өлкәне мин булдым. Кулыма әлифба китабы тотып, беренче сыйныфка укырга кергән көннәремдә инде әтием ябырылып килгән дошман явыннан Ленинград шәһәрен сакларга керешкән була. Аларның 885 нче тупчы полкы шәһәр оборонасының иң хәтәр бер урынында, атаклы Киров исемендәге заводка килү юнәлешендә дошманга каршы тора. Шул көзнең 17 сентябрендә язган хаты сакланып калган. Шакмаклы дәфтәр битенең ике ягына ашыгып язылган юллар. «Сездән әлегә бер хәбәр дә ала алганым юк, ничек яшисез?» дип борчылган. «Игеннәр, бәрәңгеләр уңдымы, җыеп ала алдыгызмы?» дип сораган.

Сакланган икенче хаты 1942 елның 11 июлендә язылган. Яраланып, Ленинградтагы госпитальдә дәваланганнан соң, кабат хәрби частькә билгеләнгәч җибәргән беренче хәбәре. Хәзер мина «п/п 699 адресы белән языгыз, 3 нче дивизиянең 14 нче гвардейский полкына эләктем, авылдашлардан аерылдым» дигән. «Җаным, синнән биш ай хат алганым юк, сезнең өчен бик тә борчылам» дип ике урында кабатлаган. Хәтеремдә әле, аның госпитальдә ятканда язган хатлары да бар иде. (Өч мәртәбә яраланды. Соңгысында, 1943 елның башында, озак кына Череповец шәһәре госпиталендә дәваланды. Аннан җибәргән соңгы фотосурәте минем кулда.) Ленинград госпиталеннән җибәрелгән хатының берсендә әни белән әбигә иң вак бәрәңгене дә исраф итмичә, кышка сакларга кушылган иде. Ул кинаяшнең Ленинградтагы галәмәт ачлык чагылышы булганлыгын без бик соңлап аңладык, билгеле.

Әйе, Хәмидуллин Хәйдәрҗан Нурыйҗан улының яу кырыннан җибәргән хәбәрләренең байтагы безгә килеп ирешкән. Ә әнинең күз яшьләрен түгә-түгә язган хатларының күпчелеге исә 1941 елның 8 сентябреннән чолганышта булган Ленинград хәрабәләре арасындагы окопларга барып җитә алмаган икән. Хәрби җитәкчеләр ул авыр көннәрдә бәлки тонналап җыелган хатлар урынына чолганыштагыларга берничә тонна өстәмә ризык яки корал илтүне өстенрәк күргәннәрдер.

Әтине авылдан 7 август иртәсендә озатып калуыбызны яхшы хәтерлим. Егерме чакрымдагы район үзәгенә алар берничә олауга төялеп чыгып киттеләр. Әти белән әни утырган җинел тарантас артына тотынып мин дә авыл очына җиткәнче бардым. Аннары әле башка озатучы малайлар белән бергәләп күрше авыл ызанына чаклы чабып баруыбыз да хәтеремдә саклана.

Мөбәрәк энем шул көзнең иң хәтәр көннәрендә—Мәскәүгә дә чолганыш янаган бер вакытта—1941 елның 5 ноябрендә дөньяга килде. Ул иртәдә мин мәктәпкә чыгып киткәндә әнинең эшкә бармыйча ятып калуы бик гаҗәпләндергән иде. Сабыр гына кар сибәләп торган көн уртасында укудан кайтсам—«үә-үә» килгән аваз каршы алды үземне. Сабыйның аяк табаннарын, тырпайтып куелган кул чугын кәгазь битенә төшереп, әтигә җибәреләсе хатлар эченә сала идем. Янәшәдә утырган Хупҗамал әбием дә, сабый башын сыпыргалап, үз сүзен белдергәләп куяр иде: «Яз, килен, кече улымның чәче Нурыйҗан бабасыныкы кебек салам төсендә, диен. Көлгәндә дә бабасы чалымнары сизелә, дип яз». Менә шул хатларның күбесе әти кулына барып ирешмәгән, кайлардадыр аунап, югалып калган икән.

Әтинең хатлары күп иде. Зур бер өлешен без—бала-чага—югалтып, ерткалап бетергәнбездер, күрәсең. Әнинең туган якларына, Оренбург өлкәсенә кайткач, ике гаилә бергә кушылып яшәдек. Әнинең җизнәсе дә сугышның беренче елында ук—каты сугышлар барган Смоленск тирәсендә билгесез югалган иде. Ике яшь ана, бер ояга биш баланы сыйдырып, унөч ел буе бергә яшәделәр. Балаларның иң олысы мин идем. Менә шуннан соң атамның ике-өч хаты сакланып калу гаҗәп тоелырга мөмкин.

Цензура тикшерүен белгәнгәме, әллә башка сәбәптәнме—әтинең сугыш

хәлләренә кагылышлы бер генә җөмлә дә язмаганлыгын хәтерлим. Элек зур бер колхозда баш хисапчының уң кулы булган әнигә яңа урында андый эш табылмады. Унике чакрымдагы рус авылыннан почта кайтару һәм өләшү эшенә алынды. Хат алучылар күп очракта аны укып биргне дә үтенәләр иде. Кайбер хатларда кара тушь белән буялган өлешләр күп була. Әтием хатларында андый таплар бик сирәк иде. Сак кеше булгангадыр инде, сугыш хәлләрен бер дә иркенләп язмады, мәрхүм. Кайларда, кем булып сугышуын да хәбәр итмәде. Очраклы рәвештә алар сугышка Гаяз абый белән бер көндә алынганнар икән. Аерым хәрби берәмлекләргә бүленер алдыннан тупчы старшина Гаяз Зәйнуллов авылдашларына әйткән: «Үзегезне тупчы дип танытыгыз, бергә булырбыз»,—дип. Шул рәвешле әти тупчы булып киткән.

Гаяз абый 1941 елның декабрендә каты яралана, өч-дүрт ай госпитальдә ятканнан соң аны ялга җибәрәләр. Ул килеп сөйләгәч кенә без әтинең хәләхвәлен беркадәр күзаллаган идек. Бер вакыйга бик хәтергә сеңеп калган.

Бабай вафат булгач, 1921 елның җәй башында, аның туганнары унөч яшьлек әтине үзебезнең яктагы бер немец хуторына көтүчелеккә яллыйлар. Шул рәвешле дүрт кешелек гаиләне ачлык афәтеннән коткаралар. Авылдан егерме чакрымдагы ул хуторда әти ике җәй бозау көтүе көтә. Шунда немец телен дә беркадәр үзләштергән була.



*Лирон Хәмидуллин үзенең җәмәгате Дания ханым һәм улы Булат, кызы Зөһрә, оныклары белән. 2001 ел.*

Гаяз абый сөйли: «Немецча әз-мәз белүчеләрне җыеп дошман телына озата башладылар. Йөкләнгән бурычны үтәгәч үзебезгә кайтырга тиеш булсалар да, берсе дә кире кайтмый диярлек. Шулвакыт абый миңа әйтә: дошман телен төшенгәнне берәүгә дә белгертмә. Авылдашларга да әйтеп куй, ди. Абый батарея командиры карамагында элемтәче иде, җае чыккан саен безнең блиндажга килеп, хәл белеп киткәләр иде».

1943 елда Ленинград блокадасын өзү омтылышы ике мәртәбә кабатлана. Кышкы зур һөҗүм барышында әти яралана, бер ай чамасы Череповецта дәвалана. Ә июль аенда Ленинград һәм Волхов фронтларының божра эченнән һәм тышыннан алып барылган зур һөҗүмнәре вакытында яу кырында ятып кала. Безгә җибәрелгән белешмәдә: «1943 елның 23 июлендә батырларча сугышып һәлак булды. Синявино биеклеге, 6 нчы поселок янында җирләнде», диелгән иде. Хәзер ул бистә Ленинград өлкәсенең Киров шәһәре биләмәсенә керә. Әтинең кыш уртасында тууын исәпкә алганда—ана әле утыз биш яшь тә тулмаган була. Ә Шакир җизнигә утыз яшь Варшава концлагерында вакытта тула. Шул гомер аралыгында алар өчәр мәртәбә солдат булырга һәм икешәр мәртәбә яу-сугышларда катнашырга өлгерәләр...

Әйе, алар язмышы илнең: «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр» җыры рухында яшәү дәверенә туры килде. Хәмидулла бабам токымыннан ул сугышта катнашучылардан берәү дә иленә әйләнеп кайтмады. «Хәтер» китабының Иске Тәгәлбуга авылына багышланган битләрендә соңгы зур сугышта һәлак булган өч Хәмидуллин теркәлгән. Ә Урта Азиядән сугышка алынган һәм башка меңнәрчә сугышчы кебек үк яу кырында эзсез югалган Хәмидуллин Әхмәтгәрәй Шакирҗан улы исә ул хәтер китабына да кертелмәгән...

## РЕДАКЦИЯДӘН.

**Танылган тәрҗемәче һәм язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Лирон ага Хәмидуллинга бу айда 70 яшь тула. Шул уңайдан аны кайнар котлыйбыз һәм иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез.**

*Тел дәрьясы тирәндер*

**Флера Сафиуллина,**

*филология фәннәре докторы, профессор*

# ХӘЗЕРГЕ ӘДӘБИ ТЕЛЕБЕЗ ҮСЕШЕ

Соңгы елларда үзенең олпат әдипләре—күп еллар мәйдан тоткан көчләре - мәңгелеккә китеп баргач, татар әдәбияты ятимләнеп калган иде... Әйе, Г. Бәширов, Ә. Еники, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев зур әдәби мирас, тирән эз калдырып киттеләр. Андый сүз осталары үсеп-өлгереп җиткәнче, күп еллар үтәр әле...

Әмма әдәбиятта бушлык булмый, әкренләп яңа шәхесләр, яңа көчләр аякка баса. Алар арасыннан милләтебезнең, әдәбиятыбызның йөзек кашы булырдай әдипләр, шагыйрьләр үсеп чыгасына ышанасы килә...

Татар әдәби теленең хәрәкәте, яңалыгы, яшәүчән көче матур әдәбиятның төрле жанрларында чагыла. Проза жанры исә, телебезнең тулы канлы яшәеше өчен, халыкның рухи көчен арттыру өчен, халкыбызны милли рухта тәрбияләү өчен, авыр кавалерия вазифасын башкара. Бу җаваплы вә зур эшне олы буын белән бергә урта буын әдипләре, яшь көчләр тартып килә.

Телебезнең яңадан-яңа катламнарын ачуда төрле әдипләребез катнаша: алар төрле төбәктә туып үскәннәр, телләрендә кендек каны тамган шул төбәкнең алмаздай ялтыраган тәгъбирләре дә, мәкальләре дә, фразеологик берәмлекләре дә, төрле грамматик формалары да урын ала. Һәр әдип үз төбәгенең байлыгын халкыбызның зур тарихлы теленә куша бара.

Хәзерге прозаның стилистикасы гаять төрле. Мисал өчен «Казан утлары» журналында басылган әсәрләрдән З. Зәйнуллинның «Агыйделнең аръягында» дигән роман-кыйссасы, Н. Гарифның «Мәмеш бирде» дигән «тарихтан бер кыйсса»сы, Н. Әхмәдиевнең «Амбирак яки кара каен кыйссасы», Г. Ахуновның «Тимерханның эзләнүләре» документаль повесте, Р. Сибатның «Ялгызак» моңсу романы, Ф. Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга» роман-нәсере, Г. Гыйльмановның «Албастылар» хыялый кыйссасы һ. б. шул турыда сөйли.

Авторлар сайлаган жанрларын шулай атаганнар икән, димәк, тел-эслүб чаралары да әлеге стильгә тәңгәл килергә тиеш була бит. Безнеңчә, алар моңа нигездә, ирешкәннәр. Журнал битләрендә басылган зур күләмле проза әсәрләре белән бергә кечкенәрәк күләмле хикәяләр дә тел ягыннан матур тәэсир калдыра. М. Хуҗин, М. Закир, Ф. Яхин һ. б.ларның хикәяләре җыйнак, эмоциональ-табигый булуы һәм сүзе кирәкле урынына кую белән аерылып торалар. Татар теле күңелгә рәхәт булып, талгын гына агылып тора.

Татар укучысы соңгы елларда үзе өчен бер талантлы әдипне ачты. Бу—Рауль Мирхәйдәров. Аның Марс Шабаев тәрҗемә иткән «Иртәләгән сагыш» романы һ. б. әсәрләре интеллектуаль прозаның матур үрнәге булып тора. Чыннан да, әсәрнең тәрҗемәсе үткән гомернең сагышлы интонациясен бирә алган. Тәрҗемә әсәр икәнен онытып укып чыктым мин бу әсәрне. Безнең татар дөньясы өчен яңа дөнья, яңа геройлар, деталь-штрихлар, үзенчәлекле сурәтләү стиле укучыны үзенә тартып тора. Киләчәктә дә бу үзенчәлекле әдипнең әсәрләрен тәрҗемә итү кирәктер.

А. Тимергалинның «Игезәкләр» әсәре яңа темасы белән бергә үзенчәлекле стиль дә алып килде. Әсәрнең теле Адлер аганың үзе кебек катлаулы, саллы, уйланган, сайланган...

Стиле, теле ягыннан аерылып торган, татар прозасы өчен бөтенләй яңа булган «Албастылар» әсәре дә хәтергә уелып калды. Г. Гыйльманов язганга күрәдер дип уйлыйм. Аның элегрәк шөгыльләнгән фәнни проблемасы да татар мифлары иде бит. Шул дөньяга тирән үтеп керүе аның фантазиясенә гаҗәеп үзенчәлекле импульс биргәндер дип уйларга нигез бар. Теле бай, хикәяләве гаҗәеп серле, сихерле—могҗизалы әсәр куркыта да, әмма аны укыйсы да килә; текст артындагы символик мәгънәләрне дә тоясың кебек... Бу әсәрдә стиль таләбе гаять төгәл үтәлгән. Әсәр укыла, мавыктыра, күңелне кузгата... Мондагы кебек стилистик үзенчәлекле серле сүзләрнең концентрациясен беркайда да укырга туры килмәгән иде әле.

А. Хәлимнең «Казыктагы итальян» хикәясендә халкыбызның илле еллар элек кулланылган теле чагылыш тапкан. Бик үзенчәлекле ул. Анда рус сүзләре яңгыраш ягыннан үзгәртелеп тәмам үзебезчә яши: гөбернатыр, эсминә, мачтыр, чәйнүк һ. б. Сурәтләнә торган төбәккә караган, әдәби телгә дә кереп китәрдәй кызыклы сүзләр гаять күп: *үсендерү, су алкымын эзләп табу, суы татырлы, егетләрчә укталу, чәмләнеп китү, эше ырамлы гына бару, чәчкәләре белән гезгелдәп утыру, калҗаны сайлап сагыну, чагу-сары көлмәк, егет корына кереп җитү, мәрәкә икән, серәеп кайтып керү, ләкап чәпү, язгы карага басу, кып итеп тору, «шәлия табынына утыру»* һ. б. Нигездә уртак сөйләмдә алып барыла торган бу хикәя үзенең самимилеге, сафлыгы, оптимизмы белән, йөрәкне кисеп үтә торган сурәтләре белән күңелгә кереп кала.

Әдипнең чагыштырулары да тапталмаган, алар үзенчә кызыклы: *чыңрау торна кебек сайрау, кымыз пешергән сөян гөбе кебек зеңгелдәү, яңгырда быксыган гөмбә кебек тору, ат духтыры алдында учка кунган сандугач кебек, бала-чага терекөмеш кебек урамга эркелде, күк йөзендә сары май булып туңган ай йомарлыгы озата килде аларны* һ. б.

Соңгы елларның проза әсәрләре турындагы фикерләр арасында М. Вәли-Барҗылының «Ир-ат турында» мәкаләсе аерылып тора («Казан утлары», 10 сан, 2000). Анда Р. Сибатның «Ялгызак» моңсу романы турында сүз бара. Бу әсәрдәге Заһидулланы тәнкыйтьче җирдә нык басып торучы, көчле рухлы, хезмәт яратучы, бераз үҗәт, сау-сәламәт, рухи яктан таза, беркемнән һәм бернәрсәдән курыкмыйча яшәүче, ирекле кеше буларак яшәүче дип билгели. Тел ягыннан М. Вәли-Барҗылы әйткән аерым төгәлсезлекләр белән дә килешергә мөмкин: Заһидәнең «Аһ, аһ!» дип һаман әйтеп торуы, Максимның «чәпчим» сүзен һаман кабатлавы... һәр герой да тел ягыннан үзенчәлекле булырга тиеш иде, ә монда ике герой гына үзенчәлекле сөйләшә.

Шагыйрь күңелле Нур Әхмәдиевнең прозага керүе аңа шигъри кыйсса язарга мөмкинлек биргән. Кыйссаның сүзлек байлыгы, алардан оешкан җөмләләр, фразалар, аларның яңгырашы гаҗәеп бер гармония барлыкка китергән. Әсәрнең диалекталь сүзләр-гыйбарәләр белән бизәлүе, хикәяләү стиле, аның самими-әкияти, романтик характеры татар әдәбиятының бу чорында гүзәл бер әсәр буларак истә калыр кебек...

Аяз Гыйләҗевнең «Күңелем серләре» шәлкеме хөрмәтле әдибебезнең соңгы сүзе буларак кадерле. Аның дөньяда яшәү шатлыгын татуы, хатирәләре, аныңча гына ихлас һәм бераз аныңча гына «арттырып язуы» укучыны тартып тора. Ф. Сафин бу әсәр турында ихлас сүзләр әйтә: «Тел җәһәтенә килгәндә исә әсәр—соклангыч. Менә кайда ул осталык мәктәбе!» *(«Казан утлары», 3 сан, 2000).*

Үз стиле булган, бай телле әдибәбез Н. Гыйматдинованың «Аргы очта, бирге очта...» повестен укыган кеше андагы вакыйгаларның киеренкелегенә, әсәрдәге халык теленең тәмле-тәмле, ачы-ачы сүзләренә гаҗәпләнеп, укып чыкканын да сизми кала. Автор безне шушындый хәлләрдән сакларга тырышып язгандыр дип уйлыйсы килә. Андагы геройларының сөйләм үзенчәлекләре, уртак сөйләмдәге гыйбарәләр, диалекталь лексиканың чама белән генә кертелүе, әсәрдә һәм җөмләдә урынлы кулланылган фразеологик берәмлекләр һәм канатлы сүзләр бу әсәрнең телен лабораториядә өйрәнерлек итә. Андагы Шәләй үзе генә дә ни тора! Динамизмның соң чигенә җиткерелеп язылган бу әсәрне мин никтер гротеск дип кабул иттем.

Ф. Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга» дигән роман-нәсеренең теле турында Факил Сафин мондый сүз әйтә: «Теле хәрәкәтчән, мул сулы якты Ык

елгасын хәтерләтә». Ф. Сафин әдәби әсәрләрнең теле турында тәнкыйть фикерләре дә язып чыкты: «... бүгенге көндә прозага килгән авторларга тел мәсьәләсендә туры мәгънәдә ярдәм кирәк. Безнең әдәбият институтыбыз юк, әгәр булса, әдипләребез—тел осталары булган прозаиклар—шул институт кысаларында курслар, семинарлар алып барган булырлар иде... Кызганыч, әдипләребез китә тора. Алар белән бергә күпме тәҗрибә, байлык китә. Гафу ителмәслек битарафлык бу! Осталык мәктәбеннән мәхрүм итәбез яшьләрне» *(«Казан утлары», 3 сан, 2001).*

Хәзерге әдәби әсәрләрнең теленә хас кытыршылыклар, җитешсезлекләр, хаталар турында бердәнбер саллы сүз әйтүче дип Ф. Латыйфины күрсәтеп үтү кирәк. Үзенең соңгы әсәре («Бәйсез этләрне атарга») белән әдәбиятта югары бәя алган язучыбыз телдәге кимчелекләрне түбәндәгечә билгели: «Авторларның хәтта ни әйтергә теләгәнен аңлап та булмый. Аптырагач, мин ул җөмләне урысчага тәрҗемә итеп карыйм һәм шуннан соң гына ул аңлаешлы хәлгә килә. Авторларның күбесе, урысча уйлап, татарча яза» *(«Казан утлары», 3 сан, 2001).*

Әдәби телнең публицистик стиле турында Ф. Латыйфи фикерен болай дәвам итә: «Кайчагында татар газеталарын аласың да андагы төгәлсезлекләрне, сүзнең мәгънәсен белмичә, бозып кулланганнарын күргәч, ул газетаны хәтта ертып атасы килә башлый. Телдәге шапшаклыкның иге-чиге калмады бит... Газеталар, радиолар күбәйде, ә телнең нюансларын, нечкәлеген, тәмен тоеп эшләүче журналистлар саны артмады. Әдәбиятка килүче яшьләр дә тел җәһәтеннән шактый надан...»

Әйе, мондый фикерләр «Казан утлары» журналының 1999 елгы 12 санындагы редакцион мәкаләдә дә әйтелгән иде: «Бигрәк тә проза әсәрләрендә күп төсмерле, сыгылмалы, җырлап торган милли тел сирәк кунакка әйләнде».

Әдәби тел мәсьәләләренең «Казан утлары» журналында даими тикшерелә торган бер юнәлешкә әйләнеп баруы сөендерә. Ф. Латыйфи бу турыда аеруча борчылып яза: «Хәзер кем ничек тели, шулай яза. Элекке вакытта таләпчәнлек бик югары, белемле редакторлар, корректорлар бар иде. Һәр өтер өчен зур бәхәсләр булгалый торган иде. Сүз иреге белән бергә «наданлык иреге» дә килде. Мисал өчен, Оренбург шәһәре генә дә матбугатта дүрт төрле языла: Оренбург, Ырынбур, Оренбур, Ырымбур... Ул өтерләрне әйткән дә юк инде... *(«Казан утлары», 3 сан, 2001).* Бу сүзләрнең хаклы икәнлегенә шигебез юк. Казан университетына укырга килгән абитуриентларның да белем дәрәҗәсе элекке белән чагыштырганда төшеп бара. Ә тыныш билгеләре безнең өчен—укытучылар өчен дә—зур проблема булып кала бирә.

Соңгы елларда безне шатландырган бер вакыйга булды. Сүзнең нинди көч, нинди тылсым икәнен үзенең шигъри иҗаты белән күрсәткән Лена Шагыйрьҗан «Сүзләр, сүзләр...» дигән эссе язды. Аның һәр тәгъбире—сүзгә мәдхия! Тормышта, әдәбиятта, дөньяда сүздән дә бөек нәрсә юк икәненә ышанасың. Шагыйрә биредә сүзгә сүзләр белән һәйкәл куйган! Моңа кадәр сүзнең тылсымлы, шигъри көчен Лена Шагыйрьҗан кебек эсседа күрсәтә алган шагыйрә булмагандыр кебек...

Прозабызга милли хисләр, милли детальләр, милли идея әкренләп кайтып килә. А. Хәлимнең—«Татар вакыты», «Казыктагы итальян», Ф. Сафинның—«Саташып аткан таң», В. Имамовның—«Утлы дала» һәм М. Хуҗин, М. Юныс, Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов әсәрләрендә татар дөньясы, татар тарихы, татар мохите шактый тулы сурәтләнә. Татар әдәбияты бу елларда сан ягыннан да шактый үсте: дистәләрчә романнар, повестьлар, драма әсәрләре, том-том шигъри басмалар иҗат ителеп, укучыларыбызга барып җитте.

Әдәби телебез үзенең халыкчан нигезләрен һаман саклап калырга тырыша. Шулай булырга тиеш тә, чөнки халыкның җанлы сөйләменнән аерылган телнең укучысы булмый, ул алга таба яши алмый. Һәр сүзнең кадерен белгән Дәрдемәндебез юкка гына болай дип язмагандыр: «Урамнан һәм базардан чүплә сүзне»...

Хәзер дә әдәби телебезнең халыкчан булуын күрәсебез килә. Һәм күп чагында өметләр аклана: проза әсәрләре халыкның җанлы сөйләм теле искиткеч бай икәнен күрсәтеп тора. Әдипләребез кайчак артык халыклашып китмиләр микән дип тә уйлап куясың: чөнки бер җөмләдә ике-өч фразеологик берәмлек

килә; гади сөйләм сүзләре кирәгеннән артык мул кулланыла; диалекталь сүзләр, формалар да килеп өстәлә; ватылып җимерелгән-үзгәртелгән рус-европа сүзләре дә чиктән тыш очрап тора... Шулай итеп, әдәби телебез бәйдән ычкынган шикелле тоела башлый. Әйе, демократия җәмгыятьнең барлык яшәү сфераларына килеп керде! Цензура юк! Кем тели, шул яза! Ничек тели, шулай яза! Ничек уйлый, шулай яза! Беркемнән курыкмыйча яза! Болары бик яхшы. Ләкин китап меңнәр өчен языла, халыкның төрле зиһенле, төрле яшьтәге, төрле һөнәрдәге, төрле төбәкләрдә яшәүче төркемнәре өчен языла. Димәк, телебездә гомумхалык өчен уртак лексик, грамматик нормалар өстенлек алырга тиештер. Әмма бу һич тә индивидуаль стиль булмасын дигән сүз түгел!

Хәзерге әдәбиятыбызның теленә караган түбәндәге кызыклы юнәлешләрне билгеләргә мөмкин. Әдәби әсәрләрдә сүз байлыгы катлаулана бара. Моның сәбәпләре дә бар: чөнки, беренчедән, тыелган темалар юк, әдәбиятның сурәтләү объектлары чиксез күбәйде, тематик лексика һичбер чикләнүсез килеп керә (М. Юныс, Н. Әхмәдиев, Г. Гыйльманов һ. б.) Икенчедән, төрле яклардан язалар: Себер, Башкортстан, татарлар яши торган күп санлы Россия төбәкләре... Әсәрләргә шул төбәкләргә хас диалекталь һәм этнографик лексика килеп керә. Өченчедән, тарихи әсәрләр күбәйде. Ә бу, үз чиратында, телебездәге сүзлек байлыгының тарихи катламнарын хәрәкәткә китерә. Дүртенчедән, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә яңа сүзләр барлыкка килеп тора. Аннары язучы үзе дә яңа сүзләр ясый, бигрәк тә шагыйрьләр. Һәм бу— табигыйдер дип уйларга нигез бар. Чөнки сүз остасы яңа сурәт, яңа мәгънә төсмерләре эзләргә хаклы. Алар, бәлки, халыклашып та китмәсләр, ләкин язучының, шагыйрьнең акылында туып, аның әсәрендә яңа сүзләр буларак беркетелеп калалар. Мәсәлән:

**Зәңгәрәйде** күкләр.
Ачыклана төште,
төсләр, югалтулар, табулар...

*(Р. Фәйзуллин. «Тагын килде язлар».)*

**Хыяллар рәшәсе**
Тирбәлә дөньяда.
Офыктан-офыкка—
Ир бала.
Ир бала...

*(Мөдәррис Вәлиев. «Сулыштан—сулышка».)*

**«Зариф кебек тешсез патриархларны инде алар чынга кабул итмиләр»**. *(Х. Мөдәррисова. «Бәйге хакы».)*

Туксанынчы елларда рус теленең тәэсире кимегән кебек тоелса да, бу хәл дәвам итмәде. Киресенчә, рус теленең башка халыкларга, шул исәптән, татар теленә тәэсире киму ягына түгел, ә арту юнәлешендә бара кебек тоела. Берничә еллар элек бездә рус сүзләрен татарчалаштыру процессы барган булса, хәзер радионың да, телевидениенең дә, журналистларның да, язучыларның да артык татарчалаштырып утырасы килми кебек тоела. Без никадәр качарга тырышсак та, рус теле безнең ишебездә, урамда, трамвайда, Татарстан Дәүләт советында, бәйрәмнәрдә, балалар бакчаларында, җәмәгать һәм дәүләт оешмаларында, халыкка хезмәт күрсәтү урыннарында, мәктәптә, югары уку йортларында һ. б. рәхәтләнеп, тулы көчкә, телебезне кысып яши бирә. Иртән рус телендә яңа сүз туса, кич белән радио-телевидениегә, матбугат чараларына килеп кереп гаҗәпләндерә. Шунысы бар: һәммә сүзне дә эквивалент тәрҗемә итеп бетереп булмый! Шуңа күрә күп чагында яңа сүзне әзер килеш алабыз: циклон, буклет, блондин, коррупция, банкир, форум, бизнесмен, компьютер, парламент, интеллект, Дума, файл, дискет, критерий, «Мерседес», «Макдональс», робот, чип, коттедж...

Әйе, техника үсә, камилләшә, дөнья да үзгәрә, яңара... Әгәр һәр яңа төшенчәне белдерә торган яңа сүзне русча яисә дөнья телләрендә генә ала башласак без нишләрбез икән? Әнә бит: французлар инглиз теле тарафыннан йотылудан куркалар; төрекләр күп еллар буена әдәби телләренә европа һәм дөнья алынмаларын кертмәскә тырышып яшәделәр, том-том сүзлекләр

яздылар—үз сүзләрен иҗат иттеләр. Ләкин, барыбер, аралашканда, конгрессларга барганда күрдек: төрекләр үзләре бу ясалма сүзләр белән сөйләшмиләр, алынма сүзләрне бик күп кулланалар, филолог галимнәре дә шулай эшли. Димәк, алынмаларга каршы көрәш әллә ни уңыш китермәгән. Иң кулае шул булыр кебек: без һәр алынмага конкрет якын килергә тиешбездер. Телебездә ул төшенчәне белдерә торган сүз булса, шуны алырга. Әгәр андый сүз юк икән, күчерелмә мәгънәле сүзләр эзләп карарга. Булмаса, диалектларга, сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә. Мондый чаралар әйбәт нәтиҗәгә кичермәгән очракта гына, сүзне алынма сүз буларак кабул итәргә кирәк.

Телебездә мондый тәҗрибәләр булмады түгел. ТР Фәннәр Академиясенең һәм Казан университетының ясалма фәһем лабораториясе галимнәре компьютер дөньясына караган русча-татарча сүзлек бастырып чыгардылар. Анда бу өлкәгә караган сүзләрнең байтак кына татарча вариантлары табылган: компьютер—санак, принтер—басак һ. б.

Алынма сүзләр табигый кабул ителгән әсәрләрдә арта бара. Техника һәм зур төзелешләр, фән заманында бу табигыйдыр. Әйтик, Р. Фәизовның «Рәхим итегез, сэр!» дигән фантастик хикәясендә билгеле бер сүзләр җыелмасы әсәрне тотып тора. Аларның күбесе европа сүзләре: гигант, космоплан, Джеймс Райт, двигатель, бетон полоса, атмосфера, штурвал, Пентагон, Америка, генерал, президент, физик, пилот, гризли (аюыдай), кабина, пассажир, салон, плафон, корабль һ. б. Бу фантастик хикәя кысылган код кебек. Ул заманча стильдә һәм заманча лексика белән киеренке язылганга күрә, җиңел укыла, аны алынмалардан башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Әнә шулай эчтәлек белән форма туры килгәндә, алынмаларның кулланышы аклана.

Әйе, тормышта нәрсә булса, әдәбиятта, бигрәк тә прозада, рус-европа алынмалары күпмедер күләмдә котылгысыздыр да. Әмма кешене рух саклап кала ала. Шуңа күрә кеше әдәби әсәрләр укый һәм аның милли рухын үстерә торган эчтәлек белән бергә милли әдәби тел дә заманча дәрәҗәдә бөек, тулы, сурәтле, бай булырга тиеш.

Илдар Юзеевның бер шигырендә «киллер» сүзе бар. Ике строфалык бу шигырь шушы бер сүз аркасында заманча иҗтимагый яңгыраш ала:

Еллар узган саен сагындырыр
Мәхәббәткә тугры корбаннар.
Килде Исмәгыйльләр—киллер булып
Акча өчен ата торганнар...
*(«Казан утлары», 2 сан, 2000.)*

Шулай да куанычлы: соңгы еллар әдәбиятында персонаж сөйләмендә генә түгел, автор сөйләмендә дә җирле төбәк колоритын бирү өчен диалекталь сүзләр куллану арта бара. Арча төбәге дә, Сарман ягы да, Башкортстандагы типтәр сөйләшләре дә, мишәр ягы да, Себер татары да прозада сизелеп тора. Мәсәлән, Г. Гыйльмановта—*«чиялэйләп төенләү», «япалай карама», «бәрәңге тәрмәсе»; Я. Зәнкиевта—олы-корылар, курты (җамбы балыгы), күлдәвек, ирмәк, беравык, сыгыт (сагышлы), бакчар (сыерчык), астанә (зыярат), биртенү (радикулит)* һ. б.

Татар теле аерым сөйләшләрдәге грамматик формалар аша да баеый бара. Мисал өчен **малы (мәле)** кушымчалары прозада да, поэзиядә дә, хәтта публицистикада да актив. «Бер офыкка кереп күмелгәч, кемнең кайда йөргәнен дә **белмәле** түгел» *(Ф. Сафин. «Саташып аткан таң».)* «**Карап кына тормалы** инде—чиста, пөхтә...» (Ф. Сафин. Шунда ук.)

Сине туган иткән сихри дәрья
Минем өчен йөзеп чыкмалы.
*(З. Мансур. «Сихерләнү».)*

Р. Фәизовның «Рәхим итегез, сэр!» әсәрендә ул аеруча күп очрый: *искитмәле машина, искитмәле күркәм чибәр егет, искитмәле кыз, искитмәле очкыч, искитмәле тизлек* һ. б. -Гачтын (-гәчтен) формасы да активлаша бара: «Сусагачтын килә күлгә». (Г. Садә.) «*Тугачтын* ук коенып үскән гүя». (Р. Гаташ.) «Каты чирдән бераз хәл *алгачтын*, озак итеп тышка карап тордым». (Ф. Яруллин.)

Сөйләшләрдән бәйлекләр дә, кисәкчәләр дә килеп керә: *тиңентен, битәр, тәүмәле, мәлдә, ише, эргәсендә.* Җирле сөйләшләрдән кергән сүзләр шигърияттә дә, прозадагы автор һәм персонаж сөйләмендә дә шактый күзәтелә. Алар күп түгел, әмма, кабатланудан котылу, өчен кулай бер чара булып тора. Мәсәлән, «... Чәкине ваттырасы, әрәм иттерәсе, *«Зәм-Зәм» суыннан* колак кагасы килми.» (З. Хәсният.) «Хәмит төшеп калгач, яшь хатынның ачуы *отыры* кузгалган иде». (З. Хәсният.) «Нәкъ Фәгыйлә! Кайнар сулышына тиклем!» (З. Хәсният.) «Бу *тиклем* куәтле, уңайлы һәм акыллы очкычны Галәмгә ничәмә тапкыр күтәреп тә, Райат әле һаман да шул гадәти бер тойгыдан котыла алмый». (Р. Фәизов.) «Бәхетне без умырып тотар идек, Тик кайда соң аның *кулчасы*? (Р. Идиятуллин.)

Диалекталь сүзләрнең әдәби телне баету мөмкинлекләре чиксез. Вакыты-вакыты белән бу сүзләр җирле төбәктәге вакыйгаларга бәйле рәвештә текстка гаять табигый кереп китәләр. Аерым язучыларыбызның әсәрләрендә алар матур гына бер лексик фон да барлыкка китерәләр. Н. Әхмәдиевнең «Амбирак яки кара каен кыйссасы», Я. Зәнкиевнең «Өтелгән мәхәббәт» әсәрләрендә җирле сөйләш сүзләре урынлы кулланылалар һәм сурәт ясауда гаять матур яңгырап бирәләр.

Әдәби телебездә, аеруча матур әдәбият телендә һәм фәнни-популяр стильдә парлы сүзләрнең активлашуы күзгә ташлана. Әлбәттә, телебездәге синоним сүзләрдән, антоним сүзләрдән парлы сүз ясау тәҗрибәсе ерак-еракларда килә: *тирә-юнь, ир-егет, киңәш-табыш итү, ата-баба, исәп-хисап, исән-имин, көн-төн, юк-бар, теше-тырнагы белән, ул-бу булмау, җәбер-золым, чит-ят* һ. б. Бер сүзгә авазлаш икенче сүз килеп тә яңа сүз ясала, шулай ук икесенең лексик мәгънәсе булмыйча да яңа сүз ясау бар: *әкәм-төкәм, әҗе-гөҗе* һ. б. Әдәби телдә якынрак мәгънәле сүзләрне парлап яңа сүз ясау тенденциясе дә арта бара кебек. Безнеңчә, яңа сурәт чаралары кирәк булу сәбәпле, бу күренеш яңа чорда шигырьдә башланды. Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Р. Хариста аеруча күп булган мондый сурәтләү чаралары хәзер инде шигырьдән прозага, публицистикага, хәтта фәнни-популяр стильгә дә күчеп бара. Мәсәлән, «Ялыкты авыл туктаусыз *куалау-ашыктырулардан*» (Факил Сафин). «Дыңк иттереп капка ябылган тавыш *ис-һушына* китерде бугай, бер мәлгә туктап калды... (З. Хәсният.) «Үзләренә качып китәргә *җай-җирлек* эзерлиләр». (С. Шәмси.) «Анда дөнья күргән әсәрләр безне *алга күз ату-фаразлары* аша яшәргә өйрәтә». (И. Әхмәтҗанов.) «Аның *әмер-хәрәкәтләре* кыю». (С. Шәмси.) «*Ил-дәүләт* хуҗасы саналган колхозчылар бушка дигәндәй эшләгән...» (М. Госманов.) «*Түрә-чиновниклар* арасында да ихлас күңелдән *халык-кавем*, кешеләр мәнфәгате алдында үз бурычларына тугрылыклы игелекле затлар очрап торгалаган». (М. Госманов.) «Укытучыларга *мөрәҗәгать-гозерем* дә бар». (Р. Юсупов.)

Соңгы елларда әдәби телебездә гади сөйләм сүзләрен куллану чиктән ашып китте. Тормышыбыз тәртипсезлегеннәнме, башка телнең дә шушындый түбән стиле таралуданмы—әмма соңгы вакытта әдәби әсәрдә сүгенү сүзләре дә күп күренә башлады. Алар образ ясау өчен кызыклы гына алым булса да, әдәбиятта дорфалыкка, тотнаксызлыкка китерми микән? Мәсәлән, «Каршыда ат йөзле, сыер гәүдәле, тап-таза марҗа тора иде». «Әле син исәнмени, гад?» «Дуңгыз кебек тазалар, чәпчим, менә тазалар, аналарын корт чаккыры», Аяз мулла болар өстенә килә. Авызыннан күбекләрен чәчә-чәчә.» Болар Р. Сибатның гаять кызыклы әсәрләреннән алынган җөмләләр. Һичшиксез талантлы, сурәт ясауда зур осталыкка ия булган бу язучы гади сөйләм сүзләрен кирәгеннән артык кулланмый микән?! Әлбәттә, ул көчле импульслы, кыска, халыкчан тел белән яза. Курыкмыйча, алга-артка карамыйча яза. Дөньясы шундый булганга, гади кешенең—җир кешесенең газаплы тормышын яза. Әмма түбән стильгә үк төшеп китмәсә иде Р. Сибат. Укучы, тупас сүзләрдән туеп, аның китабын читкә алып куя күрмәсен иде. Әдәби телнең, нигездә, әдәпле булуы кирәктер...

Татар прозасы милли проза буларак йөз елдан артык үсеп, камилләшеп килә. Аны стилистик яктан дөнья әдәбиятының казанышлары белән тоташтырган күп кенә күркәм күренешләр бар. Мәсәлән, дөнья прозасында уртак сөйләм дип аталган стиль татар әдәбиятына XX гасыр башында сак кына аяк басты һәм кыюсызрак кына, күзгә ташланмыйчарак кына яшәп

килде (Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Нәҗми һ. б. әсәрләре). Ниһаять, ул аякка басты. Прозабызның өлгергән заманында (Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, М. Мәһдиев һ. б.) ул әдәбиятта хикәяләүнең төп чарасына әйләнде. Хәзерге әдәбиятта аның белән исәпләшмичә мөмкин түгел.

Уртак сөйләм өчен автор һәм персонаж планының мәҗбүри булуы кирәк. Хикәяләүдә ике план—автор сөйләме һәм герой сөйләме килеп кушыла. Автор һәм герой «тавышлары»ның кушылуы авторның герой халәтендә булуына китерә: авторның объектив планы белән персонажның субъектив планы кушылып китә. Автор һәм персонаж сөйләменең кушылуы проза сәнгатенең иң югары сыйфатын барлыкка китерә. Ул хикәяләүдә фальшька, ясалмалыкка урын калдырмый. Бу адым белән язган әдип үз героен ахыргача тоярга, андагы күңел тибрәнешләренең иң нечкәсен дә сиземләргә, фикерләрнең каршылыклы бөтенлеген сурәтләп бирә белергә тиеш була. Соңгы елларда язылган проза әсәрләре, бәлки, Әмирхан ага Еники дәрәҗәсенә җитеп тә өлгермәгәннәрдер, ләкин алардагы заманча стиль уртак сөйләм аша да сиземләнә.

Хәзерге хикәяләүдә автор кайчак югалып бара кебек. Әсәрләр драматургия стиленә якынлаша. Бу—киеренкелекне, эмоциональлекне арттыра. Темасы, хикәяләүнең юнәлешенә карап кулланганда, ул гаять заманча, экономияле, максатка яраклы. Ә менә тарихи, иҗтимагый яңгырашлы әсәрләрдә саллы, салмак яңгыраш таләп ителә һәм диалоглар күләме сизелерлек кими. *(В. Имамов. «Утлы дала».)* Хәзерге кайбер проза әсәрләрендәге зур күләмле абзацлар тарихи жанр өчен генә характерлы кебек. Безнеке сыман дөньяда «яшәү—бер мизгел» булган заманда, озын-озын җөмләләрне укып утырырлык укучылар да кими бара. Күп тиңдәш кисәкләре, аерымланган кисәкләре, җәенке җөмләләре булган озын җөмләләр дә заманга яраклаша. Аларны махсус таркатып, берничә мөстәкыйль берәмлеккә аерып, нокта аша язу да ныгып бара. Телдә *парцелляция* дигән бер стилистик алым үсеп килә. Мәсәлән, З. Хөсниярның «Айның туган-тумачасы юк» дигән әсәре нәкъ менә шулай башланып китә: «Теге китте. Сөт машинасына утырып. Райүзәккә. Судка дип. Ул калды». (З. Хөснияр.)

М. Юныс өчен дә бу алым шактый кулай булып чыккан. Чөнки җөмлә җиңеләя, мәгънәви акцентлар көчәя бара: «Адәм баласы яшәр өчен дөньяга килә. Бәхетле булыр өчен. Дөнья көтәр өчен. Буыннарны-буыннарга, ата-бабаны балаларга-оныкларга тоташтырып, милләтнең мәңгелеген тәэмин итәр өчен».

Хәзерге прозаның тагын бер үзенчәлеген билгеләп үтәргә мөмкин. Бу—прозада диалоглар күләме арту. Диалог хикәяләүнең бер формасын тәшкил итә башлады. Хәтта авторның *әйтте, диде, җавап бирде, сорады, сөйләде, кычкырды* кебек сүзләре дә юкка чыга бара.

«—Исемең Лотфулла бугай?
—Әй-е.
—Син нәрсә, гелән генә тәрәзәгә киләсең, ә үзең чакырсам кермисең?
—Һы! Кызык бит!
—Нәрсәсе кызык?
—Урысча укыганны карау кызык.
—Син әллә урысча беләсеңме?
—Кайбер сүзләрен генә беләм!.

*(З. Зәйнуллин «Агыйделнең аръягында».)*

Диалогларны автор сүзләреннән башка бирү фикерне тыгызлый, хикәяләүне кискенләштерә, динамизмны арттыра. Хәзерге укучы озын-озын хикәяләүне укып утырмасын өчен, әдипләр шулай язалардыр!

«—Апа, ә Айчибәр үзе кайда?
—Кайда дип... Белмәйһеңмени? Ул бит моннан китте.
—Ничек китте?
—Кыдлар ничек китәләр һуң?»

*(Н. Әхмәдиев. «Амбирак яки кара каен кыйссасы».)*

Әдәби әсәрләрдәге башламнар турында материаллар җыйганда да бер нәрсәгә игътибар иткән идем: безнең әдәбиятта диалоглар белән башлау гадәткә әйләнеп бара кебек. Гәрчә аларны барлык язучылар бик өнәп бетермәсә дә. Гомумән, диалогның хикәяләүдәге, текст төзелешендәге роле үсә бару прозабыз

өчен характерлы бер күренеш дип санарга мөмкин. Шуңа бәйле тагын бер яңалыкны да күрсәтик: диалог, нигездә, җанлы сөйләмдәгечә кыска, динамик, табигый оешкан була.

Шул ук вакытта әдәбиятта салмак хикәяләү дә сакланып килә. Бу аеруча тарихи әсәрләрдә күзәтелә. В. Имамовның «Утлы дала»сында *(2000, 1, 2 саннар)* саф диалоглар бөтенләй диярлек очрамый. Язучының максаты—эпик хикәяләү. Әсәрдә персонаж сөйләмен хикәяләүгә алып керүче фигыльләрнең кайберләрен генә карап үтик әле: *әмер бирү, сөрән салу, авызын еру, сорау ишетелү, әмере белән өтеп алу...* Бәлки, бу рәвешле хикәяләү тарихи әсәрләр өчен, гомумән, хастыр. Н. Гарифның «Мәмеш бирде» исемле тарихи кыйссасы да шундый ук стильдә язылган. Монда да персонаж сөйләме күп түгел, саф диалоглар да аз очрый.

Сиксәненче еллар азагында безгә башламнар мәсьәләсендә беренче күзәтүләр ясарга, хәзер инде күбесе арабыздан киткән олпат әдипләребездән сорауларга җаваплар алып, бер зур мәкалә дә язарга туры килгән иде. Ә туксанынчы еллар әдәбиятында бу мәсьәлә ничегрәк соң? XXI гасырга аяк басканда алга китә алдыкмы? Безнеңчә, язучыдан зур осталык, интуиция, стилистик тоем сораган башламнарның үткән гасыр әдәбиятындагы кебек вакыйга булырдайлары күп түгел. «Фәхрине үтереп ташладылар». (Г. Ибраһимов. «Тирән тамырлар».) «Ул туды, туганда ул кеше иде». (Ф. Әмирхан. «Татар кызы».) «Яшь бала елый иде». (Ш. Камал. «Буранда».) «Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә...» (Ә. Еники. «Әйтелмәгән васыять».) «Казмаш заводында яңа директор көтәләр». (Г. Әпсәләмов. «Сүнмәс утлар».) Менә шушындый бер укылгач хәтердә калырдай башламнар хәзер азрак кебек тоела. Әсәргә бит шулар аша кереп китәсең. Әсәрнең нота ачкычы, прелюдиясе бит инде алар!

Хәзерге прозада менә мондый мисаллар: «Җәнҗал аларны үзе эзләп тапты». (Н. Гыйматдинова. «Аргы очта, бирге очта».) «Район үзәгендәге хастаханә янына яңа тарантаска җигелгән кара айгыр килеп туктады». (Г. Галиева. «Тулгак».) «Тагылга барасы чакта, анда уздырган берничә көнемнең гомерем буенча җитәрлек рәхәт әрнү, татлы сагыш, газап китерәсен ялгыш та уйламаган идем». (Н. Әхмәдиев. «Амбирак...») «Хисмәтулланың өй салу артыннан йөри башлавы авылдашлары тарафыннан сәеррәк кабул ителде». (Ә. Моталлапов. «Картлык».) «Суздаль урамнарын көтелмәгән һәм хәвефле тояк тавышлары уятты». (В. Имамов. «Утлы дала».) «Кешелек дөньясы егерме беренче гасырга аяк басты». (Р. Фәизов. «Тәңре хөкеме».) Алмасар авылында уңганлыгы белән тирә-якка мәгълүм механизатор Лотфулла Арукаев көн итә». (Б. Камалов. «Дөмбер Даниял».)

Хәзерге әдәбиятта тагын бер күренеш активлашып бара. Атау җөмләләр XXI гасыр башы поэзиясендә дә, прозасында да заманча фикерләү өчен кулай булып чыкты. Р. Фәйзуллиннар, Р. Харислар шигырьдә актив кулланган атау җөмләләр чәчмә әсәрләргә дә чылбыр булып кереп китте.

Җәяүле буран.
Еламсар яңгыр.
Җилкәнле болыт.
Шадра кыр.
Салкын чишмә.
Төсле җыр.

*(Р. Фәйзуллин.)*

Ак кар.
Кызыл төлке
Яшел күзле,
Зәңгәр эзле...

*(Р. Харис.)*

«Чәй сала торган көмеш калак... Кара чәчәкләр төшкән ак фарфор чынаяклар... Үз өе... Аның тәмле, татлы исе... Акрын гына җан тибрәткеч музыка... Зәп-зәңгәр, үтә күренмәле ялкын телләре... Болар барысы да юлда кайтканда, аннары әле генә өйдә туган икеле-микеле моң-зарларны алып киттеләр». (А. Гыйләҗев.)

«Туган ягым Эстәрле буйлары».

Бүгенге Башкортстанның казакъ далаларына чиктәш җирләр...

Көньяктан Ырынбур далалары белән тоташкан изге урыннар... Ах, бу Эстәрле яклары! (З. Зәйнуллин.)

Без үзенчәлекле чорда яшибез. Бер яктан, цензура юк, ничек телисең шулай яз. Икенче яктан, бу чиксез иркенлек әдәби телебезне какшатмас микән? Бу ирек, сиздермичә генә, рус теленең сүзләрен генә түгел, грамматик калыпларын да арттырмасмы? Берничә мисал китерик: әдәби телебез әкрен-әкрен рус теленең лексик, синтаксик-стилистик тәэсирен тоя бара. Элек туры сөйләмнән соң «диде», «әйтте», «сорады» фигыльләре килеп, җөмлә тәмамлана иде. Хәзер бу сүзләрдән соң аерымланган хәлләр урын ала башлады. Рус телендәге сүз тәртибе безгә дә килеп керде: «—Ты пойдешь с нами?—спросила она, одевая ребенка». Нәкъ шушы тәртиптә без дә җөмлә төзи башладык. Язучыларның яше дә, олысы да шулай яза:

—Тот, чукынган!—диде бит алмалары кызарган Заһидулла, дуңгыз мае уртлап. (Р. Сибат.)

—Ә-әйе,—дидем, гаҗәпләнүдән тотлыга төшеп. (Н. Әхмәдиев).

—Ничек соң, Кызылъярда әйбәт кенә яшәп ятасыңмы?—диде ул, хәйләкәр елмаеп. (Ф. Яруллин.)

—Ярый, кирәгез,—диде министр ханым, модалы кыска күлмәгенең итәген тарткалап куйгач. (Г. Ахунов.)

Рус теле тәэсирендә таралган тагын бер төзелмә активлашты. Бу—*«-рга,—ргә»* формасындагы инфинитив. XX гасыр башына кадәр аның вазыйфаларын *«-мага,—мак,—у»* формалы фигыльләр үтәгән. Бу форма хәзерге чорда рус теленең үзендә дә искиткеч актив икән. Ул турыда рус галимнәре язып чыга. Ләкин бу форманы татар телендә сүзлек маддәсе итеп кую шактый уңышсыз булган дип әйтәсе килә. Ырылдап торган бу форма татар балаларына телне өйрәткәндә гаять авыр. Рус балаларына татар теле өйрәткәндә әйтмим дә инде!.. Иң куркынычы шунда: безнең бу форма белән ясалган фигыльләребезнең синтаксик-стилистик кулланышы нәкъ русча икән! Сүзләре татарча, ә җөмлә калыбы—русча! «Укырга, укырга, укырга!» дигән өндәмәләрдән башланмады микән бу «рга»ларның кулланышы?! Без бер лингвистик тәҗрибә үткәрдек: Г. Ибраһимовта һәм М. Мәһдиевтә «-рга» формасының күпме икәнен санап чыктык. Хәзерге телебездә ул 20 тапкырга арткан булып чыкты!

Мин үзем фигыльләрдәге элекке *«-мак,—мәк»* формасын кире кайтару ягында. Хәзер ул бездә пассивлашкан, Төркия белән бәйләнешләр беткәннән соң, егерменче елларда сүзлекләрдән махсус төшереп калдырылган, аннары *«-рга»* формасы килеп кергән. Ни өчен кергәне дә мәгълүм: никадәр карарлар, күрсәтмәләр рустан тәрҗемә ителгәннәр! 60-70 ел буе! Шуңа күрә *«-рга»* активлашкан да.

Татар теленә рус теленең тәэсире калькалар күбәюдә дә сизелә. Менә мисаллар: хәлендә—*в состоянии*; юлында—*на пути*; дәрәҗәдә—*в степени*; нәтиҗәсендә—*вследствие*; хисабына—*за счет*; ягыннан—*со стороны*; буларак—*будучи*; нигезендә—*на основе* һ. б. Татар телендә рустан калькалаштырылган менә мондый кушма бәйлекләр барлыкка килде: *аермалы буларак, белән бергә, белән рәттән, капма-каршы буларак, мөнәсәбәте белән, сыйфаты белән, уңае белән һ. б.*

Рус телендәге иялек килеше катлаулану татар теленә дә кире яктан тәэсир итә. Бу хәл матбугат телендә күбрәк күзәтелә, әлбәттә, ләкин ул кайчак прозага да үтеп керә. Менә мисаллар: *педагогия фәннәре академиясе член-корреспонденты М. И. Мәхмутов; республика агропромышленность комплексы работниклары активы җыелышы* һ.б.

... Татар әдәби теле яңа гасырга аяк атлады. Күркәм, ышанычлы тенденцияләргә йөз тотып һәм халыкның җанлы сөйләменә нигезләнеп үсә торган татар әдәби теле яңа гасырда да затлы әсәрләр, зыялы әдипләр вә шагыйрьләр теле буларак тагын да камилләшер. Ул заманча төсмерләр, сурәтләр белән баеп үзгәрсә дә, милли үзенчәлекләрен, табигый яңгырашын һәм халыкчан традицияләрен саклап калыр дип ышанабыз.

# Ədəbi tənqit
# Әдәби тәнкыйть

## ТОЙГЫ КАТЛАМНАРЫ

*Күк йөзенә карагандa да гүзәлрәк күренеш бар: ул—кеше күңеленең тирәнлеге.*

Виктор Гюго

Татар әдәбияты егерменче гасыр дәвамында дөнья мәдәниятенә байтак каләм осталары бирде. Гасыр башында әдәбият мәйданына килгән Г. Исхакый, Г. Тукай, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов һәм Ф. Әмирханнар сафына соңрак К. Тинчурин, Һ. Такташ, Х. Туфан, ә гасыр урталарында бүтәннәр белән бергә Әмирхан Еники дә килеп кушыла.

Әмирхан Еники тормышына социаль-иҗтимагый хәлләрнең тынычсыз агышы туры килгәнгә, ул байтак чигенешләр һәм төрле борылышлар ясарга мәҗбүр. Әмма ул—әлеге гарасат гаугалары эченнән үзенчә юл ярып яктылык эзләгән һәм тапкан, тормышы белән дә, иҗаты белән дә якты юл сызып калдырган әдип.

Булачак әдипнең якты хәяткә беренче аваз салуы 1909 елның 17 февралендә (яңа стиль белән 2 мартта), элекке Уфа губернасының Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылында була.

Анын әтисе—таза хәлле крестьян—соңыннан вак һөнәрчелеккә бирелеп китә. Озак та үтмичә аларның гаиләсе Яңа Каргалыдан кырык чакрым ераклыктагы Дәүләкән авылына күчеп килә. Дәүләкән—Дим буеның гүзәл почмагы. «Мин Дим буенда үстем,—дип яза Ә. Еники үзе дә,—һәр җомганы без, Дәүләкән яшьләре, Дим өстендә ишкәкле көймәләргә утырып, гармунга кушылып җырлап йөрергә ярата идек» *(Хәтердәге төеннәр. Казан, 1983)*. Язучының ел саен туган җиренә кайтып йөрүе туган ягының шигъри табигатен, бәрәкәтле һавасын оныта алмавыннан килә, күрәсең.

Еникиләр гаиләсе үзе дә кызыклы һәм шактый күп тармаклы: әдипнең нәсел шәҗәрәсе әнисе ягыннан атаклы Купринга ук барып тоташа. Нигъмәтҗан абзый (Әмирханның әтисе)—аң-белемле кеше, улына беренче хәрефне танытучы да ул. Мәктәпкә барганчы ук кечкенә Әмирхан шулай укырга-язарга өйрәнә. «Тукайның Сәгыйть ага бүләк иткән «Су анасы» минем өчен чын мәгънәсендә тел ачкычы булды»,—дип искә ала язучы үзенең бер мәкаләсендә. Шуннан башлап Әмирханның китап укуга хирыслыгы гел арта бара: «Китап уку, әгәр аңа бер иялəшеп китсәң, бик мавыктыргыч эш бит,—дип дәвам итә ул.—Ашаучүне дә онытасың... Бик күп мәгълүматларны, бик күп рухи байлыкны без китаптан алабыз. Китап ул—кешенең гомерлек юлдашы... Әгәр миңа, бала чагыма кайтып, укуны янадан башларга туры килсә,—дип яза ул,—мин баштарак төрле илләр, халыклар турында язылган популяр китапларны укырга тырышыр идем. Ни өчен? Бердән, аларны укуы бик күңелле, икенчедән, бик кирәк тә икән. География белән тарихтан яхшы хәбәрдар булу ул киләчәктә, әйтик,

дөнья әдәбияты белән танышканда, бик зур ярдәм итәчәк икән *(шунда ук)*.

Ә. Еники төплерәк белем алу өчен егерменче елларның икенче яртысында Казанга килә һәм университетта оештырылган рабфакка укырга керә. Бу чорда авыллардан, шахталардан күпләгән яшьләр шәһәр уку йортларына килеп тула. Әмма ул чор—ыгы-зыгылы, шаукымлы; кешеләрне чыгышы белән гаепләп, укудан куган чак. 1926 елда Фатих Әмирхан фани дөньядан китә, аңа «либераль буржуа» мөһерен басып куялар, Г. Тукайдан вак буржуа шагыйре ясыйлар. Яшь язучыларны да берәм-берәм әдәбияттан куу башлана. 1927-28 елларда зыялыларга донос көчәеп, Ә. Еники дә, әлеге рабфакның I курсын тәмамлагач, китәргә мәҗбүр була. Үзе әйткәнчә, бу инде аның «рабфактан икенче тапкыр китүе» икән. Яшәү өчен эш эзләү кирәклеге алга килеп баса.

Ул рабфакта укыганда байтак кына язучылар белән аралашып өлгергән була, шуңа күрә тиздән «Кызыл Татарстан» газетасында штаттан тыш хәбәрче булып эшли башлый. «Эшләрем бик шәптән булмаса да, һәм матди ягым бик хөрти булса да, редакциядә эшләве күңелле иде,—дип яза ул үзенең истәлегендә.— Кешеләре кызыклы иде. Аннары көлке күп иде—ул чакта кешеләр юктан да көләргә, көлке уйлап чыгарырга ярата лар иде. Такташ үзе юмор капчыгы, Исмәгыйль Рәми бик чая телле, Кутуй—фантазер... Менә ул *(Кутуй.—М. Ж.)* озын, нечкә сыйраклы әкәмәт бер кош шикелле килеп керә. Өстендә—сары эт тиресеннән тегелгән, тезләренә дә житмәгән, шунлыктан гәүдәсен бик калынайтып жибәргән галәмәт йонлач авыр тун, ә нечкә аякларында—кыска галифе, обмотка урап кигән кара ботинкалар...» *(Шунда ук)*.

Казан инде тынычлыгын югалткан, кулга алулар ешайган, шуңа да булачак язучы шәһәрдән югалып тору ягын карый. Җәлил белән икесе Сәмәркандка китәргә язылып, Мәскәүдә тукталгач (бу Урта Азиягә поезд көткән арада), Татбашбюрога керәләр. Мондагы өлкән агайлар яшьләрне Донбасс шахталарына ликбез өчен юллап, путевка бирәләр. Шулай Ә. Еники татар шахтерларын язга кадәр укытып, туган иленә кайта. Аннары Урта Азия якларына китеп, укытучы булып эшли, бары сугыш башланган көннәрдә генә сагындырган шәһәренә кайтып төшә. Урамнарда аңа борчулы кешеләр, хәвефле йөзләр очрый. Еники хәрби комиссариаттан чакыру көтеп яши һәм, озак көттермичә, 1941 елның июль аенда фронтка китә. «Мин сугыш вакытында әдәбиятка кайткан язучы,—дип яза Әмирхан ага үзенең «Язу—намус эше»,— исемле мәкаләсендә.—Менә дәһшәтле авыр елларда күргән-кичергәннәрем сәбәп булгандыр, дип беләм. Гомумән, мин үз иҗатымда күбрәк тормышта күргәннәргә яки ишеткәннәргә таянырга тырышам» *(«Казан» журналы, 1998 ел, 5-6 саннар)*.

Аның фронт шартларында язылган «Бала», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге», «Бер генә сәгатькә» кебек әсәрләре психологик тирәнлеккә, рухи нәфислеккә ия һәм кыска, киеренке сюжетлы әсәрләр буларак үзенчәлекле. Соңыннан, тыныч хезмәткә күчкәч тә, Ә. Еники сугыш темасын чагылдыруга байтак әсәрләр багышлый: «Кем җырлады?», «Без дә солдатлар идек», «Рәшә» повестьлары моңа ачык үрнәкләр.

Әмирхан Еники тыныч хезмәт көннәрендә дә актив иҗат итүче язучыларыбызның берсе булды. Аның «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Вөҗдан», «Әйтелмәгән васыять», «Ялгызлык», «Туган туфрак», «Төнге тамчылар», «Гөләндәм туташ хатирәсе», «Соңгы китап» кебек хикәя-повестьлары алтмышынчы, житмешенче еллар прозасын бизәп торалар.

• • •

Әдипнең иҗат лабораториясе дә кызыклы. Ул бер әсәрне дә тота-каба язмаган, озак уйланып йөргәннән соң гына язарга алынган икән: «Әсәрнең темасын миңа мәрхүм Баязит Бикбай биргән иде, дип искә ала ул «Әйтелмәгән васыять» хикәясе турында.—Дөресрәге, бер башкорт карчыгының аяныч үлемен сөйләгән иде... Уйла, бәлки язарсың, синең каләмгә туры килә торган нәрсә бу, дигән иде. Ләкин минем тиз генә эләктереп алып язып ташлый торган сәләтем юк... Бер ел-ел ярым вакыт узгач кына мин аны тәвәккәлләп язарга керештем. Башкорт авылын, башкорт картларын яшьтән үк күреп үскәнгә күрә, алар миңа яхшы таныш һәм якын иде... Кыскасы, «Әйтелмәгән васыять» әнә шулай язылды» («Хәтердәге төеннәр»).

Иҗат эше гаҗәп нәрсә бит ул, мәшәкатьле дә, авыр да. Әмирхан ага миңа «Саз чәчәге» повестен ничек язуы турында сөйләгән иде. «Минем өчен иң кыены—әсәрне башлап җибәрү,—диде ул.—«Саз чәчәге»н башлау турында шактый уйланып йөрдем. Башкортстанга танышларга барып чыккач, чәй эчкән вакытта, кинәт аның беренче җөмләсе искә төште, һәм мин тиз генә урынымнан торып, куен дәфтәремә язып та куйдым. Шуннан соң әсәрне язып чыгу авыр булмады».

Әсәрне язу бер нәрсә: әмма аны бастырып чыгару мәшәкате кычкырып тора бит әле. «Язучылык эше—акыл һәм йөрәк катнашыннан туган авыр эш,—дип яза Әмирхан ага үзенең истәлегендә *(«Долгая жизнь», «Казань» жур. 5-6 саннар, 1998)*. Таләп зур, җаваплылык бихисап,—дип дәвам итә ул,—ә иҗатның төп мәгънәсе—ышанычта, инанып, теләк белән язуда». Шулай булгач, төрле тоткарлыклар, ясалма киртәләргә дә карамастан, язучының әсәрләре хаяткә юл яра. «Саз чәчәге» (1956) басылып чыккач та, тәнкыйть, ду килеп, авторны гаепләгән иде; янәсе, коммунистлардан яшерен көлү сизелә түгелме... «Рәшә» повесте исә, байтак каршылыклар кичереп кенә дөнья күрә. Шунысы хак, Еникины укыйлар, халык аны үзенеке дип кабул итә. Язучы да «моны үз хезмәтемә туган халкымның иң юмарт түләве» дип кабул итүендә ялгышмый.

* * *

Һәр язучының үз иҗади йөзе, үз кыйбласы була. Ә. Еники моны «Язучының эчке дөньясы» дип атый. Менә шул эчке дөнья, аның әсәрләрендә «үз йөзе булып, көзгедәге шикелле чагыла да инде». («Хәтердәге төеннәр»). Ни дә булса өстәве кыен язучының сүзләренә, халык әйтмешли, хак сүзгә җавап юк. Ә. Еникинең иҗат сере дә кешенең шул эчке дөньясын сурәтләүгә кайтып кала.

«Кешенең бит чын йөзе—эчендә, эчке дөньясында»,—ди язучы яшьләр белән бер әңгәмәсендә *(шунда ук)*. Бу—һәркемне уйландырырлык сүзләр, бу—тормыш хакыйкате. Чорның катлаулы яклары, андагы каршылыклар, төрле конфликтлар, гаять киеренке хәрәкәтне эченә алган яшәеш—барысы да укучыга олы язмышларның психологиясе аша, аларның эчке дөньясында бара торган тирән агымнар аша гына житә. Ә. Еники хикәя һәм повестьларының үзенчәлеге дә кеше язмышларын сурәтләү белән характерлы. Әмма язмышларны төрлечә тасвирларга мөмкин бит әле язучы. Гомумән, язма сәнгатьтә шәхес дөньясына киң урын бирелүе мәгълүм. Моның классик үрнәкләре дә байтак: Гюго, Бальзак, Флобер, Мопассан, һәм дә ки, XIX гасыр буе иҗат иткән күрше рус әдәбиятында да уңдырышлы туфракка салынган традицияләрнең (Достоевский, Л. Толстой, Чехов, Тургенев, Лесков, Куприн, тагын башкалар) бүгенгә көнгә килүенә юлыгасың.

XX гасырның алтмышынчы-сиксәненче еллар татар прозасында матур үсешне тәшкил иткән якты кыйбланы Еники әсәрләреннән башка күз алдына китерә алмыйсың. Бу кыйбла иҗатка сискәндерерлек этәреш биреп, үзенең оригинальлеге, мәгънәви тирәнлеге, тасвири осталыгы белән укучы күңелен яулый, аның уй-гамь дөньясын уятып, онытылмас яшәве белән гыйбрәтле вә реаль. Хикмәт нидә?—диярләр. Бөтен хикмәт сәнгати әсәрнең психологик эчтәлегендә: аның персонажларыннан алып, психологик пейзажына, психологик детальләренә, психологик диалогларына кадәр сурәтләнгән үтә җыйнак һәм киеренке төзелгән сюжетына тап буласың. Әйтерләр, психологик дөнья башка язучыларда юкмыни? Әйе, оста каләм иясенең иҗат байлыгы моннан башка яшәвенә ышанасы да килми.

Ф. Хөснине, А. Шамовны, Г. Бәшировны, И. Газины, А. Гыйләҗевне аласынмы, һәм гомумән, алтмышынчы-житмешенче еллар прозасының эволюциясе шушы психологик якны сурәтләү белән алдыра шикелле. Тик һәр чәчкәнең үз гүзәллеге, үзенең хуш исе булган кебек, Еникинең, беренчедән, тасвирлаган вакыйгасы, шәхесе һәм кешеләре психологик дөнья белән уратып алынган булса, икенчедән, ул шул эчке дөньяны төзүче сәнгати кануннарның үзе өчен яраклы үзенчәлеген табып гәүдәләндерә ала. Ачыграк әйткәндә, эстетик анализны шуна юнәлтеп, әдәби тәнкыйтьтә еш телгә алынган «Ә. Еники—психолог», дигән төшенчәнең нидән гыйбарәт икәнен ачыклыйсы килә.

Ә мондый омтылыш безне Еники стиленен үзенә генә хас ягына, әсәрләрендәге форма белән эчтәлекнең сурәтләнеш гармониясенә, анын уйлы дөньясынын хиссиятенә, киеренке тойгылардан үрелгән күнел ачышына илтә. Шул нәүбәттә әдип эчке агымнарны, көтелмәгән борылышлы хәлләрне ясап куя. Бер ноктадан этәрелеп китеп, калган геройларнын уй-хис дөньясы үз эчендә кайный, үзенчә каршылыклы агымнар тудыра, фикри кичереш һаман эчкә, тирәнгә китә дә, әсәрнең тармаклы сюжеты ясалып, ул бер кинәя, бер жыела, әмма сәнгати төзеклек югалмый. Шушы жирлектә психологик герой бирелешендәге беренче үзенчәлекне—анын үз эчендә күптөрле тавышлар тудыра алу сәләтен әйтеп була.

Үзәк геройның күнел дөньясында урын алган башка персонажлар исә, төрле юнәлешкә киткән хис агымын гына тудыралар. Үрнәк өчен «Йөрәк сере» (1957) повестена мөрәҗәгать итик. Әсәрнең төп герое Зөһрәнең эчке тавышында ярәшелгән егете Нәҗип, һәм очраклы танышкан Бәхетгәрәй белән киеренке мөнәсәбәте, шунын өстәвенә әтисе, әнисе белән кискен бәрелешләре яктырып күренә. Бу геройларнын һәркайсы үз карашлары, үз кичереше, үз дөньясы белән яши. Зөһрәдән тармакланып, үсеп киткән хисләр агышы сюжетны урап ала да, ана бөтенлек бирә һәм финалны да ясый.

* * *

Әдипнең байтак хикәяләре дә шундый ук стильдә язылган. «Төнге тамчылар»нын (1964) баш герое Хәлил Ишмаевнын эчке дөньясында, уйлана торгач, үз тавышлары белән башка персонажлар туа. Анын сагышлы кичерешләр дулкынында һәркайсы үз язмышы белән калка, үз аһәне, үзенең психологик интонациясе белән янгыраш ала: «Бик нәфис, бик чибәр иде бит ул, шайтан алгыры!—дип борчылып уйлана татар теле профессоры Ишмаев.—Озаграк карап торсан, кара кайма булып күренгән ул күзләрнен төбендә акрын гына эреп югалгандай шикелле тоя иден үзенне... Ак күбәләк кебек нәфис, жинел, нечкә жанлы булганга күрә Ләйлә исемле иде...» (Сайланма әсәрләр. II том. 1971 ел). Шундук икенче персонаж—профессор Хәлил Ишмаевнын үз хатыны гәүдәләнеш таба: «Мәрвәр ханым сизә калса, утыз сигезле башмаклары белән бөтен саф хисләренне таптап изәр... Үткәннәр турында сагышлы бер уйлануы дип тормас. Карт алаша, күрсәтермен мин сина Ләйләне, закон минем якта, дип кенә жибәрер» (шунда ук). Әйтеп тә торасы юк, һәр ике ханымнын капма-каршы сыйфатлары ачык күренә. Утызынчы елларда фәнгә очраклы үрмәләгән әлеге Ишмаев үзенең чуалчык тормышын укучы хөкеменә куя: анын болганып яшәвендә үҗәтлек тә, үз-үзенә мәсхәрәле янау да бар.

Иҗат таңынын элгәрерәк балкышында пәйда булган «Бер генә сәгатькә» хикәясе дә (1944) психологик сурәтләргә нигез булырлык әлеге үзенчәлеккә ия. Фронтка үтешли командирыннан рөхсәт алып, солдат Гомәрнең туган йортына тик бер генә сәгатькә кайтуы бу. Хикәядә персонажларнын катлаулы, аптыраулы кичерешләренә юлыгасын. Улын кинәт күрү белән ата-анасынын куанычы, жингәсенең үксеп жибәргән тавышы, ул да түгел, ун яшьлек Зәйнәпнең сөенеченнән абыйсына килеп сарылуы минут эчендә юкка чыга. Чөнки солдатнын «бер генә сәгатькә» керүен әйтүе белән «елмаерга өлгермәгән кояшнын кинәт кара болыт артына яшеренүе кебек иде»,—дип хикәяли автор. «Бу хәбәр тәэсире барысына да шундый булды ки, гүя ул Гомәрнең авызыннан чыкмады, ә кайдандыр стена аша килгән ят, ямьсез бер тавыш булып ишетелде, һәм алар бу тавыштан ничектер барысы берьюлы кинәт катып калдылар...» *(Сайланма әсәрләр. I том. 1970 ел).* Аннары инде хисләр «казаны»нын ничек кайнавына, хикәя геройларынын ни хәлдә калып, аларнын гаҗәеп житезлек белән үзгәреп торган көчле кичерешләренә тап буласын.

Ә. Еники сурәтләвенең икенче психологик үзенчәлеге—герой хисләренең тышкы дөнья белән каршылыкка керүендә. Башкорт халкынын олуг анасы Акъәбинең хисси халәтен нәкъ шушы үзенчәлекнең якты үрнәге диярргә кирәк. Повестьнын исеме үк серле—«Әйтелмәгән васыять» (1965), ул баш геройнын йөрәккә үтә торган язмышы белән бәйле. Ана үз балалары белән эчке һәм тышкы бәхәскә керә, хаста карчык үзенең үпкә-сагышлары белән һаман ялгыз кала; анын борчулы уй-кичерешләрендә жанланган улы Суфиян, гыйльми

хезмәткәр кызы Гөлбикә, җаваплы урында утыручы «акыллы кияү» һәм тагын башка шәһәрләрдә тыныч кына яшәп ятучы улы белән кызының тормышы— болар һәммәсе укучыны заманча проблемаларга юнәлтә, күңелне кузгатып, моңсу уйларга күмә.

Авыру карчыкның көйрәп яткан эчке газаплары бермәлгә ачылып китә дә, ана шагыйрь тавышы кушылып, менә мондый психологик диалог ясала:

«—Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

—Ни сөйлисең син, улым, синең әсәең бардыр бит?!

—Юк шул, юк. Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр...

—Рәхмәт, улым!—ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь, тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

—Юлкотлыны сагынасыңмы?

—Сагынам, улым!» *(Шунда ук).*

Монда һәр ике геройның үз эченә яшерелгән хисләр тирәнлеген әйтелеш интонациясе бирә. Авыру ананың «Сагынам, улым!» фразасында инрәүле гаҗиз тавышы ишетелгән сыман тоела. Бу исә, хәзерге чорны үткән белән тоташтыручы буынның фаҗигасе. Акъәби үзенең моңсу-тын даласын сагынып-сагынып та, әйтергә теләсә дә, әйтә алмаган васыяте белән китеп бара. Мәгълүм ки, заманы белән зур каршылыкка кергән шәхеснең көйсез тәкъдире монда бик реаль чагылыш таба.

Психологик тасвирда «тавышны» еш очратып булмый диярлек. Еники исә, тавыш тембрыннан, сүзнең ничек әйтелеш агышыннан читләшми генә түгел, бәлки шуның катламлы тирбәлешен, куәтле тәэсирен күңел кылларына сала; ул тәэсир синең хәтереңә йә үкенечле хакыйкать, йә назлы моң, йә зарлы сөю, яисә якты сөенеч булып инә. Хисси фикер һаман тәрләнеп, тирәнгә, бик тирәнгә китә. Аны бары сүзнең дәвамлы өч ноктасы, өзек эчке тавышлар, уйнакчыл басымнар гына тыңлаучыга җиткерә ала.

Тагын шуны да өстәргә кирәк: Еникидә әдәби геройның ясалышы аз сүз белән бирелгән диалоглардан, кичерешләр тирбәлешеннән, үзенә хас мимика, ишарә ярдәмендә туган чырай үзгәрешләреннән, зирәк күз карашыннан гыйбарәт. Диалогик формага кыскалык һәм үткенлек биреп, язучы эчке мәгънәле, кинаяле сөйләмгә ирешә:

«...Нәкъ шул чакта кемнеңдер урам яктан зал тәрәзәсен бик каты итеп кагуы ишетелде. Төш кинәт өзелде, Зөфәр сискәнеп, күзен ачып җибәрде. Ул ни дә булса уйлап өлгергәнче, залда яткан әнисе Тайбә абыстай торып тәрәзәгә барган иде инде.

—Кем ул, ни булды, пожармы әллә?—диде карчык куркынган тавыш белән.

Урамнан бер хатынның бик кабаланып нидер кычкыруы ишетелде. Зөфәр күпме колагын салып ятса да, аның сүзләрен аера алмады, тик ахырдан көлепме, елапмы җибәрүен генә ишетеп калды. Ул да булмый, бүлмә ишегендә Тайбә абыстай күренде. Аның йөзенә карау белән Зөфәр ниндидер галәттән тыш хәл булганын сизеп алды.

—Улым, тор әле,—диде Таибә абыстай әкрен генә, серле һәм сөенечле тавыш белән.—Әнә күрше Митриләрнең килене килгән, сугыш бетте ди...

—Сугыш бетте?..

—Әйе, сугыш бетте, ди, хәзер генә радиодан әйттеләр, ди, нишләп ятасыз, ди...» *(Шунда ук).*

* * *

Әмирхан Еникидә әдәби характерның үз эчендәге каршылыгы психологик сурәтләүнең өченче билгесе булып истә кала. Тышкы якның эчке халәт белән ярашмавы кебек табигый канунчылык язма сәнгатьтәге психологик күренешнең кызыклысы, һәм ул геройларның үзенчәлекле, төгәл бирелешен тәэмин итә. Кеше драмасының күзгә бәрелеп тормаган әнә шул каршылыклы сыйфатын тәфсилле тасвирлавы белән ул укучыны янача уйлауга, янача фикерләүгә этәрә. «Шаяру» (1959) хикәясенең героинясы Диләрә ханым тышкы чибәрлеге, мөләемлелеге

белән Зөһрә («Йөрәк сере»), Клара («Туган туфрак»), Гөләндәм («Гөләндәм туташ хатирәсе») шикелле гүзәл туташлардан калышырлык түгел. Яшь ханымның чибәр портреты беренче карашка сокланугa якын табигыйлеккә ия:

«Өстендә анын тулылана башлаган гәүдәсенә ыспай ятып торган тар итәкле, ачык изүле, әфлисун төсендәге йон күлмәк, аягында кара «лодочка» туфлиләр, ялангач беләгендә кечкенә алтын сәгать. Куллары аның бик ак, бик нәфис, тырнакларына тип-тигез алсу кына салган, бер бармагында кечкенә бриллиант каш яна. Чем кара шома чәченең озын толымнарын бик пөхтәләп артка өеп куйган. Һәм ап-ак муенында сөйкемле генә кара мине дә бар... Сөрмәле күзләре, кара керфекләре дә берәмләп диярлек югарыга һәм түбәнгә матурлап бөгелгән—кыскасы, әнә шулай шартына бик житкереп көязләнгән, үзе чибәр, үзе яшь, үзе нигәдер боек бу ханымга игътибар итмичә узарлык түгел иде». *(Шунда ук).*

Әмма шундый тышкы чибәрлек ханымның эчке дөньясына тәнгәл килеп бетми шул: тук яшәүгә җайлашкан героиняга баш түбәсе агарып калган өлкән ир дә килеп кушылгач, аның элекке тышкы бизәкләре уңып киткәндәй була. Бигрәк тә студент яшьләр белән мөнәсәбәттә бу ханымның шактый ямьсез эчтәлеге тырпаеп күренә, аның шаяруы да күңелгә рәнҗүле сагыш кына сала.

Автор бәхетсезлекне күрсәтеп кенә калмый, бәлки аны барлыкка китергән сәбәпләрне дә ача: талымсызлыгы, карашының тарлыгы, ваемсызлыгы бу яшь ханымны тормыш эргәсеннән төшерә; рухи ярлылык аны фаш итә. Бу, үз чиратында, чынлык хөкеме булып, укучыны сагаюга, уйлы гыйбрәткә китерә.

Ә менә «Матурлык» хикәясендә шәкерт Бәдретдиннең әнисе беренче карашка бик чирканыч, күңелсез тәэсир калдыра. Әмма ямьсез ана белән чибәр улның үзара ягымлы мөнәсәбәте соклангыч та, гажәпләндерә дә. Бәдретдиннең үзе ясаган скрипкасында «Салкын чишмә» көен өздереп уйнавын тыңлаган шәкертләргә, «әнисен ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп торган кебек». Башта килеп бәрелгән мескенлек тойгысы соңрак җуела, шәкертләрнең күңел үксүен ананың куанычлы, нурлы дөньясы басып китә. Геройның үз эчендәге капма-каршылыгы хисләр дулкынын айкап җибәрә; инде матурлык төшенчәсенә караш үзгәрә, кешенең эчке матурлыгы тагын да кыйммәтрәк, мөһимрәк булып кала. Психологик геройлар бирелешендәге мондый үзенчәлекне язучының башка әсәрләрендә дә очратып була. Зөфәр Сабитов («Рәшә»), Нажия («Саз чәчәге») образлары бу төргә кулай үрнәкләр.

Гомумән, Ә. Еникинең тойгы катламнарын оста үрә, психологик процессларның үзгәрәк якларын сурәтли торган язучы икәнлеген укыган саен тирәнрәк аңлыйсың. Вакыт-вакыт геройның эчке дөньясы үзе психологик процесс мәйданына әверелеп китә. Бер тамырдан шытып чыккан яшь үрентеләр кебек кичерешләр таралып китәләр дә, каршылыклы, әйләнеч юллар үтеп, шул ук ноктага урап әйләнеп кайталар, әмма яна бәрелешләр хисләрне тагын да тирәнәйтеп җибәрә. Гаилә көйсезлегеннән суд алдына баскан Зәбировның («Яшьлек хатасы») эчке дөньясы каршылыклы хисләр белән тулы: ул тыштан яуган сорауларга җавап бирерлек түгел. Егерме өч еллык гаилә газабы аның уй-хис дөньясы булып, эчке бәхәстә генә юнәлеш ала. Суд утырышы бары киеренке тойгының этәрелеп киткән ноктасы гына, ә төп процесс геройның эчке халәтендә, ул, төрле борылышлар ясап, элекке ноктага килеп тоташа.

* * *

Язучының эстетик фикерләвендә психологик процессның дүртенче үзенчәлеге—пейзажны, табигать образын сурәтләве аша яңарак сыйфатлар табуында. Әдип кеше йөрәгенең уй сөрешен, аның үзенә генә хас тирбәлешләрен, әле күтәрелеп, әле төшеп торган дулкыннарын пейзаж ярдәмендә ачып сала. Табигать күренешләренең аерым кисәген генә, агачларның берсен генә, чәчәкләрнең бары бер оясын гына алып, язучының ачык бизәкләргә дикъкатьне тартырлык рәвештә ихлас тасвирлавы үтә тәэсирле чыга. Уйсу җирдә бер оя булып үсеп утырган, сары гәрәбәдәй тамып торган ут чәчәкләре («Саз чәчәге») матур, бик матур. Райком секретаре Мостафин ана ихтыярын югалтып, сокланып карый. Тик шул ут чәчәкләре агулы икән, яшь председательнең характерлавынча, «бик зәһәр булганы өчен аларны ут чәчәкләре диләр икән. Менә син аны тотып

иснәсәң, тәчкертә ул, капсан—авызны уттай яндыра, ышкысан—тәнне боза. Так что алама нәрсә, шуңа күрә мал да ашамый аны». *(Шунда ук).* Никадәр ачы алдану! Мостафинны әнә шул «ут чәчәге» үскән Майпәрвәз сазлыгы әчкә суырып алганга күрә, фаҗига тирәнәеп күренә.

Язучының мәк чәчәге образы да бер бөртек бизәк кенә («Мәк чәчәге»). Бомба төшеп казылган чокыр төбендә бер генә бөртек мәк чәчәгенең балкып утыруы үзе могҗиза диярлек. Фронтка үтүче солдатлар аның яныннан аерылып китә алмыйлар. Чәчкә һәр солдатның йөрәген айкап ала: тыныч көннәрне, еракта калган газиз кешесен, шушындый ук чәчәкләр үсә торган туган җирен искә төшерә. Шунысы гаҗәп: тирә-яктагы сугыш афәтенә исе китмичә, уттай кызыллыгы белән янып торучы бу чәчәк—тормышның дәвамын, тереклек көченең сүнмәвен әйтеп тора. Реаль эчтәлекле, гаять матур бу шартлы образ укучының күңел дөньясын тибрәтергә җитә кала.

Идел образы язучының әсәрләрендә шулай ук еш очрый. («Шаяру», «Рәшә» һ. б.). Аның «Рәшә» повестенда беренче сиземләүдә үк Идел бик киң дә, бик кечкенә дә кебек, ягъни ул бер мизгелдә ике төрле һәм капма-каршы ассоциацияне үти. Рәшидәнең «Зөлхиҗҗә җыры» төнге манзараны, кара сулы киң Иделне урап алган. Рәшидәләр «көймәсе күзгә күренмәс дегеттәй кара суны авыр ерып акрын гына бара шикелле, ләкин каршы якка бер дә якынаймый төсле иде. Әллә ничек менә җир дә, кешеләр дә моннан бик-бик еракта кебек. (Шунда ук.) Алай ук ерак түгел икән, җыр белән ярга якынайган көймә шул киңлек хисен үзенә җыеп өлгерә, Иделнең бары көймә ерып барган су юлы гына хәтергә нык сеңеп кала. Бу исә, көйсез язмышның озак юлы булып та, билгесез мәхәббәтнең тынгысыз бүгенгесен дә сиздереп куя. Шул рәвешчә, Идел әледән-әле психологик вариацияләрнең уйнаклавын белдереп тора, ул һаман да эчке дөньяга юнәлгән булып, персонажның тышкы күренешләргә капма-каршылыгын ачып күрсәтә.

* * *

Татар прозасында тау пейзажын реаль сурәтләгән язучы да—Әмирхан Еники дияр идем. Ул ана ерак тарих иңкүлегеннән килә торган кырыс моңсулык бирә, биеклекләрне иңләп алу аркасында халыкның тереклек чишмәсен ачып җибәргәндәй итә. Локман картның өзелмәс чылбыр булып килгән гомер юлын автор «Тауларга карап» хикәясендә күрсәтә. «Локман өенә кайтып төшкәч, тарантаска аягүрә басып, уң кулы белән бөеренә таянып, тауларга карап күпме кунаклар алдында көр тавыш белән сузып җырлаган иде...

Агыла болыт, ай агыла,
Таулардан да тауга кагыла...» *(Шунда ук).*

Ә менә гомер үткәч тә, карт күңелендә изге хатирә булып, сугышларда корбан булган уллары, оныклары, бөтен нәсел җебе таулар тезмәседәй сакланалар икән, аның иң соңгы—нәни оныгы Газизҗан да таулар итәгендә, бабасына кайтып килә. Нәсел җебе өзелми, тормыш дәвам итә. Ниһаять, Локман карт үзе дә авылны иң башыннан кочып алган олуг тауны хәтерләтә сыман. Димәк, таулар образы язучының бай хыялына очыш бирә, ул төрле юнәлештәге фикер-хис агышын тудырып өлгерә.

Язучы стилендә дала пейзажы—милли традицияләрнең янаруын искәртеп тора торган онытылмас бизәк. Күз күреме житмәслек ераклыкларга сузылган дала башкорт халкының хөрлек яраткан ашкынучан характерын, киң күкрәк авазы булып ишетелгән куәтле моңнарын бик тулы чагылдыра. Шул яктан дала образы бик тәэсирле, ул—халыкның борын-борыннан килгән туган җире, туган моңнары, бөтен яшәү образы, тарихы лабаса. «Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш селкеп, акрын гына, кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да, чабасы килә... Дала буш, дала киң, җир жылыкай, шаян җилкәй биттән сөя. Рәхәт тә, һәй рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу... Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш башкорт даласында...» «Әйтелмәгән васыять» хикәясе шушындый пейзаж сурәте белән башлана. Хикәянең герое Акъәбинең тормышын башкорт даласыннан

башка күз алдына китереп булмас иде: Акъсылу, Акъкилен, Акъжингә һәм дә ки Акъәби булып башкортның каршылыклы тарихы, мәгънәле дөньясы, монсу табигате вә гайрәтле рәнжеш тулы җырлары, ярсу батырлыгы кылганнар символында гәүдәләнә. Табигатьнең куенына ук кереп яшәгән бу кардәш халыкның караңгы тарихын, сакланган гуманистик табигатен, әмма бүгенге юл чатындагы янаулы үзгәрешләрдән туган билгесез кыйбласын да, бернигә ярашмый юл ярып барырга күнеккән бөтен бер халәтен дә чагылдыра сыман ул «тын, буш, монсу башкорт даласы». Нәкъ шушы әйтелгәннәрнең яшәешен, аларның мәгънәви тирәнлеген куәтләп киң дала образы икенче әсәрдә («Рәшә») бөтенләе белән диярлек тискәре ассоциация уята. «Зөфәр төшендә күргән дала тын, очсыз-кырыйсыз. Үләннәре саргаеп кипкән... Төпсез күктән кызган тимердәй ап-ак кояш туп-туры аның күзенә карый». *(Шунда ук.)* Мондый дала күренеше сәүдә эшендәге коммерсантның болганчык, астарлы тормышын ачуга бик кулай килә. Чөнки, әсәрдәге «буш, корган башкорт даласы» киләчәк вакыйгаларга мон өсти, геройлар язмышына сугардай хәтәр яшеннәрне укучы сагаеп көтә.

Ә менә һәртөрле үзгәрешнең, хәрәкәтнең дәвамлылыгын, табигатьтәге өзлексез алмашынуларның танып-белүгә этәреш ясавын җанлы сурәтләп, автор укучының зиһенен, хис дөньясын уятып җибәрә. Кыш белән язның тартышын, ел вакытлары алмашынуын күрсәткән эпизодны искә төшерик. Мондый нечкә күзәтүчәнлек табигать кочагында яшәгән авыл кешесенең үткен акылын, күпьеллык тәҗрибәсе аркасында крестьянча зирәк фәлсәфәсен искәртеп тора. «...Әмма март аеның шушы салкын һавасында каядыр якынча гына йоклаган язның сулышы сизелә, гүя ай батып, йолдызлар сүнгәч тә, кышкы төн урынына язгы көн балкып туачак. Таң үзе дә хәзер күктән генә иңмичә, җирдән дә күтәрелә кебек. һәм караңгылык ике уртада эреп югала төсле... Әйе, бу вакытларда кыш белән язның янәшә—берсенең монсу-хәлсез, икенчесенең—йомшак-дәртле сулавын һәрбер җан иясе сизеп тора». *(Шунда ук.)*

* * *

Ә. Еники үз геройларының җанлы портретын да табигать детальләре белән баета, аңа төс-бизәкләрне сайлап ала белә. Шуның белән ул геройның индивидуальлеген ассызыклап күрсәтүгә ирешә: Зөһрә («Йөрәк сере») «хәзергә әле ачылмаган чәчәк бөресе» шикелле булса, җырчы Рәшидә исә («Рәшә») исәпле Зөфәргә «эссе якның хөрмәсе кебек гаять ят җимеш, сезонный җимеш» кенә. Табигать детальләре белән автор геройның әле бер ягын, әле икенче ягын ачып куя; кайвакыт төрледән-төрле бизәкләр кабатланып килүе аркасында персонажның килеш-килбәте бик төгәл күз алдына килә. «Гөләндәм туташ хатирәсе»ндә Салихның ишектән килеп керүенә ин элек менә шул «ак маңгае белән урман күледәй зәңгәр күзләре» игътибарны билэп ала. Әдәби текстта кабатланып килә торган мондый эпитетлар, ничек кенә булмасын, персонаж турында төпле бер мөнәсәбәт, җылылык һәм ягымлылык тудыруга ярдәм итә.

* * *

Җыр—Еники стилендә психологик процессның бишенче үзенчәлеге булып килә. «Кем җырлады?» хикәясендә җырның табигать образы белән үрелеп, моң ташкыны, җан тынычлыгы биреп балкуына юлыгасың. Татар кызы Таһирә фронтка үтүче үз вагоныннан караңгы төн кочагында моңлы җырлар суза. Караңгы төн, вак яңгыр шавы ут эченә баручы кызның хәтәр язмышы, гомумән, сугыш хәвефен гел сиздереп, күңелне борчып, тынычсызлап тора. Ә менә милли моң каршы вагонда үлем салкыны сырышкан яшь солдатка туган як табигатен башкача ясап куя: «яралының күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек. (Шунда ук.) Җыр тирбәлешендә туган як табигате хикәянең сюжетын төзи, егет күз алдында аның Таһирәгә беренче мәхәббәте, яңа ачылган яшьлеге булып та тасвирлана. Язучының стиле җыр кебек ага. Солдат авыр, саташу мизгелендә шулай җан бирә. Яшь егетнең үлеме безне реаль дөньяга кайтара, «калкулык өстендәге ялгыз нарат төбендә

егетнең кабере» генә торып кала. Монда миллион корбаннарны йоткан сугышның тере фаҗигасен, югалтуның авыр газабын тоясың.

Халык моңнары язучының күп кенә әсәрләрендәге геройларның рухи халәтен урап алып, ул яшәешнең үзе, саекмас хәят чишмәсе, илаһият биргән сәләте, кабатланмас биеклеге булып, өскә, югарыга китә: «Җиз кыңгырау» (1969) истәлек-хикәясенең герое Нигъмәтулла абзыкай «нечкә тавышы белән җыр суза башласа», мәҗлес тә тынып кала:

Утырдым ла көймәнең ай түренә,
Карадым ла суларның төбенә.
Су төпкәйләрендә һич кара юк,
Хак язганын күрми чара юк.

«Кеше мәрткә киткәндәй сагышка, хыялга чумды,—дип тасвирлый Әмирхан ага үзе дә моңнар эченә йотылып.—Кемгәдер яшьлеге кайтты, кемнеңдер заяга узган гомере күз алдыннан кичте, кемнеңдер күптән онытылган ярасы ачылды, әмма барысын да ниндидер бер искиткеч ләззәт-шашыну биләп алды». *(Шунда ук.)* Әйе, җыр сәләтенә ия булганнар күпләр арасында нур чәчеп тора. Мәгълүм ки, тырышып-тырмашып кына җырчы булырга мөмкин түгел. Бары илаһият биргән талантны гына үстерергә, үзенә юл ярырга мөмкин. Әнә «Җиз кыңгырау»— үзе моңлы музыка, ул күшеккән күңелләрне, җир-күк ераклыкларны урап ала да, яңгырашлы чыннары белән ага да ага. Шуңадыр ахыры, җиз кыңгырау тәңкәләр сипкән саен «кырлар уянып киткәндәй булды,—дип дәвам итә автор,—тургайлар гүя сискәнеп, тагы да югарыга күтәрелделәр». Кеше менә шундый тирән моң катнаш күңел байлыгына ия; язучының самими осталыгы исә укучының акыл сөрешен, хис тирәнлеген, көткән өметен уятып җибәргәндәй итә.

«Курай» да кичерешле моңнарга бай, җыйнак сюжетлы лирик хикәя. Курайның татар, башкорт халкында күптәннән яратып уйнала торган уен коралы икәне мәгълүм. Табигатьнең үзеннән табылган бу үсемлекне кеше акылы моңнар агышын бирә алу кодрәтенә житкерә. Курай дию белән туган халыкның бәгырьгә үтәрлек уй-сагышларын яңарткан җырлары искә төшә. Әсәрнең лирик герое халык моңнарына гашыйк, ул җырны тыныч кына тыңлый алмый. «Курай уйный башлау белән капкынга эләккәндәй, шып туктап калам»,—дип әсәрләнә малай. Курайга кушылып җырлаучы Котлыяр мулланың далага сыймас иркен тавышы йөрәкләрне әсир итеп ала да, башкорт халкының ирек сөючән табигатен һәм тарих буена сузылган фаҗигале язмышын моңнар чишмәсенә ия булган талантына салып, тыңлаучыга житкерә. Язучы туган халкының музыкаль сәләтенә шулчаклы илтифатлы, җыр исә геройларның күңел галәменә табигый яңгырашлы миллилек бирә. Әйтерсең, халкына мәңге юлдаш булып, моңы белән Тукай мәрхүм үзе торып баса: «И мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз...». Бу көйгә, бу сүзләргә бөтен бер зур халыкның гүя барлык йөрәк зары, саф вөҗданы, ачы нужасы, авыр хезмәте, кара бәхете, якты өмете... барысы-барысы бергә җыелган, бергә үрелгән, бер киң дәрьяга әверелеп ага да ага иде».

Чыннан да, автор сурәтләвенчә, Рәшидәнең («Рәшә») табигый таланты халыкка тоташкан. Ул туган халкы яшәгәндә генә былбыл булып сайрый ала, шул юмарт агачтан шытып чыккан эре бизәкләрнең берсе булып балкып тора. Әлеге искә алынган «Кем җырлады?» хикәясендәге кызның моңы газиз тугайларын, яшел болыннарын, урман-суларын һәм бөтен туган җир күкрәген иңләп, тыңлаучының күңел төпкелендәге хисләрен каядыр өнди, аны эчке мәгънәле якты сагышка күмә. Һәм дә ки, төрле көйләргә бай бу җыр әсәрнең бөтен эчтәлеген бердәм сугарып, сары гәрәбәдәй тезелгән бал кәрәзен хәтерләтә. Ниһаять, язучының җырны ничек куллану осталыгына карап, персонажның эчке дөньясындагы төрледән-төрле хәлләр вә төрледән-төрле көтелмәгән табышлар ачылып китә.

Әл-хасыйл соңгысы, психологик процессның алтынчы үзенчәлеге—детальләр, психологик диалог һәм символлар ярдәмендә милли-тарихи проблеманы реаль сурәтләүдән гыйбарәт.

«Әйтелмәгән васыять»нең финалда бөтен вакыйгаларны җыеп китерә торган «яшел сандык» детале психологик процессның шушы алтынчы үзлеген тулысынча ачарга ярдәм итә. Чөнки сандык эчендәге әйберләрнең һәркайсы диярлек мәгънәви тирәнлеккә ия. Алар башкорт халкының күпьеллык үзгә

хәзинәсен, буынара бәйләнешләрне, тулаем тарихи-милли яшәешен чагылдыра торган символлар. Шунысы дикъкатьне җәлеп итәрлек: Акъәбине заманча гына җирләп мәңгелек дөньясына озаткач та, Юлкотлыдан килеп төшкән сандык аның балаларын яна кичерешләргә күмеп ташлый. Ил анасының кәфене—тирән мәгънәне белдерә торган символ ул, туган халкының кешелеге дә, намусы да, милли яшәеше дә ул. Икенче деталь—бабакайның камчысы—тарих түренә үк алып китә. Башкорт халкының азатлык сөйгән гайрәтле батырлыгына, урыс «туганына» баш бирмәс өчен көрәшенә тере шаһит дияргә генә кала бу «өч җәпле, һәр җәбенең очына көмеш пластинка бөкләп кидергән камчы»ны. Авторның үткен психологик диалогында нечкә ирония белән бүген дә үз көчендә булган милли изүне ачык сиземләргә мөмкин:

«—Да-а, менә бу ичмасам реликвия!—диде кияве дә сокланып.—Тик кем саклар аны?

—Ә аның хуҗасы бар,—диде Суфиян катгый рәвештә, һәм улы Геннадийга борылып тантаналы итеп әйтте:—Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны...

Һәм Геннадий Шаяхметов баш кагып, елмаеп кына өч җәпле камчыны кулына алды». *(Шунда ук.)* Башкача комментарий кирәкми дә шикелле. Башкортның Рәсәй тарихындагы кара бәхете, камчылы юлы әле һаман-һаман да дәвам иткәнлеген шәйләве кыен түгел монда.

Дөрестән дә, хикәянең финалы милли-тарихи кичерешләрнең бер төенгә җыеп китергән өч детале белән тәмамлануы бик оригиналь, минемчә. Ак кәфен дә, өч җәпле камчы да һәм йөз яшәр Миңлебай бабай кабызган сүнмәс учак та... Бер-берсенә каршылыклы мондый өч психологик деталь—авторның отышлы табышы—бөтен югалтуларның тарихи җирлеге, шулай ук туган халыкны киләчәккә ымсындырган хаклы өмете дә.

Мондый үрнәкләрне язучының әсәрләреннән байтак табарга мөмкин. Ә.Еникиның иҗат диапозоны киңлеге, психологик процессларны оста тасвирлавы тәрҗемә эшендә дә ачык чагыла. А. Н. Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» драмасы, К. Паустовскийның «Җәй көннәре» исемле хикәяләр җыентыгы, Ч.Айтматовның «Беренче мөгаллим» повесте аның тарафыннан тәрҗемә ителү үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Шунадыр, безнең укучы яратып укый аларны. 1984 елда Ә. Еники «Юлчы» дигән хикәяләр җыентыгы өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Ә соңрак аңа Татарстанның халык язучысы дигән мәртәбәле исем бирелде.

1996 елда әдипнең кызыклы вә гыйбрәтле уйлануларыннан торган «Кояш баер алдыннан» исемле публицистик җыентыгы дөнья күрә. Тарихи ягы өлкән буынга танышырак төсле тоелса да, ул яңача кабул ителә; без кичергән мәшәкатьле чорларга, андагы киеренке вакыйгаларга үзенчә ачык бәя бирә. Әсәр 1991 елгы Рәсәй хәлләре белән башланып китә, ул чуалчык елларның бер җепкә тезелеп, эзлекле дәвам итүе белән гыйбрәтле.

1998 елда авторның «Санаулы көннәр» исемле истәлеге басылып чыкты. «Сүз белән гамәл, дәрт белән дәрман бер-берсеннән шунча еракта»,—дигән фикерне автордан да үткәзеп әйтеп булмас минемчә. «Русиянең XX гасыр дәвамында кичергән бөтен бәла-казалары, фаҗигале бәхетсезлекләре, түккән каннары өч большевик—Ленин, Сталин, Ельцин исеме белән бәйләнгән. Аларның өчесенә дә власть кирәк булды. Ә власть өчен нишләсәң дә ярый—алдау, көчләү—явызлыктан тыя торган бернинди мораль кагыйдә юк. Большевикларның канына сеңгән бу галәтләр аларның балаларына да күчәчәк әле» *(«Мәдәни җомга» 16, 17 саннар, 1998 ел).* Әйе, дөрес сүзгә җавап юк. Безгә бәхетне көтү өмете генә кала. Әдипнең соңгы язмаларында да Рәсәй сәясәтенең психологиясе бик дөрес ачылган. Гомумән, яшәештәге психологик процесс, автор уйларының, аның күңел төпкеленең үзәген тәшкил итә.

**Мәдинә ҖӘЛӘЛИЕВА**

# СӨЙЛӘР СҮЗЛӘР ӘЛЕ НИКАДӘР

*Мин—шагыйрә. Шулай булгач әле*
*Ник калырга тиеш оҗмахсыз.*
*Гөнаһларым булса ялгыш кына,*
*Ялгышларым минем гөнаһсыз.*

К. Булатова.

Һай бу гомер дигәнең, сизелми дә уза икән—әле кайчан гына безгә урта мәктәптә әдәбият, ана теле укыткан шагыйрә Клара Булатованың тәүге шигыре матбугатта басылып чыкканга да 50 ел (!) үтеп киткән. Ә үзе ул, «Мәдәни җомга» газетасы язганча, «бик матур яшьтә генә бит, аннан элеккечә үк сөйкемлелек, зыялылык, зирәклелек һәм әлбәттә, шаянлык бөркеп тора».

Менә шушы 50 еллык иҗатына аның кырык бер ел мәктәптә балалар укытуын һәм дә 10 ел Әлмәттәге «Нур» телевидениесендә «Җомга» тапшыруларын алып баруын да өстәсәң, Клара Булатованың инде 100 яшьтән дә «өлкәнрәк» икәне күренә. Әйе, илленче еллар ахырында, алтмышынчы еллар башында поэзиягә килеп, анда күптән үз сүзен әйткән, егермедән артык китап чыгарган, 200 дән артык шигырьләренең җыр булып китүен күрү бәхетенә ирешкән шагыйрә бүген дә актив иҗат итә.

Тик ни өчендер беренче шигырьләре белән үк Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек аксакаллар игътибарын җәлеп иткән шагыйрә иҗатына тулаем күзәтү ясаган, аны җентекләп тикшергән тәнкыйть язмалары гына юк дәрәҗәсендә. Дөрес, К. Булатованың 2000 елда «Рухият» нәшриятында дөнья күргән җыентыгына язган кереш сүзендә Равил Рахмани аның иҗатына күпмедер дәрәҗәдә бәя бирергә омтыла, күп кенә шигырьләрен тәнкыйди күзлектән чыгып анализлый. Әлбәттә, кечкенә генә язмада ярты гасырлык иҗатны колачлау мөмкин дә түгел, әмма танылган шигърият белгеченең К. Булатова иҗаты хакында тәүге тапкыр зурдан кубып сүз әйтүе игътибарга лаек.

Без фәкыйрегез тәнкыйтьче дә, әдәбият галиме дә түгел, ул фәкать Клара Булатовадан дәресләр алган шәкерт кенә һәм күпмедер дәрәҗәдә үзенең журналистикага кереп китүендә һәм поэзияне яратуында шагыйрәнең роле зур булуын әйтергә тели.

... Клара Булатова шигырьләрен кайта-кайта укыйм. Һәм гаҗәп хәл: укыган саен алар үзләренең яңа яклары белән ачылалар. Югыйсә, гап-гади алар—аяктан егарлык чагыштырулар да, оригинальлеккә омтылып язылган ясалма юллар да юк. Геройлары да шушы үзебезнең як кешеләре—колхоз рәисе Алмаз, шофер Хатимә, укытучы Галимә, гади шәфкать туташлары, колхозчылар... Иң беренче чиратта нәкъ менә шул гадилекләре, тиз аңлаешлы булулары белән дә җәлеп итәләр икән ул шигырьләр.

Үзенең бер язмасында күренекле шагыйребез Гамил Афзал аны «башыаягы белән авыл шагыйрәсе» дип атаган иде. Бу урында хөрмәтле әдибебез белән бераз бәхәскә керәсе килә. Күпчелек шигырьләре, чыннан да, авылга, аның хезмәтчәннәренә багышланса да, алай дип кенә әйтү К. Булатова иҗатын шактый тарайту булыр иде. Себергә, Кырымга, Әлмәт шәһәренә багышланган циклларны кая куясың?!

Клара Булатова шигырьләрендә күзгә бәрелеп торган иң беренче матур сыйфат—аларда күңел кичерешләренең табигать мизгелләренә тыгыз бәйләнеп бирелүе. Ул шушы Җир кызы, шигырьләренә дә шушы яктан, шушы туфрактан килеп керә. Әнә китап исемнәренә генә күз салыйк: «Җәйләр җитсә», «Язлар алда», «Гел кояшка карап», «Печән өсте», «Миләш кагы»... Әйе, шагыйрә өчен үзе яшәгән як кадерле, чөнки «мәтрүшкәләр монда хуш ислерәк, ромашкалар монда эрерәк».

Тәнкыйтьчеләр кайчак кайбер шагыйрәләр иҗатына бәя биргәндә, «ул ир-ат шагыйрьләр кебек уйлый, алар әйтмәгәнне дә әйтә» дигәнрәк фикерләр

ычкындыралар. Әмма шагыйрә шигырьләрендә иң әүвәле хатын-кыз кичерешләрен һәрьяклап ачарга тиештер, безнеңчә. Күп кенә шигырьләрендә К. Булатова да Ана булып та, бала булып та уйлый. Шуның белән ул буыннар бәйләнешен ныгыта, үткәнне бүгенге белән бәйләп киләчәккә тоташтыра. Әйтик, бер шигырендә: «Әнкәй, сиңа ак чәчләрне күрсәтмим мин, алар өчен оят миңа синең алда»,—дип әнисенә мөрәҗәгать итә һәм шунда уйнап йөргән малае хакында сөйләүгә күчә, аның рәсем ясаганын күреп болай ди:

Дәфтәренә бала чиста язны,
Якты Майны куйган күчереп...
Сакла тормыш, бөтен шул дөньяны,
Вата күрмә аны, кешелек!

Бала психологиясен оста итеп ачу шагыйрәнең «Марс китабы»нда ачык чагыла. Бу китап балалар тарафыннан да, олылар тарафыннан да җылы каршыланды һәм К. Булатованың балалар поэзиясендә дә уңышлы эшли алу мөмкинлеген күрсәтте. Бу уңышта шагыйрәнең укытучы булып эшләве нигез булып торадыр, мөгаен.

Клара Булатова иҗатында тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читкә калып килгән тагын бер тема—ул Бөек Ватан сугышы темасы. Балачагы сугыш елларына туры килгәннәр исеменнән сөйләнгән шигырьләр аның «Һәрвакыт янымда» дигән җыентыгында күп урын алган иде һәм азмы-күпме һәр җыентыгында кабатланып килә.

Кол Галидән калган шигъри сүрә,
Борынгылар язган берәр дастан...
Кайта-кайта төшкә шулар керә
Сугыш чорындагы балачактан.

Мич буенда олы яшел сандык
Әни өскә палас шәлен япкан.
Көйле әсәр укыйм, ятлап алып
Кулга килеп кергән һәр китаптан.

Җыелалар кичен солдаткалар,
Безнең өйдә якты—бишле лампа.
Күз яшьләре белән тыңлый алар
Көйләп мин укыган һәр китапны.

Ул үз шигырьләрендә халык авыз иҗатын рәхәтләнеп куллана. Халыкчан интонацияләр белән өретелгән «Кыз җыры», «Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Бию көе», «Сабан туе иртәгә», «Нәүрүз» кебек шигырьләрдә сөйләм телебездә инде онытылып бара торган матур тәкъбирләрне, сүз уйнаткычларны мул очратабыз.

Асылмалы күпер, асылмалы,
Алты үттем күпер аркылы.
Алты үттем, күңелем басылмады,
Басылмаска купкан, ахры.

Күпер төбе генә зәңгәр капка,
Тугыз гына түгел, ун такта.
Капка бавын ятлар тарткан чакта
Үз дигәнем йөри еракта.

Шагыйрәнең күпләр яратып тыңлый, укыганда күзләрдән яшь китерә торган «Сиңа кайтам» дигән шигыре бар. Югыйсә, темасы һич тә яңа түгел бу шигырьнең: әдәбиятта борынгыдан килә торган тема—мәхәббәт. Шигырь нинди сыйфаты белән алдыра соң? Автор биредә кайберәүләр кебек «ах, яшьлегем үтте» дип сыкрамый, ә тәүге мәхәббәтнең, беренче хисләрнең матурлыгын шигъри детальләр, отышлы табылган чагыштырулар аша укучыга күрсәтеп бирә. Ул аны шул хәтле эчкерсез, шул хәтле самими итеп сөйли ки, шигырьне укыганда син үзең дә геройның «хәленә» керәсең, ул булып уйлый башлыйсың. Поэзиянең көче дә шундадыр, мөгаен.

Без К. Булатованың һәр тапканы алтын дип әйтергә җыенмыйбыз. Беренче язганнары белән үк поэзия сөючеләрнең дә, өлкән шагыйрьләребезнең дә игътибарын җәлеп иткән шагыйрә иҗатында да бер урында таптану, баштагы уңышлардан бераз артка чигенү булып алды. Бу хәл бигрәк тә җитмешенче еллар уртасына, сиксәненче еллар башына карый.

Шагыйрәнең шушы чордагы иҗатында төшенкелек мотивлары

яңгыраган, вак шәхси кичерешләргә генә корылган, сентименталь шигырьләре дә күренгәләде. Тик бу чор да шагыйрә өчен эзсез үтмәде, аның тавышы елдан-ел ныгый барды һәм туксанынчы еллар башына инде без үз шәхесеннән бигрәк дөньяви мәсьәләләр, илдә-көндә барган мөһим вакыйгалар турында җитди фикерләүче җитлеккән шагыйрәне күрәбез. Университетта укыганда хәтта диплом эшен дә тезмәләп—шигъри формада язып укытучыларын шаккатырган Клара Булатова соңгы елларда үзенең көчен прозада да сынап карады—аның «Сөембикә» журналында дөнья күргән «Чучундра» хикәясе һәм әле беркайда да басылмаган повестьлары бәлки киләчәктә аерым китап булып дөнья күрер?!

Аның 200 дән артык шигыренә көй язылган дигән идек. Әлбәттә, арада төрлесе бардыр, әмма «Кырга чыктым, юлга чыктым», «Кыңгыраулар», «Язлары еракта гомеремнең», «Дөмәй буе», «Кыяк үлән», «Ялгыз янам», «Авыл урамыннан баян үтә», «Ә йөрәк соң, йөрәк нишләсен», «Татарстан, бәхет җырым син» кебекләре Зөһрә Шәрифуллина, Асаф Вәлиев, Искәндәр Биктаһиров, Мирсәет Сөнгатуллин кебек танылган җырчылар тарафыннан да, үзешчәннәр тарафыннан да еш башкарыла.

Шагыйрәнең шигырьләре тыңлаучыларга бигрәк тә үзе укыганда ничек тәэсир иткәнен карап торганым бар. Алар берәүне дә битараф калдырмый, чөнки анда безнең хисләр, безнең кичерешләр. Әйе, йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып җитә диләр. Шулайдыр, шагыйрь хакында аның шигырьләреннән дә көчлерәк итеп әйтеп булмый торгандыр...

Өндәү билгеседәй туры
Калырга күпме тырыш—
Сорау билгесе шикелле
Бөгә дә куя тормыш.

Калмады бугай күрмәгән
Шул тормыш юлларында.
Яшәүдән шулай мин мәгәр
Туярга уйламыйм да.

Болай дип тормышның ачысын да, төчесен дә күргән, кичергән кеше генә әйтә ала. Клара Булатова да үз гомерендә авыр балачак та кичергән, югары белем дә алган, Әлмәт шәһәрен төзүдә дә катнашкан, мәктәптә балалар укыткан, кияүгә чыгып үзе дә малай үстергән, әти-әнисен, каенанасын карап соңгы юлга озаткан, хәзер оныкларын карый... Һәм шулардан бушаган арада ул шигырьләр язган! Ә бит кешеләр күңелен яулап алырлык шигырьләр язу өчен хатын-кызга икеләтә батырлык та кирәк әле.

... Ул көн саен яза. Хәтта көндәлеген дә шигырь юллары белән алып бара. Аның әле без күрмәгән, матбугатта чыкмаган, әлегә үз күңелендә генә йөрткән шигырь юллары күп, ниятләре зур. Шагыйрә үзе бу хакта болай ди:

Утлардан—суга, сулардан
Утына керәсе бар.
Аласын алган бу җиргә
Әле күп бирәсе бар.

Бүген шигырь язучылар буа буарлык булса да тумыштан чичәнлек сәләте бирелгән чын шагыйрьләр алай ук күп түгел. Клара Булатова әнә шул азлар арасында.

**Атлас ГАФИЯТОВ**

# МАКТАУ ГЫНА АЗ...

Фирдәвес Хәйруллинаны Г. Камал театрында берәү белән дә бутап-саташтырып булмый. Фирдәвеснен тургай сайравына охшаган тавышы үзе генә дә ни тора!.. Карлыгач канатына охшаган кыйгач кара кашлары, кайнап торган эчке хисләрне бөтен кайнарлыгы белән тамашачыга житкерә ала торган кап-кара зур күзләре... Классигыбыз Гаяз Исхакый, нәкъ менә Фирдәвеснен күзләре кебек күзләр турында: «күзеннән күнеле күренеп тора торган, күзе берлә дөньяны сөясөендерә торган күзләр»,—дип әйткәндер дә әле.

Безнен халыкта: «Үз-үзенне мактама, кеше сине мактасын»,—диган гыйбарә яшәп килә. Хәтеремне актарып, милли актрисабызга үзебез, үз тамашачыларыбыз тарафыннан бирелгән югары бәяләр, алкышлар арасыннан читләр әйткән мактау сүзләрен дә барларга керешәм. Алары да житәрлек икән. Атаклы театр белгече булу өстенә, бик таләпчән театр тәнкыйтьчесе дә саналган Борис Поюровский моннан күп еллар элек «Советская культура» газетасында: «... театрдагы тагын бер героиня—Фирдәвес Хәйруллина турында әйтәсем килә. Ул бик нечкә тоя, гаҗәеп тирәннән эзли һәм өстәвенә эмоциональ хисе тетрәндергеч көчкә ия булган чын артистка да. Атаклы «Татар хатыны»нда Гөлбануны уйныймы ул (концертлар гына китерә ала торган популярлыкка ия ролен), «Әниләр һәм бәбиләр»дәге ана булу теләге белән янган Билгесез хатынныммы—һәр ике очракта да анын күнел байлыгы бетмәс-төкәнмәс, нәфис лирика янәшәсендә үк без чигенмәс ихтыяр көче белән очрашабыз да тәмам танга калабыз»,—дип язган иде.



*«Әбугалисина» (Н. Исәнбәт) спектаклендә Бибкәй-Солтан ролендә.*

Фирдәвеснен сәхнәдәге беренче адымнарын үк күреп соклану насыйп булган иде мина. Марсель Сәлимжанов «Канат җәйгәндә» спектаклен куйганда, Нәфисә роленә үз шәкерте Фирдәвес Хәйруллинаны алды. Беренче ролендә үк ирешкән тәүге сәхнә уңышы яшь артистка шәхесенә театрнын башка режиссерларында да зур кызыксыну уятты. Прәзат Исәнбәт ана шул ук елны Нәкый Исәнбәтнен «Әбугалисина»сыннан Бибкәй-Солтан ролен бирде. Шушы рольне искә алуга күнел төбемдә бер хатирә уяңды. Театр дөньясына бик яшьли аяк баскан һәр артист яки театр кешесе кебек мин дә карт артистлар үзара сөйләгән бик күп хатирә-легендаларны хәтеремә сендереп калдырганмын. Шуларнын берсе—Галимә апа Ибраһимованын «Отелло» спектаклендә халык каршына Дездемона булып килеп керүе: «Башта тамашачылар анын йөзен күрмиләр, чөнки фәрештәләрнекедәй зифа сыны, назлы сак йөреше аларны шактый вакыт сихерләп тора, шунын белән бергә битен каплап алган нәфис пәрдә-пәрәнжә дә анын йөзен күрергә комачаулый...»—дип ничәмә-ничәнче кабат тынланган, инде күнелгә беркайчан да җуелмаслык булып кереп калган истәлекне йөз дә беренче кат сөйләп китә иде алар... «һәм менә, ниһаять, Дездемона-Галимә Ибраһимова йөзен

каплап торган нәфис пәрдәне күтәреп, Отеллога беренче сүзләрен әйтә... Әмма бу сүзләрне залда берәү дә ишетми. Чөнки артистканың гүзәл йөзен күргән тамашачы, аеруча ирләрдән торган өлеше йөрәкләреннән күтәрелгән тыелгысыз хис белән ирексездән аһылдап куя. Шуңлыктандыр инде, сүзне ишетсәләр дә аның мәгънәсенә төшенмиләр. Моны белгән режиссер Галимә Ибраһимовага әлеге репликаны тагын бер кат кабатларга онытма дип кисәтә».

Мина әлеге сихри йөзне дә, тылсымлы карашны да күрергә насыйп булмады. Ул спектакль уйналган 50 елларда бик кечкенә булганмын. Аның каравы, миңа «Әбугалисина» спектаклендә Фирдәвес Хәйруллина-Бибкәй-Солтанны күрү насыйп булды. Әллә үзе дә аксөякләрчә затлы, зыялы булган режиссер Празат Исәнбәт булышканмы, Фирдәвес сәхнәдә тудырган бу хан кызы киләчәктә яшь артисткаың, һичшиксез, Сөембикәне дә уйнаячагына өметләнерлек затлылыкка, гүзәллеккә ия иде. Үз чорында Галимә Ибраһимованы ничек «аһ» итеп каршы алсалар, Фирдәвес-Бибкәй-Солтанны күреп мин дә хуштан язардай булып утырганымны хәтерлим. Зал өчен дә могжизага әверелә иде ул. Ир-атларга гына түгел, хатын-кызларга да тәэсире шулай көчле иде. Фирдәвес катнашкан күренешләрдә бары Фирдәвескә генә карап утыра идек шикелле. Сүз уңаеннан шуны өстәп куйсак та урынлы булыр, сәхнәдә генә түгел, тормышта да аны туктатып сүз кушалар, трамвай-троллейбуста күреп, сез дә безнең кебек кешемени соң, ничек инде шундый фәрештә, шундый зур талант трамвайда кысылып йөрергә мөмкин дип гажәпләнеп үзалларына ризасызлыкларын белдерәләр иде. Фирдәвес дан дигән, шөһрәт дигән нәрсәләрне бик иртә татыды шул. Әле студентка чагында ук телевидение күрсәткән «Казакъ кызы»нда Карлыгач-Сылуны уйнавы да аны нык популярлаштырды. Атаклы Ринат Сакаевтан соң эстафетаны үз кулына алган фидакарь Әхтәм Зарипов режиссурасында «Жомга көн кич белән» (А. Гыйләжев) телефильмындагы Бибинуры аерым бәяләнерлек... Аяз Гыйләжев кебек ин катлаулы язмышларны бөтен зурлыгы белән тасвирлый торган әдипнең әсәренә нигезләнеп туган роль-образ иде бит ул. Бу үзе генә дә артисткага ничаклы җаваплылык өсти. Ничек итеп, нинди эзләнүләр аша Фирдәвес Хәйруллина хәтерләребезгә үзенә бер зур дөнья булып кереп урнашырлык Бибинур образын тудыра алды соң?. Авылның иң матур гореф-гадәтләрен чагылдырган, милли йөзебезне үзенә туплаган татар карчыгын? Ил сындырып-сыналган чорда, халык кат-кат кыйналган чорда шәхси бәхетен ил-халыкның киләчәге хакына корбан иткән Бибинур, бүгенгесе көндә хаерчелектә яшәп ятса да, горур булып кала белгән авыл карчыгы Бибинур ничек итеп яшь-яшь артистка Фирдәвес Хәйруллина башкаруында тетрәндерерлек итеп, бик күп еллардан соң да онытылмаслык образ итеп гәүдәләндерелгән иде соң? Шушы уңайдан әсәргә кагылышлы бер хатирә искә төшә. Ул Академия театрында «Жомга көн кич белән» пьесасы, ягъни инсценировкасы укылганда булды. Аны—авторы Әхтәм Зарипов үзе укыды. Шул истәлек турында әйтердән элек, Аяз Гыйләжевнең әлеге әсәрендә күтәргән төп фикеренә тукталып үтик. Әсәрнең героинясы Бибинур карчыкка адәм баласындагы иң югары халәтне, бәхеткә илтүче мәхәббәтне тормышында бер тапкыр да татырга насыйп булмаган. Өч ятим бала хакына аларның тол калган аталарына хатын булып килгән яшь-яшь кыз балада бөредә чакта ук уяналмый йоклап калган, ахры, ул изге хис. Көзен чәчәк аткан чия яки алмагач ботагын күреп шаккатып калганыбыз бар. Бибинурның күңеле дә тәмам карчык булып әверелгән чорында, әлеге соңга калып чәчәк аткан җимеш агачыдай, бер гадәти булмаган халәт кичерә. Авылга яңа тормыш алып килгән яшь председатель Жиһангир Сәфәргалинга гашыйк була ул.

Инсценировка укылгач, артистлар арасында фикер алышу китте. Шуның соңында баш режиссерыбыз Марсель Сәлимжанов: «Пьеса белеп язылган, әсәр үзе дә бик мәгънәле, кирәкле, Аяз кебек оста куллы язучыныкы... Тик без бу инсценировканы әлегә репертуарга алалмыйбыз, чөнки повестьны башка повестьлардан берничә башка күтәрә торган төп вакыйга, Бибинур карчыкның яшь рәискә булган гыйшкы повестьның үзенә тин итеп, шул югарылыкта эшләнмәгән—иң мөһиме, сәхнә теленә күчерелмәгән. Бу хәлдә аны артист та, режиссер да күпме генә көч куйса да сәхнәдә чагылдыра алмый»,—диде. Ягъни, көзен чәчәк аткан чия ботагы шикелле күргән һәр кешедә гажәпләнү катыш үкенү тойгысы уятучы, нәкъ Бибинур карчыктай бар кешеләр тарафыннан онытылып авылларда яшәп ятучы меңнәрчә карчыкларның сагышларын бик үзгә шигъри вакыйга аша чагылдыручы төп күренеш булмаса, әлбәттә, сәхнә әсәре булып җитмәгән дигән сүз иде ул. Ә менә Фирдәвес Хәйруллина (Әхтәм Зарипов режиссеры иде) әлеге инсценировка экранлаштырылган чорда сизгер күңел,

котелмәгән буяулар, гаҗәеп төсләр челтәре аша, инсценировкадагы әлеге йомшак якны җинеп чыкты, Аяз Гыйләҗевнын тирән фәлсәфәсен тамашачыларга да тоярга булышты. Анын телеэкрандагы Бибинуры повесть героинясына тин булырлык иде. Заманалар кырыслыгы аркасында ачыла алмый калган мәхәббәтенен кайнар хисләрен карчык булгач кына кичерүче Бибинур-Фирдәвесне күреп йөрәкләребез елаган иде ул чакта. Уйласан уйларлык нәрсәләр бар. Әгәр безнен татарнын үз киносы, үз «Татарфильмы» булса, һич булмаса, сабын куыкларыдай берөзлексез экраннан коелып тора торган күп серияле телефильмнарыбыз гына булса да, әйе, хәтта шулар ярдәме белән генә дә, дөньяда татар барын танытып булыр иде. Чөнки шул сабын куыгыдай фильмнарда да безнен Фирдәвесләребез чын тормыш турында байтак дөреслекне сөйли алырлар иде.



*«Солдат хатыны» (Н. Анкилов) спектаклендә «солдатка» ролендә.*

Фирдәвес бер генә режиссер артисткасы түгел. Шулай да була бит әле ул театр дигән дөньяда, кайсыдыр бер артист театрларында үз иҗатына якын булган режиссер эшләгән чорда бик тә гөрләп үсә, чәчәк ата. Әмма шул җанына якын режиссер театрдан китүгә, әлеге артист югалып кала, иҗат мәйданын акрын-акрын калдырып чигенә торгач, арткы планга ук күчә, репертуардан бөтенләй диярлек төшеп тә кала. Фирдәвес, киресенчә, барлык режиссерлар өчен дә тансык иҗат иясе. Театрга Дамир Сираҗиевнын килүе моны тагын бер кат раслады. Мона кадәр Марсель Сәлимҗанов режиссурасында искиткеч тирән кичерешле, җаны-тәне белән өзелеп сөя белгән, шул сөю аркасында алданган һәм ялгышынын ата-анасына чиксез кайгы-хәсрәт китерүен күреп шашар чиккә җитеп үкенгән саф күнелле Гөлчирә («Ташкыннар», Т. Гыйззәт), шат күнелле, чая һәм кыю булуы белән тамашачы йөрәген язгы кояш кебек балкытучы Сайра («Ир-егетләр», Т. Миннуллин), мулланын китап җене кагылган, тормышны бөтенләй белмәве аркасында кат-кат алданган, ә шулай да һаман сөйкемле булып калган кызы Зөһрә («Качаклар», Н. Исәнбәт), Празат Исәнбәт куйган спектакльләрдә мәхәббәте өчен көрәшүче Финея («Җүләр кыз», Лопе де Вега), җаваплылыкнын ни икәнен бик иртә төшенгән укытучы кыз Моршидә («Мәхәббәтен чын булса», Х. Вахит), татар хатын-кызларынын ин зәвыклы, затлы, нәфис якларын үзенә туплаган Гөлбану («Татар хатыны ниләр күрми», Г. Ибраһимов, Х. Сәлим), режиссер Ришат Хаҗиәхмәтовнын күп кенә спектакльләрендә кызыклы рольләр уйнап килеп һәм театр яшьләре үз араларыннан сайлап куйган Илдар Хәйруллин сәхнәләштергән «Солдат хатыны»ндагы Клавдия белән дә сокландырып, ул инде Камал театрынын төп артисткаларыннан санала башлаган, үз тамашачысы булган, йолдыз булып танылырга да өлгергән иде.

Дамир Сираҗиев белән Фирдәвес Хәйруллина арасында башланган иҗади дуслык монарчы башка режиссерлар белән булганыннан һичнн белән дә аерылып тормады диярлек. Фирдәвестән алынган интервью-әнгәмәләрнен берсеннән мин Дамир театрга килгән чорда «Фирдәвес торгынлык кичерә иде» дигән юлларны укып бик гаҗәпләндем. Дөреслеккә туры киләме бу? Кайдан алып, ни-нәрсәгә таянып артисткага: «Син Дамир театрга эшкә килгәнче сәхнәдән берара югалып торган идең»,—диярга мөмкин. Дамир диплом спектаклен чыгарасы ел алдыннан гына (бу 1979 ел була инде) Фирдәвес Марсель абый Сәлимҗанов җитәкчелек итеп куйдырган «Тормыш дулкыннары»нда (Р. Ишморат) Рәзиләне, шул ук елны Марсель абыйнын «Талак, талак» (Х. Вахит) спектаклендә Рәшидәне, Ришат Хаҗиәхмәтов куйган «Нихәл, яшь иптәш?»тә (Ш. Тоот) венгр кызы Агаешны, Празат Исәнбәт сәхнәләштергән «Банкорт»та (Г. Камал) шулай ук бер яшь кызны башкарган иде. Тагын да берәр елга чигенсәк— «Татар хатыны ниләр күрми»дә Роза Хәйретдиновалар уйнап тан калдырган

аталы Гөлбануы балкый. Ары таба Илсөяр («Онытa алмасан нишләрсен?», Х. Вахит), Анджолетта («Хатыннар гайбәте», К. Гольдони), Катя Круглова («Мәскәү каникуллары», А. Кузнецов) образлары. 1976 елга барып тормасак та була, чөнки артистканың анда иҗат иткән «Ташкыннар»дагы Гөлчирәсе шул ук газета әңгәмәсендә, бик хаклы рәвештә, артистканың зур уңышларыннан берсе дип телгә алынган. Бәс шулай икән, Фирдәвес һаман да сәхнәдә булган түгелме соң! Һәрхәлдә, «югалып торган» Фирдәвес Дамир килгәч кенә кабат уйный башлады дип әйтү дөрес булмас иде. Дамир мөгез чыгармады. Ана каләрге режиссерлар артистка белән ничек иҗаттәшлык итсәләр, ул да шулай эшләде. Фирдәвес өчен генә аерым шартлар тудырмады. Рольгә ике артистканы алырга туры килгән очракларда, ул кайсы артистканың шәхесе, уйнау манерасы бу рольгә күбрәк туры килә, шуны беренче составка куйды. Фирдәвес Хәйруллинаның байтак рольләрне икенче составта, йә Алсу Гайнуллина, йә Рузия Мотыйгулла белән уйнавы мәгълүм, һәм алда бу күренешне дә ачыклап китми булмас. Аннары тагын шунысы да бар, Дамир, диплом спектакле булган «Кияү белән Кәләш»ен (1980) куйганнан соң, Камал театрына эшкә чакырылмады. Ул бары 1986 елда гына, ягъни «Ләйсән ире Хәсән»не (Ю. Сафиуллин) бик уңышлы сәхнәләштергәннән соң гына режиссер булып күчеп килде. 1981 елда «Алмазбулат»ны (Ю. Сафиуллин) ТЮЗда эшләгәндә, 1983 куйган «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз»ны (И. Юзеев) филармониядән килеп сәхнәләштерелде. Һәм, Дамир, Г. Камал исемендәге театрда нибары 3 елга якын эшләп, 1989 елда К. Тинчурин исемендәге театрга баш режиссер булып күчеп китте. Академия репертуарында Дамирның 9 спектакле калды. Әгәр мона Марсель Сәлимҗанов белән бергә иҗат иткән спектакле «Зифа»ны да (Н. Исәнбәт) кушсак, җәмгысе унга тула икән. Шуларның алтысында Фирдәвес өчен роль табылган. «Кияү белән Кәләш»тә (М. Байджиев)—Кәләш, «Алмазбулат»та—Кәләш жен, «Зифа»да—Эсмиральда, «Ләйсән ире Хәсән»дә—Ләйсән, «Бәхетләме син?»дә (М. Садыйкова)—Гөлчәчәк, «Ахырзаман»да (Ч. Айтматов)—Гөлемхан. Менә шулай бер-берсен берничек тә кабатламаучы, теләсә кайсы артистка кызыгырлык камил образлар иҗат ителгән. Бик күп театрларда артистлар үзләрен икенче составта уйнатуны кимсетү итеп кабул итәләр. Безгә иҗади үсәргә комачаулый бу хәл, диләр. Театр тәнкыйтьчеләренә һәм министрлыктан килгән вәкилләргә икенче составтагы артистның уенын карау бөтенләй диярлек насыйп булмый бит. Шуна күрә икенче составта уйнаучылар гел күләгәдә кала. Бервакыт, Рузия Мотыйгулладан: «Син гел Алсу белән алмашлап уйныйсын, әнә «Бирнәсез кыз» (А. Островский) Лариса Огудалованы да Алсу Гайнуллинадан соң уйнадын, үсәргә комачауламыймы ул сина»,—дип сорадым. Бу сорауның бирелүе минем режиссерлар хәзерләүче Югары курсларда укып йөргән чагымда, Г. А. Товстоноговның студентларына әйткәннәре тәэсирендә дә булды шикелле... Санкт-Петербургтагы Олы драма театрын (БДТ) совет чорында ин шәп театрларның берсе итә алган олы оста: «Мин беркайчан да бер рольгә ике артистны алмыйм. Әйтик, Лебедев театрдан китсә, мина «История лошади»ны репертуардан төшерергә яки башка артист белән өр-яңадан сәхнәләштерергә, ягъни шул рольгә алынган яңа артистның шәхесенә, иҗади мөмкинлекләренә таянып, бөтенләй башка спектакль тудырырга туры килер иде»,—дигән иде. Рузия исә, минем соравыма: «Юк, күп очракта бу мина булыша гына. Марсель абый Алсуны эшләткәндә, «Өч аршын җир» репетицияләрен гел карап утыруым аркасында, Алсуның Шәмсегаяненә бөтенләй охшамаган үз Шәмсегаянемне тудыра алдым, «Бирнәсез кыз»дагы Лариса Огудалова образы да шулай дөньяга килде»,—дип, мин көткәннен киресен әйтте. Фирдәвесне дә «Кияү белән Кәләш»тә Дамир Сиражиев Алсу янына «икенче состав» итеп алды. Мин әлеге спектакльне һәр ике состав уенында да бик күп тапкырлар карадым. Һәр ике состав башкаруында да карап туярлык түгел иде бу спектакль. Г. Товстоноговта, Марк Захаровта һәм башка күп кенә театрларда ризасызлыклар, каршылыклар тудыра торган әлеге күренеш Г. Камал театрында артистлар һәм режиссерларның аңлашып эшләве нәтиҗәсендә театрны, артистларны үстерүче бер чарага әверелгән. Дамир Сиражиевнын Фирдәвескә бирелгән икенче роле «Алмазбулат» экиятендәге Кәләш жен булды. Бөтен сүзе берничә җөмләдән генә торса да, Фирдәвес анда шундый кызыклы образ тудырды, менә егерме ел вакыт үтсә дә, ул гел минем күз алдымда: Әсхәт Хисмәт-Кияү жен белән тотаклашкан хәлдә: «Яратасын да инде биергә...»—дип тыпырдап тора. Дөньяга адәм баласы булып килсә дә, явыз көчләр ярдәмендә хәтере, акылы урланып, хәзер бар белгәне бию булган Кәләш жен образын ин саран төсләр белән дә хәтергә уелырлык итә алган артистканы ничек инде тылсымчы, дип әйтмисен. Дамир 1986 елда Фирдәвескә «Ләйсән ире Хәсән»нән Ләйсән ролен бирде. Әмма бу юлы да, инде «Кияү белән Кәләш»тә сыналган

булса да, ул аны икенче составка билгеләде. Һәм шуны да әйтү кирәктер, Фирдәвеснен *Ләйсәне* беренче составта репетицияләр ясаган Рузиябезнекеннән кайтышрак килеп чыкты. Ә инде 1986 елда *Ләйсәннән* сон ук уйнаган *Гөлчәчәге* («Бәхетлеме син?») белән ул (Дамир бу рольдә аны беренче составта уйнатты), Рузия тудырган *Гөлчәчәктән* өстен чыга алды. Шушына охшаш очрак «Сөяркә» спектаклендә дә кабатланды дип раслаучылар бик күп булды. Фирдәвеснен *сөяркәсе* Алсу *сөяркәсеннән* купкә ышандыра, диделәр. Шулай булырга да бик мөмкин. Кабат «Бәхетлеме син?»дәге (М. Садыйкова) *Гөлчәчәгенә* кайтсак, гап-гади генә бер пьесаны режиссер белән артистка шулчаклы баеттылар ки, күп сәхнә күренешләрен күз яшеннән башка карап та булмый иде. Кайчандыр мин шулай тетрәнеп Рузия Мотыйгулланың «Китәм инде»дәге (Р. Хәмид) *Заремасын* караган идем. Театрыбыздагы тагы да шундый образларны саный китсән, Алсу Гайнуллинаның «Өч аршын җир»дәге *Шәмсегаяне*, һәм дә «Идегәй» трагедиясендәге ире, улы, иле һәлак булган *Йәникә ханбикә* дә шулай таң калдыра алган иде. Зөлфирә Зарипованың *Миңлекамалы* («Миңлекамал», М. Әмир) һәм Дамир Сиражиев 1987 елда сәхнәләштергән «Ахырзаман»да (Ч. Айтматов) тинсез *Ана бүресе* дә, Рузия белән Фирдәвесебезнен *Зөләйхалары* да нинди тетрәндергеч көчкә ия!.. Көчләп чукындырылганнан сон яраткан гаиләсе, кадерле туганнарыннан гына түгел, сөекле халкыннан, иманыннан да аерылган *Зөләйханың* дәһшәтле язмышы, бик күп еллар кара көчләргә каршы фидакарьләрчә алып барган тигезсез көрәше аны татар драматургиясенен ин катлаулы героиняларе рәтенә күтәрүен беләбез. Фирдәвеснен *Зөләйхасы* да дистә елларга сузылган кимсетүләр белән килешеп, алар каршында баш игән мескен хатын түгел иде. Ул—манкорт булырга дучар ителгән бала анасы, ерткычларча кыйнап үтерелгән ир хатыны һәм туган иле коллыкта калган татар кешесе икәнен, коллыкның җир йөзендәге ин каһәрле халәт булуын да яхшы анлаган һәм шуна каршы гомере буе көрәшүдән туктамаган олы шәхес булып гәүдәләнде. Белинский юкка гына трагедия сәнгатьнен тажы димәгәндер—Фирдәвес белән Рузияләрнен *Зөләйхалары* да һәр сахнәсе тирән фәлсәфә белән тулы булган, трагедия югарылыгына күтәрелеп балкулары белән безнен күнелләрдә ин түрдән урын алды. Исемнәре атап үтелгән һәр дүрт артисткага хас уртак сыйфат бар—алар җан кылларынын сон чиккәчә тартылуыннан курыкмыйлар һәм нәкъ шундый мизгелләрдә аларнын үеннары кабатлап булмаслык дигән ин югары бәяне ала да.



*«Портфельле кияү» (Н. Исәнбәт) спектаклендә Мәстүрә ролендә.*

Биредә бер парадокс туа. Фирдәвес, Рузия, Зөлфирә, Алсу—һәркайсы Марсель Сәлимҗанов шәкертләре. Марсель Сәлимҗановны сәхнәдә гадәти тормыш-көнкүрешне җырлаучы, ачык тоннарга мөкиббән киткән, асылда комедия беләнрәк мавыгучы режиссер итеп күрүчеләр бар. Алайса, ничек теләсә кайсы жанрда иркен иҗат итә алучы, җир йөзендәге теләсә кайсы театр сәхнәсен бизи алырлык артисткалар үстерә алды икән сон ул? Шушы бер факт кына да безнен тәнкыйть тарафыннан Марсель Сәлимҗанов шәхесенен, иҗатынын бөтен зурлыгы белән әлегәчә өйрәнелмәвенә бер мисал була ала. Сәнгатьтә фундаменталь дип йөртелә торган, ягъни төп дүрт нигез ташы бар. Беренчесе—миллилек; икенчесе—мәктәп; өченчесе—метод, дүртенчесе—традиция. Оста үзенен укучыларына әнә шуларны камил үзләштерергә булышкан. Бүген рус театр сәнгатенә бик күпләп шушы төп нигез ташларына көләп кенә караган яшь режиссерлар, яшь артистлар, яшь драматурглар килә. Бөтен теләк-омтылышлары шаккатыру булган бу яшьләрнен «җимешләре» Станиславский, Мейерхольд, Вахтангов, Чехов, Горькийларнын иҗат җимешләреннән кыргый алмагач алмалары культуралы алмагач алмаларыннан аерылган кебек аерыла. Үзләренә бер яна дин уйлап чыгарган сектантлар шикелле, менләгән еллардан бирле бөртекләп җыелып, янадан-яна буыннар ярдәмендә туктаусыз үстерелә, янартыла барган театр сәнгате традицияләрен

өнәмичә, бүгенге көн драматургларын гына түгел, классикларны да ясалма рәвештә (русларда болай кылануны фортель җибәрү, котыртык әмәлләү диләр) куя-оештыра башлаган әлеге «сектант» режиссерларның йогынтысы иртәме-соңмы безгә дә үтеп керәчәк. Чөнки безнең Фирдәвесләребезгә дә 50 тулды. Чөнки яшь буын артистлары авызыннан без ачыктан-ачык: «Галиябану»ны карап, «Су буйлары» дигән җырлар тыңлап үскән драматургларның әсәрләреннән кайчан гына котылып, бишектән үк Карузоларны тыңлаган, рус драматургы Коляда пьесаларын, режиссер Коляда спектакльләрен карап өйрәнгән яшь шәһәр драматурглары әсәрләрендә уйный башларбыз икән»,— дигән усал сүзләрне дә ишеткәли башладык. Әле ярый, шул авыр мизгелдә хәтер төбеннән әдип Аяз Гыйләҗевның йөрәккә май булып яткан: «Вальпаранса, Титикака, Куала-Лумпур—шәп яңгырый торган исемнәр, беләм! Әмма минем өчен Аксыргак авылы, Ташлыяр елгасы тагын да шәбрәк яңгырый! Калерле булганга...»—дигән үлемсез сүзләре күтәрелә. Инде яшьләр сокланган әсәрне алып карыйсың да баш ватасың, авторы житәкләп йөртсә генә җанлы күренгән, анда да чалыш-чолыш кына хәрәкәт итә алган, татарча рәтләп сөйләшә белмәгән курчак геройлар ни-нәрсәләре белән җәлеп итә соң андый яшьләрне? Бу бит милли театр. Милли тамашачы өчен яшәгәнебезне оныталар, ахры, алар. Әгәр сәхнә әсәрендә кеше рухының язмышы, аның көрәше нәкъ менә Фирдәвесләребез иҗатындагыдай артист үзенә аша бөтен зурлыгы белән чагылмаса, замандаш язмышы характер һәм «поступок» (геройны билгеле бер герой итеп танытучы адым—Отеллоның Дездемонаны бууы, Гамлетның бөтен бер системага каршы чыгып кылган кыланышлары, ягъни һәр геройның бары үзенә генә хас гамәле) аша бирелмәсә, бию, пантомима, җыр белән ясалма укмаштырылган шакшы көлке сүзләр җыелмасы ни бирә ала? Ни өчен әле без башка милләтләр шулай эшли дип, кешелек идеалларын пычрак эченә салып таптарга тиеш? Кайчандыр Станиславскийлы, Товстоноговлы, Эфрослы, Чеховлы, Вампиловлы рус театр сәнгатеннән өйрәнү безнең театрга бик шифалы иде. Ә хәзерге акча, ялган шөһрәт өчен «чукынырга» әзер торган сәнгать белән ерак китеп булырмы? «Явызлыкка дөньяга килергә булышма, ул



*Журналыбыз турында*

## Мостафа Өнәр,

Төрек галиме

***Миңа татар телен ике хәлфә өйрәтте. Беренчесе—кечкенә Апуштан татарның зур улына әверелгән Габдулла Тукай иде. Ул 27 яшендә үлемсезләр дөньясына күчте. Зур иҗаты бүген дә сау-сәламәт. Икенче хәлфәм яшь буенча Тукайдан өлкәнрәк. Ул «Казан утлары». Бу журнал турында бик күп сөйләргә мөмкин булса да, мин беренче чиратта шуны әйтергә тиеш, ул—мәктәп, татарның һәм татарлыкның мәктәбе. Бу мәктәп иң авыр вакытларда да Казаннан Америкага, Финляндиягә, Германиягә, Япониягә, Төркиягә, Австралиягә, Себергә, Питерга, Кытайга, димәк, әйтергә мөмкин, бөтен дөньяга ишек ачты. Татарның, татар теленең яктысы төшмәгән урыннарга «Казан утлары» үз нурларын сирпеде, татар дөньясын балкытып торды. Анда нәрсә генә язылса да, ул татар рухын яшәртте. Без, төрекләр, башка төрки туганнарыбыз арасында озак вакытлар бер ялгызы ирекле дәүләт булып торган Төркиядә шул теләктә калабыз: татарлар да үзләренең бу матур, гүзәл илләрендә үз байлыкларына үзләре ия булып мәңге яшәсеннәр. Шул рәвешле «Казан утлары» журналы да күп санда басылып, аның таралу чикләре тагын да киңәйсен.***

ахырда үзенне ашар» дигән борынгы мәкаль бар. Изге китапта шуна ышанмаган бер хатын 9 ипи пешереп, берсенен эченә агу сала һәм аны шәһәргә кереп килүче юлчыларга илтеп бирергә боера. Агулы ипи юлчылар белән кайтып килүче улы белән ирен һәлак итә. Саф хыяллар уятучы, көнелдә яхшылык тойгылары тәрбияләүче, милли гореф-гадәтләребезне, иманыбызны саклаучы, туган телне үстерүче, ирекка омтылган рухыбызны ныгытучы театрнын нигез ташларын Татарстанда да Россиядәге модага ияреп какшата башласалар ни булыр? Куркыныч уйлар болар. Әле дә ярый, хәзергә безнен Фирдәвесләребез көчендә. Әле ярый, алар уеннары белән дә, яшь артистлар арасында алып барган тәрбия чаралары белән дә чын сәнгатькә хезмәт итәләр.

Сөйләмнәрендә татар аһәне булмаган, күзләреннән нур, жаннарыннан мон, сафлык качкан бүгенге буын яшьләре арасыннан чыгып сәхнәгә менеп баскан хәзерге яшь артистларыбызга Габдулла Шамуков, Хәким Сәлимжанов, Фатыйма Ильская, Шәүкәт Биктимеров кебек чын милли артистларыбыз югарылыгына күтәрелү өчен күпме вакыт кирәк булыр икән? Әллә бөтенләй дә мөмкин эш түгелме бу! Таланты булган кайбер артистлар да гомер буйларына татар теленен аһәнен тоймыйча, монына төшенмичә яшәп яталар бит әле әнә! Нәкъ шундыйлар арасыннан Казан ханлыгы чорындагыча «Мәскәү тарафдарлары» килеп чыга. Хәлләреннән килсә, русча гына язучы язучыларыбыз кебек алар да спектакльләрен гел рус телендә уйный башларлар иде. Тфү, тфү, Алла сакласын, башка бик күп милләтләр шул көнгә төштеләр дә бит инде. Әйе, Мәскәүнен үз позициясе. Анынча гына эшләү үзенне юк итү дигән сүз. Аларга чын милли спектаклебез «Зәңгәр шәл» дә, татарны бетерә торган катнаш никахларга каршы юнәлдерелгән «Илгизәр + Вера» да (Т. Миннуллин), үз шәжәрәләренә хөрмәт белән карый башлаган «Шәжәрә» геройлары да, ана образы аша туган илнен ачы язмышын чагылдырган «Әни килде»дә (Ш. Хөсәенов) элекке чорда уздырылган көчләп чукындыруларны күрсәтү аша, бүген башкарак төстә булса да, чукындыру әле дә дәвам итә дип чан каккан «Зөләйха»лар дә кирәкми. Империягә табынучы театр белгечләре алардан мен хата эзләп табалар... Бәхәсләшмим, хаталары да юк түгелләр... Мәгәр, ин кызыгы, аларнын мактаганы—яшьләрне наркотик кебек мингерәтү көченә ия «Казан егетләре», христиан динендәге татарлар тормышын өстән-өстән генә күрсәткән «Гөргөри кияүләре», яшь гаилә корган парларнын килделе-киттеле кыланышлар белән кеше көлдереп, тормышларын юкны-бушка авыштырып үткәрүләрен генә тасвирлаучы «Килә ява, килә ява» кебек спектакльләр. Алары да булсын, әйдә. Әмма туган жирен сагынып елый-елый сөлге чигеп утырганда Шәмсегаян сөйләгән монологнын чын татар кешесе йөрәгенә ничаклы тетрәндергеч көч белән тәэсир итүен, кара йөрәк өендә намазлыкка баскан Зөләйханын Аллага ялваруы таш бәгырьләрне дә эретерлек кайнар булуын, көчләп чукындыручыларга юнәлткән каргышынын иртәме-соңмы рәнжетүчеләр башына төшәсен дә анламамышка салышмасыннар. Яшьләребезнен башын чуалтмасыннар.

Шуна да, рәхмәт Фирдәвесләргә... Жаннарында күпме генә тукынмасыннар, осталыкларына бөек рус театр сәнгате ирешкән казанышларнын, шуларга нигезләп элеккеләребез тапкан табышларнын да ин кирәклеләрен сайлап ала белделәр һәм хәзер дә читләр кулындагы курчак түгеллекләрен раслый киләләр.

Әйе, гомер агышлары кеше кодрәтенә буйсынмый. Фирдәвескә дә 20 яшь түгел, 30 да түгел: 20+30! Үз яшеннән күпкә яшьрәк күренсә дә, хәзер ана инде барыбер үз яшендәге хатын-кызларны башкаруны йөклиләр. Тере организм булган театрда туктаусыз үзгәрү, алмашынулар бара. Яшь буын артисткалар килә тора. Аларга да уйнарга кирәк. Һәм, табигый, яшь кешене яшьрәкләр уйный. Фирдәвес Хәйруллина да сынатмый. Үз яшендәге зур рольме ул, әллә сәхнәгә бер-ике генә кереп чыга торганымы, кайсын гына тапшырсан да, берсеннән-берсе кызыклырак характерга ия хатын-кызларны ижат итә тора. Кызы—күз нуры Нәфисә дә инде зур кыз булып килә. Ул анын илһамчысы да, ул анын беренче тамашачысы да. Ак бәхет телик аларга!

**Юныс САФИУЛЛИН,**
*Татарстаннын атказанган сәнгать эшлеклесе*

# ЕРАКТАГЫ ЯКЫН ДУСТЫМ

Табигатькә мәхәббәт безнең һәркайсыбызда үзенчәлекле: әйтик, берәү, бишектән төшү белән, мүкәләп чирәмгә чыга, ихатада кош-корт белән таныша, кәҗә-сарык ише мал-туарны күреп, гомерендә беренче тапкыр гаҗәпсенә, тора-бара аларның барчасын үз итә, холыкларын белеп ала, ата каз һәм әтәч кебек усалракларыннан сакланырга өйрәнә. Әйе, авылда туган балалар сабый чакта ук табигатькә якынрак булучан. Тик менә, кызганыч ки, еш кына авылдагы матурлыкның бәясен белеп бетермибез, туган якка ияләшеп өлгерәбез дә яңадан-яңа җирләрне күрергә омтылабыз. Моны, әлбәттә, үз авылыңнан, туган төбәктән йөз чөерү дип бәяләү дөрес үк булмас иде. Хәтта әле бәхет эзләп читкә-ягага чыгып киткән очракта да. Чөнки адәм баласы туган ягын, авылдашларын сагынмыйча калмый, ахыры бер ул аларны сагына, олыгайган саен авылы, урамы, сабый чакта уйнап үскән елга-ерынты исенә ешрак төшәчәк, сагындырып үзенә дәшәчәк...

Бу юлларның авторы да, ягага китеп, дистәләрчә еллар буена шәһәрдә яшәп, төрле җирләрдә йөреп, ул төбәкләрдәге гүзәллекләргә ихлас күңелдән сокланып туйганнан соң да туган авылын, Кече Чынлының Диңгелде буйларын үлеп сагына башлады, аннары инде ике елның берендә авыл юлын таптарга тотынды.

Кызык бер хәл инде: без фәкыйрегез Тау ягының да аргы бер почмагында туып, тугыз яшендә, бер авыз урысча белмәгән чагында Казанга күченеп килгән. Ә менә Мәскәү шәһәрендә туып, шунда урысча гына укып яткан икенче берәү - Әнәс атлы малай авыл урамына беренче мәртәбә фәкать тугыз яшендә генә аяк баскан. Дөресен әйткәндә, Ватан сугышы башланып, әтисе Рәхимҗан абзый фронтка киткәч, әнисе бала-чаганы (ике улын, бер кызчыгын) алып үзләренең туган авылларына кайта. Шул ук Тау ягына, Апас районындагы Колгына авылына!

Зөя буйларындагы тауларны, болыннарны, куе урманнарны күрү тугыз-ун яшьлек малайга һич әйтеп бетергесез нык тәэсир итә. Урысчаны шәп белсә дә, үз ана телендә бер генә китап та укымаган, татарча фәкать өендә генә сөйләшкән малайны авылдашлары гаять җылы каршылыйлар. Үзенең яшьтәшләре аны кайларга гына алып барып бетермиләр! Малайлар халкы һәркайсына тиешле бәяне бирә, һич тартынып тормый, бик тиз синең кем икәнеңне ачыклый. Әнәс үзенең сабыр холкы, бәйләнчек тә, мактанчык та булмавы белән, урыс сүзләрен катыштырып булса да, күргән бер әйберен сораштырып, яхшырак белергә тырышуы белән иптәшләренең күңелен җәлеп итә.

Әллә бәлкем, Әнәснең рәссам булып китүенә Зөя буйларының гаҗәеп үзенчәлекле һәм бай табигате йогынты ясагандыр, сәбәпче булгандыр? Әллә бәлкем, Тау ягының хәйран уңган һәм киң күңелле халкы тәэсир иткәндер? Әллә бәлкем, нәкъ шушы төбәктә гомер кичергән борынгы бабасының әйләнә-тирәне үзенчә күрү сәләте буыннан-буынга бирелеп тә, яшь-яшь рәссамның күзе туган туфракта, шунда ачылгандыр? Кем белә бит, кем белә...

Һәрхәлдә, тугыз-ун яшьлек Әнәс киләчәктә нинди һөнәр сайлаячагын шунда ук билгели. Чөнки буш вакытында рәсем ясау белән мавыгып китә. Авыл өйләрен, болында үлән уртлап йөргән атларны, бигрәк тә аларның колыннарын болай килешле генә кәгазьгә төшерсә дә, Зөянең кызу агымын һич кенә дә күңеленә хуш килердәй итеп сурәтләп бирүгә ирешә алмый.

Хәер, Зөя белән егетебез «алышып» та карый. Дөресрәге, шулай туры килә. Ике сыйныфны урысча укып бетергән Закиров татар мәктәбенә кереп укырга үзендә кыюлык тапмый, шуннан, елганың аргы ягында урысча уку мөмкинлеге барын белеп, Зөянең саерак урыныннан чыгып, укырга йөри башлый. Мондый хәлгә ана кешенең йөрәге ярылырга җитешеп әрни, һәм ул күз яшьләре белән улын үз авылларында укырга күндерә. Юньләп татарча да

белмәгән малайны мәктәпнең өченче сыйныфына алырга батырчылык иткән мәктәп директоры Һади абыен рәссам әле бүген дә җылы сүзләр белән искә ала.

Әтиләренең туган авылында Әнәс татарча сөйләшергә өйрәнә, Колгына малайлары исә аз-маз урысча сукалап азапланалар. Колгынада узган ике ел, татар мәктәбендә ана телендә укуы Әнәснең гомере буена якты хатирә булып саклана. Җае чыкканда ул авылга да кайткалый, Казанга кайткан саен авылдашларын күрмичә китми. Әйтик менә, узган ел Мәскәүдә чыга торган «Лесная новь» журналының ноябрь санын Татарстанның урман хуҗалыгына багышлый: искиткеч күп материал туплый, урман эшенә, агач үстерергә гомерләрен җәлләмәгән якташларыбызның язмышын, аларның фотосурәтләрен күрсәтә. Шунда ук без Колгына авылы ягыннан Зөя елгасын һәм аның икенче ярындагы урманлы тауларны күрәбез. Әлеге картинаның авторы - Әнәс Закиров. Ул үзенең авылы янындагы, кайчандыр үзе малайлар белән бергә коенган, аргы ягындагы мәктәпкә йөргән чагында җәяүләп кичкән елганы олыгаеп житкәч тә хөрмәт вә мәхәббәт белән тасвирлый.

Хәер, Әнәс Закиров элек-электән Мәскәүдә чыга торган басмаларда Татарстан җирләрен, уңган-булган якташларыбызны пропагандалау белән мавыга килде. 1948-1951 елларда Гознак техникумында, аннары (1955-1961) Мәскәү полиграфия институтында махсус белем алган һөнәрмән буларак ВДНХның матбугат бүлегендә баш рәссам (1951-1961), «Турист» журналында шулай ук баш рәссам (1961-1990) булып эшләгән, 1990 елдан соң «Лесная новь» («Урман яңалыклары») журналында эшләүче рәссамыбыз Татарстан китап нәшриятында альбомнар чыгарырга да ярдәм итте: 1983 елда «Бакый Урманче», 1986 елда «Габдулла Тукай», 1990 елда «Лотфулла Фәттахов» альбомнарының рәссамы булды, полиграфия белгече буларак, аларны җиренә җиткереп эшләде.

Гәрчә гомер буе редакцияләрдә эшләсә дә, иҗат кешесенең хезмәте һич тә моның белән генә чикләнми. Очсыз-кырыйсыз Советлар Союзын гизгәндә дә, Идел буе, Кавказ табигате белән танышып йөргәндә дә рәссам үзенә һәрчак «азык таба»—күңеленә хуш килгән төбәкләрне, шундагы матурлыкны бик теләп һәм онытылып сурәтли, мәңгеләштерә. Ул иҗат иткән рәсемнәрнең саны дистәләрчә генә түгел, мин күргәннәре генә дә йөзләрчә. Ә бит әле һәр иҗат кешесенең берәүгә дә күрсәтмәгән эшләре дә бихисап булучан...

Сәнгатькяр башкалада үткәрелгән күргәзмәләргә дә үзе язган картиналарны куйгалый, зур-зур залларда аның шәхси күргәзмәләре дә булгалый. Тик инде рәссам үзе эшләгән җирдә елның-елында хезмәттәшләре алдында иҗат отчеты белән чыгуны үзенең төп бурычы саный. Әлеге күргәзмәгә ул, яңа язган картиналары белән бергә, журнал бизәү өчен хезмәт иткән эскизларын да, эзләнүләрен дә куя - болар барысы да аның тырышлыгы, аның сәләте, аның «балалары».

Биредә без рәссамның аеруча уңышлы саналган хезмәт җимешләреннән фәкать кайсыберләренә генә күз салыйк: «Саратовтагы Чернышевский йорты» (1961), «Кавказда көн үзәге» (1964), «Абхазиядәге чәй плантацияләре» (1965), «Идел буенда» (1970), «Яңгырдан соң» (1973), «Зөядә кояш баюы» (1975), «Язгы парк» (1985), «Язның елмаюы» (1995) һ. б. картиналар.

Киң күңелле, сабыр холыклы дустым Әнәс табигать күренешләрен язган чагында үзенең төпле акыл иясе, зур иҗат коллективының җитәкчесе икәнлеген бөтенләй онытып, ихлас күңел биреп, дәртләнеп иҗат итә. Хәер, шунсыз сәнгатькяр булу мөмкин дә түгелдер.

Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Әнәс Рәхимҗан улы Закировка 70 яшь тулды. Моннан соң да рәссамның иҗат дәрте сүрелмәсен иде!

Кыям МИҢЛЕБАЕВ



Qөrʼәn tatar telendә
Коръән татар телендә

## 33—ӘХЗАБ (ТӨРКЕМНӘР) СҮРӘСЕ

**Әхзаб сүрәсе 73 аятьтән тора. Мәдинә-и Мөнәүәрәдә иңгән. «Әзхаб» сүзе: төркем, гаскәр, фирка, өер кебек мәгънәләрне үз эченә ала.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, Пәйгамбәр, Аллаһтан курык. Кяферләргә, монафикъларга буйсынма. Хактыр ки, Аллаһ—барысын да белеп торучы бердәнбер хөкем вә хикмәт ияселәр.

**2.** Раббың иңдергәннәр буенча гына гамәл кыл. Шик юктыр ки, Аллаһ бөтен кылмышларыгыздан хәбәрдар.

**3.** Аллаһка тәвәккәл ит. Химаяче буларак, Аллаһ җитәр.

**4.** Аллаһ бер кешегә ике йөрәк бирмәде. Зиһар дип игълан иткән хатыннарыгызны анагыз сурәтендә танымады. Асрауга алынган угылыгызны да үз угылыгыз итеп танымады. Болар *(бу уйдырма йолалар)* сезнең үз авызыгыздан чыккан сүзләр генә. Аллаһ дөресен сөйли вә тугры юлга ирештерә.

*(«Борынгы гарәпләрдә шундый бер гадәт бар иде. Берәр ир үз хатынына: син миңа анамның аркасы кебексең, дип әйтсә, ул хатын ирнең үз анасы кебек булып калыр. Шул сәбәпле, алар инде моннан соң җенси мөнәсәбәтләргә керә алмый. Бу—аерылышу, дигән сүз була. Шушы йола «зиһар» дип атала иде. Кешенең күкрәгендә ике йөрәк була алмаган кебек, бер хатын бер үк вакытта иренә ана да, хатын да була алмый, янәсе».*

*«Ягъни, никахлы хатын да, аерылганы да үз иренең анасына әверелә алмый. Яки угыллыкка алынган ир бала өйләнеп, үлсә, аның тол хатынын үги атасы хатынлыкка ала ала».*

Хәсән Чантай һәм Ибраһим Дөнмәз тәфсирләреннән.)

**5.** Угыллыкка алынган балаларга атасының исеме белән эндәшмәгез. Аллаһ каршында иң дөресе шул булыр. Аталарының исеме мәгълүм булмаса, аларга дин кардәшләрегез дә күреп-белгән танышларыгызга булган мөнәсәбәттә булыгыз. Ялгышып эндәшсәгез, бу эш тә гөнаһ булмас. Белгән килеш, хөсетлек белән эндәшсәгез генә гөнаһ булыр. Аллаһ—ярлыкаучы һәм миһербан иясе.

**6.** Иман китергәннәргә Пәйгамбәр үз жаннарыннан да якынрактыр. *(Пәйгамбәрнең)* хатыннары аларга *(иманлыларга)* ана кебектер. Ләкин туганнары, Аллаһның Китабына күрә, бер-берләренә башка мөселманнардан һәм мөһаҗирләрдән якынрак. Әмма диндәш дусларыгызга игелек кылыгыз. Болар Китапка шулай язылган. **(7)** Һәм Без пәйгамбәрләрдән сүз алдык. Синнән, Нухтан, Ибраһимнан, Мусадан һәм Мәрьям углы Гайсәдән. Хактыр ки, Без алардан катгый ант сүзе алдык.

*(«Ант сүзе: бары тик бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырбыз һәм өммәтләребезне дә шуңа өндәрбез. Һәм шушы антыбызга тугры калачакбыз».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**8.** Аллаһ аларны *(пәйгамбәрләрне)* антка тугры булганнарның тугрылыгын сынар өчен ант иттерде. Кяферләр өчен хәтәр җәза хәзерләде.

**9.** Әй, иман китергән кешеләр, Аллаһның сезгә булган мәрхәмәтен онытмагыз! Сезнең өскә яу килгәндә, яуга каршы Без өермә куптардык һәм сезнең күзгә күренми торган гаскәрләр *(фәрештәләр)* күндердек. Аллаһ сезнең ни кылганыгызны белеп тора.

**10.** Алар *(дошман явы)* өстән дә, астан да сезгә ябырылганда, күзләрегез *(куркудан)* акайган иде, котыгыз ботыгызга җиткән иде; һәм Аллаһ турында төрле-төрле *(шикле)* уйлар башыгызга килгән чакта; **(11)** менә шулай итеп, иман китергәннәрне сынау аша кичердек. Вә алар дәһшәтле тетрәнүгә дучар ителде.

**12.** Шул вакытта *(динсезлек чире белән авырган)* монафикълар әйтте:
—Аллаһ белән аның илчесе коры вәгъдәләре белән безне алдады,—диделәр.

**13.** Араларында:
—Әй, Ясриб сугышчылары, сез дошманга каршы торалмаячаксыз, качыгыз,—дип кычкыручылар да булды. Кайсылары исә:
—Йорт-җирләребез саксыз калды *(өебезгә кайтар безне)*,—дип Пәйгамбәрдән рөхсәт сорый иде. Йорт-җирләре саксыз түгел иде аларның, *(сугыш кырын ташлап)* качу иде аларның теләге.
*(Ясриб—Мәдинә шәһәренең борынгы атамасы иде.)*

**14.** Әгәр *(мөшрикләр Мәдинә шәһәренең)* төрле ягыннан басып кереп *(монафикъларны Пәйгамбәргә, мөселманнарга каршы)*, фетнә суешында катнашырга кушсалар, һич шик юк ки, ике дә уйлап тормастан, алар *(монафикълар)* кушканны үтәр иде.

**15.** Хактыр ки, алар моннан әүвәл *(Җиһад сугышында)* артка борылып качмаска Аллаһка сүз биргәннәр иде. Аллаһка бирелгән сүз өчен җавап бирергә туры киләчәк.

**16.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син аларга:
—Үлемнән яки үтерелүдән качсагыз да файда булмас. Качкан тәкъдирдә дә гомерегез озын булмас,—диген.

**17.** Әйт син:
—Аллаһ сезгә берәр яман эш теләсә, сезне ул бәладән кем килеп коткарыр? Сезгә рәхмәт иңдерергә теләсә, ул рәхмәтне кем тоткарлый алыр?—диген. Алар Аллаһтан башка үзләренә бер дус та табалмас, ярдәмчеләре дә булмас.

**18.** Аллаһ сугышка барудан тыючыларны:
—*(Сугышка бармагыз)* безнең белән булыгыз,—дип котыртучыларны бик яхшы белеп тора. Аларның бик азы сугышка катнашты. **(19)** Катнашканнары да *(менә без дә кяферләргә каршы сугыштык, безгә дә ганимәт малы тиеш, дип әйтер өчен)* хөсетлек белән генә килде. Йөрәкләренә курку төшсә, син аларны, үлем исереклеге белән, күз-башлары акайган килеш, синнән ярдәм көтеп, шашып калганнарын күрерсең. Куркыныч узып киткәннән соң, алар үзләренең әче телләре белән бәгырьләрегезне үтәли тишеп чыгар. Алар ганимәт малына хирыс. Алар иман китермәс. Шуңа күрә, Аллаһ аларның *(ихлас булмаган)* кылмышларын юкка чыгарды. Бу эш Аллаһ өчен бик тә җиңел нәрсә.

**20.** Дошман гаскәрләре ерак китмәде *(аларның кире борылуы да мөмкин)*, дип курыктылар. Алар чүл эченә качып, бәдәви гарәпләре янында яшәп, *(сугыш кырына кире кайткан дошман гаскәрләре турында)* сораштырып ятарга хыяллана иде. Алар сезнең белән бергә *(сугыш кырында)* булса да, чынлап сугышмас иде.

**21.** Хактыр ки, Ахирәт көнендә Аллаһ белән кавышуга ышанганнар

өчен һәм Аллаһны күп зикер иткәннәр өчен Пәйгамбәрдә үрнәк сыйфатлар бар.

**22.** Дошман чирүен күргәч:

—Менә бу Аллаһның һәм Пәйгамбәрнең безгә биргән вәгъдәсе *(сынавы)*,— диделәр.

—Аллаһ белән Пәйгамбәр дөрес әйткән икән. *(Кяфер явының һөҗүм итүе)* мөэминнәрнең иманын һәм Аллаһка буйсынуларын арттырды гына.

**23.** Мөэминнәр арасында Аллаһка биргән антларында торучылар бик күп. Аларның кайсылары вәгъдәсен азагына чаклы китереп җиткезде *(Җиһадта шәһит китте)*. Сабыр гына *(әҗәлен)* көткәннәре дә бар. Алар берничек тә антларын бозмады.

**24.** Аллаһ тугры булганнарга тугрылыклары сәбәбе илә әҗерен дә бирәчәк. Ихтыяр итсә, Аллаһ монафикъларны җәзалаячак яки *(тәүбә итсәләр)* ярлыкаячак. Шик юктыр ки, Аллаһ—ярлыкаучы һәм чиксез миһербан иясе.

**25.** Аллаһ кяферләрне һичбер хаергә ирештермичә *(җиңелдерде, ганимәт ала алмадылар, мөселманнарның динен какшата алмадылар)*, сөмсерләре коелган хәлдә чигенергә мәҗбүр итте. Алла сугышта мөэминнәргә ярдәм итте *(давыл куптарды, Күктән фәрештәләр гаскәре җибәрде)*. Аллаһ—көч-кодрәт иясе, Һәрвакыт җиңүче.

**26.** Китаплы халык *(яһүдиләр)* булып та мөшрик гаскәренә ярдәм иткәннәре өчен, Аллаһ аларның йөрәкләренә курку салды, ныгытмалары арасыннан чыгарга мәҗбүр итте. Аларның бер өлешен сез үтердегез, башкаларын әсир иттегез. **(27)** Аларның йорт-җирләрен, малларын, сез аяк басмаган *(уңдырышлы)* туфракларны сезгә бирдек. Бар нәрсәгә Аллаһның кодрәте җитә.

**28.** *(Ул заман бер иргә тугыз хатын рөхсәт ителә иде. Рәсүлулланың хатыннары да йортта булмаган зиннәтләр таләп итә башладылар. Шуннан соң бу сүрә иңдерелде.)*

—Әй, Пәйгамбәр, хатыннарыңа әйткел:

—Әгәр дә сез бу дөньяда муллык, зиннәт эчендә яшәргә телисез икән, алайса, әйдәгез, мин сезнең һәрберегезгә үз өлешегезне биреп, матур гына аерып, ирекка җибәрермен,—диген. **(29)**—Әгәр дә сез Аллаһка иман китереп, Пәйгамбәренә ияреп һәм Ахирәт йортында яшәргә теләсәгез; шик юктыр ки, игелек кылганнарыгыз бөек бер әҗергә лаек булачак.

**30.** Әй, Пәйгамбәр хатыннары, берәрегез тәрбиясез эш белән тотылса, анын җәзасы *(гади хатыннарга бирелә торган җәзадан)* ике тапкыр артык булыр. Бу эшне башкару Аллаһка берни дә тормый. **(31)** Аллаһка һәм Пәйгамбәргә итагать итүче, игелек кылучыларыгыз булса, андыйларга бүләкне дә *(башка хатыннарга караганда)* икеләтә арттырып бирербез. Һәм алар өчен Без *(җәннәттә)* бик тә затлы ризыклар да хәзерләп куйдык.

**32.** Әй, Пәйгамбәр хатыннары, сез башка хатыннар кебек түгелсез. Аллаһтан курыксагыз, *(чит ирләр белән)* кыланып сөйләшмәгез. Кыланып сөйләшү күнелендә женси азгынлык чире булган ирләрне өметләндерер. Сөйләшүегез гади һәм әдәпле булырга тиеш. **(33)** *(Мәгъруранә)* өегездә утырыгыз. Элеккеге җаһилият вакытындагы хатыннар кебек *(канчыклап, зиннәтләрегезне башкаларга күрсәтеп)* йөрмәгез. Намазны тәртибенчә укыгыз. Зәкят бирегез. Аллаһка, Пәйгамбәргә итагать итегез. Ий, Пәйгамбәр хатыннары, Аллаһ сезне керсез (гөнаһсыз) итеп, пакьләрдән пакь ясарга тели. **(34)** Аллаһның өегездә укылган аятьләрен, гыйбрәтле мисалларын отып алыгыз *(һәм башкаларга сөйләгез)*. Шик юктыр ки, Аллаһ һәрнәрсәнең асылын белеп, һәрнәрсәдән хәбәрдар торыр.

**35.** Шик юктыр ки, мөселман ирләр вә мөслимәләр, мөэмин ирләр вә мөэминәләр, жаннары-тәннәре белән Аллаһка бирелгән итагатьтәге ирләр вә итагать бозмаган хатыннар, *(антларына, дингә, хатынына)* тугры ирләр вә тугры хатыннар, чыдам-сабыр ирләр вә түзем-сабыр хатыннар, мөтәвази

*(тыйнак)* ирләр, мөтәвази *(әдәпле)* хатыннар, садәка бирүче ирләр, садәка бирүче хатыннар, ураза тотучы ирләр, ураза тотучы хатыннар, намусларын саклаучы ирләр, гыйффәтләрен саклаучы хатыннар, Аллаһны чиксез зикер итүче ирләр, зикер итүче хатыннар бар. Аллаһ боларга ярлыкау һәм бөек әҗер хәзерләп куйды.

**36.** Аллаһ белән Пәйгамбәр бер эшкә хөкем чыгарганнан соң, мөэмин ир белән мөэминә хатын-кыз үз ихтыярлары белән ул хөкемне бозып, үзбаш гамәл кылырга тиеш түгел. Аллаһка һәм Пәйгамбәргә каршы гамәл кылганнар адашкан булыр.

**37.** *(Ий, Рәсүлем Мөхәммәд)* исеңдәме, ничек итеп Аллаһ сиңа нигъмәт бирде, игелек кылган кешегә дә син:

—Хатыныңны аерма, Аллаһтан курык,—дигән идең. Ләкин Аллаһка ачык мәгълүм булган нәрсәне син *(кешеләрдән)* яшереп калдырдың. Юкса, *(кешеләрдән түгел)* Аллаһтан куркырга кирәк иде. Зәед хатыны белән арасын кирәгенчә өзеп бетергәннән соң, ул хатынны сиңа никахладык. Угыллыкка алынган үги балаларының хатыннарын, тәртип белән аерылышканнан соң, үги атага никахлау мөэминнәр өчен гөнаһ түгел, дидек. Аллаһның әмере җиренә җиткезелде.

*(«Сабый чагында әсирлеккә алынган Зәедне хәзрәти Мөхәммәд азат итеп, угыллыкка алды. Балигъ булгач, Мөхәммәд туганнан туган сеңлесе Зәйнәпне Зәедкә никахлатты. Ләкин бай нәселле Зәйнәп кол Зәед белән тыныч тормыш кора алмады. Зәед тә аның тәкәбберлегенә түзмичә, аерылырга теләде. Шул вакыт хәзрәти Мөхәммәд аңа сабыр итәргә кушты. Ләкин барыбер Зәед Зәйнәпне талак итте. Мөхәммәд Аллаһ рөхсәтеннән соң Зәйнәп белән никахлашты».*

Али Тургут тәфсиреннән.)

**38.** Аллаһ хәләл кылган нәрсәне башкарганнан Пәйгамбәргә гөнаһ юктыр. Элек яшәп китүчеләр *(пәйгамбәрләр)* дә Аллаһ хәләл кылганны гына башкаралар иде. Аллаһның әмерләре, һичшиксез, җиренә җиткезелә, алар (Ләүхел Мәхфүзгә) язып куелган тәкъдирдер.

**39.** Ул пәйгамбәрләр—Аллаһ иңдергән әмерләрне *(кешеләргә)* ирештерүчеләр, Аллаһтан куркучылар, Аннан башка беркемнән дә курыкмаучылар. *(Хәттин ашканнардан)* исәп-хисап алыр өчен бер Аллаһ Үзе җитәр.

**40.** Мөхәммәд сезнең арагыздагы бер генә ирнең дә атасы түгел. Ул фәкать Аллаһның Рәсүле һәм пәйгамбәрләрнең соңгысыдыр. Аллаһ һәрнәрсәнең асылын белеп тора. **(41)** Әй, иманлы халык, Аллаһны һәрвакыт искә алыгыз. **(42)** Һәм Аны иртә-кич *(мактап)* тәсбих тартыгыз.

**43.** Сезне караңгылыктан *(наданлыктан, динсезлектән)* яктылыкка чыгармак өчен рәхмәтен вә мәрхәмәтен һәм фәрештәләрен күндергән—Улдыр. Аллаһ мөэминнәргә чиксез мәрхәмәтле.

**44.** Аллаһ белән кавышкан Көнне аларга эндәшү:

—Сәлам!—сүзе булыр. Аллаһ алар өчен бик тә мәртәбәле бүләкләр хәзерләде.

**45.** Әй, Пәйгамбәр, Без сине, чыннан да, шаһит, сөенче алучы вә кисәтүче буларак күндердек.

**46.** Аллаһның фатихасы илә *(тугры юлга)* чакыручы, нур чәчүче бер кандил сыйфатында күндердек. **(47)** Мөселманнардан сөенче ал: алар Аллаһның бөек Сәгаләтенә ирешәчәкләр. **(48)** Кяферләргә, монафикъларга баш имә. Аларның рәнҗетүләренә диккать итмә, түз. Аллаһка инан, иманыңа таян. Химаяче буларак та, таяныч буларак та Аллаһ сиңа җитәр.

**49.** Әй, иманлы ир кешеләр, мөэминәләрне никахлап алганнан соң, зөфаф мөнәсәбәтенә кермәгән очракта, аерырга теләсәгез, ул хатыннан гыйддәт таләп итәргә сезнең хакыгыз юк. Бу очракта хатынның күңеленә хуш килерлек мал биреп, яхшы мөгамәлә белән өенә озатыгыз.

*(«Зәфаф кичәсе—никахтан соң ир белән хатынның бер ятакта төн уздыру мәддәтедер. Зәфаф алдыннан бу хатынны яратмаячагызны сизенеп, аның сезгә охшамаган гадәтләрен күреп, аның чирле икәнен белеп, җенси якынлык кылмыйча талак итсәгез, шәригать кануннары бозылмый. Гыйддәт—аерылган хатынның башка иргә чыгарга ярамаган вакыты».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**50.** Ий, Пәйгамбәр, мәһәрен биргән хатыннарыңны, Аллаһ сиңа ганимәт буларак биргән *(сугышта әсир алынган)* вә синең колың булган җарияләрне, *(атаң белән бертуган)* агаңның, *(атаң белән бертуган)* тутаңның, *(анаң белән туган)* абзаңның вә *(ана ягыннан булган)* түтекәеңнең кызларын, синең белән бергә *(һиҗрәт иткән)* күченеп килгән кызларны сиңа никахта хәләл кылдык. Иман китергән мөэминә үзен Пәйгамбәргә *(мәһәр алмыйча гына)* багышларга теләп, син дә аны алырга теләсәң, *(мондый никах)* башка мөселман ирләренә харам булып, бары тик сиңа гына рөхсәт ителәчәк. Хактыр ки, сиңа уңайсыз булмасын өчен, *(башка мөселманнарга)* хатыннар вә җарияләр мәсьәләсендә Без төгәл мәгълүмат биргән идек инде. Аллаһ—чиксез мәрхәмәтле вә ярлыкаучыдыр.

**51.** *(Хатыннарың белән төн уздыру тәртибен син боза аласың; аларның бүген)* теләмәгәнен *(ялгыз)* калдырып, теләгәнен янына алдыра аласың. *(Чираттан)* калганнарын янына алдырсаң да, зыян юк. Бу эш аларның куанып, үз өлешенә тигәннәргә шөкер итеп яшәүләренә кулай булыр. Аллаһ күңелегездәгене белеп тора. Аллаһ—бөтенесен дә белүче сабыр миһербан иясе.

**52.** Моннан соң *(сиңа тигән тугыз хатыннан гайре)* хатын алу һәм шушы хатыннарыңны алмаштыру *(берсен аерып, яңасын алу)*, хәтта никадәр генә гүзәл булсалар да, сиңа хәләл булмас. Кол рәвешендәге җарияләреңнән башка. Аллаһ—барысын да күзәтеп торучы.

**53.** Әй, иман китергән кешеләр, мәҗлескә чакырылмаган көе, Пәйгамбәр өенә кермәгез, табын әзер булудан иртә килмәгез. Фәкать *(табынга)* махсус дәшкәч кенә керегез. Ашап-эчкәч тә таралышыгыз. Киңәш-табыш итәр өчен дә, әңгәмә корыр өчен дә *(рөхсәтсез)* кермәгез. Чөнки Пәйгамбәрне кыен хәлгә куюыгыз ихтимал, ул *(сездән кыенсына.)* Аллаһ дөреслекне әйтүдән кыенсынмас. Берәр нәрсә кирәк булган чакта, чаршау аша Пәйгамбәрнең хатыннарыннан сорап алыгыз. Бу һәм сезнең өчен, һәм дә аларның күңел сафлыгы өчен шулай кирәк. Аллаһның Пәйгамбәрен кыен хәлләргә куймагыз, (вафатыннан соң) аның хатыннары белән никахлашмагыз. Бу—Аллаһ каршындагы иң зур гөнаһларның берсе. **(54)** Аллаһ ачык гамәлләрегезне дә, яшертен-пошыртыннарын да бик яхшы белеп тора.

**55.** *(Хатыннарың)* аталары, угыллары, ага-энеләре, бертуганнарының угыллары, кыз кардәшләренең угыллары, үз *(мөэминә)* хатыннарың, хезмәтче җарияләр каршында *(пәрәнҗә, чадрасыз)* йөрсә, гөнаһ саналмас. Аллаһтан *(җәзасыннан)* куркыгыз. Хактыр ки, Аллаһ һәрнәрсәгә шаһиттер.

**56.** Шик юктыр ки, Аллаһ та, фәрештәләре дә Пәйгамбәргә күп салават әйтерләр. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез. Ий, мөэминнәр, сез дә хәзрәти Пәйгамбәргә салават әйтегез һәм сәламнәр күндерегез.

**57.** Хактыр ки, Аллаһ һәм дә Аның Рәсүле турында нахак сүз сөйләгәннәр аз түгел. Аллаһ аларны дөньяда да, Ахирәттә дә ләгънәт орып, рәхмәтеннән куды. Аларга интектерүче, рәнҗетүче җәза хәзерләнгән.

**58.** Гөнаһ кылмаганнары көенчә: бу ир белән бу хатын гөнаһ кылды, дип нахак яла якканнар, һичшиксез, үз өсләренә зур гөнаһ алыр.

**59.** Әй, Пәйгамбәр! Хатыннарына, кызларыңа һәм барча мөэминнәргә әйт, *(йомыш белән урамга чыкканда)* өс киемнәренең яхшысын кисеннәр. Бу—*(аларның затлы нәсел хатыны икәнен)* танысыннар һәм рәнҗетмәсеннәр өчен бик тә кулай эш. Аллаһ—ярлыкаучы һәм миһербан иясе.

**60.** Хактыр ки, икейөзлеләр, эчләрендә чир булганнар *(җенси хасталыклары булганнар)*, шәһәрдә *(фетнә чыгарыр өчен)* яман хәбәр таратучылар шушы гамәлләреннән ваз кичмәсеннәр, алар өстенә *(яу белән)* сине җибәрербез. Менә шуннан соң инде алар синен янда *(күрше булып)* озак тора алмаслар. **(61)** Ләгънәтләнгән кавем буларак, аларны кайда очратсалар, шунда тотып үтерәчәкләр. **(62)** Әүвәл яшәп киткәннәр хакындагы Аллаһның хөкеме шулдыр ки. Аллаһның канунында һичбер үзгәреш табалмассың.

**63.** Кешеләр синнән Кыямәт көненең кайчан киләчәге турында сорыйлар. Әйт син аларга:

—Ул турыда бары тик Аллаһ кына белә,—диген. Син каян беләсең аны.—Бәлки, ул озакламый килер. **(64)** Шунысы хактыр ки, Аллаһ кяферләргә ләгънәт орды. Алар өчен хәтәр ялкынлы ут газабы хәзерләде. **(65)** Алар анда мәңгегә калачак һәм аларга ярдәм итүче бер генә дус та табылмас. **(66)** Ут эчендә йөзләре бөрешеп янганда алар әйтер:

—Ай, валлаһи, Раббыга итагать иткән булсак, Пәйгамбәргә ияргән булсак,—дип үкенерләр. **(67)**—Йа, Раббыбыз, без үзебезнең житәкчеләребезгә һәм киңәшчеләребезгә иярдек, алар безне юлдан яздырды,—дип әйтерләр. **(68)**—Раббыбыз, аларга икеләтә җәза бир вә аларны коточкыч итеп ләгънәтлә *(рәхмәтеңнән читкә ку)*. **69.** Әй, иман китергән кешеләр, сез дә Мусаны рәнҗетүчеләр кебек булмагыз. Барыбер Аллаһ аны сез сөйләгән нахактан арындырды. Ул Аллаһ хозурында абруй казанды. **(70)** Иманлы кешеләр, Аллаһның *(җәзасыннан)* куркыгыз һәм дөресен сөйләгез. **(71)** Аллаһ эшегезне уң кылыр вә гөнаһларыгызны ярлыкар. Аллаһ белән Пәйгамбәргә итагать иткән кеше *(хәтәр җәзалардан)* котылып, Сәгадәткә ирешәчәк.

**72.** Күкләргә, Җиргә вә тауларга Без әманәт тәкъдим иттек, ләкин алар *(җаваплылыктан куркып)* бу йөкне үз өсләренә алмады. Адәм баласы бу әманәтне үз өстенә алды. Чөнки кеше—*(табигате белән)* залим һәм наданлыр.

**73.** Монафикъ ирләрне вә монафикъ хатыннарны, мөшрик ирләр белән мөшрик хатыннарны җәзага тартыр өчен, иман китергән ирләр белән иманлы хатыннарның тәүбәсен кабул итәр өчен *(Аллаһ шушы әманәтне кеше өстенә йөкләде)*. Аллаһ—ярлыкаучы, мәрхәмәт итүчедер.

صدق الله العظيم

*Юмор-сатира*

## Маннур Саттар

### Галимулла күрше

Галимуллин яши каршы йортта,
Тавышлана кайчак, жене купса.

Баса да ул балконына чыгып,
Нотык сөйли башлый кызып-кызып.

Бен Ладенны тетә:—Азды бит,—ди,—
Бушны тереләй кумә язды бит,—ди.

Туктап тынлый үзен узган-барган,
Китә кайсы:—Бу,—дип, кубрәк салган!

Юк, кызыкмый шайтан суына ул,
Гәжит тотып кайта кулына ул.

Күрсәң аны бакча юлларында,
Радиоалгыч булыр кулларында.

Сөйлим дисәң аңа яна хәбәр,
Ул ишеткән була сина кадәр.

Бәхәсләшә хаклы санап үзен,
Бугазына ябыша бирми сүзен!

Менмим дисәң анын теленә син,
Туры килмә женле көненә син.

Була акылы аек айлары да,
Саташудан, әйтик, яллары да.

Күптән түгел, әле шушы кышта,
Күреп алды мине автобуста.

Утыргычтан шундук торып басты,
—Беләм мин,—ди,—ике даһи затны:

Берсе Ленин, берсе менә—ул!—ди.—
Лениннан да кубрәк белә ул!—ди.

Бармак төрткәч, бар да мина карый,
Тукталышта төшеп калдым, ярый.

Аһ, төшкән бит ул да минем арттан!
—Качма!—диеп, разбуй сала чаттан!—

Сез «азатлык» сулап исердегез,
«Суверен!»—дип болай сикердегез!

Һәм күрсәтә үзе сикереп ул,
Тук бозауга тәңгәл китереп ул.

Биеп бара, бүлеп минем юлны:
—Әйт,—ди,—алдыгызмы суверенны?

Очындыгыз болай!—дия-дия,
Бүрегем алып баштан, куккә чөя.

Әйттем, житеп бер кундырыр чиккә:
—Үз бүрегенне ник чөймисең күккә?

—Минем бүрек аңа күнмәгән,—ди,—
Мәйдан күген менеп күрмәгән!—ди.

Дүрт-биш кеше алды безне урап,
Сугыша, дип, хәзер ике дурак.

Белми аннан котылырга ничек,
Аргы якка чыктым юлны кисеп.

Күрәм, ул да урам аша уза:
—Кем хәзер,—ди,—нефтебезгә хужа?

Калдырмыйча безгә азын да,—ди,—
Суырачак Мәскәү газын да!—ди.

Әйләнеп без савым сыерына,
Киләчәкбез ачлык сызыгына!

Президент,—ди,—нигә боза антын,
Ник талата Татарстан халкын?

«Закон сагы мин»—дип әйтмәсен,—ди,—
Алыштыргач кырык маддәсен!—ди.

Качалмагач, атлап аксый-аксый,
Утырып киттем, туктатып бер такси.

Калды үзен жиһүчегә санап:
—Дөрес сүзгә юкмыни,—дип,—жавап?

## *Безнең календарь*

### Хәйдәр Гайнетдиновның тууына 50 ел

Шагыйрь һәм прозаик Хәйдәр Гайнетдинов (Хәйдәр) 1953 елның 27 ноябрендә Татарстанның Зәй районы Дүрт Мунча авылында хезмәткәр гаиләсендә туып үсә.

1970 елда ул урта мәктәпне тәмамлый, бер ел колхозда эшли.

1971—1976 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала.

1976 елның апрелендә, «Ялкын» журналында җаваплы секретарь буларак, матбугат эшчәнлеген башлап җибәрә.

Хәйдәр Гайнетдиновның әсәрләре татар матбугатында алтмышынчы еллар азагында күренә башлый. 1982 елда Татарстан китап нәшриятында аның лирик шигырьләрен һәм бер поэмасын («Иске кара урман») туплаган «Ут теле» исемле тәүге җыентыгы дөнья күрә. Сиксәненче еллар башында шагыйрь әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә көчен-сәләтен сынап карый башлый. 1982 елда Рауль Мирхәйдәровның «Безне онытмагыз...» повесте аның тәрҗемәсендә «Казан утлары» журналында (№ 4) басылып чыкты.

1983 елда Хәйдәр Гайнетдинов СССР Язучылар союзына кабул ителә.

Соңгы елларда шагыйрь тулысы белән проза жанрына күчә. Аның балалар һәм өлкәннәр өчен язылган повесть-хикәяләре «Су кызы», «Яшел алма» кебек җыентыкларга тупланып, укучылар игътибарына барып ирешә. Язучының иҗаты тирән мәгънәле фикер белән, йөгерек-тыгыз һәм җор тел белән сугарылган.

Гомеренең азагына кадәр (ул 2000 елның җәендә фаҗигале төстә вафат булды) Хәйдәр Гайнетдинов Татарстан дәүләт телевидениесенең әдәбият-сәнгать бүлегендә мөхәррир булып эшләде.

---

## Uqucı süze
## Укучы сүзе

Хөрмәтле редакция!

Журналыгызны күптән укып килә, 1991 елдан бирле мәктәптә тел һәм әдәбият укытучысы булып эшлим. Әлегәчә IX, X, XI сыйныфлар өчен йә дәреслеге, йә хрестоматиясе юк. Инде 11 ел китте! Хәзер инде юкка күнектек. «Казан утлары»н, «Мирас»ны беренче киңәшчеләрем иттем. Уңайдан файдаланып рәхмәтемне белдерәм һәм теләгемне дә җиткерәм. XX гасыр башы әдәбияты буенча (дөресрәге шигърияте) авырлыклар кичерәбез. Татарстан өчен бу кыен хәл түгелдер. Башкортстанда хәл аянычлырак. Кайбер китапханәләрдә Тукай булып Тукайның тулы томнарын табып булмый. Без Татарстан дәреслекләре буенча укыйбыз. Унынчы сыйныф нәкъ XX гасыр башын өйрәнә. Дәреслеге бар, яхшы дияр идем мин аны. Ләкин эш материалы—шигырь, әсәр—юк. Теләгем: журналыгызда бер битнең ике ягына гына булса да шул чор шагыйрьләренең әсәрләренә урын бирелмәс микән.

**Илгиз ФАЗУЛЛИН,**
*Башкортстан.*

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНДА

Бөтендөнья татар конгрессының яңа сайланган башкарма комитеты үзенең беренче утырышын үткәрде. Аны конгресснын рәисе Ринат Закиров алып барды. Башкарма комитет рәис урынбасарлары итеп Разил Вәлиев, Римзил Вәлиев, Дамир Исхаков, Камил Аблязовны һәм 13 кешедән торган бюроны сайлады, даими эшләүче комиссияләрне формалаштырды. Алар—алтау. «Татар этносы үсеше стратегиясе» комиссиясенә—Дамир Исхаков, «Эшмәкәрлек һәм бизнес»ка—Камил Исхаков, «Татар мәгарифе һәм фәне» комиссиясенә—Фарис Харисов, «Татар халкы мәдәнияте һәм рухи мирасы»на—Илдус Тарханов, «Гаммәви мәгълүмат чаралары»на—Илшат Әминов, «Халыкара мөнәсәбәтләр һәм кеше хокуклары» комиссиясенә Рафаэль Хәкимов җитәкчелек итәчәк. Конгресс башкарма комитетының җаваплы сәркатибе итеп элек мәгариф министры урынбасары булып эшләгән Илсур Һадиуллин расланды.

## ЕВРОПА-АЗИЯ ДИАЛОГЫ

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миннуллин, Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе Разил Вәлиев, татарларның милли-мәдәни мөхтәрияте Федераль советы җитәкчесе Римзил Вәлиев һәм «Заман» газетасы баш редакторы Йосыф Саглам составындагы Татарстан делегациясе «Платформа Диалог Евразия» (ПДЕ) халыкара оешмасының дүртенче конференциясе эшендә катнашты. Ул Төркиянең Кемер шәһәрендә узды.

Бу оешманы 2000 елның май аенда Төркия Республикасы язучылары һәм журналистлары төзегән иде. Аның эшендә Советлар Союзы, Балтыйк буе илләреннән башка, элеккеге барлык республикалар вәкилләре, шулай ук Татарстан, Башкортстан һәм Дагыстан вәкилләре катнаша.

«Евразия халыкларының мәдәни үзаның үстерү Евразия төбәге дәүләтләре өчен зур әһәмияткә ия һәм ул тарихи зарурилык булып тора», диелә ПДЕ Уставында.

Шушы конференциянең төп темасы—«Евразия һәм глобальләштерү процесслары». Моннан тыш, «ДА» журналын нәшер итү стратегиясе мәсьәләләре тикшерелде. Аны ПДЕ чыгара. Журналның чираттагы саның тәкъдир итү булды.

## ДАНЛЫ БАСМАХАНӘ

Республиканың элеккеге полиграфия предприятиесе—«Полиграфия-нәшрият комбинаты» дәүләт унитар предприятиесенә 80 ел тулды.

1997 ел урталарына кадәр Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты дип аталган предприятие Татарстан һәм Татарлар күпләп яшәүче төбәкләрнең милли мәктәпләре өчен әдәби һәм фәнни әдәбият, дәреслек һәм дәрес кулланмалары бастыручы бердәнбер басмаханә булды.

«Полиграфия-нәшрият комбинаты» дәүләт унитар предприятиесе 1997—2001 еллар эчендә тотрыклы һәм нәтиҗәле эшчәнлек алып барганы өчен халыкара «Алтын Меркурий», «Гран-при», «Хрусталь Ника» призлары белән бүләкләнде.

## ГУМАНИТАР ИНСТИТУТКА 10 ЕЛ

Татар дәүләт гуманитар институты моннан ун ел элек—Татарстан Конституциясе кабул ителгән 1992 елны ачылган иде. Шушы чор эчендә институт авыл һәм шәһәр мәктәпләре өчен 800 дән артык белгеч әзерләп чыгарды. Шуларның күбесе—авыл мәктәпләре өчен әзерләнгән инглиз, гарәп, фарсы, төрек теле укытучылары.

Гуманитар институт юбилеена багышланган тантаналы кичә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында узды. Институт ректоры, Васил Гайфуллин әлеге милли югары уку йортының барлыкка килүе, бүгенге эшчәнлеге турында сөйләде.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева институт коллективын тәбрикләде һәм Президент М. Ш. Шәймиевнең котлау адресын тапшырды.

## ХАҖ ГАМӘЛЛӘРЕ СОВЕТЫ

РФ Хөкүмәте каршында Хаҗ гамәлләре советы төзелде. Совет рәисе итеп Дәүләт Думасындагы Дагыстан депутаты Ә. Билалов сайланды. Аның составында 15 әгъза, шул исәптән Россия төбәкләре мөселманнарының Диния нәзарәтләре рәисләре, Татарстаннан Госман хәзрәт Исхаков һәм «Идел-Хаҗ» программасы җитәкчесе, «НАСКО» иминият компаниясе генераль директоры Р. Гатауллин бар. Совет хаҗга баруны оештыру кысаларында Россия төбәкләре мөселманнарының Диния нәзарәтләре эшен тәртипкә сала.

## ЯЗУЧЫЛАРГА—АЛИШ ПРЕМИЯСЕ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе «Карурманданиләр бар?» («Мәгариф» нәшрияты) китабы өчен Роза Хафизовага һәм «Көмеш тарак» (Татарстан китап нәшрияты) җыентыгы өчен Галимҗан Гыйльмановка Абдулла Алиш исемендәге әдәби премияләр бирү хакында карар чыгарды.

## «ТУГАН ТЕЛ» КЛУБЫ

Казанның Тукай музеенда татар теле һәм татар әдәбияты укытучылары «Туган тел» исемле мөгаллимнәр клубын ачуны билгеләп үттеләр. Аның президенты итеп шәһәр хакимиятенең мәгариф идарәсе хезмәткәре Р. Баһавиева, вице-президент итеп пенсионер укытучы Р. Мифтахова сайланды. Очрашуларны һәр айның өченче атнасында пәнҗешәмбе көнне үткәрергә килешенде. Эмблемасы һәм гимны итеп Г. Тукайның «Туган тел» җыры расланды. Клубның беренче җыелышында Тукай музее директоры М. Низамиев Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, энергетика университетының кафедра мөдире Р. Ногманов, Казан дәүләт университеты профессоры Р. Ганиева, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары З. Рәмиев, һ. б. чыгыш ясады.

## ИЖАУДА ОЧРАШУЛАР

Удмуртия Республикасында Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрелде. Бирегә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин җитәкчелегендә бер төркем каләм әһелләре, сәнгать осталары килде. Делегация составында Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе В. Имамов, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире шагыйрь Х. Әюпов, «Казан утлары» журналының әдәби тәнкыйть бүлеге мөхәррире М. Вәлиев, «Ватаным Татарстан» газетенең әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, шагыйрә А. Юнысова һ. б. бар иде. Ижау каласының «Акцион» мәдәният сараенда «Бер көрешү—бер гомер» дип исемләнгән әдәбият-сәнгать кичәсе булды. Тамашачылар алдында Казан, Чаллы кунаклары, Удмуртиянең төрле төбәкләрендә һәм Әгерҗедә яшәп иҗат итүче авторлардан Р. Шәфи, Ш. Садыйков, Ч. Мусин, И. Биектаулы, И. Шәрипов, З. Нуретдинов, Р. Батталов һ. б.лар чыгыш ясады. Әлеге очрашуда Әгерҗе районы хакимияте башлыгы Ф. Габбасов һәм ТР Министрлар Кабинеты референты Р. Хәсәншин да катнашты.

## ЯЗУЧЫНЫ ЗУРЛАП

Язучылар берлегенең Габдулла Тукай исемендәге клубы үзенең яңа сезонын күренекле әдип Барлас Камалов иҗатына багышланган кичә белән ачып җибәрде.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин кичәне ачып, өлкән прозаикның киң кырлы иҗатына югары бәя бирде.

Кичәдә Б. Камаловның якташлары, Матбугат ветераннары җәмгыяте, татар газеталары редакцияләре вәкилләре, педагогика университеты галимнәре, язучылар һәм шагыйрьләр катнашты.

## ШАГЫЙРӘНЕҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

30 сентябрьдә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында шагыйрә Флера Тархановaның иҗат кичәсе үткәрелде. Залда аның хезмәттәшләре, каләмдәшләре, сәнгать әһелләре, шигырь сөючеләр белән бергә аның якташлары—Чистайлылар, дуслары, туганнары бар иде.

## ИСКӘ АЛУ

Фронтовик шагыйрь Әзһәр Габиди бөтен гомерен диярлек үзенең туган авылы Чукмарлыда үткәрде, мәктәптә укытучы булып эшләде, иҗат эше белән шөгыльләнде. Үткән ел ул вафат булган иде.

25 сентябрьдә Чукмарлыга Казаннан, Чаллыдан, Әлмәттән, Сарманнан, Җәлилдән килгән язучылар, күп санлы авылдашлары, туган-тумачалары шагыйрьнең каберенә истәлек ташы куюда катнаштылар һәм хәтер җыены үткәрделәр. Каләмдәшләре Әхмәт Гадел, Вахит Имамов, Фәкил Сафин, Клара Булатова, Дамир Гарифуллин, Разим Вәлиуллин, Нур Әхмәдиев, Вәсимә Хәйруллиналар үзләренең чыгышларында Әзһәр аганы олылап һәм сагынып искә алдылар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Хакимиятнең вәкаләтле һәм башкарма органнарында озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, журналыбызның редколлегия әгъзасы Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.


---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы. *Н. Исмәгыйлев фоторәсеме.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Әхәт Мушинский.

# «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ 2003 ЕЛДА




Татарстан Республикасы Милли нәшрияты «Мәгариф»—нигезе гасыр башында ук салынган шул исемдәге нәшриятның рухи дәвамчысы, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр чыгару үзәге. Аның янадан торгызылып эшли башлавына да инде 11 ел булды.

«Мәгариф»—Россиядә милли телдә китаплар чыгаручы иң зур нәшрият. Соңгы 11 ел эчендә бирелә 900гә якын исемдә 15 миллион чамасы китап басылган. «Мәгариф» нәшриятында, дәреслек һәм методик әдәбияттан тыш, балалар бакчалары өчен кулланмалар, белешмә әсбаплар, матур бизәлешле әдәби китаплар да дөнья күрә. Яшь буынны татар һәм дөнья әдәбиятының классик әсәрләре, бүгенге әдипләрнең иң яхшы иҗат үрнәкләре белән таныштыру да—нәшриятның мөһим бурычларының берсе.

«Мәгариф» нәшрияты актив рәвештә татар теле һәм әдәбиятыннан өр-яңа дәреслекләр һәм уку әсбаплары эшләүнең дәүләт программасын тормышка ашыра. Аларның бер өлеше рус телендә сөйләшүче балалар өчен чыгарыла.

«Мәгариф»нең 2003 елда гамәлгә ашачак тематик планы бик бай һәм кызыклы. Киләсе елда нәшрият 150 ләп исемдә китап һәм төрле методик кулланмалар чыгарачак. Алар арасында ике дистәдән артык әдәби әсәрләр дә бар.

Төрле серияләрдә («Укытучы китапханәсе», «Балалар күңеле», «Минем тәүге тормышым», «Укучы китапханәсе» һ. б.) Р. Төхфәтуллин, Н. Дәүли, Г. Сабитов, исән язучыларыбыздан Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин, А. Тимергалин, Р. Гаташ, Р. Вәлиев, Г. Морат, Г. Гыйльманов, К. Кәримов, З. Хөснияр һәм башкаларның әсәрләре дөнья күрәчәк.

*«Мәгариф» нәшриятының адресы: Казан, Бауман ур. 19.*

*☎ 92-19-81-, 92-11-90.*

Индекс 73210



Әхәт Мушинский

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)